ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2001





**Афзал Шамов**
**1901–1990**

**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2001*

# 5

**(943)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Факил Сафин,**
**Ренат Харис,**
**Зиннур Хөснияр,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Гамил АФЗАЛ. *Шигырьләр.* ..... 5
Рәдиф ГАТАШ. Гамь һәм моң илчесе. ..... 9
Фоат САДРИЕВ. Бәхетсезләр бәхете. *Роман.* ..... 12
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Заманга иш иҗат. ..... 87
Ренат ХАРИС. Хыянәт. *Поэма.* ..... 92
Тәуфикъ ӘЙДИ. Венада очрашу. *Бәян.* ..... 100
Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Үз жанына үзең әнкә булсаң. *Шигырьләр.* ..... 124

КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА

Чал тарихлы башкала. *(Фаяз Хуҗин белән Алмаз Гыймадиев әңгәмәсе)* ..... 129

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәрит ХАТИПОВ. Рухи куәт. ..... 137

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Зират коймасына тияр-тимәс... ..... 145

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

9—Тәүбә (Тәүбә) сүрәсе. ..... 148

ФӘН

Вил ГАНИЕВ. XX йөз татар әдәбияты. *(Тарихи-библиографик күзәтү)* ..... 159
Рөстәм МӨХӘММӘТШИН. Заман чаткысы. ..... 170

СӘНГАТЬ

Кадим ЖӘМИТОВ. Нәрсә ул «Хөррият»?. ..... 164

ЮБИЛЕЙЛАР

Рафаэль МОСТАФИН. Көчле рух, тынгысыз җан, кызыклы иҗат. *(Язучыга 70 яшь тулу уңаеннан).* ..... 174
Наис ГАМБӘР. Очканында ни булса... *(Әхәт Мушинскийга 50 яшь).* ..... 180
«Мәгариф» гасыры. ..... 182

ЮМОР-САТИРА

Aziz NӘSİN. Өç fәreştәçeknen әnise. *Xikәülәr.* ..... 186
Россия Президентына хат. ..... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Ф. САДРИЕВ. Роман «Счастье несчастных» *(продолжение)*; повесть Т. АЙДИ «Встреча в Вене»; поэма Р. ХАРИСА «Измена» *(вступительная статья Р. Файзуллина о творчестве поэта)*; стихи Г. АФЗАЛА *(с предисловием Р. Гаташа)*; стихи Л. ШАГИРЗЯНА.
«К 1000—летию Казани»: «Седая старина столицы»—руководитель археологической экспедиции «Казанский Кремль», археолог Ф. ХУЗИН отвечает на вопросы А. ГИМАДЕЕВА.
«Литературная критика»: статья Ф. ХАТИПОВА о творчестве Н. Фаттаха.
«Актуальная проблема»: Р. ШАРАФИЕВ размышляет о трагических мотивах в современной татарской литературе.
Коран на татарском языке.
«Наука»: историко-библиографическое обозрение В. ГАНИЕВА «Татарская литература XX столетия» *(продолжение)*; статья Р. МУХАМЕТШИНА «Искра времени».
«Искусство»: статья скульптора К. ЗАМИТОВА посвящена памятнику-символу «Свобода».
В номере отмечаются 10-летие воссоздания издательства «Магариф», юбилеи Р. Мустафина, А. Мушинского.
«Юмор-сатира»: Азиз НЕСИН. Рассказы *(на латинской графике)*.
Открытое письмо Президенту Российской Федерации.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Государственный Большой концертный зал имени С. Сайдашева; писатель Радик Фаизов.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": F. SADRIEV'S novel «The happiness of unhappies» (continuation), T.AIDY «Meeling in Vienna», R. HARIS'S poem «Treachery» R. FAIZULLIN'S article about poet's creative works; G. AFZAL'S verses (with R. Gatash's preface), L.SHAGIRZHAN'S verses.
"Commemorating of 1000th anniversary of Kazan": «The old capital» - archaeologist F. KHUZIN is answered A. GIMADEEV'S questions.
"Literary criticism": F. HATIPOV'S article about N. Fattah's creative works.
"Actual problem": R. SHARAFIEV'S reflection modern Tatar literatura.
"Koran in Tatar language".
"Science": V. GANIEV'S history and bibliography review «Tatar literatura of XX century». R. MUKHAMMETSHIN'S article «Spark of century».
"Art": Sculptor K. Zamitov'S articles devoted to monument of «Liberaty».
In this issue is noted jubilees of R. Mustafin, A. Mushinsky, «Magarif» publishing house.
"Humor and satira": A. NESIN stories (in Latin graphic).
Letter to President of Russian Federation.
The diary of social and cultural life.
In our covers: The •Big State consert Hole, writer R. Faizov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.04.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108[1]/[16].
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8619 Заказ А-153
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.



## Гамил Афзал

### Гамь төсмерләре

*Көн яктысын кырыкка сындырган*
*Кырык кырлы алмаз кебек дөнья,*
*Һәр кырына үз төсмере сыйган,*
*Төсләренә карап йөз ел уйла,*
*Йөз ел уйла!*

**Алсу төс—гамьсез төс,**
**Сабыйлар иртәсе,**
**Уеннар көтәсе, кызыклар көтәсе,**
**Абыйлар иркәсе, апалар иркәсе,**
**Жылы жир, жылы нур гомергә житәсе.**
**Алсу төс—жылы төс,**
**Гомерләр иртәсе,**
**Хыяллар киртәсез, еракка китәсе...**
**Шатлыклар көтәсе,**
**Бәхетләр көлтәсе,**
**Мәхәббәт, зөфафлар кичәсе.**

**Ак төс—пакь төс,**
**Беренче кар төсе,**
**Он төсе, сөт төсе, гөнаһсыз яр төсе,**
**Риясыз, хәрамсыз, хәйләсез чак төсе,**
**Кояштан иңгән иң изге тап төсе,**
**Тормышның шат төсе, хак төсе.**
**Яшел төс—ямьле төс,**
**Гомерләр бизәге:**
**Уҗымнар гөжләве, урманнар җилләве,**

Яшәү һәм яшәрү, өмет һәм яз төсе,
Сөю һәм сөелү, иркәлек, наз төсе,
Озонлы айлы төн, яфраклы җил төсе,
Төчкелтем-әче, әчкелтем-төче,
Кыяр, кузгалак, кычыткан исле,
Үлемгә үчле, тереклек төсе.

Зәңгәр төс—тыныч төс,
Аяз көннәр төсе,
Болытсыз, офыксыз, төпсез төннәр төсе,
Чая чаткылы сихри күзләр төсе,
Рәшәле болыннар, зур диңгезләр төсе,
Серле эзләр төсе,
Иртәнге томан һәм кичке эңгер төсе,
Бәхетле мәхәббәт, ләззәтле сер төсе,
Җитлеккән акыл, сабыр холык төсе,
Аккошлы күл, ерак киңлек, уйчан болыт төсе,
Бик чибәр кыз, якты йолдыз, мәңгелек боз төсе.

Кызыл төс—дәһшәтле,
Көрәш һәм кан төсе,
Чамасыз кыюлык, ярсыган җан төсе,
Янгын һәм һәлакәт, борчулы таң төсе,
Тынгысыз көч, кичке шәфәкъ, тәмуг уты төсе,
Нәфис чәчәк, кыргый кеше, мамонт сырты төсе,
Борынгы җир, сугышлы чор, социаль аң төсе,
Яралы вөҗдан, хәвефле ял төсе.

Сары төс—моңсу төс,
Әбиләр чуагы—
Җимешнең мул чагы, дөньяның моң чагы,
Сары ай сагышы, балигълык төсмере,
Җитлегү, хушлашу, күз яше бөртеге,
Көрсенү, үкенеч ямьнәре—үз сере.

Кара төс—кыйгач каш,
Сөрмәле күз төсе,
Урланган мәхәббәт, яңгырлы көз төсе,
Туган туфрак, затлы кием, шомлы төн төсе,
Янаулы, мәкерле, зәһәрле өн төсе,
Ачы агу кебек хәйлә-хыянәт төсе,
Явызлыкның канәгать төсе,
Чукмар тоткан вәхши,
Надан ир,
Ачы тир төсе.

Соры төс—пассив төс,
Кол төсе, көл төсе,
Таланган, изелгән, ирексез ил төсе,
Кыргаяк ите төсе, мумия бите төсе,
Бетү төсе.

Көн яктысын кырыкка сындырган
Кырык кырлы алмаз кебек тормыш,
Һәр кырына дөнья гаме сыйган,
Исен-төсен төсмерләргә тырыш,
Тырыш!

## Чишмә башы

Бер эсседән качып,
Бер суыктан,
Кыргыйлыктан җаннар көйгәндер.
Тау астыннан чишмә тибеп чыккан,—
Бер яхшылык булсын дигәндер.
Тау итәген ярып чишмә типкән,
Салкын гына суы—саф көмеш.
Челтер-челтер итеп агып киткән,
Дөнья буйлап киткән саф килеш.

Ярларына яран гөлләр үскән,
Юлаучылар ятып су эчкән,
Төннәрендә ай шәүләсе төшкән,
Иң кадерле нигъмәт—су икән.

Анда килеп намаз укыганнар,
Мосафирлар дога кылганнар.
Чишмә башы—изге урын диеп,
Тәсбих әйтеп торган урманнар.

И хилафсыз,
И хәйләсез дөнья,
Һәр чәчәгең көләч, шат була,
Талларыңа асыл кошлар куна—
Идеал да шулай саф була.

Күктә кояш аңа карап торган,
Шат йолдызлар аңа күз кыскан,
Ана булып торган кара урман,
Саф энҗеләр тамган болыттан.

Челтер-челтер чишмә көләдер, һәй,
Яшен атып болыт киләдер,
Бу гөнаһлы җиргә, бәхет теләп,
Изгелекләр шулай иңәдер.

Еракларга агып киткән чишмә,
Гасыр-гасыр гомер буенча.
Ярларына тинтәк тирес түккән,
Аны-моны уйлап тормыйча.

Төрле чүп-чар җыеп бара-бара,
Килеп җитә чишмә елгага.
Һәр тармагы яфрак яра-яра,
Идеал да шулай болгана.

Гомер бакый дигән гөлбакчада
Сандугачлы таңнар яктыра.
Ага-ага суы болганса да,
Чишмә башы һаман саф тора.

## Бик читен

Тар сукмак белән
Тауларга менәм,
Ерактан күрәм күк читен.
Бик кирәк, димен,
Түз, йөрәк, димен,
Тауларга менү бик читен.

Үзәнгә төшәм,
Түбәнгә төшәм,
Бик якын күрәм күк читен.
Нихәл итәсең,
Кая китәсең,
Түбәнгә төшү бик читен.
Елап туганмын,
Елак булганмын,
Дөньяга килү бик читен.
Сөенеп китәрмен,
Дөньядан киту бик читен.

## Минем 100 яшь тулгач язачак җырым

Күз алдымда шаулап 100 ел үтте,
Тел зиначылары үлеп бетте,—
Ялганчыга дөнья тар икән.
Күңелем һәр көн илгә бәхет көтте,
Бәхет көтеп, уй киләбен сүтте.
Эшчәннәргә бәхет бар икән,
Кичләр зәңгәр, таңнар ал икән.

Ничаклы даһилар дөньяга килде,
Ничаклы нәбиләр дөньядан китте,—
Мин һаман да эшлим, мин исән.
Көнгә карап көлеп йөргән өчен,
Кешеләргә шатлык биргән өчен,
Йөрәгем яшь, күңелем шук икән,
Әллә миңа үлем юк микән?

* * *

Үзем өчен генә шигырь язам,
Шигырь язмый тора алмаганга.
Каләмемне ай нурына манам,
Агачларда яфрак шаулаганда.
Айлы кичтә зәңгәр утта янам,
Йөрәгемдә хисләр кайнаганга.
Үзем өчен генә шигырь язам,
Шигырь укыр дуслар калмаганга.

Каләмемне таң нурына манам,
Агачларда яфрак шаулаганда.
Үзем өчен генә шигырь язам,
Шигырь язмый тора алмаганга.

Чәчәкләрдән нәфис төсләр алам,
Агачларда яфрак шаулаганда.
Үзем өчен генә шигырь язам,
Хыялымны тормыш алдаганга.

Каләмемне үт суына манам,
Йөрәгемдә нәфрәт кайнаганда.
Яшен булып, яшел тауда янам,
Болыт килеп, дөнья шаулаганда.
Әҗәл упкынына каршы барам,
Акыл, намус җирдә аунаганда.
Ядрә кебек кайнар шигырь язам,
Мәхлук булып тора алмаганга.

# ГАМЬ ҺӘМ МОҢ ИЛЧЕСЕ

Әрем исле, татлы-ачы тәмле, гамьле жыр... Очсыз-кырыйсыз тоелган жорлык, үткен теллелек, шаянлык, нечкә күзәтүчәнлек, нәкъ чәчәннәрчә төгәл-акыллы, кинаяле һәм хикмәтле матурлык—сүз иясе, ә кайчакта, халык үзе әйткәнчә, теленә шайтан төкергән усал, төртмәле булу—менә шулар уйга килә, Гамил Афзал атлы олуг шагыйребезне укыганда. Әрем, ә бәлки бөтнек тәме, жир-туфрак жылысы, туган ил, туган жир яме... Шагыйрьнең без, яшьрәкләр, гел кабатлап, искә ала торган шундый юллары (Рафаэль Сибат аеруча гашыйк иде яшьтә бу «сәтырьләр»гә!) бар:

Язмыш мина әрем генә бирде,  
Рәхмәт инде әрем өчен дә...

1921 санәдә (кара инде, чынлап та нинди шомлы, ябык елда башланган икән бит Гамил аганың гомер чишмәсе!) туып, шул елдан соңгы чорларның котылгысыз афәтен халкы, нәселе-гаиләсе белән бергә кичергән, «бөек бишьеллыклар» касәфәтен сабый йөрәгеннән үткәргән, шуңа да Уралда—Магниткаларда, сөрелгәннәр-хокуксызлар «йорт»ында үсеп, яшәп, туган тел, әнкә сөтедәй ил догасы, ә бәлки, Ходай кушуы буенча шигърият бәхетенә исән калган бит ул. Әйе, яшьтән үк тирән гамь, моң дөньясын күргән, тормыш сабакларын мул алган Г. Афзал әнә шул шартларда да шагыйрь булып житешкән. Шулай үскән, шунда рухи чыныккан... Сүз жаеннан: аның яшьтәше, нәкъ шул язмышка дучар булган, шул ук шәһәрләр—Чиләбе, Магнитогорск, Троицкиларда тормыш һәм белем мәктәпләрен үткән, шулай ук хәрби заводларда эшләп, сугыш елларын кичкән, азак бу якларда укытучы булып яшәп калган Басыйр ага Рәфыйков та бар бит әле! Аңа да сиксән яшь тулды быел. Кызык: алар бер-берсен белделәр микән яшьтә? Аралашканнармы? Һәм шунсы да күңелне гел тырнап тора: соңгы елларда әнә шулай «сөрелеп» киткәннәрнең нәселе булса да—ул тарафлардан туган тел, әдәбият, шигърияткә килүче юк бит инде, юк!

Ә Гамил ага әнә шул дәһшәтле елларны кичеп, соңлап булса да (хәер, шигырь-Әнкәбезгә соңлау бармы ул? Һәрнәрсәне жайлап торган илаһи көч вакытын үзе белмәгәнме әллә?!), төрле авырлыкларны, соңра авыруларны жиңеп, шигырьгә килде. 1955 елда безнең журналда басылганнан бирле—олы әдәбиятка, халык күңеленә юл салды ул. Ышанып әйтәм: мәңгелеккә.

Ә бит, беренче шигырьләре бик авыру хәлдә, үлем белән көрәшкән халәтләрдә язылa аның:

Үзем сүнеп ятам,  
Үзем көлеп ятам,  
Кеше шатлыгына сөенеп.

Бу юлларны Гамил Афзалны чиксез хөрмәт иткән, аңа багышлап шигырь, мәкаләләр язган Нажар ага Нәжми дә кабатларга ярата иде. Гомумән, шагыйрьгә багышланган һәр язмада диярлек искә алынды ул канатлы тәгъбир-юллар!

Алдарак, бәлки, ныгытылачак фикеремә нигез-дәлил итеп башта ук шуны әйтеп, үз күзәтүем белән бүлешим әле: әлеге шигырьдәге халәт—ул безнең тарихи аң-хәтердә, рухи дөньябызда, олуглар язмышында аерым бер урын тота. Әйе, әйе, бу—изгеләр, әүлиялар, пәйгамбәрләр халәте!

«Үлгәндә дә көлә-көлә бирде жан» дип тәкърарлый иде безгә, пәйгамбәрләр тормышын күзаллап, нәнәебез. Менә каян килә ул «Мусалар (татарлар) елмаеп үлделәр» гыйбарәсе! «Елмаеп» түгел инде ул (урысчадан калькадыр, бәлки?!), «көлеп» пакь жан, саф күңел белән Ходай каршына бару... Көлә-көлә яшәү, шулай үлү. Тукай да Ямаш турында: «... жәза бирде, көлеп...»—ди. Төректәге «гүлә-гүлә» дә шул ук мәгънәдә. Бу мөселман-төрки әхлагының, рухи дөньясының бер көчле кануны ахры. Ул инде безнең канда, жанда—

берегеп яши: бүгенге көндә милли-рухи вәзгыять үзе үк сайлап, саклап, яшәтеп, халыкның асыл уллары дәрәҗәсенә күтәрелергә көч биргән—ягъни үз шагыйре итеп язмышына ук язган Фәнис Яруллиннарда шулар ныклыгы, горурлыгы түгелмени? Гамь белән, Моң белән сыналып, бөек Сүз бәхете китергән илаһи язмыш бу! Әйе, бу тәкъдирнең, халык рухы һәм ышанычының үз таләбе, үзе биргән кануны, шагыйрьлек-пәйгамбәрлек миссиясе. Шул ук көч Хәсән Туфан кебек бөек затны да, җәһәннәм утларыннан сау чыгарып, халкының газиз улы булу мөнбәренә кадәр яшәтеп, сиксән еллык гомер бирде бит...

Ә Н. Исәнбәт, Б. Урманче, Г. Бәшир, Ә. Еники кебек, энциклопедик талант ияләре, олуг шәхесләребезнең, халык бәхетенә, 90 яшькә кадәр, хәтта артыграк та яшәүләре?

... Бүгенге көндә Әлмәттә яшәп ятучы (әле үзе кебек 80енә аяк баскан кордашы Әдип Маликов та бар!) Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты могтәбәр Гамил ага турында язарга каләм алгач менә шундый хисләр кичереп, уйландым мин. Китапларын күздән үткәрдем. Шагыйрь турында язган саллы, матур мәкаләләрне кабат укып чыктым: Сибгат ага Хәкимне, Нил Юзиев язганнарны, Нажар ага «хат»ын... Нурмөхәммәт Хисамовның да безнең журналда дөнья күргән зур, әтрафлы мәкаләсен укып, Г. Афзалның юмор-сатирасын, бу өлкәдә шагыйрь тудырган бай сурәтле дөньяны күзалладым.

Әмма иң кызыклысы үзебезнең буынның Г. Афзалга булган мөнәсәбәтен хәтерләү булыр кебек (мин дә бу хөрмәтле шагыйребез турында берничә мәкалә язган кеше!). Безнең чордашлардан, әле бу шагыйрьнең 50 яше генә тулган вакытта, аның белән Әлмәттә аралашып яшәгән, шәхес буларак аңлап һәм чорыбызга китергән шигъри яңалыгын шактый тулы ачып, әтрафлы, саллы беренче мәкаләне... Равил Фәйзуллин язып чыкты. Бу мәкалә дә «Казан утлары»нда басылды, соңыннан Равилнең томнарына да керде. Аны да яңадан карап чыктым. Беренче кат мин мәкаләне бераз гаҗәпләнебрәк укый башлаган идем: әле иркле шигырь белән җенләнгән, авангардистик шигърият, «дөнья әдәбияты критерийлары» белән генә уйлаган еллар иде ул. Әйе, бөтенләй башка мәктәп, иркле форма, яңа алымнар, яңа образлы-фикерле шигъри дөнья тарафдары, хәтта лидеры булган каләмдәшемнең, фикердәшемнең—классик шигырьгә ябышып, шул нигездән купкан, халыкчан моң һәм юмор белән өртелгән, гамьле, гади сүз сәнгатен көчле итә белгән, Акмулла, Тукай, Бабичларның варисы булуга дәгъва кылган Г. Афзалга «апологиясе» гаҗәпләндергән, уйландырган иде. Хәзер уйлыйм: чордашым миннән гел акыллырак булган, олуг традицияләргә, алтын мираска илткән күперләрне беркайчан да якмаган икән (ә минем бу юлда адашкан чакларым күп булды!). Ә бит, бик нык хәтеремдә калган—1965 ел ахырында, Равилнең атаклы, шау-шу кузгаткан нюансларын, бөтен иҗат яшьләре бергә җыелып, тикшергәндә—дәррәү яклаганда!—безнең арадан, булачак зур галим Рифкать Әхмәтьянов: «Гамил Афзал алай язмый бит... Мондый башваткыч иҗат итми ул!» дип чыгыш ясады. Мисал китерде:

Урман буйларында яшел юрган:
Галиябану монда урак урган.
... Зөлхәбирә монда печән чапкан...

Ә без көлеп кенә куйдык: янәсе, бу—искечә, кадими уйлау чаралары!.. Кая ул халыкчанлык турында телгә алу! Марс Шабаев та, композитор Ренат Еникеев та шулайрак сөйләде—авангардка гашыйк идек шул!

Гәрәйләр, Рөстәмнәр, Айдарлар да хәтерлидер әле бу әдәби мәҗлесне. Әмма хәзер, инде яңа XXI гасыр башында бу эпизод безнең эзләнүле, табигый ярсулы яшьлектән бер кызыклы ядкарь гына... Ә вакыт инде күптән безнең уйларны да, исемнәрне, иҗатларны да рәткә китереп—үз урынына куйган: Гамил ага да, Равил дә—халык шагыйрьләре, милли рухның киң танылган, үз мәктәбен үк булдырган илчеләре... Ул чакта да, бүген дә бәхәсләргә артык катнашмаган Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиләр дә шулай.

Зөлфәт тә, Мөдәррис тә—халыкчан нигездә... Алардан яшьрәкләр дә. Яңа гасырда килгән яшь шагыйрьләр дә үзләренә кадәрге исемнәрне читләп үтмәсләр, уйланырлар, эзләнерләр, шауларлар, мөгаен. Шигърият дәрьясы да—мәңгегә тирән агымлы, киң, гүзәл бер дәрья булып ага бирер («Әтил суы ака торур!»), ә ана шаулы-ярсу чишмәләр дә, мул, тоныклы сулы инеш-елгалар да кушылыр. Бу—гел дәвам итәр, иншалла! Җыр—мәңгелек, моң—яшәешнең үзе кебек борынгы... «Узган гомер белән калган хәтер... генә—сатып алыйм дисәң (дә) табылмас!» Шулай...

Ә мин, яшьтән үк Гамил аганы укып, сәхнәләрдә яттан сөйләп үссәм дә ( илленче еллар азагында ук, беренче очрашуда Нажар ага миңа: «Казанда, Уфада булсын—Г. Афзал—иң көчле сатира-юмор остасы ул!»—дигән иде), «Ирәмәлкәй тавы бигрәк биек, тора торгач мендем башына» дигәндәй, аны төрле елларда төрлечә «ачып», төрлечә кабул иттем, бәхәсләштем, аны «яклап» яздым, сөендем, хупладым—кыскасы, беркайчан да бу шагыйрьгә битараф булмадым. Аның да: «Рәдиф мелла!» йә «Тәкъсир!» дип нәкъ үземчә өслүб белән башланган хатлары хәтсез җыелган миндә. Барсы да шигырьләрен җибәргәндә язган «нәмүнәләр», аңлатма-«намә»ләр! Әле Зөлфәт белән сөйләшеп утырдык: соңгы 25-30 елда Гамил аганы «иң күп укучы» без булганбыз: мин—«Казан углары»нда, Зөлфәт—«Чаян»да. Эш буенча инде: сайлап, шәлкемнәргә аерып, басмага әзерләгәндә. Рәхмәтләре дә күп килде, үпкәләре дә, мөгаен... Чөнки ул гел бик продуктив булды, күп язды, күп басылды. Әре матур орлыкларны гына калдырырга тырыштык (ә кибәк була ул—кемдә дә!).

Хәзер инде күрәм: ул еллардан зур бер чиста, шәп, хәтта алтын орлыклар көшеле хасыйл булган ләбаса! Ил-көн үзгәрешләре, соңгы дистә елларның борчулары шагыйрьнең һөҗү-көлүен дә, лирикасын да тирәнәйтте, үстерде, ахры! «Тәвәккәл әби», «Ногман Дон Жуан», «Өф-өф итеп», «Мыек борам» кебекләр, шиксез, үз вазыйфасын үтәп, артта калдылар; «Гөлмәрьям» дә, «Дөнья матур, дөнья киң» кебек җырлар да... Фәлсәфи лириканың яңа формалары—нииндидер газиз кыйссалардан өзекләр кебек парчалар, кыска, хикмәтле шигырьләр, уйланулар, робагыйлар мәйданга куелды. Төрлелек, Тукайга карата замандашлары әйткәнчә, «берсе—сыйпый, юата, ә берсе—кыйный торган ике канат»ның гамьле, салмак, сабырлана төшкән җилпешләре. «Гамь төсмерләре», фәһемле тәҗрибә авазлары булган өн-нидалар бу! «Мәзәк белән җылыта җанны Гамил Афзал шикелле» дип язган иде Хәсән ага Туфан, Буадагы бер картны тасвирлап. Инде җор, үткен телле Хуҗа Насретдинны Хуҗа Ясәвиләр акылы, Хозыр Иьяслар зирәклеге алмаштырган чор, бәлки. Шагыйрь инде үзенең олпатлык-пәйгамбәрлек тавында, ашыга-ашыга васыятьтәй «сүрә»ләрен һаман безгә житкерә. Бәхетле язмыш, бәхетле зур иҗат!

Күптән түгел генә туып, игелекле эшләр өчен җан аткан яңа «Рухият» нәшрияты аксакал шагыйрьнең «Гомер кичүләре» исемле бик затлы эшләнгән басмасын—матур сайланмасын дөньяга чыгарып, шигырь сөючеләргә янә бер бүләк китерде. Китапка зур трактат саналырдай кереш—Галимҗан Гыйльманның мәкаләсе дә урнаштырылган. Ул анда халык шагыйренең милли поэтикасы кодларын—образлар символикасын бик кызыклы итеп билгели; әйе, урман, авыл, җир, күк кебек гади сүзләр дә, пәйгамбәр авызыннан ишетелгәндәй, нинди яңгыраш-көч алуы бик кызыклы мисалларда ачыла. Әйе, бу—пәйгамбәрлек биеклеге—безнең рухи ихтыяҗыбыз. Шуңа да Ходай белән иркен сөйләшкән шагыйрь булып килә минем күз алдыма Г. Афзал... Ялгышмыйм дип беләм.

**Рәдиф ГАТАШ**

**Фоат Садриев**

## БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ

РОМАН

...Ул төнне аландагы йортта ут сүнмәде. Председатель шоферы машинасында кемнәрнедер алып килде, кемнәрнедер алып китте. Ләкин ул шундый кеше иде, күрсә дә күрмәде, ишетсә дә ишетмәде...

Ирек иң элек партком секретаре белән теге фермада булды. Шакир белән бер торакта эшләүче ап-ак чырайлы, ябык озын гәүдәле Ләбип исемле кеше бу вакыйганың бердәнбер шаһиты иде. Аның сөйләве буенча, чыннан да Шакир соңгы ике-өч көндә салгалап күренгән, ләкин эшен ташламаган. Батталов кергәндә, алар икәүләп үгезләргә сенаж салып йөргәннәр. Председатель килеп тә кергән, эчүеңнән туктыйсыңмы син, юкмы дип, Шакирның яңагына салып та җибәргән. Ул да булмаган, кулыннан сәнәген тартып алып, биленә суккан, шуннан соң Шакир егылган. Батталов аның кайсы төшенә туры килә, шул җиренә типкәләргә тотынган, үтерәсең бит, дип килә башлагач, Ләбибне дә селтәп җибәргән. «Әйдә, күргәннәреңне язып бир», дигәч, ул бөтенләй кача башлады. Ахырда Ирек аны күндерде, барыбер бу хәл болай гына калмаячак, председательнең персональ эше тикшереләчәк, дигәч, кыска гына аңлатма язып бирде. «Шушы житәр, калганын партия жыелышында сөйләрмен», диде.

Ул көнне Ирек кунак йортында ялгызы гына булды. Кич караңгы төшкәч, бер хатын килеп керде.

—Сине, апаем, Казаннан ук килгән дип әйтәләр, шуңа кердем,— диде.

—Нинди йомышыгыз бар соң?

—Председатель турында сораштырасыз ди бит.

—Әйтәсе сүзегез бармыни?

Хатын кычкырып елап җибәрде.

—Алып атыгыз сез аны, апаем. Халыкның түзәрлеге калмады,—

---

Дәвамы. Башы 4 санда.

диде ул, күз яшьләрен сөртә-сөртә.—Малаебыз, армиядән кайткач, Чаллыга барып урнашты. Шуның өчен электрыбызны өзделәр, председатель газ баллоны бирдерми, печәннән мәхрүм итте, сарыкларыбызны көтүгә кудырмый. Үзем көне-төне фермада эшлим, ничек яшәргә безгә?!

—Исем-фамилиягезне әйтегез әле, апа.

—Ай-һай-һай! Алай булгач, бетте, бетте, исән бул, апаем!

Хатын шулай диде дә, ишекне шартлатып ябып, бүлмәдән чыгып ук китте. Ирек, җәһәт кенә киенеп, аның артыннан йөгерде, капка төпләрендә аны куып җитте. Хатын аны капкадан кертмәскә тырышып карады, ләкин Ирек көчләп эчкә үтте. Өйдә сүрән генә яктылык бар, ул өстәлдәге керосин лампасыннан төшә иде. Лампа тирәсендә ике малае нindidер китап актаралар, берсе күзлекле.

—Менә шулай яшибез,—диде хатын тагын елый язып.—Ашны казанда пешерәбез, лесник утын бирми. Урманнан сынган, ауган агачларны бәләкәй арба белән ташып, утын әзерлибез.

Ул арада түр якта «И-и-а-а!» дип кычкырган нindidер сәер тавыш ишетелде. Хатын шул якка кереп китте, Ирек тә иярде. Кулдан рәшәткәләп ясалган караватта ун-унике яшьләр тирәсендәге бер малай ята иде. Майкадан-трусиктан гына булганга, аның сөяк белән тиредән генә торучы мускулсыз аяк-куллары коточкыч куркыныч иде. Теге яктагы тынчулык, бередәге сидек исе белән аралашып, күңелне болгатып җибәрде.

—Абыегызны ашатыгыз,—диде хатын балаларга.

Малай, сырты белән әйләнгән үрмәкүч кебек, кул-аякларын хәрәкәтләндереп, нindidер аңлаешсыз тавышлар чыгарып ята бирде. Алар тагын алгы өйгә чыктылар. Шулчак ишектә йөзен кактус кебек сирәк ак сакал баскан ир күренде. Уртача гәүдәле ябык бу адәмнең өстендә ни икәнен аңларлык түгел: әллә ул ямаулы халат, әллә иске җилән, ертык итәк очлары астында галуш кигән шәрә аяклары күренеп тора иде. Ир бер сүз дә эндәшмәде, исәнләшмәде. Ирек кыенсынудан нишләргә белмичә:

—Исәнмесез, абый,—диде.

Ир җавап бирмәде, ачулы күзләрен елтыратып, хатынына карады.

—Тагын кемне алып кайттың, җодыгыш?—диде ул ачулы гыргылдык тавыш белән һәм буылып ютәлләргә кереште.

—Аны мин алып кайтмадым, үзе килде...

Ир кеше ютәлләүдән көчкә туктады.

—Бар, чыгып ычкын,—диде ул, ачу белән Иреккә карап.

—Туктале, абый, мин бит...

—Ни өчен туктарга? Әйдә, ычкын, ычкын!

Ул аның янына килеп этә үк башлагач, Ирекнең чыгып китүдән башка чарасы калмады. Баскыч төбенә чыккач, Ирек аңа борылып:

—Мин бит начар ният белән килмәдем, райком инструкторы,—дип сүз башлаган иде, ир кеше бөтенләй дөртләп капты, аны капкага таба этеп үк җибәрде.

—Нәкъ кешесе икәнсең, нәкъ син кирәк идең инде безгә! Беләбез без сезне, Батталов хезмәтчеләрен,—диде.—Әгәр әнә теге җодыгыш кыткылдап корреспондент китермәгән булса, без әле бу хәлгә үк төшми идек.

—Моның булуы мөмкин түгел, сез алдашасыз!—диде Ирек, аңа таба атлап.

Ир кеше, күкрәгеннән этә-этә, аны капкадан ук чыгарып җибәрде.

—Мин алдашсам, әнә аларга кереп кара!—дип төртеп күрсәтте ул каршыдагы йортка.

Ирек аптырап басып торды. Ул үзен нindidер бер ят дөньяга килеп эләккән кебек хис итте. Бераз исен җыйгач, чыннан да каршындагы йортка кереп карарга булды. Йортның тәрәзәләреннән саргылт яктылык күренә иде. Ирек капканы дөбердәтә башлауга, өйдә ут сүнде. Ул, дөньясыннан, үз-үзеннән гайрәте чигеп, кунак йортына кайтты, чишенеп тә тормыйча караватка ауды.

Икенче көнне иртән ул идарәгә килгәндә, Нәҗмиев партком

бүлмәсендә утыра иде. Алар Фәрдиев белән быдыр-быдыр сөйләшкән җирләреннән, Ирекне күргәч, тынып калдылар.

—Ну, Сабитов, кунак йортында йокладыңмы?—диде Нәҗмиев.

--Әйе.

—Анда председательнең УАЗигы районга бара, ашыгыч эшләрең булса, мин сине кайтарып җибәрәм. Монда мин үзем дә ерып чыгармын.

Нәҗмиевнең бу сүзләре Ирекне аптыраушта калдырдылар. Ник соң әле ул аңардан бер әйбер дә сорашмый? Нәҗмиев аны Батталовның персональ эшен әзерләшергә дип алып килде бит. Кичә партком секретаре белән кешеләрне күреп сөйләш, дип җибәрде. Ә бүген берни булмагандай кайтып китәргә куша. Әллә чыннан да кайтып кына китәргәме? Аның бит үзенең дә эше муеннан. Шулай уйласа да, китә алмады. Бу эшнең ахырын күрәсе, аңлыйсы килде аның. Шуңа күрә Нәҗмиевкә:

—Бер килгәч, кайтмыйм инде,—диде. Аннары, үзен читләштермәсен өчен, юри салпы ягына салам кыстырды:—Сезнең кебек тәҗрибәле кеше белән эшләү минем өчен үзе бер олы мәктәп бит...

Нәҗмиев, бу сүзләргә кәефе килеп, елмайды. Аннары Ирек өчен бөтенләй аңлашылмаган нәрсәләр башланды. Иң элек Нәҗмиев председатель бүлмәсенә кереп китте, аннары алар Фәрдиевне чакырып алдылар. Ирек аптырап утыра бирде. Ул да булмады Фәрдиев ашыга-ашыга чыкты да, нindидер кәгазьләр алып, тагын кереп китте. Бераздан ишектә Нәҗмиев күренде.

—Йә, ниләр таптың?—диде ул.

Ирек кемнәрне күргәнен, ничек булганын түкми-чәчми сөйләп бирде. Ләбиб Латыйповның аңлатмасын Нәҗмиев, ничектер сәер елмаеп, авыз чите белән пышылдый-пышылдый укып чыкты да папкасына салды. Аннары бераз уйланып торгач:

—Син, Сабитов, агитколлектив җитәкчесен күр әле,—диде.—КПСС Үзәк Комитетыннан эчүчелеккә һәм алкоголизмга каршы көрәш турындагы карарын тормышка ашыру буенча ниләр эшләнә? Планнарын, үткәргән чараларын, бөтенесен җентекләп тикшер. Безнең бу персональ эш шушы карарга барып тоташмагае әле.

Ирек мәктәпкә китте. Ул, нәкъ Нәҗмиев әйткәнчә, барысын да тикшерде, блокнотына тиешле саннар, фактларны теркәде. Сәгать уникe тулганда, идарәгә кайтты һәм, ишек янына эленгән зур белдерүне укыгач, бөтенләй аптырашта калды. Анда бүген унөч сәгатьтә колхоз коммунистларының гомуми җыелышы булачагы әйтелгән иде. Ирек, аптырап, идарәгә керде. Партком бүлмәсе дә, председатель бүлмәсе дә бикле иде. Үз күзләренә үзе ышанмагандай, белдерүне тагын бер мәртәбә укып чыкты. «Нәҗмиев шулай барысын да тикшереп, ачыклап бетерде микәнни?»—дип хәйран калып уйлады ул. Ләкин бит тикшерелеп беткән очракта да җыелышның булачагы коммунистларга һич югы бер көн алдан хәбәр ителергә тиеш иде. Ул, кунак йортына барып, капкалап алырга уйлады. Анда район үзәгеннән килгән ПМК эшчеләре төшке ашка кайтканнар иде. Ул, шулар белән утырып, тиз-тиз генә ашады да идарәгә ашыкты. Партком бүлмәсендә кеше юк, председатель ягында Батталов, Нәҗмиев һәм Фәрдиев утыралар иде. Батталов Ирек белән зурлап торып күреште, утырырга урын күрсәтте дә:

—Менә бит, Кәрәм Нәҗмиевич, без картаябыз, ә сәләтле яшьләр үсеп, үкчәгә басып киләләр,—диде.—Сабитовның чыгышлары да, район газетасындагы язмалары да бик ошый миңа.

—Йә, тикшердеңме агитколлективны?—диде Нәҗмиев.

—Тикшердем,—дип җавап бирде Ирек.

—Эшләгән эшләре бармы?

—Мактанырлык түгел.

—Ярар, мактанырлык булмаса.—Нәҗмиев кул селтәп куйды.—Әгәр кирәге чыкса, җыелыш барышында бу мәсьәлә буенча сиңа сүз бирербез. Әзерләнебрәк тор.

—Мин әзер,—диде Ирек, тыныч кына.—Тик бу партия җыелышы ничек болай бик тиз генә...—ул сүзен әйтеп бетерә алмады, Нәҗмиев мәгънәле итеп баш бармагы белән түшәмгә таба күрсәтте:

—Ашыктыралар. Үзебез дә шуны әйтеп утырабыз: һич тә кабаланырга кирәкми иде...

Ул арада, берәү кереп, коммунистларның җыелып бетә язганлыгын әйтте. Алар утырышлар бүлмәсенә керделәр. Нәҗмиев күпләр белән кул биреп күреште, кайсының җилкәсеннән какты, кайсына сабакташ, диде, кайсына яшьти, дип дәште. Ирек залдан теге Латыйпов дигән кешене эзләде, ул артта почмакка кереп поскан, башын аска иеп утыра иде. Фәрдиев, исемлектән карап, җыелышка килергә тиешле алтмыш дүрт коммунистның илле алтысы килгәнлеген әйтте. Җиде кеше командировкада дип аңлатты.

—Шакир Хәмәтшин үзе кая соң?—дип кычкырды кемдер.

—Мин әле генә аның янында булдым, ул җыелышка килүдән баш тартты,—дип аңлатма бирде Фәрдиев.—Чөнки исерек.

Зал шау-гөр килә башлады.

—Үзеннән башка нинди тикшерү ди!

—Җыелышны таратырга кирәк!

—Мужыт ул ел буе айнымас!

Шулчак Батталов торып басты.

—Мин, иптәшләр, аны алып килергә дигән тәкъдим кертәм. Җыелыш буласын ул алдан белде. Әгәр шушы кадәр коммунистны санга сукмый икән, сезнең барыгызга да төкереп карый икән, ничек мона юл куярга мөмкин? Без хәзер партия җыелышын да ул айныгач кына җыярга тиеш булабызмыни?

—Дөрес, дөрес, алып килергә!—дип кычкырдылар залдан.

Дүрт кеше махсус машина белән аның өенә китте. Биш минуттан Хәмәтшинны алып килеп тә җиткерделәр. Ул чыннан да бик нык исерек иде. Залга кереп, пыялаланган күзләре белән карап торгач, алпан-тилпән атлап, иң алдагы урынга барып утырды. Фәрдиев, җыелышны ачып, көн тәртибен раслаткannан соң, тикшерелә торган персональ эшнең асылын аңлатты. Фәлән көнне фермада исерек хәлендә Хәмәтшинның колхоз председателе Батталовка ташлануы, аның үзен яклаганда артык көч куллану нәтиҗәсендә һөҗүм итүчегә тән җәрәхәтләре ясавы турында сөйләде. Аның тән җәрәхәтләре алуы турында медицина белешмәсе барлыгын әйтте. Хәмәтшинның даими рәвештә эчүчелек белән шөгыльләнүе, ул көнне дә эчкән булуы турында әйтте. Аннары сүз Батталовка бирелде. Кемдер:

—Сорау бирергә мөмкинме?—дип кычкырды.

—Янадан, тыңлап бетергәч,—диде Фәрдиев.

Батталов басты да, ике кулының бармакларын аралаштырып, кендек турына куйды.

—Миңа сезнең каршыда гаепле булып басып торуы ифрат та кыен,—диде ул.—Утыз ел бергә эшләп, менә бу көннәргә дә килеп җиттек. Әйдә, хөкем итегез.—Ул чал башын иеп, еларга әзерләнгәндәй, туктап калды, авыр сулап, янадан башын күтәрде.—Иң элек минем шуны әйтәсем килә. Шакир белән безнең арада бернинди ачу-кычу юк, моны ул үзе дә раслар, хәер, сез дә беләсез. Безнең күчәр башлары орылышкан икән, ул Шакирны тәртипкә чакыру аркасында килеп чыкты. Сез минем күпме ертылганымны беләсез... ничә еллар буе... Ник? Менә шушы колхоз дигән уртак йорт өчен ул. Халык әйбәтрәк яшәсен дип. Ә минем кычкырып елыйсым килә. Чөнки бер яктан тәзибез, икенче яктан шул йортны төрлечә җимерү бара, ә сез битараф! Мин җитәкче эштә эшләмәгән гади коммунистларга мөрәҗәгать итәм: эленке-салынкы йөрүчеләрне, каракларны, эчкечеләрне кайсыгызның фаш иткәне бар?! Хет бер генә очрак әйтә аласызмы, иптәш коммунистлар?!—Батталов туктап, карашы белән залның әле бер, әле икенче урынына күз атты.—Юк шул! Авыз

ачып сүз әйтә алмыйсыз. Ник дисәң, күпләрегез үзегез шул юлда.— Батталов кинәт елый язып, дәвам итте:—Әй менә мин түзә алмыйм, минем җаным елый! Шушы колхоз дип, күпме гомер, күпме нервы, күпме йокысыз төннәр салынган!—Ул маңгаена төшкән чал чәчләрен сыпырып куйды, графиннан агызып су эчте һәм арыган, хәлсез тавыш белән чыгышын дәвам итте:—Бер башлагач, әйтим, Шакир гаебе белән өченче ел ничә үгезнең күбенеп үлгәнен сез яхшы беләсез. Шул чакта аның хатынының яхшы эшләвен, балаларының ишле булуын искә алып, мин бу зыянны аңардан түләтмәү өчен барысын да эшләдем. Ничә мәртәбә аны ун тәүлеккә утыртудан алып калганнарны Шакир үзе генә белә. Инде теге көнгә килгәндә, мин аны берничә көн буе эчмә, дип кисәтә килдем. Ана, күрәсең, шул ошамады. Кич үгезләр торагына кергәч, ул миңа сәнәк белән ташланды...

Шулчак Шакир чәчрәп урыныннан сикереп торды, бала башы кадәр йодрыгын селтәп җибәрде:

—Алдашма! Ник халыкны алдыйсың?!—дип кычкырды ул, Батталовка таба атлый-атлый.

—Менә күрәсезме?—диде Батталов, аңа таба бармагы белән төртеп.— Үзегезнең күз алдында миңа уктала!

Залда шау-шу купты.

—Милиция чакыртырга кирәк!

—Алдаша бит, алдаша!

—Председательне кыйнатабызмыни?!

—Ю-у-у-ук, мин сиңа сукмыйм!—Шакир төйнәлгән йодрыгын аска төшерде.—Тик син күрәләтә алдашасың!

Батталов, президиумга таба башын борып:

—Мина сөйләргә мөмкинлек тудырасызмы, юкмы?—диде.

—Шакир абый, урыныңа утыр әле!—дип җикерде Фәрдиев.—Юкса участковый әнә авыл Советында гына!

Шакир урынына барып чүмәште.

—Сәнәк белән ташлангач, мин күкрәгемне куеп торырга тиеш идеммени?—диде Батталов, сүзен дәвам итеп.—Сәнәгеен каерып алганда, ул егылып китте, мин шунда, үзем дә сизмәстән, кызып китеп, аңа берике мәртәбә тибеп җибәргәнмен. Кем белә, аның ул кабыргасы әллә мин типкәндә бәрелгән, әллә үзе егылганда сынган?

Шакир тагын чәчрәп торды, бу юлы Батталовка карамады, залга таба ялварып ике кулын сузды һәм еларга җитеп аһ орды:

—Ялганлый бит, иптәшләр! Дөрес түгел бит! Мин аңа сәнәк белән килү түгел, кайтарып бер сүз дә әйтмәдем!

Фәрдиев аны тагын урынына утыртты.

—Дәвам итегез,—диде ул Батталовка.

—Тагын нәрсә дәвам итәргә? Шул инде. Мин, әлбәттә, үземне гаепсез дип санамыйм. Чамадан артыбрак киткән. Ну, сез мине дә аңлагыз: хәзер нервылар тәмам беткән, дөртләп кабынырга торган кешегә күпме кирәк? Райком һәм бюро әгъзасы буларак, миңа икеләтә авыр. Әле анда да җавап тотарга туры киләчәк. Безнең коммунистлар бу инцидентка объектив бәя бирерләр һәм кешелеклелек законнары буенча карар чыгарырлар дип уйлыйм.—Бераз башын иеп торганнан соң, ул сүзен дәвам итте:—Әгәр сез моны ике ярсу кешенең бәрелеше дип кенә уйласагыз, бик нык ялгышасыз. Мин моның төп сәбәбен эчүчелек белән караклыкта күрәм. Менә, Шакир, син ул вакытта бер атна айнымыйча эчтең. Хәзер больницадан кайтканыңа ничә көннәр, һаман эчәсең. Каян акча юнәтәсең син? Мин әз генә дә шикләнмичә әйтәм, син үзеңнән тиен дә акча тотмыйсың. Әнә шул үгезләргә дигән фураж сезгә эчәргә дә, башкасына да җитә. Безгә бу нәрсәнең тамырына балта чабарга кирәк. КПСС Үзәк Комитетының эчүчелеккә каршы карарын үтәү буенча бармакка бармак та сукмыйсыз, дисәм дә, хата булмас. Барыгыз да әйбәт, барыгыз да яхшы, ул эчкечеләр белән бер Батталов кына якалашырга

тиешмени? Уйлагыз, иптәшләр! Бу чир безгә әле әллә нәрсәләр күрсәтәчәк. Минем хәзергә сүзем бетте.

Аннары Шакир Хәмәтшинга сүз бирелде. Хәмәтшин инде айный төшкән иде.

—Мин берни дә сөйләмим,—диде ул.—Тик бер нәрсәне әйтәм: минем Гайсә Батталовичка кул күтәрергә уйлаганым да, кул күтәргәнем дә юк!

Зал тагын шау-гөр килде.

—Аның мине ничек сугып екканын Ләбиб үз күзләре белән күреп торды бит. Без малларга сенаж тарата идек. Ләбиб, әйт! Ана таба омтылдыммы мин? Сәнәк белән килдемме?!

Җыелыш тагын шау-гөр килде.

—Шакир абый, син монда допрос алма әле,—дип кисәтте Фәрдиев.—Кемнән нәрсә сөйләтергә икәнен без үзебез белербез.

—Әйе, сез белерсез!—диде Шакир, мәсхәрәле тавыш белән аңа таба башын борып.—Гайсә Батталович мина күпме пычрак атты—мин барысын да күтәрәм. Ә менә мин аңа ташланды дигәне—күрәләтә ялган! Ничек булганын әнә Ләбиб әйтсен! Батталовның минем өскә менеп сикергәнен, таптаганын әйтсен!

—Ләбиб, әйдә җавап бир!

—Кирәкми, Шакир сүзен бетерсен әле!

—Аның сүзе беткән инде, Ләбиб, ник дәшмисен?

Ирек теге почмакка карады. Ләбиб Латыйповның озын гәүдәсе, пружина белән эткәндәй, кинәт турайды:

—Син, Шакир,—дип нечкә тавыш белән кычкырып җибәрде ул,—мине юк-бар белән бутама әле! Мин сенаж күтәреп бара идем, артыма борылып караганда, син Гайсә Батталовичка уктала иден бит.

—Син нәрсә, син нәрсә?!—Шакир, нишләргә белмичә, утырышлар залының бер ягыннан икенче ягына урап килде.—Ни белән, ничек укталдым мин аңа?! Әллә күзенә күрендеме?!

Ләбиб озын кулын селтәп куйды:

—Бөгештермә инде, Шакир! Тиктомалдан председатель йөгереп эшләп йөргән кешегә сугамы? Юк сүзне сөйләмә син аны!—Ләбиб тагын почмагына чумды.

Шакир шашынган күзләре белән, нишләргә белмичә, бер президиумга, бер залга карады.

—Иптәшләр!.. Ни бу... Котыртып куйганнар аны! Ул барысын да күреп торды. Ну, нишлим соң мин, башка шаһитым булмагач?!—ул калтыранып елап җибәрде, ике күзен кулы белән каплап, урынына утырды.

—Шайтан күзе сидекле була!—дип кычкырды кемдер залдан.

Кемнәрдер мыскыллап көлде.

Ирекнең киеренкелектән бөтен мускуллары таш булып катты. Ул, берничә мәртәбә сикереп торып, теге Ләбиб дигән кешегә «Сез бит миңа алай дип сөйләмәдегез, ник коммунистларны алдыйсыз?!» дип кычкырасы килде. Ләкин аны нәрсәдер аска тарткандай тыеп калды. Соңрак ул монын җыелыштагы атмосфера икәнлеген аңлады. Ул атмосфера җыелыш башланунын беренче минутларыннан ук аның нинди юнәлештә барасын, кем файдасына бетәсен сиздереп тора иде. Күпчелекнең кемне яклаячагы, монда хакыйкать мөһим түгел, ә Батталовны коткару мөһим икәнлеге инде баштук ачык билгеле һәм ул уңай хәл ителгән иде. Әллә монын шулай икәнлеген Ләбиб тә сизде микән? Ирек, үз уйларына батып, башын иеп утырды. Батталовны яклап, ике-өч хатын-кыз, тагын әллә ничә ир-ат чыгыш ясады. Кыйналучыны эт итеп сүктеләр, ул кабат бер сүз дә дәшмәде. Үз-үзен яклаганда артык көч кулланганы өчен дип, Батталовка кисәтү бирү турында карар кабул ителде. Икесенә дә партком тарафыннан бирелгән характеристика расланды. Фәрдиев, җиңел сулап, «Шушының белән, иптәшләр, җыелыш ябык», дип, сүзен бетерә алмады, Нәҗмиев торып басты:



Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе Национальная библиотека Республики

—Юк, иптәшләр, җыелыш әле бетмәде,—диде ул.—Мин райком тарафыннан җыелышка тагын бер персональ эш куюны тәкъдим итәм. Ул Шакир Хәмәтшинның партия җыелышына исерек хәлдә килүе турындагы мәсьәлә.

Зал тып-тын булды. Шакир торып басты да:

—Мин җыелыш буласын белмәдем. Миңа сәгать уникедә генә әйттеләр,—диде.

Нәҗмиев аңа каршы:

—Ялгышмасам, сез больничныйда бугай?—диде.

—Әйе.

—Больничныйдагы кеше эчеп ятарга тиешмени ул?

Шакирның башы аска иелде. Дөрес сүзгә җавап юк иде. Фәрдиев залга карап:

—Ничек, иптәшләр, икенче көн тәртибен карыйбызмы?—диде.

—Карарга кирәк!

—Больничныена түләмәскә!

Шулчак Батталов торып басты.

—Мин иптәш Нәҗмиевнең, Устав таләпләреннән чыгып, бу тәкъдимне кертүен яхшы аңлыйм. Ләкин, иптәшләр, мин үзем егылганны түбәләү ягында түгел. Булган икән инде—булган, кичерик без Шакирның бүген исереп килүен. Больничныена түләмәү белән дә мин килешә алмыйм. Ул хәзер ике ай буе акча алмады. Әгәр шул акчадан мәхрүм итсәк, аның семьясы ничек яшәр? Җыелышны мин шушының белән төгәлләргә кирәк дип саныйм. Инде бер баскач әйтим. Сезнең кисәтүегезне мин бөтен йөрәгем белән кабул итәм һәм үземдәге кызып китү кебек алама гадәтне кабатламаска сүз бирәм. Шакирдан гафу үтенәм. Булдыра алсаң, гафу ит син мине, Шакир!..

Залда бер хатын-кызның йомшарган борынын мышык-мышык тарткалавы ишетелде. Бу әйбәт куелган спектакль кебек чыннан да йөрәктән алырлык күренеш иде шул. Батталовның олы җанлылыгы хәтта Шакирга да тәэсир итте. Ул торып:

—Гайсә Батталович, Гайсә Батталович...—дип нидер әйтмәкче булды да, «Ярар инде» дигәндәй, кулын селтәп, урынына утырды.

Аның бу сүзләрен председательне гафу итүе дип аңладылар.

Җыелыш шуның белән тәмам булды. Ирекне махсус автобус район үзәгенә алып китте. Нәҗмиев: «Минем әле кайбер эшләрем бар»—дип, колхозда калды. Аннары алар Батталовның «Волга»сында урман аланындагы өйгә юнәлделәр. Бер сәгатьтән анда Миңзаһит Усманович үзе дә килеп җитәргә тиеш иде...

## 13

Язмыле җәй башланды. Зәнфирәнең туган көне дә килеп җитте. Ирек, бүләк эзләп, универмагка керде. Кызның хушбуй, иннеккершәннәргә исе китмәгәнен белгәнгә күрә, парфюмерия бүлегендә озак тукталмастан, галантерея ягына күчте. Ул ак свитердан күзен алмады. Ак һәм зәңгәр—Зәнфирәнең иң ярата торган төсләре. Свитер аның гәүдәсенә үлчәгән кебек, таман булырга тиеш. Ирек бүгенге туган көн кичәсенә бик зур өметләр баглады. Әлек килеп чыккан рәнҗеш-үпкәләрне, аның уйлавынча, бу кичә юып алып китәргә тиеш иде. Тагын берәз икеләнеп торганнан соң, ул свитерны алды, яхшылап полиэтилен капчыкка салдырып, зәңгәр тасма белән бәйләтте. Үзенең бүлмәсенә чыккач, алдан ук шигырь язып куелган открыткасын шуның эченә тыкты. Бүләген өстәл тартмасына куеп маташканда, елмаеп-көлеп Сөембикә килеп керде. Килеп тә керде:

—Уф, синең китабыңны баса-баса күзләрем күгәрде, Ирек!—диде һәм аның өстәленә әле яңа гына машинкадан чыккан битләрне китереп салды.

—Бетердем, рәхмәт әйт.

Ирек, анын башын сак кына тотып, алсу янагыннан үпте:

—Рәхмәт, Сөембикә. Күпме булды?

—Ике йөз утыз алты бит. Ничек шул кадәр сүз табып бетерәсен?

Аларнын сөйләшүе бүлендә: аны бик ашыгыч төстә Шәвәлиев чакырды.

—Өлкә комитетыннан чылтыраттылар,—диде ул.—Сина бүген үк Казанга семинарга китәргә кирәк.

Ирекнен тыны кысылып куйды. Беренчедән, ана бүген Зәнфирәнен туган көненә кайтмыйча ярамый, икенчедән, курс эшен тәгәллисе бар һәм дүрт көннән башланачак җәйге сессиягә китәргә кирәк иде.

—Мин бара алмыйм, Зөфәр Шәрипович,—диде ул, аптырашлы карашын аңа төбәп.

Шәвәлиев көлемсерәгән кебек итте.

—Монда ул турыда сүз бармый, Сабитов. Сина икенче рейс белән Казанга очарга һәм бүген үк өлкә комитетынын идеология бүлегенә керергә кирәк.

Ирек аягүрә басты:

—Мин, көне-төне эшләп, сессиягә кадәр бетерим дип тырышып, китапны тәгәлләдем. Хәзер кырык төрле эшем килеп тыгылды. Аларны бетермичә сессиягә китә алмыйм.

—Казанда эшләрсен,—диде Шәвәлиев тыныч кына.—Семинар дигәч тә, әллә син анда көне-төне укып яталар дип беләсенме. Вакытын күп булачак анда.

—Минем курс эшем тәгәлләнмәгән.

—Тәгәлләрсен дим бит. Инде әйтсәм-әйтим: берәр көн занятиесеннән дә калырсын. Ә китмичә ярамый. Әгәр син анда бүген барып житмәсән, иртәгә мине чакырып алачаклар. Мин сина берни яшермичә, ачыктан-ачык әйтәм.

—Ул вакытта мин иртәгә беренче рейс белән китәм.

—Сабитов,—диде Шәвәлиев, тавышын күтәреп.—Син төшенмәден, ахрысы. Әгәр бүген барып өлкә комитетына кермәсән, иртәгә беренче рейс белән Казанга син түгел, мин очачакмын. Шушы әйберне анламыйсынмыни син?

—Анлыйм. Тик бармаячакмын. Иртәгә булса...

—Туктале, Сабитов, сина барыбер түгелмени? Бүген төштән сон киттен ни дә, иртәгә иртән киттен ни. Нинди аерма бар монда?

—Минем бүген мөһим эшем бар. Мин китә алмыйм, ачуланмагыз, Зөфәр Шәрипович,—дип, Ирек ишеккә таба атлады.

—Сабитов, туктале. Ярый, китмәссен. Иртәгә дә бармассын. Тик белеп тор, мин сине җәйге сессиягә дә җибәрмим. Хуш!

Ирек кызулап чыгып китте. Бүлмәсенә керде дә кәгазь-каләм алды. Эштән китәргә гариза язмакчы булды, әмма бер генә хәреф тә куя алмады. Юк, хәзергә ана райкомнан китәргә ярамый. Квартира алырга, аннары Зәнфирәгә өйләнергә, шуннан сон баш-аягын белән иҗатка чумарга. Шушыларны уйлагач, ул кабат Шәвәлиев янына керде.

—Ярый, мин китәм, Зөфәр Шәрипович,—диде башын аска иеп.—Шуннан сессиягә дә калам.

Шәвәлиев елмаеп җибәрде:

—Менә бусы егетләрчә. Бар, командировка кәгазенне ал да ычкын. Сина самолетта урын калдырырга әйтелгән.

Ирек, кәгазьләрен алгач, Әхнәф янына керде. Өч сүз белән хәлне анлатып бирде.

—Сәгать ярымнан минем самолет оча,—диде.—Шунынчы авылдан әйләнергә машинанны биреп тор әле.

Килештеләр, Әхнәф шоферына анын белән кайтып килергә кушты. Ирекнен уе Зәнфирәне туган көне белән котлау, бүләген тапшырып килү иде. Алар шундук кузгалдылар. Ләкин авылга таба борылып бер чакрым да үтмәделәр, нәрсәдер дөбер-шатыр килеп, райкомолнын иске

ГАЗ-69 ы туктап калды. Шофер, тапшыру коробкасы таралды, диде. Әйттем мин аны Әхнәфкә, кайчан да булса юлда калабыз, дидем, менә шулай булды да, диде. Ирек юлга чыгып басты да әле кул сәгатенә, әле авыл ягына карады. Машина-мазар күренмәде, шулай итеп ярты сәгать үткәч, ул, кире борылып, фатирына ашыкты. Әйберләрен тутырып, аэропортка менәргә кирәк иде. Юлда аңа җәяүләп кайтып килүче мәктәп директоры Заһит Фәхруллин очрады. Ирек, бик кыен булса да, аңа хәлне аңлатты, зинһар өчен бүген үк менә шушы төргәкне Зәнфирәгә кертеп чыгыгыз, диде. Заһит абыйсы, ярар, диде, аны сумкасына салып куйды. Ирек аэропортка чак барып өлгерде, шулай да әле самолет очарга биш минут вакыт бар, дигәч, аэропорт начальнигына кереп, авылга медпунктка чылтыратты. Медпункт җавап бирмәде. Шулай итеп, ул, Зәнфирәгә бернинди хәбәр бирә алмыйча, Казанга очты.

Ах, ул кич! Зәнфирә башкалар кебек түгел: шатланса, дөньясын онытып, нишләгәнен белмичә очына; кайгырса, үзен юк итәр дәрәҗәдә төшенкелеккә бирелә. Бүген аның очына торган көне иде. Туган көненә ул йөгерә-йөгерә ике тәүлек әзерләнде. Иң якын кешеләренә әйтте, әллә ничә төрле салат ясады, күп итеп фарш чыгарды. Ике тавык суйдырды, әллә нинди бизәкләр төшереп торт пешерде. Кичке сигезләргә барысы да җыелып беттеләр. Туктаусыз котлаулардан аның башы әйләнде. Күп көлүдән, елмаюдан яңаклары авырта башлады. Әле һаман да табынга утырмадылар, Ирекне көттеләр. Ләкин Ирektән бернинди хәбәр дә юк иде. Егетләрдән кемдер аның әти-әниләренә барып кайтты, аларның да берни белмәве мәгълүм булды. Зәнфирә нәүмизләнеп калды. Инде көтеп булмый иде, табынга утырдылар. Әлбәттә, матур-матур тостлар да әйтелде, Зәнфирәгә чәчәкле-чуклы теләкләр дә теләнде, күмәк җырлар да җырланды, тик аларның берсе дә аның күңелен эретә алмадылар. Хәзер инде аның җаны елый иде. Шуны күрсәтмәс өчен, килгән кунакларның кәефен кырмас өчен ул ясалма елмайды, ирексездән генә көлде. Ирекнең кайтмавы аның уеннан бер генә мизгелгә дә чыкмады. Бередә утыручылар да бу бушлыкны сизделәр, Зәнфирәгә никадәр кыен икәнен аңладылар шикелле. Туган көн аның хәтерендә иң ачы көн булып калды. Ул, ишекне бикләмичә, савыт-сабаны да җыймыйча, урын да җәймичә, утны да сүндермичә, караватына капланды. Елаганын әнисе ишетмәсен өчен, йөзен мендәренә төртте...

* * *

Ирек, Казанга барып җитүгә, беренче эш итеп, Зәнфирәгә хат язды. Ул аңа барысын да бәйнә-бәйнә аңлатты, туган көнеңне соңарып булса да, мин сессиядән кайткач, икәү генә билгеләп үтәрбез, диде.

Менә сессия тәмам. Сары «кукурузник» район үзәге өстеннән кыегаеп бер әйләнде дә ямь-яшел чирәмгә төшеп утырды. Ирек, самолеттан авыр чемоданын тотып чыгуга, тирән итеп сулап куйды. Кырык көн буе университет аудиторияләре эчендә дөньядан аерылып яткан кешегә шушындый сәхрәгә килеп төшү үзе олы бәйрәм иде. Ул, күзләрен кысып, кайнар кояшка, зәп-зәңгәр күк йөзенә, эремчек төсле ярмаланып, күпереп торучы төркем-төркем ак болытларга карады. Әкрен генә талгын җил исә, ул чәчәк, үлән һәм басудагы өлгереп килүче икмәк исен алып килә иде. Ирек чемоданын фатирына куярга да, бүгенгә райкомда күренмичә, әти-әниләре, Зәнфирә янына кайтып килергә булды. Аэропорт бинасының почмагыннан борылганда, авылдашы Сабирҗан абзый белән маңгайга-маңгай бәрелешә яздылар. Исәнлек-саулык, хәл-әхвәл белешкәч, Сабирҗан:

—Менә кода белән кодагыйны гына очырып җибәрәм дә авылга кайтам, теләсәң, атка утыр,—диде.

Ирек шатланып риза булды. Туры юлдан болын буйлап печән салынган кабык арбага утырып кайтудан да рәхәтрәк ни бар? Ул, чемоданын Сабирҗанның арбасына куеп, аны көтеп торды. Самолет

очып киткәч, алар кайтырга чыктылар. Ирек әти-әниләренең, авыл кешеләренең хәл-әхвәлләрен сораштыргалагач, аларның сүзе бетте. Сабирҗан аның Казанга ник баруы белән кызыксынды да кабат авыз ачып бер сүз дә әйтмәде. Ирек өчен аның сөйләшмәве әйбәт иде. Ул, кулын сузып, юл буендагы һиндыбаларның зәңгәр чәчәкле башларын сыпырып барды, бал кортларының безелдәп очуын, кош-кортларның чыркылдашуын тыңлады. Төрле чәчәк, үлән исләреннән ләззәтләнеп күзләрен йомды. Таш калада табигатькә сусагангадыр, бу үләннәр, чәчәкләр, еракгагы рәшәдә тирбәлүче иген басулары, куаклар һәм калкулыклар аны тынычландыралар, йөрәгенә ял бирәләр иде.

Менә Сабирҗан, атын юлдан читкә борып, үләннең куерак һәм биегрәк җиренә кереп туктады. Аннары артка беркетелгән чалгысын алып җиргә кадады, атының аркалыгын төшереп, үлән ашарга куйды да, чалгысын янады да печән чабарга кереште. Ирек җәяүләп болынның уртасынарак керде, иелә-иелә җиләк юк микән дип карады. Яшел бөреләрне кулы белән сыпырып-сыпырып аралагач, әле җиләк пешәргә иртәрәк икәненә төшенде. Кинәт аңа бик шәп уй килде: Зәнфирәгә чәчәк җыярга. Ул бит аны, сагынып булса да, бүген туган көне белән котлаячак. Ирек сабый бала кебек, әле анда, әле монда сикереп, йөгерә-йөгерә чәчәк җыярга кереште. Шунда Сабирҗан, кыяр-кыймас кына атлап, аның янына килде, ул чалгысын бая чаба башлаган җирендә калдырган иде. Тирләгән маңгаен кул аркасы белән сыпырды да:

—Ирек, үскәнем, ул чәчәкләрне кемгә җыясың?—дип сорады.

Ирек кызарып китте. Аларның авылында кызларга чәчәк җыю, чәчәк бирү ничектер аксөякләр гадәте кебегрәк бәяләнгәнен ул белә иде, шуңа күрә аңлатып тормады:

—Җыям әле...—диде.

Сабирҗан аның җилкәсенә кулын салды да, бик еракта күкшелләнеп торучы урманнарга караган килеш, акрын гына әйтте:

—Аның өчен булса, мәшәкатьләнмә, апаем...—диде.

—Кемне әйтәсең, Сабирҗан абзый?

—Кияүгә чыкты ул кызый.

Ирек һаман берни дә аңламады.

—Кем кияүгә чыкты?

—Син, кем булсын?—диде Сабирҗан, карашын билгесез ераклыкка төбәгән килеш.—Син яраткан кыз инде...

Ирек калтыранып китте.

—Зәнфирәме?!—диде ул, шушы бер сүзне көч-хәл белән телендә әйләндереп.

—Син, шул инде, үзе...—Эш бетте дигәндәй, Сабирҗан читкә атлады.

—Кемгә?! Кайчан?!

Ирек ничек итеп Сабирҗанның каршына килеп басканын, бу сүзләрне әйткәндә тавышы ничек күтәрелгәнен, ничек кулларыннан чәчәкләре төшеп киткәнен дә сизмәде.

—Туе булганга ике атналап кынадыр әле. Күптән түгел генә чыкты...

Ирек коелып төште, авызы, бөтен йөзе, күзләре хәрәкәтсез калдылар. Ул тагын Сабирҗан каршына килде:

—Кемгә?! Кемгә?!

—Мәктәп директорына, Заһитка...

Ирек алпан-тилпән арбага таба атлап китте. Чемоданын алмакчы булды, ләкин көче җитмәде, чемодан зур, аның эче тулы китап иде. Тоткасыннан кулы белән эләктергән килеш, бөгелеп, маңгаен чемоданга терәде. Әгәр шушы вакытта күк йөзе җимерелеп төшеп, бөтен дөньяны сытса, җир убылса, яисә туфан суы басса да, аңа җиңелрәк тоелыр иде. Артта Сабирҗанның чалгы янавын ишетеп, ул бераз аңына килгәндәй булды. Ир кеше болай кыланырга тиеш түгел иде. Хәзер моны бөтен авыл сөйләячәк, арбага капланып елады диячәкләр. Ул тешләрен кысып, ике куллап чемоданын юл буена куйды да чирәмгә утырды. Зәнфирә

кияүгә чыккан! Зәнфирә үзеннән унбиш яшькә олы Заһит Фәхруллинга кияүгә чыккан! Әнә болыннан арырак арыш басуы өлгереп килә, арышлар агара... Зәнфирә юк... Мәңгегә юк... Зәнфирә китте... Юк, болай була алмый, бу мөмкин түгел! Алар бит ничә еллар бергә йөрделәр, бер парта артында утырдылар. Ирекнең тамагына кайнар төер килеп тыгылды, күзенә яшь тулды. Юк, ул Зәнфирәгә тузан кадәр дә ачулана алмады. Кызганды гына. Нишләп болай булды соң бу? Кем гаепле? Аның Зәнфирәне гаепләрлек бер генә дәлиле дә юк иде. Ирек күп мәртәбәләр аны рәнҗетте, хәтерен калдырды. Әйе, барысына да ул гаепле. «Мин шундый әшәке кеше микәнни?» дип уйлады ул ачыргаланып. Ләкин бит Зәнфирәнең хәтерен калдыруларга Ирек кенә сәбәпче түгел. Аның үзен дә тормыш мамык урынына очырып йөртмимени? Нишләргә? Шушының белән барысы да бетәмени? Юк, болай кырт киселә алмый, нидер эшләргә кирәк. Шул вакыт ул, арба тавышы ишетеп, унга борылып карады. Сабирҗан абзый, чапкан печәннәрен салып, аның янына килә иде.

—Юл буенда утырма, үскәнем,—диде ул арбасыннан төшеп.

Ирекнең чемоданын күтәреп, печән өстенә җайлап куйды да:

—Әйдә, мен арбага, чемоданың да бик авыр, алай кире бөкләгәч, райкомга илтеп куям,—диде.

Ирек, аңа рәхмәт тә әйтмичә, хәтта йөзенә дә күтәрелеп карамыйча, акрын гына шуышып, арбадагы яшел печән өстенә утырды. Ат район үзәгенә таба юыртып китте. Ләкин, ул теркелдәп атлаган саен, әйтерсең лә Ирекнең йөрәгендәге иң нечкә тамыры тартыша, сузыла башлады.

—Сабирҗан абзый,—диде ул әкрен генә.—Авылга... авылга кайтыйк...

Сабирҗан атны бераз тыйды да, юлдан чыгып, янә авыл ягына борылды.

Бәлкем аларның өйләренә барып кереп тезләнергә, икесеннән дә гафу үтенергәдер? Бәлкем Заһит абый аңлар? Ирек белән Зәнфирә барыбер бер-берсеннән башка яши алмаячаклар, мәңге газапланачаклар бит. Арба әкрен генә барды да барды, күз алдында чәчәкле болын артка шуышты да шуышты. Ирек әле үзе моңа кадәр уйламаган тагын бер сорау алдында туктап калды. Ничек соң әле алар өйләнешә алганнар? Ирек тә, Зәнфирә дә—Заһит абыйның укучылары, ләбаса. Заһит Фәхруллин әнисенең бер малае иде, чибәр дә түгел, ямьсез дә түгел, сәләтле дә түгел, акылсыз да түгел. Әнисе үлгәнгә хәзер биш-алты ел, ә ул һаман өйләнмәде, карт буйдак булып яши бирде. Абзар-курасын ныгытты, өр-яңа мунча салды, машина алды, гараж төзеп куйды. Әмма беркайчан да аның кызлар озатканын, кызларга сүз катканын авылда берәү дә белми иде. Зәнфирә белән аларның арасында нинди уртаклык булырга мөмкин? Ничек ул Зәнфирәгә тормыш кору турында тәкъдим ясарга мөмкин? Бу сорауларга җавап юк иде. Хәер, Ирек өчен аларга җавап табу кирәк тә түгел иде инде. Аның өчен икенчесе мөһимрәк: ничек кабат Зәнфирәне үзенеке итәргә? Моның өчен Зәнфирәнең аны теләве кирәк, бары тик шуннан соң гына мәсьәләнең калган өлешен хәл итеп булачак...

Ирек Сабирҗан арбасыннан төшеп калды да өйләренә керде, әти-әнисе белән күреште, алар белән утырып, ризык капкалады. Ихаталарны карагач, бакчаларны әйләнгәч, ул кабат өйгә керде. Ләкин ни генә эшләсә дә, җанына урын таба алмады, йөрәгенең януына түзәр чама юк иде. Моны әтисе белән әнисе дә күреп тордылар. Баласының күзендәге нурсызлыкны, йөзендәге сагышны, килеш-кыяфәтендәге төшенкелекне ата-ана күнеле ничек сизмәсен соң?! Тик алар аңа бер сүз дә әйтергә, юатырга кыймадылар. Синең тәнеңдәге яраны сыпырып карасыннар әле, рәхәт булырмы ул? Йөрәктәге яра бигрәк тә шулай. Ахырда Ирек түзмәде, урамга чыгып китте, капка төбендә бер максатсыз басып карап торды. Аннары аяклары аны медпунктка таба алып киттеләр. Ул барып кергәндә, медпунктта Зәнфирә белән Хәлимә икәү иделәр. Зәнфирә Ирекне күрү белән каушап төште һәм дарулар шкафыннан нидер эзләгән булып йөзен яшерде.

—Исәнмесез,—диде Ирек, көч-хәл белән телен әйләндереп.

Зәнфирә ана таба борылмады да.

—Әйдә, Ирек, түрдән уз,—диде Хәлимә.

Ирек кузгалмады. Хәлимә аларның хәлен бик яхшы аңлады. Ул ашыга-кабалана чыгып китте. Зәнфирә һаман шылтыр-шылтыр ниләрдер актаргандай итте. Ирек аның ак халаты эченә кереп киткән кара толымнарын, үзе биргән алкаларны таккан колакларын, һәрвакыт күләргә торучы иреннәрен, калку күкрәкләрен—бөтенесен-бөтенесен, беренче мәртәбә күргәндәй, күзеннән кичерде. Бу бик кадерле, беркем белән дә алыштырмаслык асыл зат хәзер инде аныкы түгел иде.

—Зәнфирә...—аның тавышы әллә каян янып-көеп чыкты.—Син... без... син нишләдең?!

Зәнфирә башын аңа таба борды. Аның күзләренә яшь тулган, иреннәре елап җибәрүдән чак тыелып тора иде. Ул шул хәлендә, бер сүз әйтә алмыйча, Ireккә карады да катты. Ирек ана таба бер адым атлады, Зәнфирә курыккандай артка чигенде.

—Аңлыйсыңмы, син нишләдең?!

Зәнфирәнең ике битеннән күз яшьләре тәгәрәп төште һәм ул ишетелер-ишетелмәс кенә итеп:

—Язмыш, Ирек...—диде.

Аннары, үзен кулга алып, юынгычка барды, битен юды, сөлге белән сөртенде.

—Нинди язмыш?! Ни сөйлисең син?! Язмыш юк ул! Язмыш менә синең белән мин ул! Без ничек телибез—шулай була.

—Юк, Ирек, язмыш бар ул!—Зәнфирә кульяулыгы белән күзләрен, борынын сөртте, берничә мәртәбә тирән итеп сулыш алды.—Синең тормыш югарыда... Мин моны син авылда чакта ук сизенә башлаган идем. Сине олы әйберләр кызыктыра, кеше акылы җитмәстәй нәрсәләр...

Ирек аның сүзен бүлдерде:

—Син бит акланырга сәбәп эзлисең, Зәнфирә! Кирәкми, акланма! Минем сине гаепләргә җыенганым юк. Гаеп миндә. Тик ул гаеп безнең синең белән ике арадагы уртак нәрсәләр белән чагыштырганда юк. Аңлыйсыңмы, юк! Син моның шулай икәнлеген үзең дә беләсең.

Зәнфирә кызарган күзләре белән аңа соңгы мәртәбә карагандай карады.

—Кемнедер гаепләргә теләсәм, язмыш дип авыз ачар идеммени? Ышан миңа...

—Мин сиңа ышанам, Зәнфирә,—диде Ирек.—Тик үтерсәң дә, язмышка ышанмыйм мин.

Сүз шунда өзелде. Алар тып-тын басып тордылар, бер-берсен соңгы мәртәбә күреп калыйм дигәндәй күзәттеләр, әмма карашлары очрашмады. Зәнфирә кинәт, үпкәләгәндәй, тәрәзәгә борылды да:

—Син Казаннан кош теле кадәр бер хат язып салсаң да, мин әле көтә идем...

—Ничек инде?!—дип кычкырып җибәрде Ирек аптырап.—Барган көнне үк аңлатып хат салдым бит!

—Син алдыйсың, Ирек...

—Алдамыйм! Әйдә, элемтә бүлегенә барыйк, шунда ятадыр. Салдым мин сиңа хат!

—Ярар, салсаң. Рәхмәт.

—Зәнфирә, әле соң түгел...

—Соң инде, Ирек.—Зәнфирә, өстәл астына үрелеп, кәгазь төргәк чыгарды.—Мә туган көн бүләгеңне. Заһит абый аны миңа өч көн үткәч кертеп бирде. Бу кадәр кыйммәтле әйберне ала алмыйм мин...

Ирек ул сузган төргәкне кире этте:

—Юк, син аны аласың!—диде кызып.

—Юк, Ирек, алмыйм.

—Алмыйсыңмы?!—Ирек кычкырып җибәрде.—Ярар алмасаң. Син минем бүген җансыз гәүдәмне күрерсең!

Ул, кырт борылып, ишеккә атлады. Зәнфирәнең ялварулы тавышы аны туктарга мәҗбүр итте:

—Ирек, тукта! Алам мин аны. Син бит аны чын күңелдән биргәнсең...

Ирек, ничектер сәер елмаеп, аның каршысына килде, пышылдап диярлек түбәндәге сүзләрне әйтте:

—Бу безнең яшьлегебез төсе булсын. Үзе ак, үзе саф. Әгәр ул синең тәнеңне җылытып тора икән, минем дә җаным тыныч булыр...

Кинәт Зәнфирә, кычкырып елап, аның муеныннан кочып алды, яшьле яңакларын аның яңакларына ышкыды. Аннары кинәт читкә китте.

—Бар инде, Ирек, хуш!..—диде, күз яшьләрен сөртеп.

—Зәнфирә! Әле бит барысын да төзәтеп була.

—Юк, Ирек, язмыштан узмыш юк. Никадәр сузсак, шул кадәр авыр булачак безнең аерылышу. Без икебез ике тормыш кешеләре. Мин синең юлыңа киртә булырга теләмим...

—Ялгышасың, Зәнфирә!..

Ишек артында аяк тавышлары ишетелде. Хәлимә ачкан ишектән Ирек чыгып китте. Баскычтан төшкәч, ул үзенең кайда басып торганын аңышмады. Тормыш юллары белән бергә урамнар да буталган иде, ахрысы...

## 14

—Исән-сау кайтуың белән, Сабитов. Тагын бер семестрны төгәлләвең белән котлыйм!

Икенче көнне иртән Иреккне Шәвәлиев үзенең кабинетында әнә шулай каршылады.

—Рәхмәт, Зөфәр Шәрипович,—диде Ирек, аның кулын кысып.

—Агарып киткәнсең, әллә бик авыр булдымы?

—Җиңел түгел инде.

—Без синең кайтуны дүрт күз белән көттек. Котлыйм әле мин сине,—ул тагын Ирекнең кулын кысты.

—Нәрсә өчен?

—Китабың миңа да, Миңзаһит Усмановичка да ошады. Нәшриятның да фикере әйбәт.

Бу сүзләрне ишетүе Ирекқә чиксез рәхәт иде. Язмасын ике секретарьның өстәленә салып китте, укуга баш-аягы белән чумды һәм шуның белән онытты. Димәк, бөтен мәшәкатьләр артта калды. Ул җиңел сулап куйды. Шәвәлиев уйга баткан хәлдә ишек янынннан ук урап килде дә Ирекнең каршысына тукталды:

—Ә ник дүрт күз белән көткәнне беләсеңме син?

Ирек, утырган җиреннән башын күтәреп, аңа каш астыннан сораулы караш ташлады:

—Нәрсәгә?—диде ул сак кына.

—Редактор китә безнең.

—Кая?

—Киткән кеше урынын табар. Менә райком бюросы сиңа ышаныч күрсәтә, Ирек Хәйриевич.

—Нәрсәгә?

—Редакторлыкка.

Ирек ялт итеп тагын Шәвәлиевкә карады һәм, үзе дә сизмәстән, акрын гына урыныннан күтәрелде.

—Сез нәрсә, Зөфәр Шәрипович?! Мин андый зур эшкә алына алмыйм! Мин яшь, тәҗрибәсез.

—Райком секретаре итеп куйганда, әллә син мине карт иде дип беләсеңме? Эшләсәң, яшь чакта эшләп каласың инде аны.

Аның соңгы сүзләре Ирекқә нәрсәнедер хәтеренә төшерде. Тукта, кем әйткән иде соң әле бу сүзләрне? Ә, кайсыдыр семинардан соң бер

язучы әйтте: «Әгәр сезнең талантыгыз булмаса, мин сезнең белән сөйләшеп вакыт та үткәреп утырмас идем,—диде. Образлы фикерли беләсез, чын халыкчан телегез бар, сезгә Ходай үзе кушкан язарга. Барлык эшләрегезне ташлагыз да языгыз! Эшләсәң, яшь чакта эшләп каласың.» Юк, тота алмады ул язучының сүзләрен Ирек.

—Ну, нәрсә, Сабитов?

—Юк, Зөфәр Шәрипович. Мин редактор булсам, мәнге яза алмаячакмын.

—Ничек инде редакциядә эшләп язмаска?!

—Минем башлаган повестем, пьесаларым ята. Аларга инде тузан кунып бетте.

—Әллә син редактор эшен бездәгедән дә тынгысызрак дип уйлыйсынмы? Рәхәтләнеп эшләү, иҗат итү өчен мөмкинлекләр нәкъ менә редакциядә инде ул. Син бит беләсең, күпчелек язучылар каләмнәрен газетада чарлаганнар.

Шәвәлиевнең үзенең дә Ирек Сабитовны һич тә кулыннан ычкындырасы килми иде. Нәрсә кушсаң да ризалаша һәм башкарып чыга торган мондый күндәм кадр янадан табылырмы? Ләкин Арсланов редакторлыкка Сабитов кандидатурасыннан тамчы да чигенергә уйламады. «Кайту белән аны ризалату сина йөкләнә,—диде ул Шәвәлиевкә,—кара аны, минемчә булсын.»

—Сез бит мине бөтенләй аңларга теләмисез,—диде Ирек.—Әле укуым бетмәгән, дәүләт имтиханнарына да күп калмый, әти-әниләр дә ялгыз.

—Син, Сабитов, әти-әни турында сөйләмә әле, алар минеке дә авылда, үзләре генә яшиләр. Кесәдә партия билеты йөрткәч, без инде алар кешесе түгел. Синең әтиең үзе дә гомер буе партия солдаты булды, ул сине аңлар.

—Нишләтсәгез дә, булдыра алмыйм, Зөфәр Шәрипович. Икенче кеше табыгыз.

Шәвәлиев Сабитовны, беренчедән, үзенең кул астында калдырасы килсә, икенчедән, редактор итүдән курка да иде. Чөнки ул артык гадел, туры кеше. Шәвәлиев аның әтисен бик яхшы белә. Ул, кемнең кем икәнен чамалап тормыйча, утлы табага бастыра иде...

—Минем белән уртак тел таба алмагач, Миңзаһит Усмановичның үзенә керәсең инде,—диде Шәвәлиев, авыр сулап.

Ирек янган мичкә кергәндәй, Беренче бүлмәсенә атлады.

—Утырыгыз, Сабитов,—диде Арсланов.—Зөфәр Шәриповичта булдыгызмы соң?

—Әйе. Миңа шундый ышаныч күрсәтүегез өчен рәхмәт. Тик минем... көчемнән килми ул эш...

—Ә каян беләсез?

—Мин ул мәгънәдә түгел. Язып бетерәсе повестем бар. Яңа пьесамны театр алмакчы. Хәзер шуны кабат эшләргә кирәк.

—Мин сине аңладым, Сабитов,—диде Беренче, ирennәренә сизелер-сизелмәс кенә елмаю билгеләре чыгарып.—Партия кушканы сиңа ошамый, ә менә үзең теләгәне ошый. Шулаймы?

—Алай каршы куярга кирәкмидер,—диде Ирек, ничектер кыенсынып.

—Ә ничек куярга соң? Әгәр барлык коммунистлар партия кушканнан баш тарта башласалар? Ни булыр иде, ә?

Ирек бирешергә теләмәде:

—Ләкин бит коммунист үзе иң зур файда китерә ала торган эшне башкарырга тиеш.

—Молодец, дөрес әйттең.—Арсланов көлеп куйды.—Син менә, район газетасы редакторы буларак, безнең партоешмага зур файда китерәчәксең. Ә повестьларыңны, пьесаларыңны яз, талант үсәргә тиеш. Бусы да безнең бурыч. Без сине анда-монда тарткаламабыз. Йә, килештекме?—Арсланов аңа кулын сузды.

Ирек, торып, аның кулыннан курыккандай, бераз чигенеп куйды.

—Ашыктырмасагыз иде, Минзаһит Усманович. Өйдә дә киңәштабыш итәсе бар.

—Соң, киңәшегез. Бүген үк кайтып китегез. Иртәгә кичкә җавап бирсәгез ярый.

Беренче бүлмәсеннән чыгу белән Ирек абыйсы белән телефон аша хәбәрләшеп, бүген авылда очрашыйк әле, диде.

Кич авылга абыйсыннан алдарак кайтса да, аннан башка ул яңа эшкә күчү хакында сүз кузгатмады. Караңгы төшкәндә, абыйсының матае капка төбенә килеп туктады. Ирек, ындыр коймасының җепсәсен алыштырып, балта-пычкыларын тоткан килеш, төшеп килә иде. Алар, күрешкәч, өйгә кереп табын янына утырдылар. Әниләре аш бүлеп китерде.

—Йә, ни бар?—диде Мэлс.—Мин ярты сәгатьтән артык тора алмыйм.

Әтисе белән әнисе, аптырашып, балаларына карадылар.

—Сездән киңәш сорарга кайттым,—диде Ирек.—Мине редакторлыкка кодалыйлар.

Өчесе дә, ашауларыннан туктап, Ирекkә карадылар. Мэлс тамак кырып куйды:

—Ни дидең соң?

—Риза булмадым.

Әтисе, күзләрен хәтәр уйнатып:

—Ничек инде риза булмадың?!—дип дөртләп кабынды.—Райком куша икән, ничек син?..

—Тукта әле, әти, кызма,—дип бүлдерде аны Мэлс.

—Кызмыйча ни... Партия куша икән—закон!

—Синең, әти, шул партия дип, райком дип, гомерең үтте инде. Ә ул башыңа менеп кәкәй итте,—диде Мэлс.

—Син партиягә тел тидермә, молокосос!

—Ярар инде,—диде Мэлс, алдындагы аш савытын этеп куеп.—Әйтеп бетерсәм, тагын кызып китәрсең.

Ул ишек алдына чыгып китте. Ирек, ашын капкалап бетерер-бетермәс, абыйсы китеп бармагае дип, аның артыннан ашыкты. Мэлс капка төбендәге эскәмиядә утыра иде.

—Нишлим икән соң инде, абый?—диде Ирек.

—Минем фикер шул: сиңа редакторлыкка да риза булмаска, райкомнан да ычкынырга кирәк. Әгәр башка эш тапмасаң, үземә килерсең.

—Әйтергә ансат та ул. Алай кинәт кенә сындырырга...

—Әгәр хәзер сындыра алмасаң, соң булачак. Аннары инде синең үзеңне сындырачаклар. Беләсеңме, ул райком тирәсендә эшләүче кешеләр теплицадагы үсемлекләр кебек: җил дә, салкын да тими, кышын да, җәен дә. Ә менә тышка күчереп утырткач, күпләре җилдән, кояштан, салкыннан куырылырга, корырга мөмкин. Шуңа күрә ул теплицага бер килеп эләккән кеше кабат чыгудан курка да инде.

—Нәрсә, мине дә шунда димәкче буласыңмыни?

—Соң, шунда булгач, кайда диим? Кабатлап әйтәм, энекәш: исән-имин чакта чык син аннан. Тышта үскән үсемлек чырышрак та, аның җимешләре дә тәмлерәк була. Килешәсеңме минем белән?

—Килешәм,—диде Ирек.—Редакторлыкка мин риза булмаячакмын. Тик иртәгә үк райкомнан да китә алмыйм.

—Ник?

—Авылга юл бикле миңа...—Бераз сүзсез торгач, ул өстәп куйды:—Зәнфирә кияүгә чыкканнан соң...

—Аңлыйм: авыр инде сиңа...

—Ашыкмыйк әле, абый. Уйлап бетерергә кирәк. Миңа бит әле квартира да вәгъдә итеп торалар.

—Монысы җитди мәсьәлә!—диде Мэлс, җанланып.—Әгәр килсәң, квартира миндә дә юк. Бездә торуын торырсың. Тик Нәфисә белән безнең анда көн саен барган гражданнар сугышы синең күңеленә ятмас.

Алар кереп чәй эчтеләр дә, абыйсы «Нива»га утырып, совхозына

китте. Ирек, Зәнфирәле авылда Зәнфирәсез урамга чыгарга кыймыйча, верандага кереп ятты...

Иртәгәсен алар тагын Шәвәлиев бүлмәсендә очраштылар.

—Мин бар ягын да үлчәп карадым, Зөфәр Шәрипович,—диде Ирек.— Ничек кенә исәпләсәң дә, мин бу эшкә алына алмыйм икән.

Шәвәлиевнең күзләрендә усал очкыннар кабынды, кашлары җыерылды.

—Ярар алайса,—диде ул ниндидер астыртын, шомлы тавыш белән.— Без дә кинәштек. Әйдә, иҗат белән шөгыльлән. Квартира турында оныт. Бу бинада сиңа андый вәгъдә бирүче булмады дип сана.

—Ә минем гаебем нәрсәдә соң? Төрмәдән кайткан кешегә дә квартира бирәләр.

—Коммунистның гаебе гади кешеләргә күренмәскә дә мөмкин. Безнең эш-гамәлләребез иң югары критерийлардан чыгып хөкем ителә. Чөнки без югары кануннар белән яши торган кешеләр.—Шәвәлиев, нәрсәдәндер җирәнгәндәй, чыраен сытып, өстәленә карап торды. Аннан соң, башын күтәреп, Ирекка карады.—Тагын бер мәртәбә уйлап кара, син бит акыллы егет. Төштән соң сәгать бердә миңа керерсең. Шуңа кадәр Минзаһит Усманович әле менә хәзер биргән җавабыңны белмәячәк. Һәммәсе дә үз кулыңда.

Ирек аның яныннан сүзсез генә чыгып китте.

Инде уйланасы уйланган, карар кабул ителгән иде бит. Алай ансат кына түгел икән шул. Ахырда Ирек иң мөһиме квартира дигән нәтиҗәгә килде. Аны алу өчен редактор булырга кирәк. Квартираны алгач, редакторлыктан китәргә була. Менә шушы бер караганда бик гади, ә тормышка ашыра башлагач, гаҗәеп катлаулы схеманы чынга әйләндерү зарур иде. Үзенең бөтен барлыгына каршы килеп, ул хәйлә корды: хәзер риза булырга, квартира алырга, аннары ул эштән китәргә дә колач җәеп иҗат итәргә. Ул вакытта университетта укуы да бетәчәк. Бер-ике ел язмаганнан берни дә булмас. Ә болай баш өстендә үз түбәсе булмаган килеш эт типкесендә йөреп, ул, гомумән, кешелектән дә чыгарга мөмкин.

Нәкъ сәгать бердә ул тагын Шәвәлиев бүлмәсенә кереп, ризалыгын бирде...

—Алайса, сиңа Сабитов, иртәгә өлкә комитетына расланырга китәргә кирәк,—диде Шәвәлиев.—Беренче рейс белән. Хәзер үк шәхси анкетаңны тутыр. Тик беркемгә дә ник, кая барганыңны әйтмә.

## 15

Ирек, самолеттан төшкәч тә, үзе белән бер курста укучы Әхмәткә шылтыратты. Ләкин ул редакциядә туры килмәде, бер атнага иҗади ял алды, диделәр. Әхмәт өлкә комитетыннан ерак түгел Галактионов урамындагы череп беткән агач йортның бер бүлмәсендә хатыны, ике яшьлек малае һәм әбисе белән яшәп ята иде. Ирек уртада ике-өч аратасы кайчандыр янып күмерләнгән, кыеш-мыеш килүче баскычтан икенче катка күтәрелде. Ишек янагында тырпаеп торган ике бакыр чыбыкның очын-очка тигереп алуга, ишек ачылып китте һәм Ирек, куркудан, чак кына аска мәтәлмәде: Әхмәтнең ярты башы пәке белән кырылган, икенче ягындагы җирән чәчләре һәм күптән пәке тимәгән сакал-мыеклары хәтәр өрпелгән, авыз читендәге чуар мөштүге дәһшәтле тәтенли иде... Ул кайчандыр зәңгәр төстә булган майкасының корсак турындагы тишеген кулы белән каплады да шаркылдап көлеп җибәрде:

—Курыкма, мин бу, әйдә уз!—Әхмәт аны эчкә сөйрәп алды.— Поэма язам, дустым. Урамга чыкмас өчен, беркем белән аралашмас өчен шулай кыландырдым бу башны.

Бүлмәдә өстәл генә түгел, иске диван белән тимер карават та язылган кәгазь битләре белән тулган иде.

—Гениальный поэма булачак!—диде Әхмәт, бер уч кәгазьне кулына алып селки-селки.—Хатыннар кайтканчы, шушылай рәхәтләнеп калам, малай.

Аның очкынланган күзләрен, илаһи нур белән балкучы йөзен күреп, Ирек көнләшеп куйды.

—Әйдә, уз инде, хәзер чәй куеп җибәрәм.

—Рәхмәт, мәшәкатьләнмә. Мин өлкә комитетына ашыгам.

—Анда сиңа ни калган?

—Редактор итеп расланырга җибәрделәр.

Ирек аңа ничек итеп бу эшкә кысуларын, ни сәбәпле ризалашуын сөйләп бирде.

—Квартирасыз яшәү дә үлем белән бер инде ул,—диде Әхмәт авыр сулап.—Күреп торасың бит менә...

—Үзем самолетта очам, ә күңелем туктаусыз елый... Ризалык биреп ялгыштым бугай мин, Әхмәт. Хәзер өлкә комитетына кермичә борылып кайтсам, баш бетте.

—Синең расланасың килми алайса?

—Әйе.

Әхмәт аскы иренен тешләп уйга батты. Бераздан кинәт кычкырып җибәрде:

—Юлын таптым!

—Ничек?

—Күтле-киреле сүз сөйлә дә тор. Ахмак булып кылана алсаң, бигрәк тә әйбәт.

—Аны булдырырга кирәк бит әле.

—Пьеса язган башың белән шуны да эшләмәгәч! Анда кергән кеше куянга әйләнә. Алар шуңа күнеккән. Ә син бүре кебек сыртыңны кабарт. Менә мин әйтте диярсең, валлаһи, борып кайтарачаклар!

... Өлкә комитетының зур авыр ишеген ачып эчкә үтүгә, Ирекне тартмалап алынган урында торучы милиционер туктатты, кемгә керүен сорады. Матбугат секторына икәнлеген әйткәч, партия билетын җентекләп карады, ничәнче катка күтәрелергә, кайсы бүлмәгә керергә икәнен өйрәтте. Ирек, шәхси делосын алып, плащы белән дипломатын кием элү урынында калдыргач, затлы келәмнәргә тавышсыз гына басып, югары күтәрелде.

Матбугат секторы мөдире уртачадан калкурак гәүдәле, бик җитди чырайлы кеше булып чыкты. Ирек, үзенең кайдан килгәнен, кем икәнлеген әйткәч, шәхси делосын бирде.

—Утырыгыз,—диде мөдир, аның керүен өнәмәгән кебегрәк итеп.

Ул шундук делоны актарырга һәм сораулар бирергә кереште:

—Газетага язасызмы?

—Язгалап торам болай.

—Кайсылай—«болай»?

—Үземә күрә диюем.

—Ничек соң ул үзегезгә күрә?

—Дөнья кубарырлык әйбер язган юк әлегә.

—Әлегә юк... Ә киләчәктә?

—Киләчәктә исәп бар,—диде Ирек, аның һич югы бер генә мәртәбә күтәрелеп карамавына һәм үртәгәндәй һәр сүзгә бәйләнүенә ачуы кабарып.

—Ни язмакчы буласыз инде сез киләчәктә?

—Мин яңа Коръән язарга ниятлим.

Мөдир, ток суккандай, башын күтәрде.

—Коръән?!

—Әйе, үзе әдәби әсәр, үзе Коръән.

Ирек, юри күкрәгән киереп, йөзенә горур кыяфәт чыгарды.

—Без бер Коръәнне ничә еллар көрәшеп юк итә алмыйбыз, сез яңасын язасызмыни?!—диде мөдир, аның делосын читкә этеп.

Ирекկә шул гына кирәк иде. Повестенда үтәли җил кебек сиздермичә генә уздыра торган фикерләрен ул ачыктан-ачык тезәргә кереште:

—Дөньяның болай бара алмаганы ачык бит. Кешелекнең уен бүтән якка борырга кирәк. Шунсыз җир йөзендә үсеш булмаячак.

Сектор мөдире, ни сөйли бу авыл гыйбаты, дигәндәй, гаҗәпләнеп, Иреккә шактый вакыт карап торды.

—Кайсы якка бормакчы инде сез дөньяны?

—Кешенең үз-үзенә иман китерүенә. Безнең эрага кадәр үк адәм баласын нәрсәләр белән генә куркытмаганнар, ничекләр генә тыймаганнар! Ә ул тамчы да яхшыга үзгәрмәгән, гөнаһ арты гөнаһ кына. Чөнки читтән ана берни дә керми.

—Социализм идеясе читтән кермәгәнмени?

—Юк! Тигезлеккә омтылыш барлык тереклекнең җанына салынган, шуңа күрә ул үлемсез. Юлбашчылар аны калкытып күрсәттеләр генә.

—Кызык сезнең фикерләрегез. Кеше берни дә үтеп керә алмый торган крепость икән, партиянең идеология эше дә бер гасыр буе юкка көчәнү генә булган алайса.

—Анысы кирәк. Мин бит кеше тын кермәслек савытка бикләнгән зат, димәдем. Адәм баласының рухын үтермәс өчен туендырып торырга кирәк. Җир шарындагы кешеләрнең туксан тугыз проценты бөтен гомерен йоклап үткәрә, шул килеш үлеп китә. Үзенә нинди кодрәт салынганлыгын ул хәтта белми дә кала.

—Сезнең Коръәнегезне аңлап бетермәдем әле мин. Нинди булачак ул? Хәзерге Коръәнне кире кагу рәвешендәме, әллә...

—Нигә аны кире кагарга? Кирәкми. Мин гади җир кешесе ич. Бусы дөньяви Коръән булачак. Аның нигезендә кешенең үзенең эчке галәменә кертү ята. Шуңа керү аша гына адәм баласы үз-үзен кулында тота алачак.

—Кем кертә инде аны?

—Яңа Коръән, яңа пәйгамбәрләр. Кешенең күңел галәмендә аркылысын-буен айкап, кешегә бөек мәгънә эзләнергә һәм табышырга кирәк.

—Нинди мәгънә?

—Мәгънә бер генә: башкаларга игелек. Кеше үзенә буйсынырга, үз кодрәтенә таянырга тиеш. Ә ул кодрәт һәркемгә артыгы белән бирелгән. Тик файдаланылмый гына...

—Сез, райком инструкторы була торып, ничек мондый фикерләргә килә алдыгыз соң?

—Алар ничектер үзләреннән-үзләре иңә миңа. Гел көтмәгәндә югарыдан әйтәләр. Күктән иңгән вәхи сыман...

Соңгысын Ирек арттырып җибәрде җибәрүен. Күңеле мөдирне ярсытырга кымырҗып торганлыктан, шулай килеп чыкты. Сектор мөдиренең чырае тәмам төс ташлаган иде инде. Ул дело өстенә шапылдатып учы белән сукты да:

—Булды, аңлашылды!—диде һәм телефон трубкасын алды.—Миңа Болынкыр кирәк. Беренчене тоташтырыгыз әле. Ул чакта икенче секретарьны. Шәвәлиев? Исәнме. Слушай, нинди икенче Мөхәммәтне җибәрдең син миңа?—Күрәсең, Шәвәлиев берни дә аңламый иде, ул тагын кабатларга мәҗбүр булды:—Редактор итеп нинди икенче Мөхәммәт пәйгамбәрне җибәрдең, дим?! Шул инде. Яңа Коръән язам дип тора ул монда!

Кинәт Ирек, янәшәсендә кемдер басып торганны сизеп, борылып карады. Ул кайчан кергән булгандыр, Ирек ишек ачылганын да ишетмәде югыйсә. Сорырак төстәге костюм-чалбар кигән, шундый ук галстук таккан, тыныч карашлы, киң маңгайлы бу кеше, Ирекнең борылуын күреп, итәгатьле генә итеп башын иде. Ирек урыныннан тормакчы булды, ләкин ул, кулы белән ишарәләп, аңа кузгалмаска кушты. Мөдир, аларга карамыйча, Шәвәлиевне кыздыра иде:

—Слушай, кадрлар сайлаганда, игътибарлырак булыгыз әле. Без аны раслый алмыйбыз! Шабаш!

Шул сүзләрне әйтеп, мөдир бу якка борылды һәм, әлеге кешене күреп, чөйкәлеп китте.

—Гафу итегез, Мидхәт Мансурович,—диде ул, ашыга-кабалана галстугын рәтләп.

Ирек керүченең өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире икәнлеген аңлаган иде инде.

—Нәрсә булды?—диде ул, тыныч кына.

—Менә Болынкырдан безгә «пәйгамбәр» җибәргәннәр. Үзе университетта читтән торып укый. Хәзер үк проректорны чакыртам, мондый кешеләр ничек безнең совет уку йортында белем алалар?

—Юньләп кенә аңлатыгыз әле.

—Булачак редактор бу. Күктән иңгәннәрне Коръән итеп язам, ди.

—Язам,—диде Ирек горур тавыш белән.

Әллә инде аның шулай әйтүе мәзәк чыкты, алар икесе дә көлеп җибәрделәр. Ирек кызарып басып торды.

—Фамилиягез ничек?

—Сабитов.

—Әйдәгез, мина керик әле, Сабитов. Бирегез аның кәгазьләрен.

Ирек шәхси делосын кулына алды да Мидхәт Мансуровичка иярде.

—Мин дә керимме?

—Кирәкми. Тик проректорны чакыртырга ашыкмый торыгыз.

Аның бүлмәсенә кереп, өстәл артына утыргач, Мидхәт Мансурович, делоны ачып:

—Исемегез бик матур икән,—дип куйды.—Ирек туган, мин дә сезнең кебек авыл кешесе, минем дә сезнең кебек яшь чагым, әллә ниләр белән хыялланып йөргән вакытларым бар иде. Минем чыннан да беләсем килә: нинди Коръән турында сүз бара соң? Тик, зинһар, бу кеше сорау ала икән дип уйламагыз.

Ирекнең усаллашу, үртәшү теләге каядыр юкка чыкты, күңеленең иң яшерен серләрен шушы бөтенләй таныш түгел кешегә чишәсе килде аның. Шуңа күрә бая матбугат секторында булган сөйләшүне ул төкмичәчми Мидхәт Мансуровичка җиткерде. Ул, аны күзен дә йоммыйча тыңлап утыргач:

—Фикерләрегез кызык,—диде.—Әмма кешене үз эчендәге галәменә алып кереп булырмы икән? Аны бит әле тормыштагы юлыннан кире борасы бар.

—Иң хәтәре шулдыр да. Безнең авылда көтүне чиратлашып көтеш. Мина да еш чыгарга туры килә. Сыерның авызы басудагы игенгә тисен генә... Күпме ярсаң да, чыгара алмыйсың. Китереп суккач, башын күтәрә, кугач, кирегә атлый кебек, син китүгә—ул инде борылган, кабат шул урында. Авыртуны да, куркуны да белми. Мин моны шуңа әйтәм. Социализмның тигезләү идеясе гениаль идея бит. Шуны юкка чыгаручы икенче максатны куясы булмаган.

—Нинди максат?

—Муллык. Байлык.

—Һе. Алай икән. Элеккечә, бетле, чабаталы, керосин лампалы тормышта яшәргә идемени?

—Әнә шул тигезләү дигәне бик җиткән булгандыр. Ә без коммунизм дип кычкырдык. Җаның күпме тели—һәммәсе дә була. Менә хәзер халыкны кирегә борып кара! Әгәр минем кодрәтемдә булса, Җир йөзенә бер генә чакыру ташлар идем: Адәм балаларын, аларның җанын, канын суыручы әйбер дигән гыйфриттән аерып алыйк!

—Әйбер кислород кебек секунд саен кирәк шул!

—Хак әйтәсез. Әмма бирәү дә кирәк дип һава запасы тупламый.

—Ул бит җитешле. Ә әйбергә халыкның ихтыяҗын ничек канәгатьләндерергә?

Ирек үзенең өлкә комитетында икәнлеген дә онытып, илһамланып китте.

—Ул проблеманы чишүнең дә юлын табып була, Мидхәт Мансурович,—диде ул, урыныннан ук торып.—Иң элек азык-төлекнен дә, кием-

салымның да, йорт-жирнең дә, башкасының да төрләрен чикләргә! Бөтен кешелек якынча бер төрле ашый, бер төсле киенә, бер төсле көнкүреш шартларында яши.

—Алай бик күнелсез булмасмы соң?

—Хәзер күнелсез! Әйберләр миллион төрле, кеше үзе генә бер төрле. Һәркөн бозылган, черегән, искергән әйбер таулары күтәрелә. Бирәнлектән чир өстенә чир өелә. Киресенчә кирәк: әйберләр бертөрле, ә кеше күптөрле. Аның эчке дөньясы—хис-кичерешләре, белеме, карашлары, омтылышлары—үсәргә, миллион төсмерләрдә камилләшергә тиеш. Шулчакта адәм балалары матурлыкны һәм мәгънәне бер-берсенең күнеленнән эзләячәкләр, ул бернинди алтын-көмешләргә, асылташларга да алыштыргысыз бәһасез мәңгелек кыйммәткә әвереләчәк. Дуслык, мәхәббәт, гаилә кору да шуна нигезләнәчәк.

Ирек, үзенең артык кызып китүен сизеп, кинәт туктап калды, урынына утырды.

—Бик күп вакытыгызны алуым өчен кичерегез. Сезгә ышанганга гына сөйләдем...

—Бу безнең көндәлек эшебез. Дәвам итегез. Мин бит күреп торам: сезнең нидер әйтәсегез калды әле.

—Анысын әйтергә дә була, әйтмәскә дә була. Кешелек тарихының бүгенге көнгә кадәрге өлеше—ул әйбер дип котыру гына. Шуның аркасында кеше Җирне дә, үзен дә һәлакәткә илтә. Бу—Галәм киңлекләрендәге миллион еллар эчендә булган фаҗигаларның иң коточкычы! Әгәр бәндәләр, әйбер дигән гыйфриттән котылып, яңа цивилизациягә таба атласалар, кеше затының әйбер дип гомерен юкка яндырган эпохаларны тетрәнеп искә алачаклар һәм аннан соңгы буыннарның яшәеше генә чын-чынлап югары мәгънәле, бәхетле булачак! Тик аңа таба ясаласы борылышның бер генә миллиметр эзе дә күренми, кешелек, Җир-әнкәсенең бугазына тешләрен батырган килеш, үлем упкынына очуын дәвам итә...

Мидхәт Мансурович елтырап торган портсигарын ачты да Ирекка таба сузды.

—Тартасызмы?

—Юк, тартмыйм, рәхмәт,—диде Ирек, ничектер аның тәкъдимен кире кагуына кыенсынгандай.

—Дөрес эшлисез.—Мидхәт Мансурович сигарет кабызды.—Агу икәнен дә беләм—ташлап булмый. Кешелек әйбердән котыла алмаган кебек...

Ул суырган төтененнән ютәлли-ютәлли көлеп алды. Аннары аның йөзе бик житди кыяфәткә керде, коңгырт кашлары бер-берсенә тия язып җыерылдылар.

—Беләсезме нәрсә... Уй-фикерләрегезне өстәге күрсәтмәләргә туры килерме-юкмы дип тормастан бәян итүегез өчен рәхмәт, Ирек туган. Тормыш безне кайларга ташлар—анысы билгесез. Әмма ләкин шуны әйтергә тиешмен: кеше буларак, минем күнелдә кадерле урын алдыгыз сез...

—Рәхмәт!—диде Ирек, ике битенең кызышуын тоеп.

—Башлаган әсәрегезне дәвам итегез. Беркем сүзенә дә карамыйча. Тагын шуны белеп торыгыз: әгәр кешеләргә кирәкле Коръән тудыра алсагыз, аңа табынучы беренче кеше мин булырмын.

Ирекнең йөрәгендә бу кешегә карата иң җылы тойгылар уянды.

—Менә хәзер кәгазьләрегезне карап алсак та ярар.—Ул тегелмәне акрын гына актара башлады.—Күп кенә җәмәгать эшләре алып барасыз икә-ә-ән... Әле бер генә партия җәзагыз да юк икә-ә-ән. Ярый, өлгерерсез, шелтәсе дә, каты шелтәсе дә, учет карточкагызга язып та бирерләр.

Ирек елмаеп җибәрде:

—Бәлкем гел бирмәсләр?

Мидхәт Мансурович рәхәтләнеп көлеп куйды.

—Минем сүзләремә ышаныгыз: сезнең кебек кеше партия җәзасыз кала алмый. Валлаһи, шулай булачак! Тик сезнең аңа исегез китмәсен берүк. Тормыштан беркая да кача алмыйсын...

Ул, шулай акрын гына сөйләнә-сөйләнә актарып чыккач, делоны япты, нәрсәсендер тигезләдеме шунда—тышлыгын сыпырып-сыпырып куйды.

—Бик яхшы бюрократик аппарат тудырдык, һәммәсе дә теркәлгән, берсе дә төшеп калмаган монда.—Ул сигаретын өстәлдәге көл савытына басып сүндерде дә соры күзләренең йомшак карашын туп-туры Ирекнең күзләренә юнәлтте.—Безгә фикерле кешеләр аз килә. Әйбәт редактор чыгар сездән. Кайтыгыз, расладылар, диегез. Курыкмыйча эшләгез.—Ул, өстәл артыннан чыгып, Ирекнең кулын кысты.—Хуш, Ирек туган!—Аның йөзенә ниндидер сагыш шәүләсе чыкты, хәтта киң якты маңгае да күләгәләнебрәк киткәндәй тоелды.—Сез биеккә очарга тиеш. Бик тә, бик тә телим мин сезгә шуны. Ә без...—ул әзгә генә тынып калды,—биредә калабыз...

«Әйт, менә хәзер әйт!»—диде Ирек үз-үзенә. Аның редакторлыкка мәҗбүри генә ризалашуы, өлкә комитетына расламыйча борып кайтаруларын теләп кенә килүе турында сөйләп бирәсе килде, Мидхәт Мансурович аны аңлар, аңа ышаныр, борып кайтарыр, дип өметләнде. Бәгырен яндырып торучы шушы уе югыйсә күңелендә, әйтәсе сүзләре телендә иде. Тик әллә бу кешенең үзенә карата булган җылы мөнәсәбәте, әллә чыннан да язмыш дигән нәрсә моны эшләргә—ике-өч авыз сүз әйтергә ирек бирмәде! Бу—үз-үзеңне харап итү иде! «Менә хәзер әйтсәң әйтеп каласың, бу бүлмәдән чыккач, сиңа кабат артка юл юк», дип кыстаклады аны эчке бер көч. Әмма күңеле, күрәсең, ул көчкә түгел, икенче нәрсәгә буйсынды, ул үзен берничек тә мәҗбүр итә алмады...

—Рәхмәт сезгә, Мидхәт Мансурович,—диде Ирек һәм, чыгып китәргә ишекне ачкач, тагын бер мәртәбә артына борылып карады. Мидхәт Мансурович уң кулы белән күкрәген кыскан хәлдә бераз иелебрәк басып тора, ирләрчә сабырлык бөркүче йөзе үзгәрешсез калса да, күз карашы берничек тә яшерә алмаслык моңсу һәм әрнүле иде...

## 16

Ирек Казаннан кайткан көнне үк алар Шәвәлиев белән редакциягә киттеләр. Редактор бүлмәсе халык белән шыгрым тулы иде. Аларны күргәч, коридорда йөрүчеләр дә йөгерә-атлый шунда кереп югалдылар. Шәвәлиев түрдәге өстәл янына узды. Ирек шуннан ерак булмаган бер урындыкны алып читкәрәк утырмакчы булды.

—Юк, юк, хәзер инде монда утырасыз,—диде Шәвәлиев, редактор урынына күрсәтеп.

Ирек кып-кызыл булды, шулай да анда бармады, урындыгын тотып килеп, өстәлдән бераз читкәрәк утырды. Ул аңа төбәлгән карашларны каш астыннан гына күзәтте. Кайсылары куркып, кайсылары кызыксынып, кайсылары мыскыллап карый иде бу кешеләрнең.

—Сезгә мәгълүм булганча, иптәшләр, Абдуллин башка районга күчеп китә,—диде Шәвәлиев, акрын гына сүз башлап.—Райком бюросы аның урынына Сабитов Ирек Хәйриевичне билгеләү турында карар кабул итте. Күпләрегезгә мәгълүм, ул безнең идеология бүлегендә шактый вакыт инструктор булып эшли.—Сабитовка сораулар бармы?—диде.

Ирек торып басты. Аның бөтен тәне кызышты, аркаларына кадәр тир бәреп чыкты. Бүлмәдәгеләрнең берсе дә дәшмәде. Шулчак редактор урынбасары Хәниф Зәбиров торып басты. Кара чәчле, кулларына кадәр кара төк баскан, тирән җыерчыклы йөзле, авыр күз карашлы бу кешедән Ирек электән үк ничектер куркыбрак йөри иде.

—Минем Сабитовка соравым юк,—диде ул.—Сезнең үзегезгә—бар. Бүгенге көндә редакциядә журналист дипломы белән биш кеше эшли. Аның икесе СССР Журналистлар союзы члены. Ни өчен райком бюросы аларның берсен дә редактор булырга лаек дип тапмады икән?

Шәвәлиев, бер аягыннан икенчесенә күчереп, гәүдәсен тибрәткәләп

алды, берничә мәртәбә бармаклары белән чәчен аралады. Шактый кыен сорау иде бу.

—Ышаныгыз: без мәсьәләнең бар ягын да исәпкә алдык. Газета райком органы. Ул үзе теләгән кадрны редактор итеп куярга хокуклы.— Шулай диде дә, Шәвәлиев ашыгып Ирекка сүз бирде.

—Нәрсә әйтим?—диде ул, аягүрә басып.—Райкомның миңа күрсәткән ышанычы өчен рәхмәт. Әгәр аны сез дә уртаклашсагыз... Редакторлыкны мин үзем сорап алмадым. Инде шулай килеп чыккан икән, безгә бергәләп эшләргә, тырышырга кала. Мин газетаның эчке казанын әле бик аз беләм. Шуна күрә, бирелә утырган барлык кешеләр ярдәменә исәп тотам, ә үземә килгәндә... намус белән эшләргә сүз бирәм.

—Җыелыш шуның белән ябык,—диде Шәвәлиев.

Кешеләр берәм-берәм чыгып киттеләр.

—Зәбиров, Хасбулатова, сез кузгалмагыз әле,—диде Шәвәлиев.

Менә алар бүлмәдә дүртәү генә калдылар.

—Редакциядә хәлләрнең җинелдән түгел икәнен беләбез. Сотрудникларыгыз да җитми. Вакыты белән бар да җайга салыныр. Сабитовны беренче чиратта сез икегез поддержать итәргә тиеш. Килешеп эшләрсез дип уйлыйм.

—Килешербез, нигә килешмәскә,—диде Хасбулатова, энҗедәй тешләрен күрсәтеп елмаеп.

Ирек аның ни дәрәҗәдә чибәр икәнлеген менә хәзер игътибар белән карагач кына күрде. Башта ике урынбасар, аннары Шәвәлиев чыгып китте. Ялан кадәр бүлмәдә ул берүзе басып калды, редактор кәнәфиенә утырырга куркып карап торды. Әйтерсең лә ул кәнәфи түгел, электр белән җәзалау урындыгы иде...

Икенче айның чәршәмбесендә Абдуллин китәргә җыенуы турында хәбәр итте. Ирек, егетләр белән барып, аларның әйберләрен төяште. Башкалар киткәч Абдуллин, Ирекне җитәкләп, агач бакчасына алып керде. Бик матур булып алмалары пешеп утыручы ике агачка күрсәтте:

—Без боларны ике кызыбыз истәлегенә утырткан идек,—диде.— Быел беренче мәртәбә җимеш бирәләр. Син аларны берүк сакла инде, Ирек. Без килеп, ул алмаларга карап, сокланып китми түзмәбез.

Аннары ул Ирекне кинәт кочаклап алды да кырынмаган, каты төк баскан ягагын аның ягагына ышкый-ышкый елап җибәрде. Аның бөтен гәүдәсе калтырый иде.

—Их!—дип пышылдады ул Ирекнең колагына.—Шулкадәр китәсем килми! Ике аягымның берсе дә тартмый...

Ирек авыз ачып ни бер сүз әйтә алмады, ни аны тынычландырыр сүзләр тапмады.

—Китмәс идем,—диде ул һаман үксеп.—Корректор булып булса да калыр идем!..

—Сон, китмәгез, Абдуллин абый,—диде Ирек, аны юатмакчы булып.

—Беренче рөхсәт итми шул. Бу районда миңа эш булмаячагын кистереп әйтте...

—Ни булды соң?

—Хасбулатованы төнлә редакциядә берәү белән күргән идем...

Абдуллинның хатыны йозак белән ачкычны Ирекка бирде һәм, яшьле күзләрен күрсәтмәс өчен, тизрәк машина кабинасына үрмәләде.

—Әйбәт кенә эшлә. Ярый, хуш,—диде Абдуллин, тагын Ирекне кочаклап.

—Кайтканда кагылыгыз, бу йортның ишекләре сезнең гаилә өчен һәрвакыт ачык булыр,—диде Ирек аларга.

Абдуллин кул селтәде дә кабинага менеп утырды. КамАЗ, бөтен ихатаны төтенгә тутырып, үкерә-үкерә чыгып китте. Ирек, капканы япкач, кереп бүлмәләрне карап чыкты. Өйдә, җиде ыргак болгасаң да, тәрәзә төбендәге сынар телефоннан башка әләгер әйбер юк иде. Ул квартираның үзенә калуына нишләптер шатлана алмады, яңагында һаман

да Абдуллинның төкле яңагын тойды, беләкләрендә аның ябык калак сөякләренең сулыгып елагандагы дерелдәвен сизде...

Квартира аңа бик күп мәшәкатьләр тудырды. Коммуналь хуҗалыкның акчасы да, буявы да, бүтән төзелеш материалы да юк иде. Шулай итеп, ремонт аның үзенә калды.

Бер көнне эштән соң идән буяп ятканда, ул аяк тавышлары ишетте. Ишектә Сөембикәне күреп, шатлыгыннан кычкырып җибәрде.

—А-а-а, Сөембикә үскәнем килгән!

Сөембикә эш киемнәреннән, чалбардан иде.

—Әллә бакчадан-мазар кайтып киләсеңме?—дип сорады анардан Ирек.

—Үзең бел,—диде Сөембикә, хәйләкәр елмаеп.

—Менә шушы пумала белән борыныңа тигерәм бит,—диде Ирек, кулындагы сары буяулы пumalаны аңа таба төзәп.—Әйт тизрәк!

—Сиңа булышырга килдем.

—Чынлап әйтәсеңме?

—Чынлап әйтмичә соң. Кая, нинди эш кушасың миңа?

—Алайса тәрәзәләрне эчке яктан акка буйый тор,—диде Ирек, аның килүенә чын-чынлап шатланып.

Бу көннәрдә ялгызлыктан ул инде тәмам туйган иде. Алар төнге унбер тулганчы эшләделәр. Ирек Сөембикәне квартирасына кадәр озатып куйды.

—Рәхмәт сиңа, Сөембикә!—диде ул, чын күңеленнән һәм аның иреннәреннән үбеп алды.

Бу аның беренче мәртәбә Сөембикәнең иренenә кагылуы иде. Ул каршы сүз әйтмәде, йөгереп кереп китте. Ирек квартирасына очып кайткандай кайтты. Аңа бүген чиксез рәхәт иде. Сөембикә икенче көнне дә, өченче көнне дә, янадан бик күп мәртәбәләр килде. Өйләр, верандалар, котельныйларны алар икесе рәткә керттеләр. Сөембикә бөтен өйне юып чыккач, аны икәүләп обойладылар. Ишек алларын, бакчаларны бергәләп себереп өйделәр. Сөембикә бу йортның үз кешесенә әверелеп китте...

## 17

Яңа ел газетасын ике төс белән басарга ниятләделәр. Район халкына яңа ел котлавы, беренче биттәге ике орнамент, дүртенче битнең телеграммалары, кайбер линейкалар кызыл төстә булырга тиеш иде. Бу бик мәшәкатьле эш, зур төгәллек сорый, һәр бит ике мәртәбә басыла дигән сүз. Яңа ел котлавын Ирек алдан ук язып Шәвәлиевкә күрсәтте. Андагы мактап телгә алган колхозлар арасында «Авангард»ның булмавын күргәч, Иреккә шикләнүле караш ташлады:

—Дөрес булмас бит бу.

—Ә ничек кертәбез соң аны, Зөфәр Шәрипович? Игенчелектәге хәлләрен үзегез беләсез. Ит заданиесен үти алмадылар, сөте менә шушы өч көндә әле сорау билгесе астында тора. Гадел булырмы соң?

Аның бу сүзләрен Шәвәлиев рәхәтләнеп тыңлады. Батталовны, бер генә мәртәбә булса да, үрле-кырлы сикертәсе килә иде секретарьның.

—Ярар, синеңчә булсын, тәвәккәлләдек,—диде ул.

Тышкы битләрне көн ярым алдан кызыл белән баса башладылар. Барысы да әйбәт дип торганда, редакциягә чырае качкан Шәвәлиев килеп керде. Ирек бүлмәсенә инде чыршы утыртылган, корректорлар, машинисткалар шуны бизәп маташалар иде.

—Кызлар, чыгып торыгыз әле,—диде Шәвәлиев аларга кырыс кына. Икесе генә калгач:

—Хәзер үк типографиянә әйт әле, тышкы битләрне басудан туктасыннар,—диде.

—Нәрсә булды?

—Башта әйт, туктасыннар.

Ирек, корректорларга чылтыратып, газета басуны туктатырга кушты.

—Эш начар, слушай,—диде ул әрле-бирле йөренеп.—Беренче уылдык чәчә, ни өчен котлауда «Авангард»ны төшереп калдырдыгыз, ди. Әгәр дә шуны кертмәсәгез, газетагызны жыеп яндырам, ди. Кертергә туры килә бит, Ирек Хәйриевич.

—Каян белгән соң ул аны?

—Батталов үзе хәбәр иткән.

—Мондый шартларда мин редактор булып эшләүдән баш тартам,— диде Ирек, чын-чынлап рәнжеп.

—Нинди шартларда?

—Әле басылмаган газетада «Авангард»ның мактап кертелмәгәнен каян белә ул? Кем житкерә аны моңа?

Шәвәлиев кулларын як-якка жәйде.

—Анысын инде син миннән сорама,—диде ул коры гына.—Үзеңнең сотрудникларыңнан сора.

—Алайга киткән икән, мин юри үзгәрттермәячәкмен моны. Житмәсә, хәзер әллә никадәр газета басылган.

—Үзгәртәбез, Ирек Хәйриевич.

Ирек кызыл белән бастырган бер газетаны керттерде:

—Карагыз әле, Зөфәр Шәрипович, сез моның күпме хезмәт икәнен беләсезме? Һәм күпме кәгазь? Уйлагыз: халык күзенә ничек карарбыз без сезнең белән? Колхоз-совхоз житәкчеләре ни әйтер? «Авангард»ны мактау—ул чеп-чи ялган. Быелгы ел планын үтәүчеләр белән аның янәшә торырга да хакы юк.

Алар тагын бик озак тарткалаштылар. Ахырда Ирек Зөфәр Шәриповичка болай диде:

—Мин уйлап таптым. Сез хәзер миңа үзгәртергә куштыгыз. Менә мин күз алдыгызда үзгәрттем.

Ул яңа ел котлавында макталган хужалыкларга «Авангард»ны өстәде. Аннары газетаның почмагына «Төзәткәч басарга», дип кул куйды.

—Әгәр ышанмыйсыз икән, алыгыз шушы газетаны. Ләкин мин барыбер үзгәртмәячәкмен. Бөтен жаваплылыкны үз өстемә алам. Сез куштыгыз—мин төзәттем, күз алдыгызда менә газетага кул куйдым. Сезнең эш бетте. Мин сезне буярга теләмим.

Ирек, шалтыратып сейфын ачып, әле генә кул куйган газетаны шунда тыкты да бикләп куйды. Аннары ачкычны Шәвәлиевкә сузды.

—Мәгез, бу газета теләсә кайчан сезнең кулыгызда булачак.

Шәвәлиев башын чайкады, ләкин бу ачкычны алырга теләмәүдән түгел, ә аптыраудан иде.

—Син бит ут белән шаярасың, Ирек...

Аның әле Ирек редактор булганнан бирле исеме белән эндәшкәне юк иде.

Шәвәлиев чыгып киткәч, Ирек тагын шактый вакыт уйланып торды. Батталовка кем бу әйберне тишкәнен чамалый иде ул. Ләкин бит Хасбулатованың котлауга «Авангард» колхозының кертелмәгәнлеген тагын әйтүе бар. Нишләргә соң? Әллә Батталовның үзенә чылтыратыргамы? Ул чакта Ирек ни ота? Юк, ул оттырачак кына. Чөнки Батталов өчен Фаунаны аңа каршы өстерү берни дә тормый. Әгәр Хасбулатованы куркытсаң? Куркыр микән соң ул? Ире ОБХСС начальнигы. Ирек эндәшмәскә булды.

Икенче көнне иртән сәгать сигезгә аны райкомга чакырдылар. Беренченең ишек төбендә торучы бюро әгъзалары белән Ирек берәм-берәм күрешеп чыкты. Батталов, аны күрмәмешкә салынып, тәрәзәдән тышка карап тора иде. Ул арада бөтенесе дәррәү Беренче бүлмәсенә керделәр. Ирек һәр бюро саен чакырыла, аның үз урыны бар, ул шул урынга барып утырды. Ул, кергәндә үк, Арсланов алдында яткан яңа ел газетасын күрде.

Арсланов, нәрсәдәндер шикләнгәндәй, бюро әгъзаларын берәм-берәм күздән кичерде. Ул бик тә кәефсез иде һәм бюро утырышын

мәҗбүри генә җыйды. Хәтта башлап җибәрергә теле әйләнмәде, ичмасам телефонының да тавыш-тыны юк бит, дип уйлап бетерергә өлгермәде— ул чылтырарга керешге. Миңзаһит Усманович, җиңел сулап, трубканы алды, әмма Хәятнең тавышын ишетүгә, ачуташ капкандай, чырае бозылды.

—Җибәрәбезме, юкмы?—диде хатыны.

Аның сүзләреннән гарык булган Миңзаһит күзләрен йомды һәм алҗау тавыш белән:

—Җибәрербез,—диде дә трубканы куйды.

Ул хәзер үзе җыйнаган менә бу кешеләрне күрмәс өчен, хатынының тавышын ишетмәү һәм ялгызы гына калу өчен, кичәдән бирле телгәләнгән җанының яртысын биреп, теләсә кая олагырга риза иде...

Кичә Рәшаттан хат килеп төште. Кышкы сессия бетмичә кайта алмыйм, квартира хакы артты, пальто белән бүрек аласым бар, дигән һәм мең сум акча сораган. Әле бит сигез йөзгә якын акчаны Октябрь бәйрәмендә генә алып киткән иде. Миңзаһитның күңеле сизенә, монда нәрсә дә булса бар: бу йә эчә, йә хатын-кызга туздыра акчасын, ә иң дөресе—шушыларның икесе дә бергә булырга тиеш.

... Бөтенесе яшьлек хатасыннан башланды. Техникум дипломы алгач, Чаллыдан ерак түгел бер авылда агроном булып эшли иде Миңзаһит. Актив җәмәгатьче итеп йөртә торгач, ВЛКСМ райкомына алдылар. Башта инструктор, аннары оештыру бүлеге мөдире, икенче секретарь булды. Шунда эшләгәндә, күрше райондагы коллегасы Хәят белән танышты. Тәүге очрашуга ук Хәятнең үтә дә ачык күңеллелеге һәм беркатлылыгы хәйран калдырды. Ярты сәгать эчендә Миңзаһит кызның бөтен үткәнен, киләчәк хыялларын белеп бетерде. Шул ук вакытта Хәятнең сөрмәле яшькелт күзләренә яшеренгән эчке бер сагыш, җитди чакларда гына сирпелеп китүчән серлелек аны тыелгысыз рәвештә үзенә тартты. Тулган айдай түгәрәк йөз, кап-кара кашлар, килешле йомры гәүдә—Миңзаһитның хатын-кызга карата булган зәвыгына искиткеч тәңгәл килде. Алар бик еш очраша башладылар.

... Яз иде, табигатьнең ак юрганын ачып ташлаган чагы иде, бөтен тереклекнең бер-берсенә тартылган вакыты, күңелләрдә дәртнең ташыган мәле иде. Бер кичне Миңзаһит аны әрәмәгә алып чыкты. Сандугачлар сайрап торган бу җылы кич, мең төрле чәчәк исләре, күк гөмбәзе тулы йолдызларның шаяртып күз кысулары аларны тәмам исәрләндерде һәм исертте, бер-берсенең кайнар кочагына сеңеп, ләззәтле үбешүләрдән алар ут булып кызыштылар, сулышлары ешайды, йөрәкләре ашкынып типте, туктаусыз кымтырыклый торгач, Миңзаһит аны чишендереп бетерде, кулларын каерды, кыз бирешергә теләмәгәч, өйләнәм дип, ант сулары эчте, ахырда Хәятне бирелергә мәҗбүр итте. Аларның татлы очрашулары җәй буе дәвам итте дә, агачларның яфраклары саргаеп коелганда, Миңзаһит, суына башлап, аның янына барудан бөтенләй туктады. Әмма Хәят, үзе килеп, дүрт айлык көмәне барлыгын әйтте һәм үкси-үкси елады, яшьлегемне харап иттең, ник мине алдадың, дип өзгәләнде. Миңзаһитны партия мәктәбенә укырга җибәрү турында сүз кузгалган иде. Ул Хәяткә шуны әйтте, безгә әлегә бала кирәкми, көмәнеңнән котыл, аннары өйләнешербез, дип ялынды. Ләкин Хәят аны тыңларга да теләмәде, баланы барыбер табам, диде. Берничә тапкыр очрашып сөйләшүләр нәтиҗә бирмәгәч, Миңзаһит аңа: тап, дөмек, синең ул корсагың, шайтан белсен, кемнән, ә мине оныт, диде.

Күрәсең, алай ук әйтәсе булмаган.

Бервакыт төнлә, танцыдан кайтканда, тыкрыктан ике шәүлә килеп чыгып, аны җиргә гөпелдәтте, авызын томалап, машинага утырттылар, елга аръягындагы урман эченә алып керделәр. Төшереп, авызын томалаган нәрсәне алгач, аларның берсе Миңзаһитның ике каш уртасына пистолет көпшәсе терәде һәм тимер тавыш белән:

—Әгәр Хәятне хурлыклы хәлдә калдырсаң, менә шушыннан чыккан пуля миеңне чәчрәтәчәк,—диде.—Аңладыңмы?

—А-а-а...

Минзаһит усак яфрагы шикелле калтырый иде. «Аңладым» дип әйтә алмады. Алар аны урман эчендә калдырып киттеләр. Өч атна тулганда, ул Хәяткә өйләнде. Хәят үзе дә, абыйсы да, әтисе дә (ул район эчке эшләр бүлеге начальнигы иде) берни сиздермәделәр, күпме еллар бергә гомер итеп, бу вакыйга аның өчен бүгенгәчә сер булып калды...

Бала туганчы, Минзаһит ул минеке түгелдер дип шикләнде, янды-көйде. Райкомолда эшләгән кеше көне-төне яшьләр белән аралаша, ни туры килсә, шуңа утырып, авылларга йөри. Ни булмас? Хатыны тулгаклап больницага кергәч тә, ул: бала үле тусын иде, дип теләде. Ана үч иткәндәй, дүрт кило ярымлы малай, дөньяга килеп, яшен ташыдай нык булып үсте. Күнелендә бала аның өчен туганчы ук үлгәнлектән, ул көяләнде генә. Чөнки Минзаһитның, утыз яшьне үтмичә өйләнмәскә, ирек дигән нәрсәнең кадерен белеп йөрергә, дигән хыялы юкка чыкты. Тыштан авыз ерган, куанган булып кыланса да, якыннары белән көне-төне аның тәпиен юса да, эчендәге әрнеп торучы ярасы йомылмады, нишләсәң дә, малай аның күнеленә ят иде. Әтисенең рөхсәтеннән башка аның бу якты дөньяга килүен, татлы хыялларын чәлпәрәмә китерүен, күпме генә тырышса да, кичерә алмады Минзаһит.

Әлбәттә, төп гаеп Хәяттә иде. Ул, Горький шәһәренә партия мәктәбенә киткәч, биш ел буе барлык стипендиясен хатын-кызларга түкте, укуын тәмамлап кайткач та, ана акча күрсәтмәде, бик кирәк чакларда, үлеп-җитеп нидер аласы булганда гына сәмән ыргытты. Рашатны сөйсә дә, яратып сөймәде, аерылып китмәсме дип, Хәят белән атналар буе сөйләшмичә йөрде, әмма хатыны ни үзен, ни Минзаһитны газаплы коллыктан коткару турында уйлап та карамады. Болынкырга райком секретаре итеп җибәрелгәч, югары партия органында утыруның отышлы якларын аңлап өлгергән Минзаһит, инде хатыны теләсә дә, аны аермас иде. Яшьлегендә бер авызы пешкәч, ул тормышта тавык кебек хәрәкәт итәргә өйрәнде. Тавык бит элгәре башын алга суза, аннары гына атлый. Югарыга үрләгәндә дә шулай: бер генә ялгыш адым ясасаң да, кабат күтәрелә алмаслык булып, аска мәтәлүең бар. Хәят, әллә тагы юри Минзаһитның ачуын китерү өчен, Рашатны бәләкәйдән үк иркәләде, тәм-томнан, акчадан өзмәде, әтисе бирәр эш кушса, аны үзе эшләде, дәресләрен үзе әзерләде. «Иркәләмә, азындырма, бозасың!» дип, Минзаһитның тиргәүләре Хәятнең бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыкты.

Рашат, кая барса да, әнисенең итәгенә тагылып йөрде, әтисе янына килмәде, зурайган саен, күзләрендә нәфрәткә тартым очкыннар күренде. Минзаһит үзе корган ояда төс-кыяфәте белән бер тамчы су кебек аңа охшаган, әмма эчке омтылышлары, кыланмышлары белән ят җан иясе—күке баласы үстерүен һаман тирәнрәк аңлый барды. Рашат аларның башын бишенче-алтынчы классларда ук тинтерәтергә тотынды. Аны класстан класска күчереп, тизрәк аттестат тоттыру өчен мескен укытучылар ниләр генә кыланмадылар. Ниһаять, былтыр котылдылар. Бер ел буе Рашат, бот күтәреп, өйдә ятты. Быел әтисе җәй буе аны мөмкин кадәр ераккарак олактыру һәм тәрбия бирердәйрәк уку йортына урнаштыру белән ныклап шөгыльләнде, әллә никадәр акча түгеп, Мәскәү инженерлык институтына укырга кертте. Инде җаным тынды дип, җиңел суларга өлгермәде, кичәге хат әле чәчләренең агарып көннәре алда икәнлеген кисәтте. Хатыны белән алар пычакка пычак килделәр. Ике айга ике мең акча түгә башласаң, ничек яшәмәк кирәк?! Рашатның шушындый юньсез булуында ул—Хәятне, Хәят аны гаепләде. Ахырда Минзаһит, «Акчаң кычытып торса, үзең җибәр, миндә артык акча юк», дип, өйдәге тавышка нокта куйды. Нервыларының соңгы чиккәчә киерелгән шундый чагында, егылганны түбәләгәндәй, Гайсә чылтыратты, газетаны ябарга кирәк дип җикерде, өлкә комитетына чыгам, дип куркытты. Гайсәне сугып үтерәсе килсә дә, аның хаксыз икәнлеген аңласа да, Минзаһитка бюро җыюдан башка чара калмады...

Тагын телефон чылтырады, тагын хатыны Хәят иде.

—Җибәрсәк, акча кирәк бит...

—Төштән соң җибәрербез,—диде ул.—Әлегә вакытым юк...

Чукынсын акчасы, барыбер алар икесе җиңәчәк. Рашат яңа елга Болынкырга кайта—акча салмасаң, бу шулай була—аның азып-тузып йөреп йөз кызартачагы, болай да какшаган абруен бөтенләй төшереп китәчәге көн кебек ачык иде...

—Бәйрәм көнне без бюро утырышы үткәреп ятарга тиеш тә түгел идек,—диде ул, күз карашын яшерер урын тапмыйча.—Ләкин газетаның бүгенге санын укыгач, мин бюро җыймыйча булдыра алмадым. Райкомның һәм райбашкарманың Яңа ел котлавында мактап телгә алган хуҗалар арасыннан безнең хөрмәтле Гайсә Батталович җитәкчелек иткән «Авангард» колхозы редактор тарафыннан махсус төшереп калдырылган.—Минзаһит башын күтәреп Ирекkә карады.—Сез моны нинди максат белән эшләдегез?

—Мин аны төшермәдем. Котлауны язган чакта ук «Авангард»ны бөтенләй кертмәдем,—диде Ирек, райкомның бу эштә катнашы юклыгын сиздереп.

—Ярый, шулай да булсын,—диде ул.—Ә бит икенче секретарь тарафыннан бу хата төзәттерелә. Сез аның алдында газетаны басарга кул куясыз һәм ул искечә басыла.

Шулвакыт Батталов урынында кыбырсып куйды һәм Ирекkә бүренеке кебек күзләрен төбәп:

—Иптәш Сабитов, сезнең, райкомга килгәннән бирле, безнең колхозга карата әйбәт булмаган мөнәсәбәтегез сизелә,—диде.—Редактор булгач, сез инде аны аерымачык күрсәтә башладыгыз. Моның сәбәбе нәрсәдә?

—Моның бернинди сәбәбе дә юк,—диде Ирек.—Бу сезгә шулай тоела. Сезне, Гайсә Батталович, мактауга шулкадәр күнектереп бетергәннәр, әгәр берәрсе сезне яисә колхозыгызны мактамаса, ул сезне дә, сез җитәкләгән хуҗалыкны да өнәмәүче затка әверелә.

Ай, дөрес тә әйтте Сабитов! Минзаһит һәркемнең йөзендә бу сүзләрне хуплау күрде. Ирекне ул сокланып та, көнләшеп тә күзәтте. Ничек саф, тәвәккәл аның күз карашы. Тормышта үз урынын белгән, үзенә ышанган кеше генә бюро әгъзалары каршында каушамыйча, курыкмыйча басып тора ала. Нигә аның Рашаты да шушындый булмады икән соң?! Хәйри Сабитов гомере буе эштән бүтән нәрсә белмәгән, балаларын хатыны үстергән. Ничек инде надан колхозчы югары белемле укытучыдан, элеккеге комсомол работнигыннан әйбәтрәк бала тәрбияләргә мөмкин?! Боларның берсен дә бу кешеләргә әйтә алмыйсың, бик теләсәң дә, Сабитовны яклап та булмый, чөнки Гайсәнең кулы кыңгыраууда гына, бер кагып җибәрсә, чыңлавы өлкә комитетына ук яңгыраячак...

—Сабитов!—диде ул, йөзенә ачу чыгарырга тырышып.—Без сезне монда акыл сатарга чакырмадык. Җавап бирегез: ни өчен райкомның күрсәтмәсен үтәмәдегез?

—Ярый, сезнең соравыгызга мин җавап бирермен,—диде Ирек.—Ләкин бер нәрсәне ачыклаганнан соң гына. Минем белүемчә, Минзаһит Усманович, «Авангард»ның макталучылар рәтендә юклыгын сез Гайсә Батталович аша ишеткәнсез.—Ирек аңа туп-туры карады.

—Ну что ж?

—Гайсә Батталович, чын коммунист буларак, бюро члены буларак, кулыгызны күкрәгегезгә куеп әйтегез әле: газета басылмаган килеш, анда нәрсә чыгасын, нәрсә чыкмасын сез каян белдегез?

Батталов аңа усал карашын күтәрде.

—Сезгә әле миннән сорау алырга иртәрәк, балакаем, һәм, гомумән, бу хакта мин сезгә отчет бирергә җыенмыйм.—Шулай диде дә Батталов башын Минзаһитка борды.—Нигә без үзебезне шушы кеше алдында мыскыл иттереп утырабыз соң әле? Әйткәнне аңлаячак түгел ул. Наказать итәргә—бетте-китте.

—Нәрсә әйтәсез?—диде Минзаһит, бюро члennарына мөрәҗәгать

итеп. Ләкин шулчак Ирекнең шактый көчле тавышы янгырады:

—Хөрмәтле Минзаһит Усманович, мин сездән район газетасы коллективы исеменнән сорыйм һәм ярдәм итүегезне үтенәм: ни өчен редакция сере булып сакланырга тиешле фактлар читкә чыгалар? Аларны Гайсә Батталович нинди канал аша ала? Әгәр ул шушы сорауга җавап бирмәсә, мин редакторлыктан баш тартам.

Барысы да тып-тын калдылар. Бераздан Минзаһит, зиһенен җыеп:

—Сез, Сабитов, мәсьәләне бик купайтмагыз әле,—диде.—Сез бик мөһим дәүләт сере чыккан кебек сүз алып барасыз.

—Димәк, сез аны яклыйсыз?—диде Ирек.—Ул вакытта мин башка бюро әгъзаларына мөрәҗәгать итәм: кадерле иптәшләр, Гайсә Батталовичның редакциядән кем аша, ничек информация алуын хәзер үк сезнең күз алдыгызда аңлатуын таләп итәм.

Барысы да, башларын аска игән хәлдә, карашларын күтәрергә кыймыйча тып-тын калдылар. Батталов кыбырсып куйды.

—Син нәрсә әле монда, үзеңне җәзага тартасы урында, бик җайлап, хәйләләп котылмакчы буласың?—диде ул һөҗүм итеп.—Кемдер чылтыратты миңа, менә шул.

—Редакциядәнме?—диде Ирек.

—Редакциядәндер инде, мин каян белим? Мин бит аны танымадым.

—Менә бусы инде чыннан да хәйләләү,—диде Ирек.—Хәйләләү генә түгел, үзегез белән бер өстәл артында утыручы шушы мөхтәрәм кешеләрне күрәләтә алдау бу. Кем икәнен үзем әйтеп биримме соң, Гайсә Батталович?

—Минзаһит Усманович,—дип сикереп торды Батталов.—Сез бу малаегызны тыясызмы, юкмы?!

—Бабае булгач, малае да булырга тиеш инде аның,—диде Ирек.

—Рәхмәт, Минзаһит Усманович, мин сезнең ник чакырганыгызны аңладым!—диде Батталов һәм, кызу-кызу атлап, ишеккә юнәлде.

—Гайсә Батталович, бюро бетмәде, мин сезгә чыгарга рөхсәт итмим!—дип кычкырды Арсланов.—Кире борылыгыз!

Батталов, туктап, гәүдәсен алга караган хәлдә калдырып, артка каерылып кына карады да:

—Без инде бабай кеше, үз гомеребезгә бер мәртәбә буйсынмаска рөхсәт итегез. Сезгә баш бирмәүче яшьләрне узындырыгыз әнә.

Аның артыннан дөпелдәп ишек ябылды.

Бюроны тизрәк бетерергә кирәк иде.

—Райкомга буйсынмаганы өчен мин Сабитовка шелтә белдерергә тәкъдим итәм. Кем дә кем шуңа кушыла, тавыш бирүегезне сорыйм.

Вафиннан кала барысы да кул күтәрделәр. Минзаһит икеләнеп калды, күрмәмешкә салышып, утырышны ябаргамы, әллә тагын куертып җибәрергәме? Соңгысын һич тә теләмәде ул. Болай гына үткәреп җибәрергә мин-минлеге каршы килде.

—Сез ишетмәдегез бугай, Лотфулла Габдрахманович?

—Ишеттем...

—Алайса сез... безгә каршы?

—Мин редактор мең мәртәбә хаклы дип саныйм.

Вафин башын күтәрмәде, аның янган яңагы кан бәреп чыгар төсле булып кызарды.

—Аңлашылды...—диде Минзаһит, өстәлдәге кәгазьләрен җыештырып.

—Ә мин аңламыйм,—диде Вафин.—Ни өчен бөтенебез шулкадәр тырышып ялганларга азапланабыз соң әле без?

—Нинди ялган?

—«Авангард»ның район өчен балластка әверелә баруын аны югары трибуналардан, газеталарда мактап кына яшереп булмый бит.

Бу сөйләшүнең Батталовка артыгы белән барып житәчәген уйлагач, Минзаһит үзенең чүгә, кечерәя баруын тойды. Ә аңа саламга ябышып булса да күтәрелергә кирәк иде.

—Гайсә Батталовичның хезмәтләрен без берничек тә сызып ата алмыйбыз.—Аның йодрыгының, акрын гына өстәлгә төшеп, шул урында хәрәкәтсез калуы моның бәхәссез икәнлегенә ишарә иде.—Бәлкем заманнан калышуы да бардыр. Сез бит яхшы беләсез: колхоздагы һәр нәрсәгә аның йөрәк җегәре салынган. Күкрәп үсүче игеннәрендә дә, техника дип аталган тимер-томырларында да, дистә еллар буе төзелгән корылмаларында да... Бөтенесе дә газиз баласы кебек якын аңа... Шуңа күрә берьяклы, туп-туры бәяләмәләрдән тыелыбрак карыйк әле без...

Инде утырыш шуның белән беткән, кемнәрдер, торып чыгып китәргә теләп, урындыкларын шыгырдата башлаганнар иде. Әмма Иректең торып басуы аларны туктарга мәҗбүр итте.

—Мин сездән бер нәрсә—редакциядән нинди канал буенча информация чыгуын ачыклауны үтендем. Сез моны теләмәдегез, димәк, бу хәл киләчәктә дә дәвам итәчәк. Мин мондый шартта эшли алмыйм һәм редакторлык вазифаларыннан баш тартам.

Шулчак район Советы башкарма комитеты председателе Гаскәров урыныннан күтәрелде. Аны бөтен район хөрмәт итә, аның төпле сүзе күпләрне буйсындыра иде.

—Ирек Хәйриевич,—диде ул.—Әйдәгез, яшьлек кайнарлыгын әз генә читкә куеп торыйк әле. Сез таләп иткән нәрсәнең менә шушы сәгатьтә генә берничек тә очына чыгып булмаячак. Сез бүгенге шелтәне бик авыр булса да йотып җибәрегез әле. Киләчәктә исә вакыт һәммәсен дә үз урынына куяр.

Аннары Шәвәлиев урыныннан тормыйча гына болай диде:

—Сабитов ул хәзер редакторлыктан котылырга җай эзли. Квартира алды, аның эш бетте. Шушыны сәбәп итеп, җайлап кына котылырга, повестьлар, пьесалар язып ятарга.

—Әйе, минем язасым килә. Мин моны яшермим,—диде Ирек.

—Ә менә без сине әле редакторлыктан җибәрмибез!—диде Шәвәлиев, аңа имән бармагы белән янап.—Әле җиде камытны берьюлы киеп сөйриячәксең. Ну шулай да, Сабитов, чама дигән нәрсә юк синдә. Моны мыегыңа чорнап куй. Уңай якларың күп синең, сәләтең дә бар, ә чама ягы, гафу ит, бик чамалы.

Кемнәрдер әкрен генә көлеп куйдылар.

—Утырыгыз, Сабитов,—диде Арсланов.

Ирек урынына утырды.

—Яңа ел алды бик матур башланмады башлануын, ну нишлисең? Дөнья булгач, барысы да була. Бәйрәм чорында төп игътибарны безгә терлекчелеккә юнәлтергә кирәк. Беренче чиратта, сөт кимемәсен. Бүген дә, иртәгә дә үзегез курировать иткән хуҗалыклардан урарга кирәк. Берninди таркаулыкка юл куелырга тиеш түгел. Сезнең барыгызны да Яңа ел белән котлыйм, сәламәтлек, иминлек, хезмәт уңышлары телим! По коням!

Дөбер-шатыр килеп, бөтенесе дәррәү кузгалдылар. Бюро утырышын тизрәк тәгәлләп бушанырга уйлаган Минзаһитның җаны тагын бәргәләнергә тотынды. Гаеплелек тойгысы, бигрәк тә Иректе рәнҗетүе аның гәүдәсенә бөтен авырлыгы белән басты. Яңа елга моннан котылмыйча чыгып булмаячак иде. Ул аннан котылу әмәлен дә тапты бугай!

—Сабитов, калып торыгыз әле.

Ирек урынына утырды. Бүлмәдә икәүдән-икәү калгач, Минзаһит өстәл тартмасыннан бер китап алды да аны, елмая-елмая, Ирекка сузды. Аның көрән тышына кызыл хәрефләр белән «М. У. Арсланов. Райком и молодежь» дигән сүзләр язылган иде. Аның русча булуы бераз гаҗәпләндерсә дә, Ирек чиксез шатланды, буяу исе килеп торган китапны җентекләп карарга, актарырга тотынды. Үзенең фамилиясе куелмаса да, әдәби әсәр булмаса да, ул аның каләме астыннан чыккан беренче китабы иде.

—Теге атнада ук почта аша килде. Алты гына экземпляр. Бирергә һич тә җай чыкмады. Бераү җитәр бит?

—Рәхмәт,—диде Ирек, һаман китаптан күзен ала алмыйча.

—Сезгә рәхмәт, Сабитов.

—Мина чыгарга мөмкинме?—диде Ирек, урыныннан торып.

—Юк, мөмкин түгел әле,—диде Минзаһит, елмаюын дәвам итеп.—Сез бит иртәгә кышкы сессиягә китәсез, шулаймы?

—Исәп шулай,—диде Ирек.

—Беркөн мина нәшрияттан чылтыраттылар. Анда ике менгә якын гонорар язганнар. Монда жибәрмәскә куштым.—Ул Ирекка бер бит кәгазь сузды.—Менә минем ышаныч язуы, кереп ал син ул акчаларны, Ирек Хәйриевич.

—Ничек инде?—диде Ирек, утлы күмергә карагандай, теге кәгазьгә куркып карап.—Мин ничек ул кадәр акча алыйм?

—Аласыз. Гонорар сезгә тиеш.

—Мин бит аны эш вакытында яздым... Бу гадел булмый...

—Давай, әкият сөйләп утырмагыз әле, Ирек Хәйриевич,—диде Минзаһит Усманович, ышаныч кәгазен анын алдына ташлап.—Әллә мин анын ничек язылганын белми дип уйлыйсызмы? Ул вакыт эчендә эштә гел шунын белән генә шөгыльләнеп утырганда да жинеп чыга торган түгел икәнлеген әллә мин анламыйммы? Гонорарны курыкмыйча алыгыз. Инде авторы урынында сезнен фамилия тормаганга мине кичерерсез дип уйлыйм... Ә кстати, мин бит онытгым. Ирек Хәйриевич, каяле китабыныны биреп тор әле,—диде Арсланов.—Һәм ул китапнын титул битенә: «Ирек Хәйриевичка—тагын да зуррак ижат уңышлары теләп, Арсланов» дип язды һәм, Ирекнен кулын кысып, китапны кабат бирде.

Ул кабул итү бүлмәсендә киенде дә, квартирына юл тотты. Анын кәефенен беркайчан да бүгенге кебек күтәренке булганы юк иде...

## 18

Ирек бер нәрсәгә гажәпләнә: май-июнь айлары анын тормышына нинди дә булса яналык алып килә. Беркөнне корректор хатын кереп:

—Сезгә Баллы Төбәк медпунктына шылтыратырга куштылар,—диде.

Ирек, «Әти йә әни авырып егылгандыр» дигән шомлы уйга төшеп, медпункт телефонын жыйды. Трубканы Хәлимә алды.

—Ирек... мин аны әле генә больницага илтеп салдым...

Ирекнен бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте.

—Кемне, Хәлимә апа?!

—Зәнфирәне...—Анын лышык-лышык елаганы ишетелде.—Алай-болай булсам, ди... алай-болай булса... синнән бәхиллек сорады.

—Ни булды сон?!

—Бәбәйләргә китердем... Курка ул... Үләрмен сыман ди...

Хәлимә, үкереп елый-елый, каядыр югалды... Ирекнен йөрәгенә чәнчеп ниндидер ут керде, ике чигәсенә кайнар дулкын йөгерде. Кыймшана алмады, тирләгән маңгаен кул сырты белән көчкә генә сөртте. Анын Зәнфирәсе бала тудыра... Тукта, тукта, ул бит инде аныкы түгел. Бу ничек була сон бу? Ирекнен бит әле Зәнфирәне йөрәгеннән чыгарып атарга уйлаганы да юк! Ә нишләп? Нинди нигез бар иде сон мона? «Ни уйлап йөрдең, Зәнфирәне кабат үзеңнеке итү өчен ник берни дә кылмадын?! Йә, жавап бир!»—диде ул үз-үзенә... Зәнфирә бала таба... Йә, йөрәккәй, әләктердең бит, зинһар аяма, сузма, туктап кына кал да—коткар... Бүлмәсендәге әйберләр, тәрәзәләр рәшә эчендәге кебек кыеш-мыеш килеп тотәделәр дә юкка чыктылар...

Ул күзләрен ачып жибәрде... Башына ак колпак, өстенә ак халат кигән хатын-кыз:

—Чү, чү, зинһар кыймылдамагыз!—диде.

Икенчесе анын беләк тамырына шприц белән дару кертеп маташа иде.

—Хәлегез ничек?

—Әйбәт...

Ирекнең бөтен гәүдәсе рәхәт изри иде, әйтерсең, гәүдәсенең һәр күзәнәге татлы йокыга талган.

—Мин аңымны җуйганмынмыни?—диде ул, нәрсә булганын белергә теләп.

—Зыян юк,—диде терапевт хатын.—Сез бик нык талчыккансыз.

Тагын бер укол кадаганнан соң, аны «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән квартирасына кайтардылар, ятып ял итәргә куштылар. Ул шундук йоклап китте һәм өч сәгатьтән соң гына уянды. Башы бераз томаланыбрак торса да, бер җире дә авыртмый, ә күңелендә... күңелендә Зәнфирә иде! Нишләп бәхилләшкән ул? Әллә кан киткәнме, нидер булганмы? Бәлкем Хәлимә барысын да әйтеп бетермәгәндер. Сәгать кичке сигез тулып килә иде. Ул кабаланып телефонга барды, бала тудыру бүлегенең номерын җыйды.

—Алло-алло! Баллы Төбәктән Фәхруллина Зәнфирәнең хәле ничек?

—Малай тапты,—дип җавап бирде нинди дер хатын-кыз.

—Үзенең хәле ничек?

—Әйбәт. Кем соң әле бу?

Ирек җавап бирмәде. Ул исән, хәле әйбәт! Кара чәчләре тирләгән маңгаена ябышкандыр, йөзе ап-актыр, ягымлы итеп елмаядыр... Ирек бернинди көнчелек хисе кичермәде. Димәк, ул барыбер аныкы, ул барыбер аның күңелендә. Алар мәңгегә кушылган, аеры яшәсәләр дә, барыбер бергә... Ул аның исәнлегенә чиксез шатланды...

Капкалап алгач, Ирек бала тудыру йортына барып кайтырга кирәк дигән карарга килде. Зәнфирә аның игелек кенә теләвен нәкъ менә хәзер тоярга, терелү өчен көч алырга тиеш. Ул дәртләнеп бакчага чыкты, ал һәм ак төстәге нәркис, лалә чәчәкләре җыйды. Блокнот битенә мондый шигырь язды:

«Сонардың, кирәкми, димә син,
Алар бит шыттылар җанымнан...
Сөюебез сагышы бөркелә
Яшьлекнең мизгеллек языннан...

Китмә син! Соңгы кат кул сузам,
Өзмәче бәгырьне, кал туктап!

Ал, зинһар! Кул җылын тоюга
Җанланыр бу гөлләр шатлыктан...

Рөхсәт ит күнелемә ябарга—
Сорамыйм мин синнән бүтәнне.
«Яшьлеккә, яшьлеккә!» ди хыял,
Кем куып житкән соң үткәнне?!

*Сәлам белән, синең мәңге гаепле кешең.*»

Кибеттән алма, берничә шоколад алгач, редакция машинасында больницага китте. Ана, бала тудыру бүлегенә күтәрелгәндә, кемнәрдер очрадылар, сәлам бирделәр, кем янына керәсең, дип сораштырдылар, ул елмаеп җавап бирде, үзе дә хәл-әхвәл белеште, әмма болар бөтенесе дә әһәмиятсез, җил кебек исеп кенә киттеләр, шундук онытылдылар. Ирек, чәчәкләрне ишектән биреп, кемгә тапшырырга икәнен әйтте дә канатланып кайтып китте...

Ике көннән соң ана Зәнфирә чылтыратты. Аның таныш тавышын Ирек тын да алмыйча тыңлады.

—Рәхмәт, Ирек... Ә шигырең...—Зәнфирәнең үксегәне ишетелде.— Шигыреңне укыйм да укыйм...

Аны тынычландырырга, әрнүле уйларын куарга кирәк иде.

—Хәлең ничек соң?

—Әйбәт. Ә малаем сиңа охшаган...

—Ничек миңа охшасын инде ул?

—Белмим... Ирек дип исем кушсак, ачуланмассыңмы?

—Шатланырмын гына,—диде ул яшерен куану белән.—Ирек дигән нәрсә никадәр күбрәк булса, шулкадәр әйбәт бит...

—Монда ашыктыралар, хуш!—диде Зәнфирә.

Арыган, кәефе кырылган чакларда Ирек гел шушы сөйләшүне

хәтереннән уткәреп юанды. Бар чакта кадерен дә белмәгән әйберләрнең, югалткач, бәләкәй генәсе дә никадәр кадерле икән!

Беренче июнь Ирекккә әйтеп бетергесез зур шатлык алып килде. Әлмәт театры Болынкырда аның пьесасының премьерасын күрсәтте. Мона Мэлс абыйсы Ирекτән дә ныграк куанды. Ул төштән соң ук хатыны Нәфисә белән иттер-балыктыр, кыяр-помидордыр төяп килеп житте. Дүртләр тирәсендә Ирек Сөембикәгә дәште һәм ике хатын-кыз кичкә кадәр аш-суга маһирлыкларын берләштереп, уртак табын ижат иттеләр.

Зал шыгрым тулы, Арсланов, Гаскәров, Шәвәлиевләр дә, алардан башка житәкчеләр дә күп иде. Комедиянең карьеристларга, булыр-булмас житәкчеләргә юнәлдерелгән көлү утын театр күп мәртәбәләр көчәйткән булып чыкты. Ирек, спектакльне карап утырганда, төп геройның үз-үзен тотышы белән дә, холык-фигыле белән дә Шәвәлиевне хәтерләтүен күреп, хәйран калды. Ул һич тә аны күздә тотып язмады, әлбәттә, режиссер да Болынкырның икенче секретаре турында берни белмичә куйган, бу очраклы туры килү иде. Зөфәр Шәрипович өчен кыенсынудан Ирекнең колаклары ут янды, ул Ирек хакында «эт тә кеше икән, мине оятка калдырды бит» дип утырадыр кебек тоелды. Халык исә әллә шул геройның таныш булуына, әллә әсәрне яратып, туктаусыз көлде, гөрләтеп кул чапты. Спектакль тәмамлангач, Ирек белән режиссерга, артистларга кочак-кочак чәчәк бәйләмнәре бирделәр. Мэлс абыйсы чәчәген тапшырганда, кулын күтәреп, халыкны тынычландырды:

—Бүгенге тамашада аңлаган кешегә сабак алырлык әйберләр күп,—диде.—Ә аңларга теләмәүчеләр барыбер аңламаслар. Рәхмәт сезгә!

Аңа зал шаулатып кул чапты. Мәртәбәле концерт-спектакльләрдә тамаша оештыручыларга рәхмәтне идеология секретаре үзе әйтә һәм моны халык инде күптән белә иде. Бу юлы да сәхнәгә Шәвәлиев күтәрелде.

—Болынкыр тамашачылары исеменнән Әлмәт татар дәүләт драма театры артистларын, режиссерны һәм яшь драматургны бүгенге премьера белән чын күңелдән котлыйсы, аларга яңадан-яңа ижат уңышлары телисе килә,—дип башлады ул.—Театр коллективы әсәрне сәхнәләштерү өчен гаять зур тырышлык куйган, авторның кимчелекләрен дә яшерер дәрәжәдә тамаша оештырган. Шул ук вакытта Сабитов үзебезнең жирле автор булганлыктан, аңа кайбер тәнкыйть фикерләре әйтсәк тә, үпкәләмәс дип уйлыйбыз. Күргәнегезчә, монда тормышыбыздагы кайбер тискәре типлар тәнкыйть уты астына алына. Ләкин алар хакыйкатьтән шулкадәр ерак ки, шулкадәр карикатура хәлендә ки, инде андыйларның житәкчелек аренасыннан киткәненә илле-алтмыш ел гына түгелдер. Козыреклы фуражка, френч, галәфи чалбар һәм күнитек кигән Бывалов тибындагы персонажларның тәрбияви йогынтысы инде юк дәрәжәсендә. Киләчәктә авторга да, театрга да тормышка сизгеррәк карарга, бүгенге геройларны хәзерге көн авырлыкларын үз иңнәрендә күтәреп баручы гадел һәм намуслы партия работникларын гәүдәләндерү юнәлешендә эзләргә чакырасы килә. Сезгә тагын бер мәртәбә уңышлар, безгә ешрак килегез!

Шәвәлиев залга карап сөйләгәндә, Ирек аның артка кушырып куйган кулларына игътибар итте. Шәвәлиевнең куллары калтырый, бармакларын ул кая куярга белми, бер-берсе белән аралаштыра, бау ишкәндәй ишә, кыса, боргалый иде.

Халык таралгач, барысы да Ирекнең фатирына кайттылар. Табын мул иде. Сөембикә белән Нәфисә туктаусыз йөгерделәр, кыстый-кыстый сыйладылар, матур-матур тостлар әйтелде. Жыр-бию, күңел ачу таңга кадәр дәвам итте. Ниһаять, артистлар да, Мэлс абыйсы да китте, алар икәү генә калдылар. Сөембикә өстәлләрне жыештырырга кереште. Ирек аны беләгеннән кочып туктатты, күңелендәге кичерешләр давылын аңлатырлык сүзләр эзләде. Ләкин ул сүзләр табылмады, әмма нәрсәдер булырга тиеш иде.

—Сөембикә...

Сөембикә аңа буйсынучан күзләре белән йотылып карады.

—Әүем лә...

—Язмыш безне юкка гына очраштырмагандыр...—карышмыйк без аңа...

—Мин сине аңлап бетермим, Ирек абый.

—Сиңа бергә булырга кирәк.

—Кем белән?

—Минем белән...—Ирек аны озак итеп иреннәреннән үпте.

—Синең, Ирек, салгач, әзрәк нитеп китә торган гадәтең бар.—Сөембикә бармагы белән чигәсенә күрсәтте.

—Юк, Сөембикә,—диде Ирек, аңа гаять җитди карап.—Син миңа күптән ошыйсың. Безгә өйләнешергә кирәк.

—Ошаган өчен генә өйләнәләрме соң?

Ирек кул селтәп куйды.

—Ярар инде, миннән төче сүзләр көтмә син. Утны сүндерәм...

—Юк, юк!

Сөембикә ишеккә ташланды.

—Нигә?

Бераз дәшми торганнан соң, Сөембикә читкә караган килеш, акрын гына:

—Син аның янына... больницага баргансың икән,—диде.

—Кем әйтте?

—Бөтен райком сөйли...

Ирек башын түбән иде.

—Бардым шул...

—Бакчадагы чәчәкләрне алып баргансың...

—Каян беләсең?

—Аларны бит мин утырткан идем.

—Гафу ит... Тик ышан: мин бары тик аның исән булуын гына теләдем...

—Синең күңелең һаман аның янында...

—Юк, дөрес әйтмисең. Мин анда түгел, ул минем җанымда! Аерылгысыз береккән.—Ирек, өстәлдән пычак алып, Сөембикәгә сузды:—Мә, әгәр булдыра алсаң, өзеп ташла аны!

—Аллам сакласын!—диде Сөембикә, ишеккә таба чигенә-чигенә.

—Мин дә көчсез! Мин дә өзеп ташлый алмыйм! Җаннар кушылган, ә тәннәр аерым. Бәлкем язмыш синең белән очраштыру өчен шулай эшләгәндер?

Сөембикәнең зәңгәр күзләре түгәрәкләнделәр, еш-еш тибрәлүче керфек очлары дымланды.

—Җанында урын булмагач... бергә яшәп булмый, Ирек. Булмый!..

Ирек, аның иңнәреннән кочып, колагына пышылдады:

—Урын бар. Сиңа гына... Гөнаһлы ташламалар аша... Кушылыйк!

—Мин куркам!!!

—Нәрсәдән?

—Белмим... Ләкин куркам!

—Бар, кайтып кит алайса! Күземә күренмә!—Ирек утырды да, беләкләрен өстәлгә куеп, башын салды.—Минем күңел кылларында кабат бер генә былбыл да сайрамаячак!..

—Сайрар, Ирек, сайрар...

—Ул кыллар әлегә синең өчен генә торалар иде. Син булмасаң, өзеләчәкләр һәм коточкыч фаҗига...

—Нинди фаҗига?

—Ялгызлык... Мәңгелек ялгызлык упкыны...

Ирек ярты стакан аракы салды, авызына китерүгә, Сөембикә аның кулына китереп сукты, стакан өстәлгә чәчрәде.

—Юк, юк, мин сине упкынга бирмим!—диде ул, аның битләрен, күзләрен кат-кат үбеп.—Синең белән горурланырга тиешләр!

—Кемнәр?—дип сорады Ирек, битараф тавыш белән.

—Мин, без, бөтен халык! Син башкалар төсле түгел. Син язарга тиеш! Яз, яз гына! Мин сине ялгызлыкта калдырмыйм!

—Алайса бүген үк минем белән каласың!

—Юк!

Ирек кинәт селтәнеп урыныннан торды да, йокы бүлмәсенә кереп, караватына капланды. Сөембикә, савыт-сабаларны юып, җыештырып бетергәч, Ireккә дәште:

—Мин киттем, ишегенне бикләп ят.

Ирек йокларга уйламаган да иде. Ул торып, Сөембикәне озатып куйды, әмма алар икесе дә ләм-мим бер сүз дә әйтешмәделәр...

Иртән ул, китапханәгә чылтыратып, кичәге дорфалыгы өчен Сөембикәдән гафу үтенде һәм аны редакциягә чакырды. Сөембикә көттермичә килеп тә житте. Аның йокысызлыктан күз төпләре күкшелләнеп тора, йөзе агарып калган иде.

—Йә, ничек йокладың?—диде Ирек.—Ялгызың әйбәт булдымы?

—Рәхмәт, әйбәт йокладым. Ялгыз йокларга күнеккән мин.

—Син минем кичәге тәкъдимне салган баштан гына әйтте дип уйламагансыңдыр бит, Сөембикә?

—Юк.

—Җавабыңны әйт.

Сөембикә озак кына дәшмичә торды, күз карашын нишләптер аңардан яшерде.

—Ашыкмыйк әле, Ирек. Син дә, мин дә ныклап уйлыйк...

Шуның белән сүз бетте.

* * *

КПСС өлкә комитетының беренче секретарен каршылау өчен район дәррәү аякка бастырылды, көн белән төн бергә буталды. Ирекләр район үзәге учреждение-оешма кешеләрен, мәктәп укучыларын алып барып, ферма торакларын тирестән арындырдылар, юдырдылар, агарттырдылар; һәр терлекченең эш урынына калайга, фанерга йөкләмәләрен, аларның үтәлешен килограммнарда, центнерларда, процентларда яздылар. Сыерлар, симертүдәге маллар, бозаулар, дуңгызлар кер порошогы белән әйбәтләп юылды. Ирекнең кул астында финанс бүлеге һәм больница хезмәткәрләре иде. Шунда бер чая теллесе:

—Иптәш Сабитов, бу дуңгызларның борыннарына иннек тигереп, битләренә кершәк сөртеп, каш-керфекләрен каралтып, әзрәк хушбуй сибеп, муеннарына төймә таксак, әйбәтрәк булыр иде бит!—диде.

Бөтенесе шаркылдашып көлделәр. Ireккә көләргә ярамый иде, ул тешләрен кысып, читкә борылды һәм китеп барды...

Урамнардагы коймалар юылды, җимерелгәннәре төзәтелде, электр-телефон баганалары, авыллардагысы гына түгел, юл буендагылары да кеше биеклеге югарылыкта известь белән агартылды. Район үзәге, бигрәк тә зуррак оешма, учреждение тирәләре кат-кат себерелде, кибет киштәләренә зур кунак килгән көнне тезү өчен халык гомер-бакый күрмәгән товарлар кайтартылды.

Казан кунагының яратып ашаган ризыклары, яратып эчә торган эчемлекләре—бөтенесе-бөтенесе ачыкланды. Иң оста пешекчеләр сайланып, аны ашату-эчертү урыннары билгеләнде, шуна җайланмалар эшләнде, команда бирелүгә, йөзләрчә кеше секунды-минуты белән дәррәү эшкә керешәчәк иде. Кунакның күңеленә хуш килердәй кыяфәтле һәм гадәтле иң чибәр, иң сылу кызлар кат-кат тикшереп сайлап алынды, аларга милли киемнәр тектерелде. Чачаклы сөлгеләр белән чәкчәк тотып, мәртәбәле кунакны шул кызлар каршыларга, аңа хезмәт күрсәтергә тиешләр иде.

Ул атнада секретарь килмәде, ашыгыч рәвештә Л. И. Брежнев үзе Мәскәүгә чакырып алган, диделәр. Тагын яңадан-яңа күрсәтмәләр алынды,

тагын ыгы-зыгы купты, хуҗалык җитәкчеләре, белгечләр, хәрби боерык көткәндәй, югарыдан фәрман төшкәнне энәгә баскандай кыбырсып көттеләр, ашаулары—ашау, эчкәннәре—эчү, эшләгәннәре—эш, йокылары йокы булмады.

Секретарь бу атнада да килмәде. Болынкырда гына түгел, күрше дүрт-биш районда да шушындый хәл икән, өлкә комитеты секретаре аларга да барачак икән. Нервылар киеренке, күңелләрдә тынычлык юк, бөтенесен дә бер олы курку чолгап алган иде.

Ниһаять, яңа хәбәр ишетелде: алдагы атнаның җомгасы, бернинди үзгәреш булмаячак, диделәр. Дәүләт куркынычсызлыгы комитетыннан Дәүләтьяров үзенең ике сотруднигы белән килеп, кунак йортына урнашты. Аларны, Арсланов бүлмәсеннән башлап, автовокзалда, кибетләрдә һәм башка җәмәгать урыннарында күрергә мөмкин иде.

Районда купкан әзерлек мәшәкатьләре белән турыдан-туры Шәвәлиев җитәкчелек итте. Шушы мәшәкатьләр аркасында КПСС Үзәк Комитеты Генераль секретаре Л. И. Брежневның «Кече җир» һәм «Янарыш» китаплары буенча конференция уздыру кичектерелеп тора иде. Аны нәкъ менә өлкә комитеты секретаре килгән көнгә туры китерергә кушылды. Аның катнашачагын искәрттеләр. Бу хәбәр Шәвәлиевнең тагын нечә чәчен агарткандыр, бер Ходай үзе генә белә. Докладны Иреккә тапшырдылар. Чыгыш ясаучыларны әзерләү инструкторларга бүлеп бирелде. Зөфәр Шәриповичның эшләрне контрольдә тота торган калын кенәгәсе бу көннәрдә фамилияләр, башкарасы эшләр, үтәлү вакытын күрсәткән язулар белән аркылы-торкылы чуарланып бетте. Ул үзе дә төс ташлады, һәркемне көнләштерерлек пөхтәлеге-көязлеге нәрсәсендер югалтты, йокысызлыктан, көне-төне тарткалашудан куллары җиңелчә генә калтыранды, башы авырайды.

Ниһаять, олы кунак иртәгә килеп төшәчәк!

Зөфәр Шәрипович бүген иртәнге чәйгә дә кайта алмады. Ашказанының борып алуы аны сәгатенә карарга мәҗбүр итте: ун тулып килә икән ич. Хәзерлек эшләрен соңгы мәртәбә тикшереп чыгу өчен унберенче яртыга шактый җитәкчеләрне чакырткан иде. Шуңа күрә тамак ялгап алу өчен өенә ашыкты. Хатыны эштә иде, бер кашык сәйлүн чәен пешереп алды, дегет кебек каты итеп чәй ясады, лимон белән шикәр салып болгаткач, кабаланып, чынаягыннан гына шопырган иде, авызын пешерде. Ачудан чынаягын этеп куйды да кызулап залга чыкты. Баядан бирле күңеле нидер искәртә, нидер онытылган иде. Нәрсә? Инде бөтенесе каткат уйланды, Арсланов белән килешенде бит, югыйсә. Ул диванга утырды, үз-үзен тынычландырырга тырышты. Нәрсә онытылды? Моңа җавапны салкын акыл гына табачак... Ләкин еряктан якынаеп килүче тытырдаган тавыш аңа фикерен тупларга ирек бирмәде. Бу—вертолет тавышы иде. Зөфәр Шәрипович нindidер начар сизенү белән телефонга атылды, Нәҗмиевне җыйды, ул исә буылып аңа җикерде:

—Син кайда йөрисең?! Килеп төште бит!

—Кем?!—диде Зөфәр Шәрипович, инде аның кем икәнлеген аңласа да.

—Әнәннең башмагы!—диде Нәҗмиев, трубкасын атып.

Димәк, аларны әзерлексез хәлдә каптыру өчен бүген секретарь капылт килеп төшкән! Ә «Кече җир», доклад, конференция? Чәкчәк тотып каршыласы кызлар?.. Ул өйдән, пуля кебек атылып, машинасына чыкты, кабызыйм дисә—ачкычы юк. Кабат йөгереп керде, өстәл өсләрен, әле генә үзе утырган диванны карады—таба алмады. Ачкычка әле медаль кадәр сары түгәрәк әйбер дә асылган, шул арада кая китәргә мөмкин? Ул, юләр кеше шикелле, өй буйлап чапты, хәтта йокы бүлмәсенә кереп, мендәрләрне атып-атып бәрде. Хатыны кичә, каз мамыгы тутырып, яңа мендәр ясап маташкан иде, күрәсең, авызын текмәгән, аның йоны бөтен дөньяга чәчелде. Зөфәр Шәрипович, шул йоннар арасыннан чыгып,

тагын өстәл янына килде. Тукта, бу нәрсә? Өстәлдә бөтен лимон тора. Ул бит аны кисеп чәйгә салган иде. Чәшкесендәге калагын төптән кысыбрак күтәрсә—теге таккан сары шөлдере белән машина ачкычы килеп чыкмасынмы! Ул тагын урамга атылды, аэропорт ягыннан вертолет тавышы ишетелә иде әле. Аның эченә жылы керде, бәлкем өлгереп тә булыр дип уйлады һәм, бик ашыгычта гына йөри торган иске елга аша турыга бәрдерергә уйлап, ярдан төште. Суы гомергә тездән күтәрелмәгән чокырның уртасына машина чәжлап керде дә гөпердәп сүнде. Ул, ачкычын борып, стартерын туктаусыз гүелдәтте—мотор кабынмады. Зөфәр Шәрипович чарасызлыктан ике йодрыгы белән рульне куллары авыртканчы төйде... Сикереп төшәргә тездән лай, сынар жан иясе дә юк, моннан да яман хәлнең булуы мөмкин түгел иде! Кинәт ул яр өстендә уйнаучы малайларны күреп алды, машинаның сигналын акыртты, ишеген ачып, кул изәде. Малайлар йөгерешеп килеп життеләр, алар шәрәтән иде, күкрәкләреннән лайлы суга керделәр. Зөфәр Шәрипович, машинаны этәргә кушып, аларга кулларын болгый-болгый аңлатырга тотынды. Шулчак... шулчак аның кулыннан ачкычы ычкынып китте һәм ике генә адым читкәрәк суга барып төште. Ул:

—Алыгыз инде ачкычны тизрәк!—дип өзгәләнде.

Малайларның берсе дә кымшанмады, алар күтәрелеп көлделәр.

—Алыгыз инде, зинһар, ал!—дип үрсәләнде ул, төпкә бата-бата ерагаючы ачкычтан күзен алмыйча.

Малайлар буйсынырга теләмәделәр, суда сикерешә-сикерешә шаркылдаштылар. Ни гажәптер, ачкыч батмады, судан чыгып үскән бер уч күрән төбенә барып терәлде, агым тәэсирендә теге сары әйберсе селкенеп тора башлады. Зөфәр Шәрипович шуна төртеп күрсәтә-күрсәтә ялварды, алып кына бирегезче, дип үтенде, тыңламадылар. Ахырда ул, аягы таеп китеп, үзе шул лайлы суга барып төште, ачкычны эләктерде, кабат машинасына сикереп утырды, бер боруга, машина дөртләп кабынды һәм судан үкереп чыгып, ярдан менеп тә китте. Куллары, өсте-башы ялтырап торган ләпек булса да, ул бернигә игътибар итмәде, райкомга таба очты.

Анда халык жыелган, уртадан юл ачык, димәк, әле кунак килеп житмәгән иде. Зөфәр Шәрипович, машинасын читкә куеп, ишеккә таба йөгерде һәм йөрәге ярыла язды: райкомның юан машинисткасы белән пенсия яшендәге бер күзле жыештыручы чачаклы сөлгеләрдә чәкчәк, ипи-тоз тотып торалар иде! «Кемдер мине яндыру өчен эшләгән!»—Шул уй аның миен көйдереп узды. Ул икенче катка таш баскычның өч аратасын бер генә сикереп менеп килгәндә, каршысына чәчләре-башлары тузган Арсланов белән Нәжмиев килеп чыкты.

—Менә ул, Шәвәли сволочь!—дип, авызыннан ут чәчте Арсланов.—Син бит белгәнсең аның бүген киләсен! Ник яшердең?!

«Белмәдем, честное партийное, белмәдем! Бу нинди дер аңлашылмаучылык!» дип кычкырырга теләде Зөфәр, әмма авызы ачылган килеш тартышты, тамак төбеннән бер генә тавыш та чыкмады. Арслановның күзләре ерткыч жанварныкы төсле коточкыч зурайганнар иде.

—Мин сине хәер сорашырга чыгарып жибәрәчәкмен!—дип үкерде ул котырынып.—Партбилетыңны бир, сволочь!

Арсланов бугазыннан эләктереп алды, Зөфәр аның киселмәгән озын тырнакларының тәненә ертып керүен тойды, Нәжмиев, маңгаена төшкән чәчләрен сыпыра-сыпыра йөгереп килеп, икесен дә сөзеп жибәрде, алар баскычтан аска мәтәлделәр...

... Зөфәр Шәрипович үзенең коточкыч тавыш белән кычкыруына тетрәнеп уянды, беркадәр вакыт, йөрәге дөп-дөп типкән хәлдә, һични аңышмыйча торды. Иң элек кесәсендәге ачкычын барлады, төш кенә күргәнлеген аңлагач, жинел сулап куйды, маңгаендагы тирләрен сөртте. Жир йөзендә бу минутларда аңардан да бәхетле кеше юк иде! Ясап куйган чәе әле суынырга да өлгермәгән, берничә минут эчендә шулкадәр кичерешләр аша узуына ул хәйран калды...

Зөфәр Шәрипович үзенә чакырылган җитәкчеләрнең һәрберсен күтәренкелек белән кабул итте. Төштән соң беренче кеше булып, район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары килде. Аның берүзенә йөз төрле эш йөкләнгән иде. Зөфәр Шәрипович, барысы белән дә вакланып тормастан (чөнки ул бу мәсьәләләрдә азау ярган кеше), ат картасы турында белеште. Алар олы кунакның яшь тай картасына маһирлыгын, барган бер җирдә аны шуның белән сыйлауларын беләләр иде. Ул суярга ничә тай әзерләнгәнлеген, аларның кайда тотылуын, кемнәр суячагын, ыслаган кабан боты, каклаган казлар, кәрәзле баллар хәзерләнгәнен, мунча ягу һәм кертү тәртибен җентекләп сөйләп бирде. Район кулланучылар җәмгыяте председателе белән өстәл әзерләү, балык шулпасы пешерү, өстәлгә нинди балыклар кую, кайсы ризыкны кайчан бирү, эчемлек төрләре кебек нәрсәләр уртага салып сөйләшенде. ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Әхнәф Шәрифуллин белән мәдәният бүлеге мөдире Азат Харисов күңел ачу өлеше буенча җавап тоттылар. Соңгы кеше итеп, эчке эшләр бүлеге начальнигы чакырылган иде. Секретарьны каршылау, кунак итү, озату, иминлеген тәэмин итүнең адымын-адымга күздән кичерделәр. Ул инде Дәүләтьяровлар катнашында әллә кайчан эшләнеп куелган, кирәкле төймәсенә басуга, бөтенесе хәрәкәткә киләчәк иде. Ахырда Зөфәр Шәрипович:

—Бөҗәкләргә каршы чаралар бармы?—дип сорады.

—Ун күрүк әзерләдек,—дип җавап бирде майор.

Былтыр Мәскәүдән зур бер министр килгәч, алар кичкырын бөтен җирне ыслап чыкканнар, ә инде ашап-эчеп утыра торган урынны агачлар арасында ерактӑн, берни сиздермичә, күрүкләр белән чебен-черкидән саклаганнар иде. Әз генә черки күренә башлауга, милиция начальнигы рациядән фәрман юллый һәм тирә-юньдә сыек кына, күренер-күренмәс төтен элпәсе барлыкка килә. Мәскәү кунагы рәхәтләнеп ашап-эчкәндә, су коенганда, аптырап:

—Ничек сездә черки юк соң?—дип сорарга мәҗбүр булды.

—Сез килгән хөрмәткә мин аларга ял бирдем,—дип көлдергән иде кунакны Арсланов.

Соныннан моны Зөфәр Шәрипович уйлап тапканны белгәч, Беренче рәхәтләнеп көлде, «башың ай-яй йомры синең!» дип мактады...

Ул бүлмәсенә кабат беркемне дә кертмәскә кушты да Ирек кичә машинкада бастырып куйган докладны укырга кереште.

* * *

Өлкә комитеты секретареның кичәдән бирле кәефе булмады. Аның язгы чәчүдән соң республика районнарына беренче чыгуы иде. Вертолеттан басуларның торышы, чәчкән чакта җибәрелгән гөнаһлар уч төбендәге кебек ярылып ята. Игеннәр матур гына күтәрелеп килә, уҗым культураларының саргайган, сирәкләнгән урыннары кышкы салкыннар тиюе турында сөйли. Димәк, арыш, көзге бодай уңышы былтыргыдан кайтышрак булачак. Аның каравы, яшел дингез булып күтәрелеп килүче сабан ашлыкларының торышы күңелдә ышаныч уята. Бәрәңге, чөгендер, кукуруз басулары инде чүптән арындырылган. Чөгендер плантацияләренең һәрберсендә халык чәчүлекләрне эшкәртә, сабантуйларга кадәр кулын чишеп, җилел суларга омтыла. Барысы да әйбәт кебек, әмма бу үстерелгән игеннәрнең күпме өлеше генә үзебездә калыр икән соң? Казахстанда, Ставрополь краенда, Волгоград өлкәсендә корылык, Мәскәүнең бөтен өмете бу тирәдә. Кичә КПСС Үзәк Комитетының авыл хуҗалыгы секретаре телефоннан шушы араларда икмәк мәсьәләсендә бик каты сөйләшүгә чакырачакбыз, бер ярым-ике план үтәргә әзер торыгыз, диде. Бу инде үстерелгән ашлыгына кул сыртын белән дога кыл, дигән сүз. «Без бит терлекләрнең баш саны буенча иң югары урыннарның берсендә торабыз, шулай булгач...» дип дәлилләр китерә башлауга, Үзәк Комитет секретаре ялгап алып

китте: «Шулай булгач, без бирѳдә хисапладык, итен дә, сөтен дә күбрәк сатачаксыз. Халыкны туйдырырга кирәктер бит?» Анысын һәркем белә. Тик нишләп гел безнең хисапка соң? Нефть ташкын булып бездән ага, ә шуна бәрабәр пычранган җирләр, кешесез авыллар кала. Кереме— тавыклар көләрлек. КамАЗга бик зур өметләр багладылар, аны төзегәндә күрмәгән нәрсә калмады. Хәзер завод конвейерыннан машиналар ташкын булып агыла, әмма көн үткән саен, берсеннән-берсе четереклерәк проблемалар тудыручы бу заводнын, Чаллы дигән бу шәһәрнең республикабыз өчен печтеки дә файдасы юк диярлек. Татар акылы төштән сон, дигәннәре шушы булды, ахрысы. Безнең бүгенге көчәнүләребезне киләчәк буыннар ничек бәяләр тагын—анысы нәмәгълүм.

Болынкы аэропортында аны Арсланов, Гаскәров, Батталов каршы алды. Райком алдына сабантуйдагы чаклы халык җыелган, ул аларнын сәламләвенә башын ия-ия җавап бирде. Аэропорттан райкомга кадәр юлның асфальты, вак ташлары чыгар дәрәҗәдә юылган, су белән сиптерелгән иде. Ана бу нәрсә ошамады. Кая гына барсан да, артык кылану күзгә бәрелә, мондый нәрсәләр сине халык алдында кыен хәлгә куя. Кайчандыр республика җитәкчеләрен Казанга бер зур гына киңәшмәгә җыйгач, ул бу мәсьәләдә кайбер район җитәкчеләрен юмор беләнрәк, үз итеп кенә битәрләп үткән иде. Шул киңәшмәдә катнашкан Үзәк Комитет инструкторы соңыннан, кабинетка кергәч, туп-туры канәгатьсезлек белдерде:

—Сез болай әйтергә тиеш түгел идегез,—диде ул, бик җитди итеп.— Әгәр сезгә кадер-хөрмәт күрсәтәләр икән—бу сезгә генә түгел, беренче чиратта, партиягә хөрмәт күрсәтелә дигән сүз. Халык өчен бу табигый халәткә әверелергә, аның канына сеңәргә тиеш!

Кызлар кулындагы ипи-тоздан, чәкчәктән авыз иткәч, алар Арсланов бүлмәсенә керделәр. Биредә өстәл тулы ризык иде.

—Бераз тамак ялгап алыйк,—диде Арсланов.

Ул ашаудан баш тартты, шикәрсез-нисез генә ярты чынаяк чәй эчте, Батталовнын хәлләрен сорашты. Җирдән мәнге аерылмас бу кешенен шактый нык бирешкәнен күреп, аның күнелендә кызгану хисләре уянды һәм ул шуны яшерү нияте белән:

—Син, Гайсә Батталович, гел бер килеш торасың, әле яшәребрәк тә китмәден микән?—диде.

Батталов аның сүзләрен элэктереп кенә алды:

—Безнең яшәрү Иванның яшәрүе кебек инде ул...

Барысы да, нindидер хикмәтле сүз чыгасын сизенеп, ана төбәлделәр.

—Анысы тагын нинди була?

—Иван, Степан, Николай исемле өч дус булган. Гомер буе баш күтәрмичә эчеп йөргән чакта, бер мәлне Иван махмырдан үлеп киткән. Урыслар бит мәетне безнең кебек көнендә кабергә илтеп тыкмый, берничә көн хушлашалар. Менә Иванны җирләр көн җиткән. Исереп яткан Степан белән Николайны хатыннары, көч-хәл белән аякларына бастырып, Иванны соңгы юлга озатышырга җибәргәннәр. Кергәннәр болар өйгә. Ята икән Иван табутта. Шоп-шома итеп кырындырылган, чәчләре таралган, үтүкләнгән күлмәк-костюм кигерелгән, өстенә хушбуйлар сибелгән. Николай пышылдый икән дустына:

—Степа, карале юри генә Ваняны! Ничек матурланган, бит очлары алланып, яшәреп киткән!

—Ничек яшәрмәсен?!—ди икән Степаны.—Уйлап кына кара: хәзер өч көн эчми бит инде ул!

Бөтенесе күтәрелеп көлделәр.

—Юри мескенләнә, әле безне ишекле-түрле куып йөртә ул,—диде Арсланов.

Конференцияне башлар вакыт житте, барысы да залга атлады. Өлкә комитеты секретаре күренүгә, халык дәррәү басып кул чабарга тотынды. Ул баш иде, елмайды, күкрәгенә кулын куеп сәламләде, әмма алкышлар көчәйгәннән-көчәя генә барды, чөнки Арсланов үзе шапы-шопы кул

чаба иде. Кул хәрәкәтләре белән туктарга кушулар да, йөзгә канәгатьсезлек билгеләре чыгарып баш чайкаулар да халыкка тәэсир итмәде, алар бары тик Арслановка гына буйсыналар иде. Ахырда секретарь утырырга мәҗбүр булды, шуннан соң гына залдагылар акылларына килделәр. Арсланов конференцияне ачык дип белдергәч, трибунага чал чәчле, күкрәге орден-медальләр белән тулы ветеран чыкты.

—Кадерле иптәшләр!—диде ул гаҗәеп көчле тавыш белән.—Советлар Союзы Маршалы, ике мәртәбә Советлар Союзы Герое, Социалистик Хезмәт Герое, КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Леонид Ильич Брежнев җитәкчелегендәге Үзәк Комитет һәм Политбюро составында конференциянең почетлы президиумын сайларга тәкъдим итәм!

Залдагы бөтен халык басып, тәмам хәлдән тайганчы кул чапты. Аннары эшче президиум сайланды, көн тәртибе расланды, Арсланов доклад сөйләргә кереште. Каршыдагы һәм сул яктагы тәрәзәсез стенага буеннан-буена ат башы кадәр хәрефләр белән «Заманыбызның бөек әсәрләре» дип язылган, «Кече җир», «Янарыш» китаплары ясалган, фоторәсемнәр, әлеге әсәрләрдән өзекләр, тагын әллә нәрсәләр урнаштырылган иде... СССР дигән бөек илнең барлык төбәкләрендә миллионнарча кешеләрне җыеп, әлеге «гениаль» китаплар турында күкрәк суга-суга сөйлиләр, әле тагын ничә еллар сөйләрләр, тау-тау хезмәтләр язарлар, фәнни дәрәҗәләр, дәүләт бүләкләре алырлар. Менә бүген ул да, йөзенә үтә житди кыяфәт чыгарып, әнә шул трибунага күтәреләчәк. Әгәр кемнәрдер әвәләгән шушы ике брошюрага берәр төрле әдәби премия биреп куйсалар? Әйтик, Ленин премиясе. Бу башка да сыярлык хәл түгел һәм, әлбәттә, ул кадәр ахмаклыкка бармаслар, әлбәттә, бирмәсләр. Әмма моның бездә булу ихтималы да бар! Иң хәтәре әнә шул ихтималлыкның яшәвендә!

... Быел февраль аенда ул Брежневка бик мөһим документка кул куйдырырга кергән иде. «Кече җир»нең әле чыккан гына чагы. Кул биреп күрешкәндә үк ул, күпме булдыра ала шулай елмаеп:

—Леонид Ильич, сезне уникаль әсәрегез белән тәбрик итәм!—диде. Китапны әле укып чыгарга өлгермәгән булса да:—Сезнең искиткеч политик тәрбияче икәнегезне «Кече җир» безгә тагын бер мәртәбә төшендерде,—дип өстәде.

—Рәхмәт, рәхмәт,—диде Брежнев телен, кысан оясында җәнлек кытыршы әйбергә ышкынгандай, көч-хәл белән әйләндереп.

Ләззәтле дулкынланудан аның авызы чап-чоп килде, ирен почмаклары елтырый башлады. Нинди гозер белән килүен әйтеп, документны кулына тоттыргач, Леонид Ильич алтын кысалы күзлеге аша кәгазьләргә төбәлде. Аның авыр ирен нәре, бүселеп төшкән саллы ияк аслары бөтен битен аска тарталар, шуңа бирешмәс өчен ул мәче койрыгыдай калын кашларын тырышып-тырмашып өскә күтәрә төсле тоела, ияк асларында, муенында сизрәгән марляның өзелеп бетмәгән буй җепләрен хәтерләтүче үтә дә вак җыерчыклар сизелер-сизелмәс калтыраналар иде... Имзасын салгач, Брежнев, күзлеген кулына алып, кая куярга белмичә уйланып калды, аның бу вакытта өстәлгә төбәлгән карашы бик житди иде. Ахырда ул дөрес рекогносцировка ясап, күзлеген ышанычлы урынга куйды да, җинел сулап, авызын шапылдатты. Секретарь, документны алып, кат-кат рәхмәт укыды, аны кунакка чакырды, татарстанлылар сезне көтәләр, диде.

—Да-һ-а,—диде Генсек.—Аһандый таһарихи ваһакыйга буһулырга мөһемкиһин...

Аның чап-чап килгән авызыннан теленең шыштырдап йөрүе ишетелгәндәй булды. Кинәт Леонид Ильич як-ягына каранды, күзләрендә нindидер наянлык очкыннары чагылды һәм ул имән бармагы белән аны үзенә чакырды. Торып якын барудан бүтән чара калмады.

Брежнев кесәсеннән елтыравыклы нәни тартма чыгарды да иелеп

ачарга кереште. Шулчак секретарь нишләптер аның колакларына игътибар итте: алар пластмассадан ясалгандай хәрәкәтсез һәм төссез иде. Ниһаять, Леонид Ильич теге әйберне алып, анын учына салды. Бу—кыйммәтле ташлардан медальонга охшатып эшләнгән ядкарь булып чыкты. Аны туры тотсаң, Брежнев сурәте, бераз авыштырсаң, Мәскәү Кремле искиткеч төсләр белән балкый иде.

—Коһостя Чеһерненко әһәллә ниһичә бүһүләгеһемне таһартыһып аһалды иһинде.—Леонид Ильичның әле генә елап туктаган кешенекедәй яңгыраган һәр сүзе күкрәгеннән зур егәр белән этелеп-этелеп чыкты.—Коһостя күһүрсә, моһонысын да эһеләктеһерәчәк...

Генеральный сүзләрендә хаклык бар иде. Әле дә күз алдында, СССР профсоюзлар съездында булса кирәк, Брежневка ниндидер сувенир тапшырдылар. Ул президиумда, гадәттәгечә, КПСС Үзәк Комитеты секретаре, Политбюро әгъзасы Константин Устинович Черненко белән янәшә утыра иде. Сувенирны Леонид Ильич тотып карый башлауга, аны Черненко шартлатып тартып алды да читкә куйды. Съезд делегатлары да, чит ил кунаклары да моңа бик сәерсенделәр, залдан жинелчә генә пышылдау дулкыны узды. Шулчакта аның артында гына пышылдашканнары бүгенгедәй хәтердә калган:

—Ул аның сувенирын түгел, чит ил житәкчеләре бүләк итеп биргән машиналарын алсын иде...

—Кырыктан артык диләрме?

—Алтмыштан арткан инде...

Шулчак ишектә аның ярдәмчесе күренде. Брежнев аның кулыннан ядкарьне тартып алды да ялт кына кесәсенә салды һәм авыз эченнән генә:

—Уһурыныңа сеңǃ—диде.

Ярдәмчесе өстәлгә кәгазьләр китереп салды.

—Гафу итегез, ашыгыч эш килеп чыкты.

Секретарь хушлашып ишеккә таба кузгалуга, Брежнев аны туктатты.

—Сеһез ниһиндидер доһокументка иһимза киһирәк диһигән иһидегез бугай?..

—Сез ана кул куйдыгыз инде, Леонид Ильич...

—Яһарый аһалайса...

Ишекне япкач та, ул әле генә үзе кичергәннәрдән айный алмыйча, бер тын хәрәкәтсез торды. Илнең көймәсен кемнәрдер каядыр никтер алып баралар, әмма ул рульдә дә түгел, хәтта беркем дә түгел—бусы бәхәссез иде...

... Көчле алкышлар аны күңелсез хатирәләрдән коткарды. Арсланов әле һаман доклад укый иде. Ул, костюмының жиң очын югарыга жыерып, алтын сәгатенә күз төшерде. Бер сәгать вакыт үткән! Арсланов үзе укыганнарга үзе ышанамы әллә тагы?! Очынуын гына кара. Нигә дип очына? Берсе дә чын түгел бит. Ил буенча ялган өстенә ялган. Шулай булгач, без—халыкның юлбашчылары булып саналучылар, чынында кемнәр соң? Ул үзе дә соңыннан хуплау сүзе белән чыгарга мәжбүр. Ялганның маңгаена югары сыйфат билгесе сугачак. Шулай бара бирә. Егерме елдан коммунизм була, дидек. Уналты ел үтте. Кайда ул коммунизм дигән жәннәт? КПСС Үзәк Комитеты уздырган идеология работниклары киңәшмәсендә, былтыр бугай, бер мөхтәрәм профессорны, ревизионист, оппортунист дигән ярлыклар тагын, марксизм-ленинизмга һәм социализм казанышларына яла ягуда гаепләп, трибунадан куып төшерделәр. Чыгышының мәгънәсе болайрак иде: Безнең югары үскән социализм дип атаган жәмгыятебездә халык массаларын яшерен формада эксплуатацияләү хөкем сөрә. Изүчеләрнең беренчеләре—халык житештергән байлыкларны күп мәртәбә кыйммәт хак белән үзенә сатучы спекулянтлар. Икенчеләре—эшләмичә төрле юллар белән халык жилкәсен кимерүче әрәмтамаклар. Өченчеләре—югары урыннарда утырып, бернинди законнарга буйсынмыйча, ил байлыгыннан нәфесләре күпме тели—

шулкадәр файдаланучылар. Чыгышының шушы өлешенә килеп җитүгә, аны өреп кенә төшерделәр, социализмда мондый нәрсәләр юк, дошман сүзләре болар, дип чыраена төкерделәр. Дөреслек хәтәр нәрсә шул! Ил табигатенең катастрофик төстә җимерелүе дә, җинаятьчелекнең елдан-ел үсүе дә, халык сәламәтлегенең какшавы да, башкасы да яшерелә. Димәк, дөреслектән куркабыз. Дөреслектән гаеплеләр кача, ләбаса! Үз гомереңне күз буяуга әрәм итү ифрат та аяныч, әлбәттә. Ләкин иң хәтәре ул түгел әле.

Иң хәтәре—кешеләрнең акрын гына шуңа күнегүендә. Без халыкның йөрәк тамырына ялганны наркотик итеп бирәбез, ә ул намус-вөҗданны үтерә. Сиздермичә генә вөҗдансызлар җәмгыяте барлыкка килә. Ә вөҗдансыз кеше өчен бернинди изге әйберләр дә, хәтта ата-ана да юк: ул талый, көчли, урлый, суя. Ана—улны, ата—кызны белми торган мәхшәрнең хәвефле билгеләре инде бүген үк сиземләнә. Аны тырыша-тырмаша күрмәскә омтылуыбыз белән без хаталарыбызны тагын да тирәнәйтәбез. Күп тә үтмәс, аферистлар, караклар, талаучылар, үтерүчеләр, һәртөрле вәхшиләр ил корабын басып алырлар, аның байлыкларына хуҗа булып, теләгәнчә туздырырлар, эшләүче халык хәерчелеккә һәм үлемгә дучар ителер... Бу инде тамырларын шул дәрәҗәдә тирәнгә җибәргән, бөтенесе бергә шул дәрәҗәдә чуалган ки, моны туктатыр көчләр юк: югарыдагылар аны теләмиләр, түбәндәгеләрнең берише төрле юллар белән югарыдагылар шикелле яшәргә омтыла, икенчеләре—алар күпчелекне тәшкил итә—инде тәмам арыган, алдаулардан туйган, әйбәткә өметен өзгән, гаделсезлекләр белән тарткалаша-тарткалаша яши бирә...

Соңгы вакытта аны мондый уйлар торган саен ныграк борчый башлады. Аны гына түгел, Мәскәүдә очрашкач та, гел шул хакта сүз куба.

...Тагын түшәмнәрне күтәреп кул чаптылар. Доклад бетте, Шәвәлиев беренче чыгыш ясаучыга сүз бирде һәм шуннан соң тәнәфес булачагын искәртте. Арсланов, кызарынып, мышкылдап, янәшә менеп утырды. Ул кырык минутлык докладны, өлкә комитеты секретарена ошарга тырышып, төп тексттан чыга-чыга укый торгач, бер сәгать егерме минутка сузган иде. Секретарьның нәкъ әнә шуңа ачуы килде, докладны мактап юри генә булса да ләм-мим бер сүз әйтмәде. Арсланов үз янына чүмәшүгә, аңа сырты белән янтаеп, артта утыручы Батталовка борылды, тегесе иелеп, колагын куйды.

—Себерке бармы?—диде ул пышылдап.

—Әзер, пешерелгән...

Аларның күз карашлары очрашып алды, икесе дә серле елмаештылар.

...Гайсә Батталович шушы берничә секундлык сөйләшүдән һәм күз карашыннан барысын да аңлады. Димәк, Беренче бүген аның аланында куначак. Ә аланда бөтенесе әзер. Хәтта яңа чабылган печәннән шалаш та корып куелган. Мунча да ягылган. Каен себеркесенең дә мәтрүшкә, бөтнек, юкә һәм имән ботаклары кушып бәйләнгәне, былтыргысы, быелгы май аеныкы, июньнеке...

...Эт тешләшми танышмый, дигәндәй, аларның дуслыгы да кызык кына башланган иде. Бик күп еллар элек чарасызлыктан өлкә комитетына ул махсус килгән иде. Беренче секретарьга керү мөмкин түгел, бер-ике ай көтәргә кирәк, диделәр. Гайсә өченче секретарь белән таныш иде. Элгәре аңа үтеп керде, хәлне аңлатты, миңа беренче кирәк, диде. Төштән соң кергән иде, кабул итү бүлмәсендә кичке алтыга кадәр утырды. Беренче һаман бүлмәсеннән чыкмады. Гайсә орден-медальләрен тагып килгән иде, коточкыч тавыш күтәрде, әгәр кабул итмәсә, тәрәзәдән сикерәм, дип куркытты, туктаусыз медальләрен чылтыратты. «Победа» машинасы көтеп тора, милиция белән сөреп төшерсәләр дә, болай да кайтып китәсе. Бәхетенә, аны кертеп җибәрделәр. Беренче ак күлмәктән, кара галстуктан, җиңнәрен сызганган, алдында бер өем кәгазь... Күрешкәч, утырырга

кушты. Гайсә утыруга, ручкасын алып, кәгазьләренә иелде.

—Сөйләгез!

Сизелеп тора, Беренченең аны тыңларга уенда да юк. Нидер эшләргә кирәк иде. Гайсә папкасын ачты да, юри ручка тотып, шунда иелде.

—Сөйләгез, кыенсынмагыз...—диде бүлмә хуҗасы, һаман кәгазьләреннән аерылмыйча.

Шактый вакыт узды. Секретарь башын күтәрде. Аптыраудан аның кашлары җыерылды, төксе тавышы янгырады:

—Нишләп сез гозерегезне әйтмисез?!

—Син бит мине тыңламыйсың, апаем!

Гайсә юри авылча «син» дип, «апаем» дип, аны җиргә төшерергә теләде.

—Гафу итегез...—Беренче секретарь, башын бераз кыйгайтып, аңа төбәлде.—Минем беркемне дә кабул итәргә мөмкинлегем юк... Инде кергәнсез икән, сөйләгез. Тик зинһар тизрәк!..

Булган булган икән, бүлмәсенә сыер килеп кергән шикелле булсын инде дип, Гайсә турыдан ярды:

—Авылдан яшьләрне качырып бетерәбед бит, әнәгеднең койрыкларын!..

Йөзенә ком сиптеләр диярсең, Беренче башын артка алды, күзләрен еш-еш йомып, әлеге сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә теләде.

—Мин нишли алам соң?

—Күп нәрсә эшли аласың! Менә минем калхудда җиде авыл.—Ул юри авылча кимәлдә алып китте. Аксак икәнен күрсәтү өчен, бүлмә буйлап хәтәр генә титаклап та килде.—Араларында кышын да, җәен дә батып үләрлек ие. Үдебеднең көч белән җөрерлек иттек. Салам түбәле ат абдарларын, читән фермаларны, үдебед сәмән кирбече сугып, әтәш-мәтәш китердек. Клублар адәм ыстырамы! Башта римутлатмакчы идем, юк, минәйтәм, күпме әүкәләсәң дә, пешергән боткадан ярма ясап булмас. Бәлтерәп йөрдем-йөрдем дә, пычагым да кыра алмагач, ишле-сыңарлы аякларым белән сина килдем, апай. Дүрт җөд чакрым җирдән. Хәдер артка ак җон чыкты, көсәнү файдасыд—сәмән кирәк!—Гайсә, баш һәм имән бармакларын бер-берсенә ышкып, аңа таба сузды.

Бүлмә хуҗасының йөзе яктырып китте. Батталовның сөйләвен тыңлагач, туган авылы, әтисе белән әнисе исенә төшеп, күнелендә инде күптән көл астына күмелгән сагыну хисләре көйри, кайнарлана башлады...

—Клублар төземәкче буласызмыни?

—Нәкъ өстенә бастың, апаем!—Гайсә куануыннан сикереп үк торды.—Иччугы калхуд үдәгенә ике ыятажлы сарай салып куясы иде. Ду килсеннәр, туйганчы мачамайлансыннар ие шунда.

—Проект кирәк бит ана.

—Бар, апаем, бар! Проекты да, бүтәне дә бар!

Гайсә, папкасыннан сөйрәп чыгарып, бер кочак документ бирде. Бүлмә хуҗасы аларны җентекләп, хәтсез озак карады. Гайсә тын да алмыйча, керфек тә какмыйча, шым гына утырды. Ниһаять, Беренче башын күтәрде, учлары белән йөзен сыпырып куйды.

—Әгәр акча бирсәк, кайчан була... ничек дисез әле... сарай?

—Көдгә өлгертәм!

Секретарь ышанмыйча башын чайкады:

—Өч айдамы? Ай-һай...

—Кулымны кисмәгә бирәм! Әйдә бәхәс, апаем?!

Ул көлә-көлә кул бирде дә:

—Документларыгыз миндә калсын. Үзегез иртәгә унда килерсез,—диде.

Гайсә хәйләкәр иде, ул үзенең бу кешенең күнеленә инде үтеп кергәнлеген аңлады. Шуңа күрә, камыр әвәләнгән, шишараны кызган мичкә тыгарга ашыкты:

—Син мине, апай, ябешкәк икән бу, мисыр хәерчесе, димә.—Ул

юри як-ягына каранып алды.—Җуарга кирәк бит инде моны, нәплүәйть дөньясына!

Секретарь, әвендәй гәүдәсен селкетеп, тыела алмыйча көләргә тотынды, кульяулыгы белән күз яшьләрен сөртә-сөртә көлде. Гайсә кызуны өсти торды:

—Гүли исертә торган әче бал кирәкме? Чемердәп тора, ишелеп кенә төшәсең, апай. Кымыд та бар.

—Кымыз? Каян алдыгыз аны?

—Үдебед җасыйбыд. Яшниге белән машинада утыра. Кымыд барда кыдык бар дигән бит бабайлар.

Юк, секретарь аны һич тә болай гына җибәрергә теләмәде. Бу кеше янәшәсендә чакта аның күңеле кымырҗып, әллә нинди ләззәтле тойгылар кичерә иде. Ул Батталовның кайда булачагын сорады да, ике сәгатьтән машина килеп алыр, кымыздан бүтән әйбер кирәкми, диде...

Иртән Беренче янына чиратсыз гына кереп киткәндә, кабул итү бүлмәсендә торучы түрәләрнең чәнечкеле чыбыктай күз карашларына сөртенеп, чак кына егылмады ул. Мәдәният сарае төзелешенә акча бүленгән иде инде.

—Ачу тантанасына мине чакырырга онытма, Гайсә Батталович!—диде секретарь саубуллашкан чакта.

Ул сүзендә торды: үзе дә йокламады, башкаларны да йоклатмады, өч ай дигәндә тәки ике катлы мәһабәт мәдәният йортын төзетеп бетерде. Өлкә комитеты секретаре аны күреп хәйран калды. Рәшәткәле тимер коймалар, чәчәкле газоннар, зәңгәр чыршылар, карагайлар, нарат, каен, юкә агачлары... Мәрмәр баскычлар, пыяла стеналы якты фойе, дүрт йөз урынлы тамаша залы, китапханә, никахлашу бүлмәсе, киң һәм якты коридорлар, зур агач тартмаларда үсеп утыручы яшел пальмалар, үрмә гөлләр... Иң гаҗәбе шунда, бу күркәм бинаны әллә каян килгән төзүчеләр түгел, ә колхоз осталары үз куллары белән салганнар. Төзүчеләр белән секретарь аерым гына, озаклап сөйләште.

—Акча гына бирегез,—диделәр алар.—Әгәр Кавказдан килеп бездә эшләп йөрүче кара халыкларга түләгән кебек түләсәгез, без сезгә тирестән боламык та ясап күрсәтә алабыз.

Ирек конференциянең беренче өлешенә кермәде, ерак авылдан килгән ветеранга чыгыш язарга булышты. Тәнәфестән соң ул иң алгы рәткә кереп утырды һәм, президиумга күз төшергәч, тамашага хәйран калды.

Арсланов танырлык түгел иде. Ул туктаусыз чәчен сыпыра, кульяулыгын алып, авыз-борынын сөртә, әледән-әле галстугын рәтли, костюмын тартып куя, үзе белән янәшә утыручы өлкә комитеты секретарена, йөзе белән залга туры торганда да күз бәбәкләре читеннән шуңа карый. Ул елмайса, елмая, ул ачуланса, ачулана, ул битараф караса, ул да битараф карый, кул чапса, кул чаба. Арслановны әйтерсең лә урындыкка түгел, кыздырылган табага утыртканнар иде. Ул туктаусыз кыбырсый, әле бер якка, әле икенче якка чайкала. Аның тәненең һәр күзәнәге, һәр төге шул өлкә комитеты секретаре турында гына уйлый сыман, шуның каршында нишләргә белми, күз бәбәкләре өзлексез сикергәли иде. Кунакка сүз бирер алдыннан, Арсланов районның барлык хезмәт ияләре исеменнән аңа, юк вакытын бар итеп, безгә килгәнлеге өчен, чиксез рәхмәт белдерде һәм аның килүе район тормышында һичшиксез зур борылыш ясаячак, диде. Шул сүзләрне әйтүгә, кулларын баш очына ук күтәреп, шапы-шопы чабарга кереште, аңа бөтен зал кушылды. Өлкә комитеты секретаре, аңа борылып, йөзенә канәгатьсезлек билгеләре чыгарып, нидер әйтсә дә, Арсланов кул чабудан туктамады, ул туктамагач, зал да туктый алмады. Ике-өч минут дәвам иткән бу алкышлар вакытында Казан кунагы кып-кызыл булды. Трибунага чыккач, ул бу хакта әйтми дә кала алмады, шактый артып китсә дә, күрсәткән хөрмәтегез

өчен рәхмәт, диде. Аның чыгышы тәмамлангач, Арсланов тагын кат-кат рәхмәтләр әйтте, партия эшендә иҗади уңышлар, гаилә бәхетләре теләде, эчтәлекле, районны перспектив киләчәккә юнәлтә торган чыгышы киләчәктә партоешмалар эшчәнлегендә кулланма булыр, аны тормышка ашыру буенча ашыгыч төстә конкрет чараларны эшләнер дип ышандырды. Үзебезнең халык алдында кулын да иренеп кенә күтәрә, сүзен дә ашыкмый, салмак кына сөйли торган Арслановның өлкә комитеты секретаре янында туктаусыз өтәләнүен һәркем күреп-аңлап торды...

## 19

Ахырда, кат-кат сөйләшкәннән соң, Сөембикә кияүгә чыгарга ризалык бирде. Бу хәбәрне әти-әниләре дә, Мэлс абыйлары да бик куанып кабул иттеләр. Сөембикәләр авылына барып, аны сорап кайтканчы, чакыру кәгазьләре таратканчы, һәр ике якның якын кешеләренә бүләкләр юнәткәнче, азык-төлек, эчемлек кебек әйберләр юллаганчы, туй киемнәре тектергәнче, тәгаенләнгән вакыт килеп тә житте. Туй мәҗлесен, әлбәттә, авылда, төп йортта июль аеның соңгы җомгасында үткәрергә булдылар. Ишек алды уртасына брезент корылып, тактадан утыргычлар, өстәлләр ясалды. Электр чыбыклары сузып, зур-зур лампочкалар эленде, бөтен җиргә яшь каен ботаклары беркетелде. Аллы-гөлле тасмалар, кабартылган шарлар белән бизәлгән машиналар, бер-бер артлы тезелешеп, Баллы Төбәк урамнарын әйләнгәч, авыл Советы бинасына никахлашу тантанасына килеп туктады. Ул тәгәлләнеп, Бөек Ватан сугышында ятып калганнар истәлеге булган һәйкәлгә чәчәк бәйләмнәре салгач, Хәйри белән Гөлҗамал йортына Сөембикә килен булып төште...

Кунаклар, авыл гадәте буенча, көтүләр кайтып, сыерлар савылып беткәч кенә җыйналдылар. Туй кичке тугызынчы киткәч башланды. Болынкырдан килгән кунаклар арасында райком, редакция кешеләреннән, шул исәптән, икенче секретарьның булуы өйләнешүчеләрнең дә, туйның да абруен күтәреп җибәрде. Шәвәлиев, аларны котлап, райком исеменнән кыйммәтле сервиз тапшырды. Ул, беренче тәнәфестә Ирек белән Сөембикәне икесен дә кабат котлап, бәхетле тормыш теләп, кайтып китте. Туй гөрләде генә, тост арты тост әйтелде, җырланмаган җыр, биелмәгән бию калмады. Мәҗлесне алып баручы Мэлска аны өч мәртәбә ябарга туры килде. Чөнки күңелләр тәмам тулышкан, дәрт-хисләр югары ноктасына күтәрелгән, кунакларның һаман җырлыйсы, биисе килә иде. Әлбәттә, Мэлс шушының белән мәҗлес тәмам дигән сүзне әйтмәде, әмма аның соңгы тосты аңлаган кешегә инде туй азагына житкәнлеген бик ачык сиздерде. Кыскасы, барысы да канәгать булды, сәгать өченче яртыда өйдә Ирек белән Сөембикә генә калды. Инде утлар сүнсә дә, яктыра башлаган бүлмәдә Сөембикә элгән пәрдәләрнең ышыклавы астында алар уртак караватка аудылар.

Кай арада йоклап киткән булгандыр, Ирек күзләрен ачып җибәрде. Ул, түшәмгә төбәлгән хәлдә беркадәр ятканнан соң, тагын әз генә черем итәргә ниятләп, күзләрен йомды. Ләкин йөрәгенең читен пычак белән телеп-телеп алган шикелле бер тойгы ана йокымсырарга ирек бирмәде. Ул, нәрсәдәндер курыккандай, башын Сөембикәгә таба борды. Аның бил турына гына одеал ябылган шәрә гәүдәсе ястык-мендәрләрдә нәфис булып таралып ята иде. Иректә әллә нинди исерткеч җылы тойгы кузгалып куйды. Ул Сөембикәгә якыная башлады, әмма, нәрсәгәдер кадалудан курыккандай, кире чигенде һәм, караваттан төшеп, стена буендагы урындыкка барып утырды. Әллә аның төшүен сизеп, Сөембикә кыймшанып куйды, йокы аралаш тәмле киерелеп, аякларын бераз бөкләгән хәлдә, аркасын Ирек ягына куеп ятты. Аның одеалы тезләренә үк шуып төшкән иде. Бу шома озын муенны, түгәрәк иңбашларны, билгә таба

нечкәреп килүче гәүдәне, билдән соң түгәрәкләнеп торучы янбашларны ул хәзер анлаешсыз бер тойгы белән күзәтте. Алар һәммәсе дә Ирекнеке, мәңгегә аныкы, шул ук вакытта ул бу гүзәл тәннең үзенеке генә булмаганлыгын да аңлаган иде. Аның бөтен барлыгы караватка омтылды, шушы ак җәймә өстендә аны көтеп ятучы кайнар, ягымлы Сөембикәне иркәлисе, кочасы, шашып үбәсе килде. Әмма ниндидер көч, ниндидер усал, әшәке әйбер аны җибәрмәде. Ирекнең күнелендә чиркану һәм рәнҗү уятты. Сөембикә шулчак чалкан әйләнде, аның матур түгәрәк күкрәкләре пәрдәләр аша кергән алсу нурда пешкән алмадай күренделәр. Менә ул, керфекләрен сирпеп, түшәмгә, аннары Ireккә бер генә карап куйды да тагын күзләрен йомды.

—Сөембикә...—диде Ирек, сыкранулы хәлсез тавыш белән.—Бу ничек була соң бу? Мин бит... Син миңа әйтергә тиеш идең...

Ул, күкрәгеннән ниндидер кайнар нәрсә күтәрелеп, сулышын кысуын тойды.

—Мин гомерем буе хыялландым, сафлыкка омтылдым... Менә хәзер, бүген моны... аңлата аласыңмы?

Сөембикә селкенеп тә карамады, керфекләрен ачмады. Ләкин юка тире астында аның күз алмасының калтырап хәрәкәтләнеп алуы ачык сизелде.

—Син бит йокламыйсың... Син әйтергә тиеш. Бу болай кала алмый...

Ирек бүтән аңа карарга теләмәде, берни күрмәс күзләре белән, тәрәзә каршына басып, пәрдәдәге бизәкләргә төбәлде. Өйдә шактый вакыт тынлык хөкем сөрде. Ләкин бу изрәүдән, йоклаудан туган тынлык түгел, ике йөрәкнең әрнүле тибүеннән, күнелләрендәге җәрәхәтнең сулык-сулык сызлавыннан иде.

—Мин мондый әйберләрне гафу итә алмыйм, Сөембикә. Син минем ни әйткәнемне аңлыйсыңмы?! Мин гомер буе беркемне дә алдамадым, ә үземне бик күп алдадылар. Мин барысын да кичердем. Ә менә бусын кичерә алмыйм! Дәш, ник дәшмисең?!—диде ул, Сөембикәне иңбашыннан селкетеп.

Шулчак Сөембикәнең ияге кинәт асылынып төште, аннары калтырана-калтырана күтәрелде, тагын төшеп китмәсен дигәндәй, ул аскы иреннәрен теше белән кысты, аның бөтен чыраена сызлану, әрнү, газап билгеләре чыкты. Сөембикәнең кашлары җыерылды һәм ул, күзләрен ачмаган килеш, бөтен гәүдәсе белән дерелдәп, очкылык тоткандай хык-хык итеп үкси башлады; шул арада, одеалын тартып, шәрә күкрәкләрен капларга да өлгерде. Күпме генә тавыш-тын чыгармаска, елавын күрсәтмәскә тырышса да, аның авызы ачылып китте һәм тамак төбеннән әллә нинди кызганыч, аһырган кебек тавыш ишетелде. Аның инде хәзер күзләре мөлдерәп түгәрәкләнгәннәр, керфекләре яшькә чыланып, учма-учма булып оешканнар иде.

Ирек акылы белән аны кызганырга, иркәләргә теләде, әмма үз-үзен мәҗбүр итә алмады, күнеле буйсынмады. Шул ук вакытта Сөембикәнең әрнүле йөзенә карап тору да кыен иде. Ул, аркасын куеп, аның янына утырды.

—Бүген еларга соң инде,—диде Ирек кырыс тавыш белән.—Син бит тозакны алдан ук сала-сала килгәнсең. Мин каптым. Ник алдадың син мине?

Сөембикә хәзер ыңгыраша-ыңгыраша, сузып-сузып елый иде инде. Ләкин бу һаман да тавышсыз елау, берәрсе тәрәзәдән тыңлап торса да, берни ишетә алмаслык тыелып елау иде. Сөембикә тышка чыгасы барлык әрнүен, аһларын эченә томалады. Шуңа күрә үксегәндә аның бөтен гәүдәсе калтыранды.

—Хәзер өйгә әниләр кайтачак,—диде Ирек.—Син җавап бирергә уйлыйсыңмы?

—Ни әйтим соң мин сиңа?!—диде Сөембикә, күз яшьләре аша.

—Мин синнән бер генә әйбер сорыйм: ник алдадың?

—Нәрсә дип?

—Нәрсә дип?!—Ирек ярсып сикереп торды.—Нигә мина кадәр икенче кеше белән булганыңны әйтмәдең?!

Сөембикә кинәт елаудан туктады, терсәгенә таянып торып утырды. Аның чәчләре тузгып, инбашларына, муенына төште. Ул аларны кулы белән артка таба сыпырып куйды да:

—Ә син сорадыңмы соң?—диде.

Ирек ачудан тешләрен кысты.

—Бала-чага булма, Сөембикә! Мондый әйберне сорамыйлар. Син үзең әйтергә тиеш идең.

—Ә менә мин әйтә алмадым! Аңлыйсыңмы, әйтә алмадым!—Сөембикә кычкырып елап җибәрде.

—Нишләп әйтә алмадың?!—Ирек аны, ике инбашыннан тотып, дер-дер селкетте.—Нишләп әйтә алмадың?!

—Курыктым, Ирек! Синсез калырмын дип курыктым. Үтер, кис, ас! Курыктым!...—Ул мендәренә капланып төште һәм ярсый-ярсый елый башлады, инбашлары, бөтен гәүдәсе дер-дер калтыранды.

Шулчак, Ирекнең ачуы бераз басылып, күңелендә Сөембикәгә карата шәфкатьлелеккә охшаган җылы хис уянгандай булды. Әйе, ул дөресен әйтә. Ул Ирекне ярата. Аны яратмаса, югалтудан курыкмас иде. Ул усал ният белән түгел, бары тик аның белән бергә булу өчен гөнаһын яшергән. Ләкин бит ул азагын да уйларга тиеш иде.

—Ә мин? Мине уйладыңмы син?—диде Ирек, инде шактый йомшак тавыш белән.

—Уйладым, Ирек. Мин син аңларсың дип өметләндем.

—Нәрсәне аңлармын?

—Мин аңлатканны...

—Миңа бернинди дә аңлату кирәкми. Мин бары тик бер әйберне беләм: син мине алдадың! Син бит, беренче танышкан көнебездән башлап, шуны чамалап йөргәнсең.

—Юк, Ирек, ышан: мин синең хатының булырмын дип соңгы вакытларга кадәр уйламадым да. Чөнки мин синнән дүрт яшькә зуррак, мин бу кадәр эчкә керербез дип, башыма да китермәдем. Ә яратуын... Син райкомга эшкә килеп, беренче күргәч тә яраттым. Зәнфирәдән көнләшә-көнләшә яраттым. Тик мин үземнең сиңа тиң түгел икәнлегемне беркайчан да онытмадым.

—Онытмагач... Нигә соң кияүгә чыгудан баш тартмадың?

Сөембикә, салкын җил бәргәндәй, калтыранып куйды, одеалына ныграк төренде һәм, инде кеше төсе калмаган чыраен Ирекккә борып:

—Миндә андый көч калмаган иде шул,—диде.—Син мине әллә нишләттең... Әле мин, бүләккә әйберләр ала башлаганда да, төн буе уйланып, йокламыйча чыкканнан соң, барысын да ачыктан-ачык сөйләшергә дип, синең янына йөгереп кердем. Хәтерлисеңме? Иртәнге алты иде. Син йокыдан торып, кырынып кына маташа идең. Мине күргәч, электр кырынгычың шул көе безелдәп эшләп калды, ә син, мине күтәреп алып, өй буенча әйләнеп йөри башладың. Аннары идәнгә бастырып куйдың да: «Сөембикә, ипи тотып ант итәм, валлаһи, Алла бар икән бит!—дидең.—Әле менә үзем кырынам, үзем, их, хәзер Сөембикә килеп керсен иде, шуның зәңгәр күзләрен бер күрсәң иде, дип уйлый идем. Менә бит килеп тә кердең, зәңгәр күзләреңне күрдем, хәтта мин аларны үбә дә алам»,—дип, ике күземнән үбәргә тотындың. Мин: «Кырынгычың эшләп тора, тартып ал»,—дидем. Ә син: «Ай-яй, экономияле хатын булачаксың икән»,—дип көлдең...

Ул тагын сыкрап елап җибәрде.

—Әйтә алмадым, сөйли алмадым шул чакта!..

Кинәт алгы өй ишеге ачылып, аяк тавышлары ишетелде. Сөембикә, ялт сикереп торып, өстенә киенде. Чәчен, йөзен рәткә китерде. Аннары, туй күлмәген бөгәрләп тоткан килеш, Ирекккә сузды.

—Мин синнән гафу сорамыйм, кеше-кара җыелганчы, мине олы юлга мотоциклың белән чыгарып кына куй, зинһар. Аннары мин үзем кайтып китәрмен.

—Алай гына булмый әле ул,—диде Ирек.—Анысы киләчәктә. Безне хөрмәт итеп, туйга килгән кунакларның йөзенә төкерергә минем хәлемнән килми.

Бүлмәдә тагын тынлык урнашты. Сөембикә яшьле күзләре белән Ирекнең каршына ук килеп:

—Рәхмәт, Ирек,—дип пышылдады.—Үлгәндә дә онытмам. Ә яңадан теләгән вакытыңда үзең әйтерсең. Мин сиңа тагылмыйм...

Шулай диде дә Сөембикә алгы өйгә чыгып китте. Ирек тә аның артыннан атлады. Тагын кунакларны хөрмәтләү, уен-көлке, җыр-бию дәвам итте. Алар кияү белән кәләш мунчасы керделәр, елмайдылар, көлделәр, эчләрендә ут иканен беркемгә дә сиздермәделәр. Абыйсы Мэлс кына, Ирекне читкәрәк алып китеп:

—Энекәш, нишләптер синең күзләрең коры күренә, әллә ни дә булса ошамыймы?—дип сорады.

Ирек аның сүзләрен уенга борды:

—Сез рәхәтләнеп саласыз, ә мине кыстаучы юк,—дигән булды.

Абыйсы кузгаткан сүзнең очы шуның белән югалды. Кунаклар китеп беткәч, табыннар җыештырылгач, кайту хәстәренә керештеләр. Сөембикә алып килгән әйберләр, туйда салынган бүләкләр автобуска төялде. Әти-әниләре йөгерә-атлый чәкчәктер, каклаган каз-үрдәктер ташыдылар. «Улым-кызым» дип өзелеп тордылар, бәхет-тәүфыйк теләделәр. Абыйсы Мэлс аларны район үзәгенә озата килде, әйберләрне Ирекнең фатирына кертешкәч кенә кайтып китте. Иң кыены шуннан соң башланды. Ул әйберләр хәзер уртак та, уртак та түгел иде. Атна буе өйгә бер нәрсә эленмәде, төенчекләр чишелмәде, сандык-чемоданнар ачылмады. Алар ашадылар, эчтеләр, яттылар, тордылар, эшкә бардылар, ачылып рәхәтләнеп сөйләшү булмады. Туйда катнаша алмаган кешеләр килеп котлаганда, табын әзерләделәр, аларның уртак бәхет теләвенә елмаеп утырдылар, ләкин, бергә ятар вакыт җитү белән, Ирекнең эчен таракан кимерә башлый, читтән генә каш астыннан, Сөембикә чишенгән чакта, аны күзәтә, аның гәүдәсенең, тәненең матурлыгына, нindidер чит кешенең байлыгына сокланып карагандай карый иде. Аның үзенеке иканен белгән хәлдә, ул шушы калку иреннәрне кемнеңдер үбүен, шушы түгәрәк күкрәкләргә, бу билләргә, бу түгәрәк янбашларга кайчандыр нindidер чит ирнең кагылуын, шуларның кайнарлыгы, шомалыгы белән ләззәтләнүен, Сөембикәнең аны шушы нәфис куллары белән кочаклавын күз алдына китергәч, Ирекнең күкрәгеп ачы үкенү, алдану тойгысы тутыра иде. Ул үзенең аек акылы белән барысы да үткән, онытылган, андый хәлләр бер синдә генә булмаган, дип әллә нинди акланулар таба, гафу итә белмәве, һаман бер әйберне генә уйлап торуы өчен үз-үзен тирги. Шул ук вакытта ул Сөембикәне төрлечә аклаучы дәлилләр таба, яшь чакта бер ялгышкандыр, аның ничә ел бергә эшләп, һичкайчан яман аты чыкканы булмады, ди. Ирек Сөембикәнең теге вакытта кунак йортында, ныклы ихтыяр көче күрсәтеп, аны куып чыгарганын хәтеренә төшерә һәм барлык дәлилләрне хатыны файдасына теркәп куя. Шул ук вакытта Ирек Зәнфирәдән соң әле беркемнең дә аңа Сөембикә кебек ошый алмаганлыгын да таный. Димәк, бары ул гына Зәнфирәне алмаштыра ала, бары ул гына аның йөрәк ярасын төзәтә ала. Сөембикәнең ягымлылыгы, ачык күнеллелеге, беркайчан да үпкәли белмәве, булышучанлыгы, нинди эшкә тотынса да, ут өертеп эшләве—болары да Ирек өчен бик кадерле нәрсәләр иде. Шушыларның бөтенесен җыйгач, бердәнбер олы нәтиҗә килеп чыга: ул Сөембикәдән башка берничек тә яши алмый. Соң шулай булгач, инде ике уйларга, аны да, үзеңне дә газапларга кирәкми, ләбаса. Барысы да ачык, гади, аңлаешлы. Син аны, ул сине ярата, бер-береңә кирәк, шулай булгач, яшәргә дә яшәргә. Ләкин теге

сагалап торган шикчел уй, әллә уй түгел, алданган күңелме—нәрсә икәнен бер Ходай үзе белсен—Сөембикәнең аныкы гына булмаганлыгын туктаусыз сиздереп тора. Шул сизелү белән Ирекнең кәефе китә, кулыннан эше төшә, саф, берничек тә пычратылмаган яшьлеге әрәм булгандыр кебек тоела. Ул төннәрен урынында туктаусыз бөтерелә, Сөембикәне тели. Әгәр аның белән ләззәтләнсә, барыбер теге уе кузгалып, аны куралмый башлый, кайчакта хәтта тотып кыйныйсы килә. Шушындый газаплы бер атна үткәч, бер кичне Ирек Сөембикәгә күптән эчендә йөрткән сорауны бирде:

—Син кем белән булдың?..

Сөембикә йокларга урын җәйгән жиреннән ток тоткандай туктап калды. Әллә ялгыш ишеттемме дигәндәй, кулындагы җәймәсен тартып тоткан килеш, артка каерылып Ирекка карады: Ирек исә аның урын җәюен, гәүдәсенең житез хәрәкәтләнүен, әллә ничәгә бүгәләнгән әнә шул тойгылар аша күзәтеп утыра иде. Зөфаф киченнән үк утлы хәнҗәр булып кадалган бу сорауны ул күңеленең ин төбенә яшереп куйган һәм аны шушы көнгә кадәр бер мәртәбә дә кузгатмаска, чыгармаска көче житкән иде. Ә менә шушы чакта әллә нәрсә булды, ул башта Сөембикәнең урынны җәеп бетерәчәген күз алдына китерде, аннары үзенең акрын гына чишенеп менеп ятасын һәм аны көтәсен күз алдына китерде. Менә шуны күз алдына китергәч, Ирекка әллә ни булды. Әйтерсең лә Сөембикә аны алдавын дәвам итә, законсыз рәвештә аның ин кадерле хисләрен суыра иде.

Аның ачулы карашыннан, тавышының тупас яңгыравыннан Сөембикә сорауны бик яхшы аңлады. Җавабы күптән әзерләнгән булса да, сорауның кискен бирелүе аны бик нык каушатып җибәрде. Ул маңгаена, борынына вак тир бөртекләре бәреп чыгуын тойды һәм җәймәсен тоткан килеш, Ирекка борылып, караватка утырды. Аңа туры карый алмады, башын аска иде.

—Әти үлгәч, яшәү авырлашты... Әни бер кешене йортка кертте, Үзбәкстан якларыннан кайтып төшкән... Ул бәндә бездә өч атна гына яшәп калды... Баш күтәрми эчте дә эчте. Соңыннан гына ишеттек: ул гомер бур төрмәдән чыкмаучы булган икән. Мин унынчы класста укыганда, әни авырып, больницага салдылар. Ул соң гына эчеп кайтты. Башланган яртысын өстәлгә утыртып, мине дә эчәргә кыстарга кереште. Өйдән чыгып китмәкче булып, ишеккә йөгердем, ул чәчемнән эләктереп алды. Без бик озак сугыштык. Мин тешләдем, типтем, тырмадым. Ахырда ул: «Әгәр карышсаң, үтерәм!» дип, буарга тотынды. Мин аңымны җуйганмын...

Ирек нишләптер моңа ышана да, күз алдына да китерә алмады.

—Ул кыргыйларча мәсхәрәләгәндә, мин әллә ничә тапкыр аңыма килеп, әллә ничә югалттым, күкрәкләрем чәйнәлеп беткән иде... Ул өйдә булган акчаларны, сатардайрак әйберләрне алып, юкка чыккан иде...

Ирек бусына да ышанмады да, дәшмәде дә... Алданган күңел тиз генә ышанмый икән шул ул...

Бер атнадан соң Сөембикә төйнәлгән әйберләрне әкренләп чиште, сандык-чемоданнарны ачты, тәрәзәләргә челтәрләр һәм пәрдәләр эленде, савыт-сабалар, башка бүләкләр дә үз урыннарын алдылар. Ирек һәр көнне биштән эшкә китә, ул торганчы, Сөембикә күптән йөгереп йөри, нәрсә дә булса кыздыра, пешерә, яшелчәдән салат ясый, юынуына сөлгесен тотып тора. Кыстый-кыстый ашата, чәй йә кофе эчерә, яңадан сәгать ничәдә кайтуын сорый, тугызда дисә—тугызга, унга дисә, унга эшеннән йөгереп кайтып өстәл әзерли, ашата һәм җыештырып китә. Көндезгә аш пешкән була, икенчегә нидер әзерләнгән, чәе кайнап тора. Кичен Сөембикә тагын Ирекнең кайтуына нәрсәләрдер хәстәрләп көтә. Аңа беркайчан да калган ризык бирми, бер генә көнне дә алдагы көнне әзерләнгән ашамлыкны әзерләми, һаман төрләндерә. Мактасаң, сөенә, башы күккә тия. Әгәр Ирек кеше-фәлән белән кайтса, Сөембикә кая басканын белми, йөгерә-йөгерә дәртләнеп өстәл әзерли, йөзеннән елмаю китми, теленнән

тәмле сүз төшми. Кергән дуслары булмасын, башка кеше булмасын, сокланып баш чайкыйлар: «Ну, хатының да хатының, күз генә тия күрмәсен, моны кайлардан таптың, бәхетеңне берүк югалтма», диләр. Җомга көн житсә, Сөембикә авылга кайтыйк, ди, әти белән әнигә булышыйк, ди. Биатасы белән бианасына алып кайтырга кәрчә-мәрчә пешерә, башка күчтәнәчләрне әзерли. Шимбә көнне Ирекнең беркайчан да бушаганы юк, якшәмбе көннәрдә дә аңа ял бик сирәк эләгә. Шуңа күрә Сөембикә, шимбә көнне мине кайтарып куй, әниләргә булышырмын, мунча ягармын, кич син дә кайтырсың, ял көнне тагын эшләрен карашырбыз, ди. Ул ике көндә Ирекнең вакыты булмаса, аның рөхсәте белән авылга үзе генә кайтып китә, ике көн буе җен урынына эшли, бианасы белән биатасын таң калдыра. Иң элек, өйләрне җыештырып, идәннәрне юып чыгара, мунча яга, керләрен юа, бакчада йә бәрәңге утый, йә агач төпләре йомшарта, кош-кортларга җим әзерли, анда-монда купкан такта-токта ише әйберләрне дә бик җайлап кына кагып куя. Бианасы белән биатасы хәйран калып бот чабалар, «Бу алтын килен безгә кайлардан килде», дип, үзара пышылдап кына сөйләшәләр. «Килен, арыгансыңдыр инде, бераз ял ит», диләр. Әмма Сөембикә аларны тыңламый, ниндидер бер тыелгысыз дәрт белән яңадан-яңа шөгыльләр таба, бии-бии эшләп йөри. Алар Нәфисә белән генә нишләптер беренче көннәреннән үк бер-берсен якын итә алмадылар. Ял көннәрдә авылга кайткач очрашсалар, Нәфисәнең ниндидер бер эчке көнчелек белән аңа чәнчеп-чәнчеп карап алуын күреп, Гөлҗамал да, Хәйри дә авыр сулыйлар, эчтән уфтаналар. «Менә бит, диләр, икесе дә безнең килен, икесе дә адәм баласы, берсе гомер буе малаеның йөрәк итен ашый, китсә дә, кайтса да, тавыш чыгара, һаман бөтенесенең муенына атланып яшәргә тиеш һәм шулай яшәвен үзенчә хаклы саный. Сөембикәнең авыз ачып каршы сүз әйтмәгәне, һәрчак ачык йөзле булганы, бөтен эшне сыдырып эшләп йөргәне өчен Нәфисә каршында гөнаһлымыни соң инде, дип, картлар аптырап баш селкиләр. Мэлс белән Ирек тә моның һәммәсен күреп торалар. Абыйсы үзенең хатыны шундый булганга, әти-әниләре алдында бик нык кыенсынса, Ирек исә унган килен белән аларны куандырганы өчен рәхәтләнеп утыра. Дөрес, аның күңелендә һәрвакыт яндырып тора торган теге утлы төере бар, ләкин менә әти-әниләренең аңа якты йөз белән карауларын, рәхмәтле сүзләрен ишетү ул төерне һаман киметә, йомшата бара. Ирек кайчакларда икеләнеп уйлап куя: Сөембикәнең, әгәр кушсаң, чәче белән җир себерергә әзер булуы, йокы, ял дигән нәрсәләрне онытып, туктаусыз Ирекка, аның әти-әниләренә хөрмәт күрсәтүе, бу чынлап микән, әллә соң теге олы гөнаһын юу өчен генә микән? Әмма ул гөнаһ бит мәңге юыла торган түгел. Әгәр алар исән булып, бергә яшәсәләр, ул гөнаһ гүргә кергәндә дә кичерелмәячәк. Дөрес, Сөембикә сөйләгәннәрнең хак икәненә ышана алса, Ирек аны бәлкем гафу да итәр иде. Ләкин бит ул мондый очракларда хатыннарның ирләрен алдау өчен берсеннән-берсе шомарак, берсеннән-берсе ышандырырлыграк әкиятләр уйлап табуларын бик яхшы белә. Әгәр өйләнешкәнче сөйләгән булса, бер хәл иде. Ул бит инде аны бер мәртәбә алдады!

Сөембикә, китапханәгә ремонт ясаучыларны алып килеп, йокы бүлмәсенең бер башын бүлдерде, ишек куйдырып, аның эченә гамәлдән чыгарылган кечкенә өстәлне алып кайтып урнаштырды, китаплар-кәгазьләр өчен киштә ясатты, яхшылап обойлады, өстәл лампасы куйды. Бу бүлмә Ирекнең язу урыны булды. «Зинһар, бикләнеп утыр, зинһар, яз гына»,— диде Сөембикә, Ирекка су керттермәде, су түктермәде, котельныйга күмерне үзе ташыды, үзе якты. Бәрәңгеләрне, яшелчәләрне, агач бакчасын үзе йомшартты, үзе утыртты, үзе утады, үзе алды. Ирекнең күңел ярасы акрынлап онытылды сыман, Сөембикәгә булган рәнҗеше кимеде, ул инде аны гафу да итте бугай. Язу өстәле артына ул кичләрен утырырга тырышып карады, яңа пьеса башлады, бер хикәясен төгәлләде. Ләкин уйлаган теге зур повестен—кешеләрнең тормышында борылыш ясарга тиешле китабын һаман дәвам итә алмады.

Ирек, алдына ак кәгазь салып, кулына каләм тотып, адәм балаларының үткәндәге тарихы, бүгенге яшәү рәвешләре һәм киләчәкләре хакында тетрәндергеч уйларга батты. Әгәр тормыш агышы һаман да хәзергечә барса, Җир шарын һәлакәт көтә, аны исбатлап торырга да кирәкми. Тормышның агышы һич тә үзгәрми, киресенчә, көннән-көн, елдан-ел шул бер юлдан дистәләрчә мәртәбә тизләнеш белән үзенең һәлакәтенә ашыга. Бәндәм, тукта, син кая барганыңны беләсеңме? Син әз генә үзенә, кылган гамәлләреңә бәя бирә аласыңмы? Менә хәзер шушы сүзне Ирек әйтергә тиеш. Бүгенге кешелек өчен күбрәк һәм сыйфатлырак әйбер житештерү ул—яшәешнең төп күчәре. Җир йөзе күпме дауларны, яуларны, сугышларны, кан коюларны күргән—барысы да әйбер өчен... Шул мәнфәгатьләрдә барлык төр үсемлекләр, су, жир, һава, тереклек ияләре зарарлана, бозыла, агулана, юк ителә. Ирек бу һәлакәтне туктатырлык бер генә юл күрә: һәммә нәрсәдә дә тыелырга! Кешелекнең чиксез нәфесен, Җир шарын балчыгы белән ашап бетерсә дә, канәгатьләндереп булмаячак. Адәм баласына син бүген йөз төрле ризык бирсәң, ул иртәгә меңне сорый. Син аңа бүген дүрт тәгәрмәчле машина бирсәң, ул иртәгә һавада оча торган, суда йөзә торган, чит галәмнәрне яулый торган машина сорый. Бүген житештерелә торган коточкыч кораллар, бәндәләрне юк итү өчен уйланган бүтән чаралар—һәммәсе дә бары бер максатны—күбрәк әйбер яулауны күздә тоталар. Адәм баласы тәңрегә табынмый—әйбергә табына, вөжданга табынмый—әйбергә табына, туганлыкка табынмый—әйбергә табына, игелеккә табынмый—әйбергә табына. Шуның аркасында күпләр, тормыш принципларыннан баш тартып, намусларын ташлап, кемнәрнеңдер кулында үзләре әйбергә әвереләләр.

Ирек үзенең язачак повестен шартлы рәвештә «Яңа Коръән» дип атаячак. Бу ярым публицистик, ярым шигъри, ярым фәлсәфи, ярым әдәби әсәр булачак. Хәзер язучы өчен, дәүләт башында утыручы житәкчеләр өчен бердәнбер бурыч—кешелекнең мең еллар буе килгән менә шушы нәфесен тыю, аның барыр юлын капма-каршы якка бору. Инде күптән, берничә йөз еллар элек бу хакта чаң кагарга кирәк иде. Йә, Раббым! Ничек аңлатырга соң шушыны кешеләргә, аларның күңелләренә, баш миләренә этәргеч ясарлык әсәрне ничек язарга? Әйе, бу әсәр Коръән кебек көчле булганда гына кешеләрне инандыра алачак. Ләкин андый әсәр язу өчен дөньядан аерылып, бөек илаһи уйлар белән генә, бернигә дә бүленмичә утырырга да утырырга кирәк. Бәлкем бөтен гомереңне, бер көнеңне дә башкага бүлмичә, шуңа гына багышларга кирәктер. Атнага бер мәртәбә килгән ял көнендә дә утырып эшләргә мөмкинлек бирелмәгәч, ул әсәрне кайчан язарга соң?

Өйдәге телефон Ирекнең иң явыз дошманына әверелде. Әле райком, әле райбашкарма, әле редакция, әле колхоз... Тәүлекнең берәр генә сәгать телефон чылтырамаган чагы бар микән? Тәмам гажиз булгач, Ирек баганадан өйгә сузылган чыбыкны төнлә баскыч куеп карга борыны белән әллә ничә мәртәбә өзде. Ләкин икенче көнне үк аны килеп ялгыйлар, телефоннан барыбер котылмак юк иде. Әгәр дә Ходайның бирмеш көнендә өстәл янына утырып эшләрлек өч-дүрт сәгать вакыт табылса, Ирек ишеген эчтән бикләп, дөньядан аерылыйм дип утырса, кешелекне коткару турындагы бөек уйларына чума гына башласа, редакциядә эшлисе мең төрле эшләре исенә төшә: әнә котельныйга ремонт ясатасы бар, күмергә киткән машина бүген дә буш кайткан, алдагы атнадан кешеләргә утын кистереп ташытырга кирәк, дипломлы ике журналист—биш-алты ел эшләгән ирле-хатынлы сотрудниклар, квартира булмаганлыктан, эштән китәргә гариза бирде, типографиядә кәгазь юк, өч саннан соң газетаны нәрсәгә басарлар—анысын бер Ходай үзе генә белә. Әле бит иртәнге сигезгә райком пленумыннан отчет язып бирергә тиеш икән ул. Боларны уйлагач, чәчләрең үрә тора. Каләмеңне ташлыйсың, бүлмәңдәге утыңны сүндерәсең һәм өстеңә киенә башлыйсың...

Шулай, фани дөнья мәшәкатьләре белән берничә ел узып китте, сизелмәде дә. Ул арада кызлары Айгөл туып, кай арада йөгереп тә йөри башлады...

## 20

...Бу шимбәдә Ирек көне буе үзенә беркетелгән колхозда бәлтерәп йөреп, эт булып арып-алҗып, ачыгып кайткан иде. Сөембикәнең кайнар өчпочмак пешереп, мунча ягып көтеп торуы гына аның кәефен бераз күтәреп җибәрде.

—Иртәгә икәүләп барып, минем чөгендерне бетереп кайтыйк инде,—диде ул Сөембикәгә.

—Ә Айгөлне нишләтәбез?

—Үзебез белән алырбыз.

—Шоферың юкмы соң булышырга?—диде Сөембикә.

—Ул иртәгә авылына печән чабарга китә. Машина төзек, рульдә үзем барам,—диде Ирек.

—Туктале, онытып та торам,—диде Сөембикә.—Сина бит иртәгә сәгать унга райкомга киңәшмәгә диделәр.

—Нинди киңәшмә тагын?—диде Ирек, ачуы чыгып. Райком сүзен ишетүгә, хәзер бала йоннары кабара иде инде.—Кичә өч мәртәбә җыйдылар бит.

Сөембикә берни дә әйтә алмагач, телефон аша пропаганда бүлеге мөдире Миннуллиннан сорады. «Агымдагы эшләр буенча колхоз-совхоз җитәкчеләрен, район активын җыялар,—диде ул.—Барысы да ачулы йөриләр, киңәшмә бик киеренке булырга охшый.»

Ирек уйлады-уйлады да Зәбировка чылтыратты.

—Мин чөгендерне эшкәртергә барам, иртәгә сәгать ундагы киңәшмәгә керерсең әле,—диде.

Зәбиров тегенди-мондый сәбәп таба башлаганчы, трубканы куйды. Иртүк торып, кәтмәннәрне үткенләп кайтты һәм алар, сигез тулганда, чәй-ашамлыклар алып, чөгендер басуына барып җиткәннәр иде инде. Айгөл шунда туфракта чөгендер яфрагы арасында курчаклар белән уйнап утырды, алар рәт арасын эшкәртә-эшкәртә түргә киттеләр. Чүп үләннәре хәзер юанайган, каткан, бер бәрү белән өзеп тә чыгарып булмый. Бу бик авыр эш иде. Сөембикә һәрвакыттагыча Иректән житезрәк, остарак булып чыкты. Ул аны әллә никадәр ара калдырып китте. Ирек жан көченә тырышты, бөтен жиреннән тир акты, авызы кипте, иреннәре ябышты, вакыт-вакыт эсседәнме, тамагы кибүдәнме, чайкалып, күз аллары карангыланып китте. Сәгать тугызга алар бер рәт барып чыктылар. Димәк, моны бетерү өчен биш сәгать вакыт кирәк. Димәк, бу озын көн буена житәчәк. Биш кенә минут ял иттеләр дә, тирләре кибәргә дә өлгермәде, тагын эшкә керештеләр. Бу рәтне менеп житкәндә, сәгать унберенче егерме минут иде инде. Шул вакыт, тузан болыты күтәреп, юлдан килүче ак «Нива» күренде. Ирекләр турына житкәч, ул туктады, аннан Нәжмиев чыкты.

—Слушай, нигә инде син шундый әйбер эшлисең?—диде Нәжмиев, йөзенә рәнжү билгеләре чыгарып.—Хатының әйткәндер бит? Нишләп киңәшмәгә кермичә китеп бардың?

—Юк, бер әйбер дә әйтмәде,—дип алдашты Ирек.—Әнә ышанмасагыз, үзеннән сорагыз,—диде ул, Сөембикәгә борылып.

Сөембикә барысын да аңлады һәм юри бот чабып куйды:

—И-и-и, Кәрәм Нәжмиевич, гомеремә бер әйбер онытканым юк иде. Ничектер оныткан мын бит, гафу итә күрегез инде, зинһар өчен!—диде өзгәләнгән булып.

Нәжмиев әллә ышанды, әллә юк, аңа кул гына селтәде.

—Әйдә тизрәк киңәшмәгә кайтабыз,—диде ул.—Кем килмәгән, барысын да эзләп таптырып китертәләр.

Ирек белән Сөембикә, аптырашып, бер-берсенә карадылар.

—Кәрәм Нәжмиевич, тапмадым дип кенә әйтегез инде,—диде Ирек, аңа ялварып.—Чөгендер тагын кала бит.

—Ирек Хәйриевич, авызыңны да ачма! Әгәр алай ярый торган булса, мин монда килер идеммени? Әйдә, тизрәк бул!

—Бар инде, Ирек,—диде Сөембикә.—Кинәшмәдән чыккач, безне килеп алырсың.

Ул өс-башын алыштырып килеп кергәндә, кинәшмә шактый кызган иде. Арсланов тәмам ярсыган, әле бер житәкчене бастыра, әле икенчесен. Тозлы-борычлы сүзләрен дә кызганмый. Ирек шунда үзләренең язмышына хәйран калып утырды. Кеше үз гомеренә бер мәртәбә яши. Шушы кадәр мәсхәрәләүләр, шушы кадәр тиргәү, сүгенү сүзләре күтәрү өчен килә микәнни соң ул тормышка? Җитәкче кешенең бер генә нәрсәгә дә, хәтта ял көнне ял итәргә дә хокукы юк микәнни? Районның бу залда утырган барлык житәкчеләре гел кабәхәт кешеләрдән генә сайлап алынды микәнни? Алай дияр иден, аларның бөтенесе дә коммунистлар, намус, вөждан ияләре, коммунизм төзүдә иң алгы сафта атларбыз дип, үрнәк күрсәтербез дип партиягә кергәннәр. Иң белемлеләре, иң тырышлары, иң намуслылары дип, аларны житәкче урыннарга куйганнар. Ә менә хәзер Шәвәлиев, йә Арсланов аларны эткә әйтми торган сүзләр белән тирги-сүгә. Бу залда утыручылар бөтенесе ангыра, киребеткән булып, алар икесе генә акыл иясе микәнни?

Кемдер трибунадан төшүгә:

—Карл Маркс, Сабитов! К ящику!—дигән тавыш ишетелде.

Ирек ачуыннан кайнап чыкты һәм каш астыннан залга карап тора башлады.

—Ну, сөйлә,—диде Арсланов.—Ничек син анда АВМнарның эшен тоткарлыйсың? Ничек син анда сенаж саласың? Ничек сөт буенча көннән-көн артка тәгәрисең? Райком члены буларак, җавап бир!

Карл Маркс исемендәге колхозның председателе, Иреккә караган килеш, көлә-көлә сөйләшеп утыра иде.

—Ә сез мине кем дип белдегез соң?—Ирек Арслановка каерылып карады.

—Кем икәнеңне мин ачык әйттем кебек.

—Әйе, сез мине райком члены дидегез. Мин политик житәкче. Ә сез сораган әйберләрне эшләр өчен җавап бирүче,—Ирек бармагы белән залга төртте,—әнә көлә-көлә сөйләшеп утыра.

Кинәт зал тып-тын булды. Арсланов та берни әйтә алмады, чырае кара көйсә дә, тиешле сүзен таба алмыйча, ык-мык килеп маташты:

—Каян чыктың әле син шундый акыл иясе?

—Сез каян чыккан булсагыз, мин дә шуннан чыктым,—диде Ирек.

Залдагылар пырых-пырых көлешеп алдылар.

—Вон из зала!—дип кычкырды Арсланов.

Ирек тагын аңа борылды:

—Әгәр дә сезгә бу зал ошамый икән, үзегез чамалыйсыз,—диде ул, ачу белән.—Ә мине сигез чакрымнан хатыным, сабый балам белән колхоз чөгендерен эшкәртеп ятканда сезнең бүлек мөдирегез килеп алды.

—Чөгендерне иртәрәк эшкәртергә кирәк иде!—дип кычкырды Арсланов.

—Мин аны, иртәме-соңмы, туганнан бирле эшкәртәм, ә менә сезнең үз гомерегезгә берәр метр чөгендер эшкәрткәнегез бармы? Һәрхәлдә, сезнең, безнең районга килеп, мондый батырлык кылганыгыз юк әле.

Ирек шулай диде дә, трибунадан төшеп, урынына барып утырды.

—Яхшы әйттең, Сабитов, чын шагыйрьләрчә,—диде Арсланов, янагын чәйнәп.—Без синең белән янадан политикларча сөйләшербез әле. Художественный өлеше тәмам, хуҗалык эшләренә күчәбез. Хотя это и есть главная политика.

Ул вәкил итеп җибәрелгән бер генә кешене дә янадан трибунага

чыгармады. Колхоз-совхоз җитәкчеләрен, партком секретарьларын гына бастырды. Аларга да аның җикерүе кимеде, сүгенү сүзләре азайды. Район тарихында беренче секретарьга болай кыю итеп, каршы сүз әйткән кеше юк иде әле. Арсланов хәзер сырты сынган атны хәтерләтте. Аның чырае күкшелләнеп чыкты, иреннәре, куллары калтыранды.

Кинәшмә яңадан сәгать ярымнан бетте. Арсланов бюро членнарына калырга кушты. Зал бушап, тәмәке тарткач, бюро членнары аның бүлмәсенә кереп киттеләр. Ирек бюро исеменә үзен эштән азат итүләрен сорап гариза язды, Арслановның кабул итү бүлмәсенә юнәлде. Анда телефон саклап, Хисмәтуллин утыра иде. Ирекнең тоткага үрелүен күргәч, ул йөгереп килеп аның каршына басты.

—Юк, юк, анда керергә ярамый, бюро бара!

Ирек аны этеп кенә җибәрде дә Беренченең бүлмәсенә барып керде. Ул, бер сүз дә әйтмәде, кызу-кызу атлап, Арсланов каршына килде һәм гаризасын нәкъ аның алдына китереп салды:

—Бүген үк бюрода каравыгызны сорыйм. Мине эштән азат итегез.— Шулай диде дә ишеккә атлады.

—Сабитов, туктале!

Ирек туктады.

—Син нәрсә тәртә җимерәсең әле?

—Мин сезгә берни дә аңлатырга теләмим. Мин бары тик мине эштән азат итүегезне генә сорыйм.

—Ә нәрсә булды?

—Өч көн элек мина әйткәннәрегезне хәтерегезгә төшерегез.

—Ә нәрсә әйттем мин сиңа?

—«Сиңа» түгел, «сезгә». Минем сезгә беркайчан да «син» дип дәшкәнем юк. Сез өченче көн, редакция белән типографияне ябып, өч көнгә колхозга кычыткан чабарга китәргә куштыгыз. Сез ул кешеләрне хайваннар урынына да күрмисез. Районда мәхшәр. Һәркемнең нервысы киеренке. Без, район үзәгеннән сезнең тарафтан өстерелгән этләр кебек, барып җитәкчеләрне таларга, җитәкчеләр халыкны таларга тиеш. Сез нинди тормыш оештырасыз? Коммунизм әллә шушы буламы?

—Син монда лекция укыма!—дип җикерде Арсланов.

—Мин лекция укымыйм. Бөтен район сезнең табаныгызны ялап торса да, кешеләргә тынычлап эшләргә дә, яшәргә дә мөмкинлек булмаячак. Йә әйтегез, мин ничәгә ярылыйм? Бүген мин көтеп алган якшәмбемдә ял итимме, колхозның чөгендерен эшкәртимме, колхозга барып кычыткан чабыйммы, әллә сөт арттырыйммы, йә булмаса газета чыгарыйммы? Мондый тормышның кемгә кирәге бар?

—Ә кайчан булган ул тыныч тормыш?—диде Шәвәлиев, Беренчене яклауга күчеп.—Әтиеннәрдән, әниеннәрдән сораганың бармы? Тыныч булганмы аларның тормышы?

—Әгәр дә тыныч булмаган икән, моңа сезнең кебек кешеләр сәбәпче. Сезнең кебекләр элек тә булган, хәзер дә сез бар.

—Карагыз әле, җәмәгать, карагыз,—диде Шәвәлиев, кулларын җыеп.—Нинди кеше басып тора безнең каршыбызда? Бу бит үзен безгә каршы куя. Мондый кешедән котылу яхшырак булыр, Минзаһит Усманович.

—Юк!—диде Арсланов, тешләрен кысып.—Без аны җибәрмибез. Зөфәр Шәрипович. Без әле аны майлаган каеш кебек итәргә тиешбез. Әле эшлисең син! Мин беләм сине, хәзер квартира булды, хатын менә дигән, китап язып кына ятмакчы ул. Не получится! Будем работать, дорогой. Кем дә кем Сабитовның гаризасын кире кагарга ди, шул бюро членнарының кул күтәрүләрен сорыйм.

Бюро членнары барысы да кул күтәрделәр. Ирек ишекне шартлатып ябып, чыгып китте...

Аны урамда абыйсы Мэлс куып җитте.

—Әйдә утыр,—диде ул, машинасының ишеген ачып.

Ирек утыргач, аның кулын кысып, бик озак селкеп торды.

—Молодец, энекәш! Бүген син районда революция башладың,— диде.

Ирек елмаеп куйды.

—Арттырма әле, абый.

—Ә бу минем генә фикер түгел. Берәр сәгать вакыт таба аласыңмы син?

—Абый кеше өчен бер сәгать тә вакыт тапмагач. Тик беләсенме, Сөембикә белән Айгөл басуда калдылар.

—Кайсы басуда?

—Кайсы басуда булсын инде, чөгендер басуында.

—Хәзер оештырырбыз,—диде Мэлс.

Алар район үзәгеннән әйләнеп үтә торган юлга чыктылар. Анда дүрт жинел машина туктап тора иде. Мэлс узып китүгә, әлеге машиналар алар артыннан иярделәр. Чөгендер жиренә житкәч, Мэлс машинаны туктатты һәм алар икесе Сөембикә янына керделәр. Сөембикәдән хәл-әхвәл сорашкач, Мэлс:

—Сине хәзер минем машина кайтарып куяр, безнең бераз эш килеп чыкты әле,—диде.

Алар, басу башыннан төшеп китеп, Ык буендагы куе әрәмәлеккә керделәр. Машиналарда колхоз председательләре иде. Алар берәм-берәм Ирекнең кулын кыстылар, бүгенге күрсәткән батырлыгы өчен мактадылар. Тиз генә урын әзерләп, азык-төлек куйдылар, берничә шешә аракы чыкты. Тора-бара бирегә район председательләренең яртысыннан күбесе жыелды. Арада иң тәжрибәлесе, иң күп эшләгән Хәкимов стаканын кулына алды.

—Җәмәгать, председательләр советының чираттагы утырышы ачык,— диде ул. Бу жәмгыятькә теләсә кем алына алмаганын сез беләсез. Биредә катнашучылар, кат-кат сыналгач кына, шушы җәмгыятьнең әгъзасы булдылар. Без элегрәк, кагыйдәдән чыгарма рәвешендә, үзебезнең арага, колхоз председателе булмаса да, Вафин Лотфулла Габдрахмановичны кабул иткән идек. Минем Ирек Сабитовны да алырга дигән тәкъдимем бар. Без аны элек тә белә идек. Ул бүген үзен чын ир-егет итеп күрсәтте. Арсланов, Шәвәлиевләргә бөтен халык алдында беренче удар ясалды. Иншалла, ул беренчесе булып кына калмас... Кем дә кем минем тәкъдимгә кушыла, кулларыгызны күтәрүегезне сорыйм.—Барысы да кул күтәрделәр.— Ә хәзер, Ирек энекәш, синең исәнлеккә.

Рюмкалар, стаканнар, кружкалар чәкештерелде. Ирек өчен бу көтелмәгән бәйрәм булды. Аның яшерен жәмгыять барлыгын, житәкчесе Хәкимов икәнлеген, ләкин аңа Батталов кебекләрнең гомер буе керә алмауларын ишеткәне бар иде. Бер елны «Ык буе» колхозының ферма буена тарттырылган өч эскерт печәне янып бетте. Кемдер ут төрткәнлегенә шикләнмәделәр, ләкин шул чакта, председательләр жәмгыяте жыелып, бу мәсьәләне тикшергән һәм бер атна үтүгә «Ык буе»ның кабат шул ук күләмдә печән эскертләре барлыкка килгән иде.

Ирек исеменә бик күп мактау сүзләре әйтелде. Аны курыкмаска чакырдылар, без барын онытма, диделәр. Ирек әле генә бюрога гариза кerткәнлеген, ләкин аны кире каккаңнарын сөйләп бирде.

—Җибәрмәсләр шул,—диде Хәкимов.—Нипель системасы шәп эшли. Аларның бит бөтен уе кешене газаплауга юнәлдерелгән. Кешегә ничек тә әйбәт булмасын, начар булсын. Ирек туган, әле сине нык интектерәчәкләр болар.—Аннары Хәкимов сүзне икенчегә борды:—Безнең «Юлдаш»ның быел чәчәргә арышы юк. Орлык белән ярдәм итик. Кем күпме булдыра ала. Кайтыгыз, капчык төпләрен карагыз да аннары хәбәр итәрсез.

Элек колхоз председателе булып эшләгән Хәбибулла дигән кеше каты авырый икән. Иртәгә кич сигездә барып, аның хәлен белергә килештеләр. Шуның белән жыелышу тәмам булды.

## 21

Февраль азагы иде. Шәвәлиев һәм райбашкарма председателе Гаскәров имзасы белән җибәрелгән күрсәтмә нигезендә һәр коллективтан бер-ике кеше район мәдәният йортына хорда җырлау өчен чакырыла башлады. Март башында районны телевизорга төшерәчәкләр, хор шунда чыгыш ясарга тиеш икән. Күрсәтмә нигезендә корреспондент Максутов көн аралаш хорга йөрде. Март башында алар, автобусларга төялеп, Казанга киттеләр, өч көннән әйләнеп тә кайттылар. Шул көнне төштән соң Ирекне Шәвәлиевкә чакырдылар. Ул бүлмәдә үзе генә иде.

—Беләсезме, Ирек Хәйриевич,—диде ул, кашларын җыерып. Теге вакытта бәрелешкәннән соң ул да, Беренче дә, башкалар да аңа «сез» дип мөрәҗәгать итә башлаганнар иде.—Монда бер четерекле әйбер килеп чыкты әле.

—Ни соң ул?—дип сорады Ирек.

—Сезгә Максутовны эштән азат итәргә туры киләчәк.

Ирек ни уйларга белмәде. Максутов хәзер редакциядә иң өметле каләм иясе иде. Читтән торып журналистика факультетын тәмамлады, теләсә нинди темага яза ала, иң күп материал биргән кеше шул. Димәк, райком ниндидер эшкә алырга тели.

—Зөфәр Шәрипович,—диде Ирек,—беләм, сезгә кеше кирәктер, ләкин кайсын алсагыз да алыгыз, Максутовка гына тимәгез.

—Аңлагыз, бу мәсьәләне тикшерергә соң инде,—диде Шәвәлиев, ничектер серле итеп.—Максутовны без, гомумән, каядыр куярга җыенмыйбыз, ләкин ул редакциядә эшли алмый.

Ирекнең күңелендә ярсу кузгалды. Шәвәлиевнең, шушылай әйтмичә, ниндидер астыртын мәгънәле ишарәләр белән җанны ашавын яратмый иде ул.

—Ул минем иң яхшы сотрудникгым, мин аны җибәрмим!

—Хәзер ул үзен тотышы буенча редакциядә эшли алмый. Әхлагы буенча.

—Аңлата аласызмы сез, юкмы? Нишләгән ул?!

Шәвәлиев аска карап бик озак утырды.

—Ул егеткә минем дә өметем зур иде,—диде ул.—Ләкин Казанда исеменә тап төшергән. Үз исеменә генә дә түгел...—Шәвәлиев ялт итеп башын күтәрде һәм Ирекнең күзләренә туп-туры карады.—Ирек Хәйриевич, әйдә чын ирләрчә сөйләшик әле. Сез миннән дә бер әйбер дә сорамагыз, Максутовка да берни дә әйтмәгез, сәбәбен табыгыз, аны эштән азат итегез. Мин сездән үтенеп сорыйм. Күпме генә карышсагыз да, тавышлансагыз да, барыбер мин әйткәнчә булачак.

Ирек баш чайкады:

—Мин аны эштән ни дип чыгарыйм?

—Теләсәң, сәбәп табып була. Әнә беркөнге рейдында күпме хата киткән, фактларны җентекләп тикшермәгән. Теләгәндә табып була бит.

—Табып була, әлбәттә,—диде Ирек.—Андый хаталар һәркемдә дә бар. Аннары мин аның Казанда ниндидер тәртипсезлек эшләвенә ышанмыйм. Андый егет түгел ул. Анда тәртип бозган очракта да, мин аны редакциядә калдыру өчен барысын да эшләячәкмен.

—Шулай итеп, сез минем үтенечне аяк астына салып таптыйсыз. Ләкин белеп торыгыз, ул үтенеч минеке генә түгел. Иң элек Минзаһит Усмановичныкы.

—Аңа Максутов ник кирәк булган соң әле?—Ирек иңбашларын җыерды.

—Тәки әйттерәсез инде!—Шәвәлиев, чәүкәдәй, як-ягына каранып алды.—Тик үзегез генә белегез—мин сезгә берни дә әйтмәдем. Хор белән чыгыш ясарга Минзаһит Усмановичның кызы да барган иде. Максутов шуңа кул салган.

—Ничек кул салган?—диде Ирек аптырап.

—Анысын мин каян белим, карап тормадым. Кочаклаганмы, үпкәнме шунда...

—Минә сина кирәк булса!—диде Ирек.—Яшь чакта ни булмас. Бәлки алар бер-берсен ярата торганнардыр.

—Анысы инде сезнең белән минем компетенциягә керми. Сез аны эштән азат итәсез.

—Болай булгач, мәнге юк!—диде Ирек.—Нишләп мин кешенең язмышы белән шаярыйм? Яңадан әйтмәгез дә, булмый.

Ирек чыгып китте.

Ничә көн үткәндер, Иреккә Нәҗмиев бер атнага Казанга семинарга китәргә кирәклеге турында әйтте.

—Кемнәр семинары?—диде Ирек.

—Совет органнарында эшләүче партоешма секретарьлары семинары.

—Соң мин бит...

—Кем анда синнән документ сорый? Райбашкармада партоешма секретаре диярсең, сорасалар.

Ирек башкача сүз озайтмады. Эчтән куанып туймады ул. Беркөн генә язучылар идарәсеннән чылтыратып алдагы атнада синең өчен мөһим мәсьәлә каралачак, килсәң, яхшы булыр, дигәннәр иде. Сорыйсы да булмады, сорасаң да, җибәрмәячәкләре көн кебек ачык. Редакцияләргә дә керәсе, очрашасы кешеләре дә бар, шуңа күрә ул Казанга дәртләнеп очты.

Язучылар идарәсендә чыннан да аның өчен бик куанычлы яңалыклар булды. Идарә утырышында Иреккне, башлап язучы тагын ике кешене алдагы елларда Мәскәүгә ике еллык Югары әдәби курсларга, йә булмаса бер еллык Югары театраль курсларга җибәрү турында карар кабул ителде. Утырыштан соң Ирек белән идарә рәисе урынбасары аерым сөйләште. Әгәр дә гаиләгез белән килешсәгез, быел көзгә үк сезне ике елга Мәскәүгә укырга җибәрү ихтималыбыз бар, диде.

* * *

Миңзаһит Усмановичта бүген аулак өй: Хәят больницада, кызы кунакта. Ул җиңелчә музыка куйды да трельяж каршына килде. Шикәрдәй ап-ак спорт костюмы килешә иде аңа. Әз генә чал керә башлаган кара чәчләре куе, күзләре дәртле карыйлар, иреннәрендә тәвәккәллек, җилкәләр киң. Ул ике кулын күтәреп киерелеп куйды. Бер центнерлы гәүдә димәссең. Әле егетләрнеке кебек төз һәм нәфис, илленең өстенә чыккач, теләсә кем мондый фигура саклый алмый. Ләкин Арсланов бер нәрсәгә гомер буе тугры калды: сәламәтлек, сәламәтлек—бары шул гына. Әле һаман да ул иртәнге зарядканы калдырмый. Бакчасына ясатып куелган махсус урында җәй буе көнгә ике мәртәбә душ коена, кышын чаңгыда йөри. Кара һәм кызыл икра, лимон, апельсин, мандарин кебек җимешләрне ел дәвамында кайтарып тора. Район аптекаларыннан да, Казаннан да женьшень, алтын тамыр кебек дефицит даруларны таптыра. Шуңа күрә аның бөтенләй диярлек авырганы юк. Әгәр дә ялгышып томау төшсә, йә булмаса тамак төбе кытыкланса, больницадан китерелгән кварц, УВЧ аппаратлары өендә тора. Әгәр нинди дә авыру сизсә, ул шундук өлкә комитеты шифаханәсенә юл тота, яхшылап тикшерелә, күпме кирәк, шул кадәр дәвалана. Ел саен иң яхшы вакытта көньякка санаторийга бара, кап-кара булып кызынып, еллык энергия җыеп кайта. Юк, аңа күзгедән карап торучы бу кешегә әле кырыктан артыкны бирерлек түгел иде. Миңзаһит кухняга чыкты, сәгатенә карап куйды. Әле тагын утыз минут көтәсе бар иде. Кәефен күтәрү өчен өстәлдәге лимон салынган «Посольский» аракысын ул тагын бер рюмка эчеп куйды. Аннары, авыз эченнән көйли-көйли, кулына ачкыч алып, ишек алдына чыгып китте. Йортның подвалын ачты, электр утын кабызды. Ул горурланып карап

торды. Әнә кешедән дә биек ике зур суыткыч эшләп утыра, аларда әллә ничә төрле май, пошц, кабан, кош итләре түшкәсе белән эленеп тора. Төрле шкафлардагы бүлкәләрдә банкаларга тозланган яшелчәләр, кайнатылган җиләк-җимешләр, балык-ит консервылары, затлы чәйләр, кофе банкалары. Өченче суыткычта туңдырылган чия, карлыган, сырганак, крыжовник, мүк җиләге, балан, виктория һәм башка җиләк-җимеш. Арырак тартмаларда пычкы чүбе белән тутырылган антоновка алмалары. Аларны ел саен Гайсә Батталович үзе тутырып китерә һәм яңа алма уңышы өлгергәнче бу антоновкалар, бүген агачтан өзгәндәй, теш арасында кештердәп торалар.

Миңзаһит полиэтилен капчыкка беркадәр алма, катырылган чия, крыжовник салды, ике литрлы банкадагы ассортины култык астына кыстырды да, подвалның утын сүндереп, кухняга керде. Музыка туктаган иде, ул, залга чыгып, зур люстраны гөлт итеп кабызып җибәрде һәм магнитофонның кассетасын алыштырды. Яңадан өйгә күңелле музыка таралды. Затлы келәм өстенә баскан килеш Миңзаһит, горурланып, стенадагы фарсы келәменә, чит илдә эшләнгән озын һәм биек стенкага, анда җем-җем итеп торучы алтын һәм көмеш йөгертелгән савыт-сабаларга карап торды. Бу өйне ул өч ел элек эшләтте. Башта, әлбәттә, кемгә нәрсә салынганын беркем дә белмәде. Болынкырда ясләләр җитми иде, җайлап кына, ясле салалар, дигән сүз тараттылар. Иң яхшы төзүчеләр, иң яхшы осталар җәй буе эшләделәр аны. Җиде бүлмә, һәркайсы эчтән бизәкле тар такталар белән эшләнде, ванна бүлмәсе кара кафель плитәләр белән әйләндерелде. Башта акны куйганнар иде, Миңзаһит аны ошатмады, карасын эзләтте. Коммуналь хуҗалык начальнигы кара плитәләрне, дөнья бетереп юллап, ахырда Ялтадан табып алып кайтты. Өйнең эченә бернинди буяу әсәре кертелмәде. Нарат идәннәр, нарат түшәмнәр шундый итеп бер-берсенә терәлделәр, аларның аерым тактадан эшләнгәне кул белән сыпырып карасаң да белерлек түгел. Йорт такта белән тышланды һәм дүрт мәртәбә буялды. Бакчага беседка ясалды, биек итеп коймалар коелды. Мунча өч бүлкәле, зур верандалы итеп эшләнде. Өйгә дә, мунчага да район үзәгенең иң зур котельныеннан җылылык китерелде. Әлбәттә, Миңзаһит анда бик күренеп йөрмәде, бик иртә, кеше-кара торганчы, Гаскәров белән кереп карап чыгып, үзенә ошамаган нәрсәләрне җимертте, кабат эшләтте. Яшелчә, агач, бәрәңге бакчаларына нечкә торбалар ярдәмендә су җибәрелде. Ишек алдында яшел чирәм, чәчәкләр үсә. Пыяладан ике метр биеклектә зур теплица эшләтте, аңа җылылык үткәрелде. Миңзаһит боларның берсен дә куркып эшләмәде. Инде ул вакытлар үткән, хәзер яшәп калырга кирәк иде. Бу районга килгәнче, аны партия мәктәбенә укырга җибәрделәр. Ул кайтуга, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире кинәт үлеп, аның урынына Миңзаһитны куйдылар. Үзен күрсәтү, танытту өчен, югары партия органнарына җаны-тәне белән бирелгән кеше итеп раслау өчен Миңзаһитка аз тырышырга туры килмәде. Районнан районга күчеп йөрүләр дә шактыйга җыелды. Партия кая куша—син шунда. Ул бер нәрсәне аңлады: сабантуй мәйданындагы колганың очына күтәрелгән саен, ул ныграк чайкала, куркынычрак була барган кебек, югарырак баскычка үрләгән саен, эш хәтәррәккә әйләнә. Кечкенә ялгыш хәрәкәт һәм син аска мәтәллисең, аннары яңадан күтәрелермен димә.

Миңзаһит өстәлне гадәттәгечә йокы бүлмәсенә әзерләде. Суда җебетеп, чия белән крыжовникны куйды, башка ризыкларны тезде. Ике чәнечке, салфетка чыгарды. Сизелер-сизелмәс кенә яктылык сибүче торшерны кабызды. Аннары магнитофонны шунда күчереп куйды. Ул түземсезләнеп сәгатенә карады. Инде вакыт житкән, ул килергә тиеш иде. Ишекләр бикләнмәгән, ул звонокка басмыйча, турыдан-туры килеп керергә тиеш. Миңзаһит, верандага чыгып, тәрәзәдән урамга күз ташлады. Ләкин беркем дә күренмәде, аяк тавышлары да ишетелмәде. Ул кереп кулына газета алды, ләкин укымады, ишек алдындагы утларның януы

хәтеренә төште һәм барлык лампочкаларны сүндереп куйды. Шулчак тышта аяк тавышлары ишетелде һәм ишектә Сөембикә күренде.

—Исәнмесез,—диде ул, кулындагы перчаткасын сала-сала.

—Озак, озак, Сөембикә,—диде Миңзаһит, аның пальтосын салдыра-салдыра.

—Айгөлне көчкә йоклаттык, үземнең китапханәче кызны өйдә калдырдым, бик озак торкарланмаска иде.

—Борчылма, төн безнеке инде,—диде Миңзаһит һәм аны култыклап йокы бүлмәсенә алып кереп китте.—Хәзер бер генә минут,—диде ул, аны йомшак кәнәфигә утыртып. Миңзаһит тышкы ишекне бикләде һәм кухнядагы утны сүндерде. Хәзер инде өй эчтән дә, тыштан да караңгылыкка чумган, бары тик шушы бүлмәдә генә сүрән яктылык бар, аның да бакчага карый торган бердәнбер тәрәзәсе көрән төстәге калын пәрдәләр белән томаланган иде.—Йә, исәнме,—дип пышылдады Миңзаһит һәм Сөембикәне, култык астыннан тотып, урыныннан торгызды, аның салкын иреннәрен үпте.

Сөембикәнең алланып торган бит очлары да сап-салкын иде. Аларга кайнар иреннәрен тигереп алып, Миңзаһит:

—И, балакаем, син тәмам туңгансың бит, әйдә бераз җылыныйк әле,—диде һәм бәллүр рюмкаларга ниндидер саргылт төстәге сыеклык салды. Алар чәкештереп эчеп җибәрделәр. Бу эчемлек, үзе бик тәмле булса да, гаҗәеп каты иде, тамак төбенең януына чыдый алмыйча, Сөембикә ашыга-кабалана минераль су капты.

—Нәрсә бу, Миңзаһит Усманович?

—Әгәр дә Усманович димәсәң, әйтәм.

—Юк, кыстамагыз. Сезгә минем хөрмәтем артык зур. Әгәр шулай булмаса, килмәс тә идем.

—Мин бит сине хөрмәт иткән өчен генә чакырмыйм, Сөембикә,—диде Миңзаһит елмаеп.—Әгәр теләсәм, менә монда хәзер унсигез яшьлек кызлар йөгереп килеп җитәчәк. Син минем нәрсә әйткәнемне аңлыйсыңмы?

—Аңлыйм...—Сөембикә керфекләрен аска төшерде.

Ул биредәге ризыкларның кайсына үрелергә белмәде, ә теге эчемлек аның бөтен канын куаларга, йөрәген дәртләндереп типтерергә кереште. Миңзаһит тагын шуны салды.

—Ни соң бу?—диде Сөембикә көлә-көлә.—Мин хәзер бөтенләй таралып төштем.

—Узган ел урманда без синең белән моның башка төрлесен эчкән идек. Хәтерлисеңме? Алсурак төстә иде ул.

—Әйе, әйе,—диде Сөембикә, кып-кызыл чияне авызына кабып.

—Кырык җиде төрле үләннең шифасын үзенә алган туксан градуслы спирт бу. Моны эчкәч, бер авыруың да калмый.

Алар рюмкаларын чәкештерделәр.

—Татарның синең кебек бар яктан да булган хатыннары өчен!

Сөембикә бер йотты да рюмкасын урынына куйды.

—Болай булмый,—диде Миңзаһит һәм, рюмкасын алып, Сөембикәнең авызына китерде.

—Миңзаһит Усманович, мин исерәм,—диде Сөембикә, башын артка ташлап, елмайган хәлдә.

Миңзаһит аның муенын үбеп алды.

—Ә мин сине айнытырмын, ах, изәрмен кебек мин сине бүген!

Сөембикә кычкырып көлде дә эчеп куйды. Миңзаһит аңа, үз кулы белән тотып, минераль су эчерде, чия, крыжовник каптырды, тавык ите бирде. Аннары барып магнитофонны кушты, шактый кызу ритмдагы җыр яңгырады.

—Танцы итәбезме?—диде ул, Сөембикәнең каршына килеп.

Сөембикә утырган хәлдә аңа үрелеп карады, елмайды, әмма бер сүз дә дәшмәде, урыннан да тормады: ул исергән иде. Миңзаһит аны,

кулыннан тотып, урыныннан кузгатты һәм, биленнән кысып, танцы иттерә башлады. Сөембикә, ике кулын Миңзаһитның иңбашларына куеп, башын артка ташлап көлде дә көлде. Бу сихри яктылыкта аның зәңгәр күзләре, ап-ак тешләре Миңзаһитны ирексездән үзенә тарттылар. Кызу гына әйләнеп барган җирдән аны диван-кровать кырына алып килде дә, алар бергәләп шунда аудылар. Миңзаһитның зур гәүдәсе астында Сөембикә бөтенләй күренми дә иде. Алар икесе дә бер-берсенең сулыш алганын ишетеп яттылар.

—Мин сине изәм бит,—диде Миңзаһит.

Сөембикәнең пышылдаган тавышы ишетелде:

—Из... мә...

Миңзаһит куллары белән аның билен, янбашларын сыпырды һәм акрын гына күлмәген өскә күтәрә башлады.

—Утны сүндер, Миңзаһит Усманович, мин булдыра алмыйм,—диде Сөембикә.

—Ә минем сине күрәсем килә, ут яктысында күрәсем килә.

—Юк-юк,—диде Сөембикә, Миңзаһитның колготкиендагы кулын тотып.

—Ярый, мин утны сүндерәм,—диде ул.—Тик аңарчы без бер ярты рюмка тотабыз.

Әгәр дә исерсә, Сөембикә кайтмаячак. Миңзаһитның уе аны төне буе биредә калдыру иде. Бусында Сөембикә карышмады. Колбаса, ит ашагач, тозлы тәм-том капкач, Миңзаһит утны сүндерде. Бүлмә кап-караңгы булды. Ул Сөембикәне кочаклап алды һәм ашыга-кабалана чишендерергә тотынды.

—Юк-юк, үзем...

Миңзаһит, урындык каршына килеп, спорт костюмын салды, үзе колагы белән Сөембикәнең чишенгәнен тыңлады. Ахырда ул анадан тума хәлдә аңа якынлашты, Сөембикәнең әз генә аксылланып күренеп торган гәүдәсен килеп кочаклады. Ул аңа аркасы белән тора иде, Миңзаһит аның ике күкрәген дә үзенең көчле куллары белән комсызланып кыса башлады.

—Ай!.. Ой! Авырттырасыз, Миңзаһит Усманович,—дип ыңгырашты Сөембикә.

Миңзаһит аның күкрәкләрен җибәрде, үзенә таба борды. Сөембикә бернинди дә каршылык күрсәтмәде, ул барысына да риза иде. Миңзаһит, әз генә артка чигенеп, почмактагы торшерның кабызгычына аягы белән басты. Сөембикә бер сүз дә әйтмәде, бары тик күзләрен генә йомды. Миңзаһит, аны күтәреп диярлек алып барып, мендәр өстенә яткырды һәм түгәрәк күкрәкләрен, муенын шашып үбәргә кереште. Сөембикә бары тик ыңгырашты, нииндидер, эченнән өзелеп чыккандай аңлаешсыз авазлар чыгарды, ахырда Миңзаһит аның өстенә ятты. Сөембикәнең бөтен гәүдәсе ут яна һәм калтырана иде. Аның кайнар куллары Миңзаһитның билләрен сыпырдылар һәм, алгы якка күчеп, аның теләген үтәргә булыштылар. Инде бернинди сүз кирәкми, алар икесе дә еш-еш сулыйлар, бер-берсен канәгатьләндерү өчен барлык күзәнәкләренең кайнарлыгын туплап, бер-берсенә юнәлтәләр иде. Миңзаһит кулы белән диванга таянмады, гәүдәсенең бөтен авырлыгын аның өстенә салды. Үзенең гәүдәсе белән бергә өскә таба күтәрелүче Сөембикәнең һәр мускулын, тәненең һәр борылмасын ләззәтләнеп карады. Инде аларның тын алулары нииндидер аңлаешсыз, тамак төбеннән ирексездән чыккан тавышлары, тизләнгәннән-тизләнә барып, магнитофон тавышын да күмеп киткән иде. Күпмедер вакыттан соң алар тып-тын булып, хәрәкәтсез калдылар. Сөембикәнең нечкә, нәфис беләкләре, бармаклары акрын гына Миңзаһитның иңбашыннан биленә кадәр аркасын сыпыра, иркәли иделәр.

—Син тирләдең,—диде Миңзаһит, аның култык асларының, күкрәкләренең юешләнүен сизеп.

Сөембикә күзләрен йомган килеш елмайды гына.
—Ваннада юынып алмыйсыңмы?
Сөембикә юк дигән мәгънәдә баш чайкады.
—Эчәсең киләме?
Сөембикә тагын баш чайкады.
—Танцы итәсең киләме?
Сөембикә кабат баш чайкады.
—Ә нәрсә телисең соң син?
—Берни дә теләмим,—диде Сөембикә пышылдап.
—Юк, алай булмый,—диде Минзаһит.—Кеше берни дә теләмәсә, үлә.
—Алайса мин дә үләм инде.
—Юк, син үлмә әле, син кирәк,—диде Минзаһит һәм аны, урыныннан күтәреп алып, үзенең алдына утыртты.
Сөембикә, сабый бала кебек, аның муеныннан кочаклады. Миңзаһит борыны, иреннәре белән аның күкрәкләрен кытыклады, кат-кат үпте.
—Сина инде тагын бер-ике баскыч күтәрелергә вакыттыр. Телисеңме?
Сөембикә бер сүз дә дәшмәде, аның күзләренә төбәлде.
—Юк, әйтмим әле,—диде Минзаһит, кинәт кире уйлап.
—Әйт инде.
—Хәзергә әйтмим. Ә менә киләсе сайлауларга, әгәр карышмасаң, сине Татарстан депутаты итәбез. Икәү бергә генә йөрербез.
Һәр чакырылыш саен районнан Татарстан Югары Советына ике депутат сайлана, аның берсе беренче секретарь, икенчесе гадирәк эштә эшләүче яшьрәк хатын-кыз була иде. Сөембикә Минзаһитка бармак янады:
—Нишләп депутатлыкка гел чибәр хатын-кызларны гына сайлыйлар микән дип баш вата идем. Хәзер серенә төшендем,—диде ул.
—Карале, син көнче икәнсең,—диде Минзаһит көлеп.
Шулчак ишек шалтыравыгы тавыш бирде. Сөембикә күз ачып йомган арада, Миңзаһитның алдыннан шуып төшеп, колготкиларына үрелде.
—Борчылма, борчылма,—диде Миңзаһит.—Бу вакытта безгә этем дә керми.—Ул ашыкмый-кабаланмый гына киенде.—Йә күршеләрнең ашыгыч ярдәм чакырасылары бардыр.—Ул, акрын гына атлап, өйалдына чыгып утны яндырды һәм:
—Кем бар анда?—диде.
—Әти, мин бу, ач әле!
Бу Рашат тавышы иде. Нишләп бу вакытта кайткан ул? Миңзаһит ни кылырга да белмәде. Әле ишекнең келәсенә үрелде, әле кулын, эссе тимергә тигәндәй, тартып алды. Рашатның калын тавышы тагын яңгырады:
—Нишләп ачмыйсың?
Инде берни дә кылып булмый, барыбер ачарга туры киләчәк иде. Минзаһит упкынга сикергәндәй тойгы белән келәне өскә күтәрде. Рашатның мыеклары, яка очлары, бүреге бәсәреп чыккан иде.
—Ни булды? Нишләп бик соң?—диде ул, ни әйтергә белмичә.
—Чаллыдан кайттым.
Рашат ишеккә таба атлады.
—Улым, туктале,—диде Миңзаһит.—Син әз генә керми тора алмыйсыңмы?
—Ник?—Рашат аңа аптырап карады.
—Әниеңнәр өйдә юк иде, анда бер кунак килде дә...
Рашат кулындагы сумкасын дөпелдәтеп почмакка ыргытты.
—Их син, карт б...т!—диде ул, теш арасыннан төкереп.
Әтисен артка этеп җибәрде дә өйгә кереп китте. Кухняның утын яндырды, келәм өстеннән тавышсыз гына барып, йокы бүлмәсенең ишеген ачты. Сөембикә колготкидан гына күкрәкчәсен эләктереп маташа иде. Рашатны күргәч, ул кычкырып җибәрде һәм, одеалны алып, күкрәкләрен каплады.

—О-о-о, редактор хатыны!—диде Рашат, мыскыллы елмаеп.—Язгы туйларыгыз башлану белән котлыйм!

Ул, стеналар селкенерлек итеп, йокы бүлмәсенең ишеген япты һәм арттан килгән әтисенә борылды:

—Мин синнән җирәнәм!—диде дә өстәлдә торган лимонлы аракыны бер стакан тутырып салды да эчеп җибәрде.—Синең үз гомереңдә шушы эштән башка берәр шөгылең булды микән?

—Рашат улым...—дип пышылдады Минзаһит.—Мин сиңа барысын да аңлатам, тавышланма гына. Ул әле генә килеп керде. Миң аңа бурычлы. Ул мине зур бәладән коткарды.—Минзаһит тагын ни алдашырга икән дип уйлап торды.—Әгәр дә ул коткармаса, без барысын да югалта идек. Шуңа күрә мин аны куып чыгара алмадым. Ул исерек иде. Килде дә ишек төбенә егылды, мин алып керергә мәҗбүр булдым. Мин сиңа янадан сөйләрмен. Берәр бүлмәгә чыгып тор инде.

Рашат шешәне алды да, бүреген дә, тунын да салмаган килеш, залга кереп китте. Минзаһит җәһәт кенә йокы бүлмәсенә кереп, Сөембикәгә: «Тиз бул!»—диде. Сөембикә, аягына киеп, пальтосы белән бүреген кулына тоткан хәлдә чыгып йөгерде. Минзаһит, ул кабат керә күрмәсен дигәндәй, утны сүндереп, келәне элде. Сәгать төнге унике иде...

* * *

Ирек Казаннан кайтып төшү белән өенә түгел, редакциягә юл тотты. Бүлмәсенә кереп чишенде, өстәл артына утыргач, үзе Казанда вакытта чыккан өч сан газетаны караштырып алды. Аннары, Зәбировка чылтыратып, аны чакырды. Алар кул биреп күрештеләр. Ирек район яңалыклары турында сорады. Зәбировның кара күзләре ничектер тынгысыз хәрәкәтләнделәр, ул нәрсәнедер яшерә иде, ахрысы.

—Әллә нинди яңалыклар юк... Максутовны җибәрдем инде.

Ирек аптырап китте.

—Кайда җибәрдең?

—Эштән азат иттем.

—Син акылыңдамы, Хәниф Кәримович?—диде Ирек, тавышын күтәреп.—Син аны берничек тә эштән азат итә алмыйсың!

—Шәвәлиев бит сезнең белән сөйләштем, диде. Шулай булгач, мин карышып тормадым.

Ирек шушында гына үзен ни өчен Казанга җибәргәннәрен аңлады.

—Мин бит аңа кисеп әйттем, Максутовны эштән азат итмәячәкмен,—дидем.

—Ә ул миңа алай димәде.

Хәзер инде Зәбиров белән сүз көрәштерү, кычкырышудан файда юк иде. Ирек барысын да төшенде. Аларның икесенең килешеп эшләгән эше иде бу. Зәбировның Максутовны күралмаганын бөтен редакция белә, чөнки егет яхшы һәм күп яза, редактордан кала, редакциядә ул беренче кеше, иртәме-соңмы, Зәбировка үз урынын аңа бирергә туры киләчәк иде. Ә ул урынын бирү генә түгел, гомер буе редактор булырга хыялланды. Тик аны ул омтылган урынга гына якын китермәделәр. Менә хәзер Ирекне Казанга җибәреп, Шәвәлиев тә, Зәбиров та үз дигәннәрен эшләгәннәр иде.

—Сез мине юләргә санамагыз, Хәниф Кәримович,—диде Ирек.—Мин сезнең Шәвәлиев белән ни сөйләшкәнегезгә кадәр һәммәсен әйтә алам. Әгәр дә Максутовны эштән азат итәргә уйлаган булсам, моны сезгә әйтмичә китәр идеммени? Уеныгыз гадел түгел. Ләкин мин сезгә хәлне төзәтергә мөмкинлек бирәм. Хәзер үк, Максутовны чакырып, приказыгызны юкка чыгарыгыз.

—Мин берничек тә Максутовны чакыра алмыйм. Аңа районнан чыгып китәргә егерме дүрт сәгать вакыт биреллде.

—Кем бирде?—диде Ирек, аны бүлдереп.

—Анысын мин белмим. Аның инде, пропискадан төшеп, Болынкырдан чыгып киткәненә дүртенче тәүлек.

—Бусына да башыгыз эшләгән икән,—диде Ирек.

Кич өйгә кайтып керүгә, Айгөл бер яктан, Сөембикә икенче яктан аның муенына сарылдылар.

—Туктагыз әле, чишенергә ирек бирегез,—диде ул.

Ирек чишенеп чемоданын ачты. Кызына алып кайткан курчагын сузды, өстәлгә торт, алма, апельсин куйды. Айгөл, әтисенә рәхмәт әйтеп, аның янакларыннан үпте, бүген яследә ниләр булганын сөйләде. Кич, кызлары йоклагач, утны сүндергәннән соң ул Сөембикәгә:

—Мине Мәскәүгә ике еллык укуга җибәрергә уйлыйлар. Югары курсларга. Син ни әйтерсен?—диде.—Тагын шунысы да бар: әгәр мин укырга китмәсәм, бу эштән мәңге котылу юк, берни дә яза алмаячакмын.

Сөембикә, аны кочагына кысып:

—Ике елга ничек тә түзәрмен, китә бир,—диде.

Хатынының аның уйларын анлавына Ирек шатланып куйды.

—Хәзергә беркемгә бер сүз дә ычкындырасы булма,—диде ул, хатынының кайнар гәүдәсен кочагына алып.

* * *

Зәбиров төштән соң Ирекнең кайтканлыгын һәм ике арада булган күңелсез сөйләшү турында әйткәч, Шәвәлиев пошаманга төште. Эш эшләнде, Беренченең әмере үтәлде, ләкин Сабитовның тавыш-гаугасыз гына дәшми калуына ышанып булмый. Әле ул килеп иң элек Шәвәлиевкә ташланачак. «Нишләргә соң?»—дип баш ватты ул. Сөт хәзерләү буенча районның квартал планы өзелү алдында, иртәгә барлык авыл Советларына сөт җыю буенча вәкилләр чыгаралар. Редакторның атна буе Казанда булуын да, Максутовның китүен дә истә тотып, Шәвәлиев Сабитовны бу исемлектән төшереп калдырган иде. Хәзер ул башкача фикер йөртте. Төшереп калдыру гына түгел, аны утның үзенә илтеп тыгарга кирәк, дип уйлады ул. Чәйнәшсеннәр Батталов белән. «Авангард» колхозына кергән Зирекле авыл Советына вәкил итеп җибәрергә кирәк. Ераклыгы да ерак, сөт хәзерләүләренең дә рәте юк, редакциянең машинасы да йөрми, ятсын шунда.

Иртәнге алтыда барлык вәкилләр, шул исәптән Ирек тә, райкомның утырышлар залына җыелдылар. Райбашкарма председателе Гаскәров сөт хәзерләү планының өзелү алдында торуын, калган сигез-тугыз көн эчендә авыл Советларында сөт җыюда борылыш ясарга кирәклеген дәлилләп сөйләде, һәр авыл Советына күпме сөт җыярга кирәклеген житкерде. Аннан соң Шәвәлиев кемнең кая беркетелгәнлеген, көн саен үзенә «доложить итеп» торырга кирәклеген әйтте, урыннарда һәр өйгә кереп, аерым сөйләшергә киңәш итте. Вәкилләр, сигездән дә калмыйча, авылларга чыгып китәргә тиеш иделәр. Хисмәтуллин һәм райкомның башка инструкторлары аларның кайчан барып житүен, ниләр эшләүләрен контрольдә тотарга, бу хакта Шәвәлиевкә хәбәр итеп торырга тиешләр.

Максутов мәсьәләсе буенча Ирек үпкә сүзләрен белдереп чыкмакчы иде, инде болай булгач, Шәвәлиевкә кереп тормады. Редакциядә эш муеннан, әле аның кайтып бер бит материал да укып биргәне юк. Ул, баш күтәрмичә, сәгать уннарга кадәр материалларны укыды да, кайтып ашап, унбердә «Авангард» ягына китә торган автобуска утырып, Зирекле авыл Советына юл тотты.

Төштән соң, сәгать икенче киткәч, Шәвәлиев Хисмәтуллинны чакырып кертте.

—Каяле исемлегегез, барысы да китеп беттеме?—диде ул ана.

—Китеп беттеләр,—диде Хисмәтуллин, каләме белән исемлеккә төртеп күрсәтә-күрсәтә.

—Ә редактор?

—Ул сәгать унда китте.

—Соңарган, сонарган,—диде Шәвәлиев.

Тагын кемнәрнедер сораштырды да Хисмәтуллинны чыгарып җибәрде. Аннары китапханә телефонын җыйды.

—Сабитова, сезме?—диде ул.

—Әйе, Зөфәр Шәрипович.

—Сезнең Бакырчы китапханәсен тикшерәсегез бар иде. Мин хәзер шунда барам.

—Ләкин бүген бит...—Сөембикә сүзен әйтеп бетерә алмыйча туктап калды.

—Сез анда бүген барасыз, машина райкомның ишек алдында. Кереп утырыгыз. Мин егерме минуттан кузгалам.—Шәвәлиев трубканы куйды.

Бакырчы дигәч, Сөембикә барысын да аңлады. Кайсы юлдан барасын да, кая керәсен дә. Юк, әле аның йөрәгеннән курку китмәгән иде. Ул тиз генә киенде дә райкомга йөгерде. Шәвәлиевтә кеше юк иде, туптуры барып керде.

—Мин бит машинага утырырга куштым.

—Зөфәр Шәрипович, сез минем башны бетерәсез. Ирек хәзергә берни сизмидер. Тик сезнең теләсә кайчан өйдән чакыртып алуларыгыз, теләсә кайчан утыртып алып чыгып китүләрегез... Юк, мин башка болай йөри алмыйм...

—Нәрсә булды сиңа?—диде Шәвәлиев битәрләгән тавыш белән. Аннары җиңелчә генә көлеп дәвам итте:—Без бит эш белән йөрибез.

—Минем өчен эшләгәннәрегезнең барысы өчен дә рәхмәт,—диде Сөембикә.—Тик минем гаиләм бар...

—Соня-я!—дип сузды Шәвәлиев.

—Әйтмәгез зинһар, алай димәгез!—Сөембикәнең куркудан йөзе агарып китте.

—Нәрсә, син минем белән бөтенләй араны өзмәкче буласыңмыни?!

—Гомер буе болай яшәп булмый ла инде...

—Менә ничек! Аңлашыла... Димәк, хәзер мин кирәк түгел.

—Зөфәр Шәрипович, сез мине дә аңлагыз. Ярар, очрашырбыз. Тик хәзер булмый. Соңрак, көз көне...

—Кызы-ык. Ә нишләп яз түгел, җәй түгел?

—Мин куркам. Мин бит аны яратам. Мин аңардан башка яши алмаячакмын.

—Ә яраткач, ник хыянәт итәсең соң?—Шәвәлиев аңа астан хәйләкәр караш ташлады.

—Зөфәр Шәрипович, әллә минем сезнең кырыгызга кереп, каш сикертеп, сырпаланып йөргәнем бармы? Безнең очрашуларның мине күпмегә картайтканын сез бит башыгызга да китерә алмыйсыз.

—Менә ниче-еек! Бер дә алайдыр дип уйламый идем. Мин ерткыч булып чыгам алайса.

—Бу хакта әйдәгез бүтән чакта сөйләшик әле.

—Мин аңламадым, ни өчен соң әле син көз көне дисең?

—Мин сезгә әйтергә дә тиеш түгел... Серне саклarsыз дип уйлыйм...—Сөембикә аның күзләренә ялварып карады.

—Минем теләсә нәрсә чәчеп йөрмәгәнне беләсең бит,—диде Шәвәлиев, нингидер бер зур яңалык ишетергә әзерләнеп.

—Көзгә Ирекне Мәскәүгә ике елга укырга җибәрергә җыеналар, Казанда әйтеп кайтарганнар...

—Алай икән,—диде Шәвәлиев, бармакларын полировкалы өстәл өстендә биетеп.—Син шушына риза буласыңмы инде?

—Ә ничек мин карышыйм ди? Аларны бит анда язарга өйрәтәчәкләр.

Шәвәлиев кычкырып көлеп җибәрде.

—Их, Соня, Соня! Аларның нәрсәгә өйрәнеп кайтканын миңа сөйләгәннәре бар инде. Иреген Мәскәү маржалары белән тәмәке тарта-

тарта аракы эчәргә, гүләйт итәргә өйрәнеп кайтачак. Шунын өчен жибәрәсенме?

Сөембикә аптырап калды.

—Сон, ул бит кирәк, ди.

—Кирәк, әлбәттә! Аерым бүлмә, кесә тутырып, ай саен стипендия. Йөрүе кызганыч та булмасын, анын бер әйберсен дә алып калмаслар. Ләкин менә шушы кеше әйткән иде диярсен: ирен алкашка әйләнеп кайтачак. Риза булма, кырык сәбәп тап, риза булма.

Шулчак секретарь-машинистка кереп:

—Сезгә керергә ике кеше бар иде, көтсеннәрме?—диде.

—Әйе, көтсеннәр.

Сөембикә, ни уйларга да белмичә, ишеккә юнәлде. Шәвәлиевнен Ирекне өнәмәгәнен белә иде ул. Нишләп сон ул анын турында шул кадәр кайгырта? Эшеннән жибәрәсе килми дисән, ул инде күптән Зәбировны редактор итәргә жай эзли. Ишеккә барып житкәч, ул борылды да акрын гына:

—Зөфәр Шәрипович, дөресен генә әйтегез әле, нигә сез шулкадәр кайгыртасыз сон әле Ирек турында?—диде.—Ул китсә, сезгә минем белән очрашу ансатрак булмасмыни?

Шәвәлиев, урыныннан торып, анын янына килде һәм бик акрын гына итеп:

—Син турысын әйтергә куштын, мин әйтәм, тик ачуланма,—диде.—Ансат булгач, ул кызык булмый. Анлыйсынмы? Тыелган, яшерен нәрсә тәмлерәк була. Анын бөтен кызыгы да шунда. Хи-хи!

Сөембикә, ул әйткәннәрнен бөтен мәгънәсенә төшенеп житә алмаса да, ана ачулы караш ташлап алгач, жәһәт адымнар белән чыгып китте...

## 22

Кырбашта булу Ирекне тетрәндерде. Анда биш кенә сыер бар дигәч, ул авыл Советы секретаре белән председательне күрше авылларга чыгарып жибәреп, Кырбашка үзе китте. Ин элек авылны бер башыннан икенче башына жәяү кисеп чыкты. Биредә нәкъ егерме өй калган. Анын өчесенен инде тәрәзәләре кадакланган. Чүп үләне баскан буш өй урыннарынын исәбе-хисабы юк. Авылда койма дигән нәрсә калмаган. Ихаталар киртә, йә булмаса утыртма читән белән әйләндерелгән. Ике хужалыктан кала бәрәнге бакчаларынын киртәсе-мазары юк. Өйләр иске, кыйшайганнар, кайберләрендә түбәләренен шиферлары череп, ватылып беткән. Әлеге сыер хужаларына кереп сөйләшкәч, алар барысы да беравыздан:

—Сатабыз, сатмаган кая. Сөтебезне савып бетерү белән алып китәләр, чәйгә калдырсак, берәр литр калдырабыз, башкасы дәүләткә китә,—диделәр.

Биредә эш яшендә сигез-тугыз кеше бар, аларнын икесе механизатор, инде пенсия яшенә якынлашып киләләр. Берничәсе терлекчелектә, берничәсе төрле эштә. Барысы да биш чакрым арадан колхоз үзәгенә эшкә йөриләр, чөнки бу авылда инде эшләр эш юк. Ирек коймалары аеруча жимерелеп беткән, капкасы кыйгайган, түл белән ябылган өй түбәсенен берничә урыныннан пар чыккан бер йортка аптырап карап торды. «Монда кеше яшиме?» дип сорады ул үтеп баручы бер әбидән.

—Яши димәсән, тереклек итәләр инде...—диде әби, тешсез авызын мимылдатып.

Ирек бу өйгә кереп карарга булды. Ул капканы этте, ләкин ача алмады. Аннары ул ярыктан капканын терәтеп куелганын күрде. Тишектән кулын тыгып, черек тактаны шудырып төшергәч, капка үзеннән-үзе ачылып китте. Анын баганасы күгән ягына ауган, ябылган хәлдә терәү белән генә тотып була икән. Ирек аны әлеге черек такта белән кабат терәтеп куйды.

Ишек алды инде күптән күрәлмәгән, кеше йөрерлек сукмак баскыч төбенә, аннан ары нидән эшләнгәнен дә аера алмаслык абзар сыман нәрсәгә илтә иде. Ул абзар сыман нәрсә кар астына күмелеп калган, аның кар эреп каралып торган урынында кыйшайган капка күренә. Такталары әле бер урыннан, әле икенче урыннан ашалып, киртләчләнеп, кайбер җирләрендә бөтенләй зур уентылар ясалып беткән баскычтан Ирек курка-курка гына күтәрелде. Такталар баскан саен шыгырдый, сыгыла иде. Өйалдына кергәч, ул башта өй ишегенең кайда икәнен күрә алмыйча аптырап торды. Аннан соң гына әллә нинди чүпрәкләр, киезләр, сырган фуфайка җиңнәре, тире калдыклары кадакланган ишекне абайлады. Аның тоткасын таба алмады, кармалана торгач, көч-хәл белән эләктереп, үзенә тартты. Ишек, әллә нинди шомлы тавышлар чыгарып, шыгырдап ачылды. Атлап кергәндә, тупса өстенә өеп куелган нинндидер иске әйбергә аягы эләгеп, абынып егыла язды. Пәлтәгә охшаган бу нәрсә тупсага ябышып бозланып каткан иде. Ул үзен базга килеп кергән кебек хис итте, чөнки дүрт тәрәзәнең икесе салам тутырып, такта белән томаланган булып чыкты.

—Исәнмесез,—диде Ирек, кеше бармы-юкмы икәнен күрмичә.

Сул яктагы зур морҗа артында нииндидер кыштырдау ишетелде. Һәм аннан бүрегенең бер колакчыны өскә тырпайган, икенчесе асылынып төшкән бер баш күренде. Ул аңа ничектер кәҗәне хәтерләтте. Чөнки әлеге башның колагыннан алып бөтен җирен сакал-мыек баскан, үзе шулкадәр ябык, төссез иде, аксыл сакал-мыек белән аксыл чырай бер төсле кушылып күренделәр. Җитмәсә, бу адәми затның тавышы да кәҗәнеке кебек бик нечкә генә, хәлсез генә ишетелеп куйды.

—Саумысез...—Ул арада чыккан уң күзеннән агучы яшен кул сырты белән сыпыра-сыпыра, Ирекне танымакчы булып, аңа төбәлде.

Ирек, бер адым атлагач, аның инде бөтенләй тураеп баскан гәүдәсен күрде. Кеше сары якалы, күкшел пәлтә кигән, билен киндерә белән буган иде. Аның бер аягында—әллә ничә ямаулы, олтанлы итек, икенче аягында—агач протез. Уң кулының өч бармагы юк, исән калган баш һәм имән бармагы белән агач саплы пычак тоткан, ә икенче кулында идәндәге тагаракка сузылып төшкән кызгылт эчәк иде.

—Мин Ирек Сабитов булам, район газетасы редакторы.

—А-а-а,—дигән тавыш чыкты хуҗа кешенең авызыннан.—Мин Сиражи, Сиражетдин булам. Утыр шунда, урын тапсаң.—Ул стена буендагы эскәмияне күзе белән күрсәтте. Чакма ташы шикелле шоп-шома эскәмия янында кулдан ясалган өстәл тора иде.

—Аяк киеменне сала күрмә,—диде Сиражи.

Ирек эскәмиягә утырды. Шунда гына ул өйдә коточкыч салкын икәнлеген сизде. Күрәсең, март кояшы монда үтеп керә алмый иде. Сиражи шәмәхә-күкшел төскә кергән кулларындагы эчәк белән пычакны ни куярга белмәде, ни эшен дәвам итә алмады, керфексез күзләрен челт-челт йомган хәлдә катып калды. Аны эшеннән туктатуы өчен Ирек кыенсынып китте.

—Бүленмәгез зинһар, бүленмәгез!—диде ул кабаланып.

—Редактор...—Сиражи, гыжылдап бик озак ютәлләгәч кенә, әйтәсе сүзен әйтә алды:—Редактор дисенме?

—Әйе, район газетасыннан. Ничек яшисез икән дип сугылган идем.

Сиражи, Ирекка сынаулы карашын юнәлткән хәлдә бераз уйланып торгач, капыл гына сорап куйды:

—Минем тормыш белән генәме?

—Бүтән кешеләрнеке белән дә кызыксынам. Менә сез, Сиражи ага, ни хәлдә ятасыз?

Сиражи, тагаракка иелеп, эчәкне юлларга керешә һәм, ара-тирә Ирекка таба башын күтәргәләп, үткәнен-бүгенгесен сүтте:

—Ни хәл икәнне күреп торасыз инде. Агач атка атланып яшәп яту...— Менә күр дигәндәй, ул пычак сабы белән протезына шакы-шокы сугып алды.—Без яшь чакта сайрамаган сандугачны сайрата идек. Минем исем Гармунчы Сирай булды. Авылга кунак кызы килсә, егетләр аны минем рөхсәттән башка озатырга батырчылык итмәделәр. Ә хәзер кәтәм генә...— Ул тынып калды.

—Ни көтәсез?—диде Ирек һәм, урынсыз сорау бирүен аңлап, телен тешләде.

Ләкин Сиражи әйтерсең лә аның соравын ишетмәде һәм баягы сүзләренә бер генә җөмлә өстәде:

—Кавын утырттым, гәрәнкә чыкты...

Шул вакыт балаларга хаҗәтләрен үтәү өчен эшләнгән эмальле сары савытта нидер кайнап чыжылдый башлады. Сиражи, чүпрәк белән тотып, савытны электр плитәсеннән алды һәм, өстендәге капкачын ачкач, яктыга—тәрәзәгә таба кыйшайтты. Үрелебрәк күз салгач, Ирек савыттан күтәрелүче пар арасыннан анда бодай икәнлеген күрде.

—Тавыкларгамыни?

—Үземә әле, үземә,—диде Сиражи.—Көз көне силсәвит бик кыстагач, бәрәңгене күпләп саткан идем. Калганы череп бетә язды. Хәзер аны орлыкка сакларга кирәк. Журна килеш бодай пешереп ашыйм. Ипекәй алып килсәләр, әйбәт тә. Атна саен булмый шул. Сез инде бу савытка гаҗәпләнмәгез—яңа ул. Чәйне дә шунда кайнатам. Калай чәйнүгем тишелде...

Ул савытын алып куйды да кабат эчәк чистартырга керешә. Ирек өйне шактый күзәтеп алырга өлгергән иде инде. Түрдәге никельләнгән караватның ялтыравыгы кубып тутыккан, аның өстендә җыелмаган ястык, әллә ничә ямаулы, ни төсле икәнен дә аермаслык чуар юрган җыерылып ята. Шунда стенада үтә дә иске күкеле сәгать йөри. Күкесе күптән кычкырмыйдыр, очып китәргә әзерләнгәндәй, өстәге тишектән башын чыгарган да туктап калган. Кече якта кулдан эшләнгән иске шкафта савыт-саба ише нәрсә күренә. Моржа күптән агартылмаган, акшары коелган, чатнаган урыннарыннан төтен чыгып, корым сарган. Моржаның ян уентыгында уртасы ватылган агач рамлы көзге тора. Аның ялтыравыгы эре тутык төсле купшаклаган, пыяласын чебеннәр пычратып, көзге берни күрсәтмәс хәлгә килгән иде. Ирек түзмәде, сорады:

—Ялгызыгыз гына яшисезмени?

—Үзем генә шул,—диде Сиражи, эчәкне сава-сава чиләккә төшереп.—Сугышка киткәндә, хатын өченче балабызга көмәнле калды. Һи, мин күргәннәр!.. Инде сугыш беткәч, чех җирендә аяк чәрдәкләнде, бармаклар өзелде. Гангрена башланды. Кисик—үләсең, ди врач. Куркам, егерме ике генә яшь миңа. Кисteләр—кая барасың? Кырык бишнең азагында кайттым. Кайтсам—беркем юк. Хатынны бер кисә икмәк өчен төрмәгә утыртканнар. Әнкәй, минем өч бала ангинадан үлгәннәр. Хатын төрмәдә җан биргән...

Ирек аны хәйран калып тыңлады. Сиражи тыныч кына, ашыкмыйча, уфтанмыйча сөйли дә сөйли. Әйтерсең лә берниндн фаҗига булмаган, әйтерсең лә ул базарга барып кайтуы турында гына хәбәр итә. Ни бу? Ныклыкмы, кешенең күңеле тәмам таш булып катканмы, һәммәсенә битарафлыкмы, әллә бүтән сәбәпме?

Сиражетдин бик озак ютәлләп, күз яшьләрен сөртеп алгач, сөйләвен дәвам итте:

—Кайткач, беренче эшне өйләнүдән башладым. Әрем басып бетергән җимерек ихатада берүзем... Гүли баш.—Ул, пычагын куеп, уң кулының исән калган теге бармагын тырпайтты.—Шушы ике бармак белән тальянда сыздырып уйнарга өйрәндем. Шуңадырмы, хатын-кыз арттан калмый, ә мин балдыз турында баш ватам. Чирләшкә иде ул мескен. Шуның аркасында кияүгә дә чыга алмады. Уйладым-уйладым да җәлләп өйләндем. Гомере буе рәхмәт укыды. Бик авырлык белән булса да, менә бу йортны салып кердек. Ул чакта абзар-кура нык иде—анысына кагылмадык. Агач аяк, гарип кул белән кая сикерәсең? Үкенечлесе шул, бала да булмады, тормышка да әллә ни кот кунмады. Үлгәненә алты елдан артык мәрхүмәнең. Берүзем тырмашып ятам шулай. Үз көнең—үз хәсрәтең. Элегрәк партия җыелышларына баргалый идем, хәзер беркая чыккан юк.

—Сез коммунистмыни?—диде Ирек, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча.

—Фронтта алдылар. Бәләкәйдән үк ут борчасы идем мин. Куркуны белмәдем. Зарлануны да... Теләсә нинди кыен хәлдән чыгу юлын таптым...—Ул, нидер хәтерләргә теләпме, туктап калды.

—Хәзер коммунист түгелмени?

—Төшеп калганмындыр инде. Бу яшькә җиткәч. Элегрәк кат-кат чакыралар иде җыелышка. Взнос сораучы да, чакыручы да юк хәзер. Ничек барыйм мин анда? Менә шулай тырманып көн үтә дә китә. Әз генә вакыт булса, җаен бәләкәй арба, кышын чана белән урманга утын юнәтергә кереп китәсең. Әле дә бәхеткә урман якын. Ерак булса, катып үләр идең, валлаһи...

Сиражи кулын чүпрәккә сөртте дә, чүмеч алып, чуен чүлмәккә үрелде. Күрәсең, анда су иде, чүмече чыкылдап бозга килеп бәрелде.

—Өйдә җылы тормый, шул арада катып өлгергән,—диде ул.

Пычагын алып, нindидер чүпрәккә сыпыргач, шуның очы белән бозны чокый башлады. Аннан бозлы суны чүмече белән чиләккә салды, чиләген плитә өстенә куйды.

—Аллаһе боерса, бүген ит ашыйм,—диде ул, авызларын чәпелдәтеп.— Ике ай инде ит авыз иткәнем юк. Майны кайчан капканымны да оныттым. Җәй көне үлән күп, ит ашамасаң да түзеп була. Кышка күршеләр сатып биргәлиләр. Аларның да күп түгел шул. Ну, күрше әйбәт. Менә бит, ферма сыеры чирләгән дә, үлгәндә суеп калганнар. Сиражетдин абзыйга дип сорадым, ди. Үпкәсе белән эчәкләрен алып кайткан. Бүген ит ашыйм, аллаһе боерса. Майга кадәр җитә ул миңа.

—Үзең сарык-мазар асрамыйсыңмыни?

—Сарыгым бар,—дип сөйләп китте Сиражи.—Кышка суярмын дип торганда, ике бәрән китерде. Шулай итеп итсез калдым. Күршеләрдән бераз сатып алган идем. Каян җитсен инде ул?

—Сарыкны күбрәк асрарга мөмкинлек юкмы?—дип сорады Ирек.

—Әле бусын да бетерәләр икән дип сөйлиләр. Без бит көтүне менә монда кашлакта гына көтәбез. Чиратлап.—Сиражи пычаклы кулын каядыр түр якка селтәп куйды.—Шуннан әз генә дә алып китәргә ярамый—колхоз маллары йөри. Менә итле булдым бит әле. Аллаһе боерса, бүген ит ашыйм. Ярый минем илектыр плитәсе бар. Әнә күршеләр бер айдан бирле караңгыда утыралар.

—Нәрсә булган?

—Минем күрше алай куркып тора торганнардан түгел. Җыелышта нидер сөйләгән бугай. Минимумы да үтәлмәгән булган. Килгәннәр дә өзгәннәр. Без аны багана башына менеп ялгый алабызмыни?

Ирек хәзер генә бөтен өйгә таралган әче тизәк исен ныгытып сизде. Аның инде аякларына да суык-таракан керә башлаган иде.

—Өенә әллә көн саен якмыйсыңмы, Сиражи абзый?—диде ул.

—Син мине кем дип белдең көн саен ягарга? Утын юк. Бик салкыннарда ике көнгә бер ягам. Мартта өч көнгә бер ягуга күчтем. Рәхиме бәләкәй шул әле кояшның.

—Кош-корт асрамыйсыңмы?

—Күз көне жиде тавыгым бар иде. Берсе нишләптер үлде, икесе югалды—күзән-фәлән алды бугай. Көнгә бер йә ике күкәй алып кереп торам. Анысы әйбәт инде. Менә Аллаһы боерса, бүген итле шулпа эчкәч, йомыркага да экономия була.

Ул бер озын гына эчәкне кисеп алды да, бармак буе итеп турап, зуррак кына эмаль табакка салды. Плитәдәге чиләктән су агызып юа башлады. Аның суы шундук тизәк калдыкларыннан кара яшел булды. Өч мәртәбә юганнан соң, бик үк чистарып бетмәсә дә, су шактый тонықланды.

—Инде шушылай җәфгалләгәч, ярар, моннан да ары булдыра алмыйм,— диде ул.

Бая бодай кайнаган савытны алып килеп, эчәкләрне шунда аударды, бераз су өстәде, иреннәрен чәпелдәтә-чәпелдәтә, тоз сибеп, плитә өстенә куйгач, «Бүген ит ашыйм, аллаһы боерса», дип кабатлады. Аннары пычагын тоткан килеш так-ток басып, өй алдына чыгып китте. Бераздан бер кыерчык ипи кадәр үпкә кисәге тотып керде һәм аны эчәк янына салды.

—Моңа суган да булса, хәтәр тәм кертер иде,—диде ул, төкереген йотып.—Калган эчәкләрне юарга су бетеп китте бит әле.

—Суны каян аласыз?

—Чишмә бар монда авыл артында. Ерагын ераграк та инде. Ташып куярга савыт юк. Ике чиләк алып кайтсаң, сарыклар да эчә, үзем дә тотам. Бик тиз бетә. Әйбер юмыйча да торып булмый бит. Әле ярый, рәхмәт, күршеләр атна саен мунчага дәшәләр. Кыен шул, ничек атна саен кермәк кирәк. Ике-өч атнага, йә айга бер керәм. Өйдә шушы калай тагаракта юынам. Мина нәрсә инде хәзер, барыбер кызлар янына барасы юк.

Сиражи кулларын эчәк юган суда чайкап сөртештерде дә кече яктагы сынар урындыкка утырды. Ирек, үзенең нәрсәдәдер гаепле икәнлеген тоеп, аның күз карашы астында куырылып-кыймшанып куйды һәм, үз-үзен коткарырга, бу кыен хәлдән чыгарга теләгәндәй, сорау бирде:

—Сиражи ага, сез бит инде олы гомер юлы үткән кеше. Тормыш хакында ни уйлыйсыз соң?

—Һи-и-и,—дип суздзы Сиражи.—Мин уйлаган уйларны бизмәнгә салсаң! Ничә тонна булыр иде икән?—Ул шактый вакыт тынып, күзен бер ноктага төбәп утырды. Аннары дәвам итте:—Карачкыны—ябалак, ябалакны чыпчык алган замандыр инде бу. Үзем генә булсам, төкереп тә бирмәс идем. Сылтар идем әле шунда йә Аллага, йә язмышка, йә бүтәнгә. Кавеме белән бит... Гомере буе эшләгән адәм баласының тамагы туя алмый икән, ызначытсы, нидер дөрес түгел. Тормыш сорап та тормады, «голт» итеп йотты гына! Кыймшанып та булмый, ичмасам тизрәк эшкәртеп, чыгарып атсын иде. Юк шул! Тарайганнан тарая гына бара... Нечкә тишек аша карыйсың—бер яктылык та күренми. Германга барып, нимесне жинеп кайттык, югыйсә...

Сиражи, «һи, сиңа сөйләдең ни дә, сөйләмәдең ни», дигән төсле кулын селтәп куйды да савыттагы эчәкләрне—авызын чәпелдәтә-чәпелдәтә болгатырга кереште, үзе акланганды әйтеп куйды:

—Эчәкне аны бик озак карда таптап чистарталар, юалар, пешерер алдыннан бер мәртәбә кабартып түгәләр дә бит... Кая инде мина алай хасиятләп тору...

Ирек урыныннан кузгалды:

—Ярый, Сиражи ага, мин китим әле,—диде ул.

Хужа ике кулын ике якка селтәп куйды:

—Чәй куйыйм дисәм инде... күреп торасыз...

—Сез сөйләгәннәрне район газетасына язып чыксам, риза булырсызмы?

Сиражи «аһ» итеп куйды. Ул тагарактан ала башлаган эчәкнең лычкылдап идәнгә төшкәнен дә сизмәде.

—Берүк харап итә күрмәгез,—диде ул ялварып.—Аннан соң мина сапсим көн бетәчәк!

—Соң шушылай яшәргә ризамыни сез?

—Риза түгел дип кая барыйм соң? Әйтегез, әгәр дә андый жир булса.

—Картлар йорты бар,—диде Ирек.

—Картлар йортыннан минем замандаш кайтты инде аннан. Сөйләде... Анда барырга Ходай күрсәтмәсен. Шушында үләргә язсын инде.

—Ул чакта, Сиражи ага, син әйткән бер сүзне дә язмыйм. Бары тик үзем күргән нәрсәләрне генә язам.

—Нәрсә соң ул сез күргән нәрсәләр?

—Менә йорт-кураларыгызның искелегән, электр плитәсе белән ашарга әзерләүләрегезне, утын юклыгын, эчәк чистартуыгызны.

—Сез нәрсә, иптәш Сабитов!—диде Сиражи, коты очып.—Эчәккә мин бит колхоздан боерык яздырып алмадым, аңа акча да түләмәдем. Минем башны судка тарттырмакчымыни сез?

—Курыкмагыз, Сиражи ага, эчәкне барлык урыннарда да ташлап баралар, аның өчен берни дә булмый,—диде Ирек, аны тынычландырырга теләп.

—Юк, юк, башка жирдә булмас, бездә булыр. Башкаларын язсаң да, зинһар, эчәк турында сүз кузгата күрмә.

Ирек аның белән хушлашып чыгып китте.

Сиражи яныннан чыккач, аның ашыйсы да, эчәсе дә килмәде, күңеленә ниндидер авыр таш ятты. Кабаланып, колхоз үзәгенә кайтты да партком секретаре Фәрдиевне эзләп тапты.

—Кырбашта Сиражи исемле кеше яшәгәнен беләсезме?—диде ул аңа.

—Белмичә! Ул безнең коммунист.

—Ул, ике-өч ел взнос түләмәдем, партиядән төшеп калганмындыр, ди.

—Ансат икән!—дип көлде Фәрдиев.—Аның билетына штамп суктырмавына мин гаепле түгел бит. Почтальон ай саен пенсиясеннән тиешле взносны кертеп бара. Ай-яй, ансат кына котылмакчы!—партком секретаре тел шартлатып куйды.

—Сезнең аңа берәр ярдәм күрсәткәнегез бармы соң?

—Ярдәм дип, нишләтәсең инде аларны? Андыйлар бит хәзер авыл саен. Ел саен центнер ярым икмәк бирәбез. Печәнне әзерләгәне үзе әзерли. Саламны тотканыбыз юк. Тагын нишләтәсең инде аларны? Ипи кайтып тора.

—Бабайның әйтүенә караганда, ул икешәр-өчәр ай ит-май ризыгы күрми.

Фәрдиев бу сүзләргә дә аптырамады.

—Соң нишләтик инде аларны? Хәзер колхоз җирлегендә өч йөзгә якын пенсионер бар. Ит биреп кара инде син аларга. Бер килограммнан гына бирсәң дә, өч центнер ит кирәк. Болай да планны ничек үтәргә белмибез. Менә сез кешеләрдән сөт җыеп йөрисез. Хәзер ике атна безнең ясле балаларына бер грамм да сөт биргәнебез юк. Чөнки районнан кысалар, телефонны алу белән беренче сүз, кем генә шылтыратса да, «сөт планы ничек?» ди. Юк, берничек тә ит белән май бирә алмыйбыз без аларга. Башка хуҗалыкларда да шулайдыр.

—Миңа бер өч килограмм ит сатып бирә аласызмы?—дип сорады Ирек, Фәрдиевнең күзләренә туп-туры карап.

Секретарь аптыраашта калды: чынлап сорыймы ул, әллә юриме? Шуңа күрә туры җавабтан качты:

—Моны инде Батталов хәл итә.

—Әгәр мин сездән үтенеп сорасам? Менә акча, минем исемгә алып, илттерегез Сиражи агага өч-дүрт килограмм ит.

Хәйләкәр, тәҗрибәле кеше иде Фәрдиев.

—Юк, юк!—диде ул елмаеп.—Моны бары тик колхоз председателе генә хәл итә ала. Ул, әлбәттә, сезгә каршы килмәячәк.

Әйе, Ирек белә, Батталов аңа сөенә-сөенә бирәчәк итне. Өч-дүрт килограмм гына түгел, унны бирәчәк. Чөнки киләчәктә авыз чайкау өчен бу аңа уен тузы ролен үтиячәк. Димәк, ярамый!

Кич колхоз идарәсе янында Ирек «Сельхозтехника» бүлекчәсе инженеры белән очрашты һәм район үзәгенә аның машинасына утырып кайтты. Сөембикә җылытырга бәрәңге куйды, чәй кайнарлады, әмма Ирек ашаудан баш тартты. Үзе көне буе ризык җыймаган, ә берни дә кабасы килми иде. Ул телефон борчыса, үзен чакырмаска кушып, бүлмәсенә кереп бикләнде. Ияге белән кулына таянып, Сиражиның сөйләгәннәрен, партком секретареның сүзләрен хәтеренә төшереп утырды. План да план, үтәргә дә үтәргә! Ничек булса да үтәп, өлкә комитетына рапорт бирергә. Анысы Үзәк Комитетка. Ничә көннәр район үзәге кибетләренә сатуга сөт китерелми. Олылар да, балалар да мәхрүм. Трибуна артына баскач, Арсланов та, Шәвәлиев тә, башкасы да: «Эшче сыйныф сөт сорый, ит сорый, аңламыйсызмыни шуны?» дип, күкрәк сугарга яраталар. Ә соң Сиражи эшче сыйныфка керми микәнни? Район үзәгендәге халык кайсы сыйныф вәкиленә керә икән? Хәер, дип уйлады Ирек, ул хәзер күпме генә бу турыда фәлсәфә сатып утырса да, моның бернинди файдасы булмаячак. Коммунист Сиражиның бүгенге тормышы турында язарга һәм тизрәк газетада чыгарырга! Картларга мондый караш булырга тиеш түгел. Аның үз әти-әнисе дә җинел яшәми ич. Ирек бер мәкалә белән генә бөтенесен йөз сиксән градуска бора алмаячагын, мондый хәлне үзгәртергә көче җитмәячәген дә белә. Шуңа күрә мәкаләне язса, аңа Сиражи абзыйга авырлык килмәслек итеп язарга кирәк иде. Батталовның картны электрсыз да калдыру ихтималы бар бит. Күп уйлый торгач, әллә авылын-колхозын әйтмичә генә язарга микән, дигән уйга килде. Ул чакта моны язучы хыялы белән күпертелгән, арттырылган әдәби әсәр кебек кенә кабул итәчәкләр. Әле гаеп тә ташларга

мөмкиннәр. «Арттыргансың, безнен тормышны каралткансың, совет чынбарлыгына яла ягасың», диячәкләр. Соң, нишләргә? Ирек шушы сорауга җавап эзләп утырганда, Сөембикә аның ишеген ачып:

—Ирек, чык әле, тышта ниндидер кеше бар,—диде.

Ирек киенмичә генә чыгып ишекне ачты. Аның каршысында бөкрәйгән, кырынмаган бер адәм басып тора иде. Аның бөтен гәүдәсе, куллары, ияге, иреннәре калтырый һәм ул шушы калтырау белән бергә өзек-өзек сулыш ала, ыңгырашып та куя иде.

—Сезгә кем кирәк?

Кеше шактый вакыт җавап бирә алмый торды. Аннары нурсыз, тоныкланган яшькелт күзләрен югары күтәреп:

—Сө... сө... Сөембикә биредә торамы?—диде.

—Әйе,—диде Ирек аптырап.

Инде Сөембикәне сорагач, аның берәр туганы дип уйлап:

—Әйдәгез, керегез,—диде.

Кеше, иелеп, веранда буена куелган хуҗалык сумкасын алды да, калтырана-калтырана, Ирек артыннан өйгә атлады. Сөембикә Айгөл янында иде.

—Әйдә, чишенегез,—диде Ирек теге кешегә.

Аннары Сөембикәгә дәште:

—Сөембикә, чык әле.

Сөембикә, аның артыннан йөгереп Айгөл килеп чыкты. Теге кеше, пальтосын элеп, Сөембикәгә таба борылды.

—Исәнме, Сөембикә,—диде һәм, кулын сузып, аңа таба бер адым атлады.

Сөембикәнең йөзенә, нәрсәдер хәтерләргә теләгәндәй, аптырау галәмәте чыкты, аннары ул аптырау ачу белән алышынды. Аның күзләре ямьсез булып шакмакландылар.

—Ник керттең моны?!—диде ул Ирекка, ачу белән.

Ирек, берни аңламыйча, әле Сөембикәгә, әле теге кешегә карады.

—Сөембикә, кызым, мине танымыйсыңмыни?!—диде теге кеше, калтыранган кулларын һаман сузган килеш.

Шунда Ирек аның кулының энә белән чәнчеп, тушь белән язгаланып беткәнлеген күрде.

—Синең урында булсам, оялмыйча мин бу йортка аяк басмас идем!—диде Сөембикә һәм аңа лач иттереп төкерде.

—Мин бит... Мин бит үләргә кайттым...—Кешенең тавышы өзелде, тамак төбеннән елауга охшаган аваз чыкты:—Урамда кунарга салкын, бер генә кич куңдырып чыгарыгыз.

—Эзең булмасын, хәзер үк күземнән югал!—дип кычкырды Сөембикә һәм, аның чөйдәге пальтосын алып, өстенә ыргытты.

Пальто идәнгә шуып төште, кеше калтыранып басып тора бирде. Аңардан укшытырлык сасы ис бөркелә иде.

—Туктале, Сөембикә,—диде Ирек.—Шулкадәр мәрхәмәтсез булма. Кем соң бу абзый?

—Бу хәшәрәт кайчандыр минем үги әтием иде!—Сөембикә елый-елый түр бүлмәгә кереп китте.

Айгөл белән Ирек аптырап басып калдылар. Кеше акрын гына иелеп пальтосын алды, калтыранган башыннан бүреге төшеп, тупсага таба тәгәрәде. Менә ул пальтосын кияргә кереште, ләкин, күпме генә мәшәләнсә дә, кия алмады. Ахырда Ирек пальтоның бер як җиңен барып тотты һәм ул шуннан соң гына кулын җиң эченә кертә алды. Әмма сәдәфләрен элəктерә алмады, куллары аны тыңламыйлар иде. Шактый маташканнан соң, ул кулын күкрәк кесәсенә тыгып, аннан бишлек, өчлек акчалар тартып чыгарды һәм Ирекка таба сузды.

—Үтермә, бер генә йотым булса да, ни булса да тап, одеколон булса да... Юкса хәзер үләм, шушында үләм...

—Акчаларыңны тыгып куй, абзый,—диде Ирек, аның кулын этеп.—Нәрсә дә булса табарбыз. Сал пальтоңны.

Кеше, дөрес ишетәмме дигәндәй, шикләнеп аңа карап торды. Ни киенергә, ни чишенергә белмәде.

—Сөембикә, чык әле,—диде Ирек, тагын хатынына дәшеп.

Сөембикәнең елаудан күз кабаклары кызарып чыккан иде.

—Бу вакытта хәзер кая барсын ул?—диде Ирек.—Ашарга берәр ризык әзерлә.

—Әгәр сиңа бик якын икән, үзең аңа сый-хөрмәт күрсәт!—диде Сөембикә, елый-елый җикереп.—Урамда кәкрәеп катсын әнә!

Сөембикә тагын кереп китте. Ирек калган бәрәңгене кайнарлатырга куйды, чәй җылытты. Кеше, пальтосын кабат чөйгә элеп, итеген салды. Тишелеп беткән юка иске итекне ул бер кат базар ноские белән кигән, ике аягының да бармаклары, үкчәләре күренеп тора иде.

—Юынып алыгыз,—диде Ирек.

Кеше, юынганнан соң, өстәл янына утырды. Ирек рюмкага аракы салды.

Кеше күзен рюмкадан алмады, ләкин аңа үрелмәде.

—Кыен булса да, миңа йә стаканга, йә кружкага салып бир инде,—диде.—Рюмкадан эчә алмыйм мин, күнегелмәгән, түгелеп бетә.

Рюмкасындагы аракысын стаканга аударуга, ул ике куллап комсызланып аңа ябышты һәм аны калтырата-калтырата авызына койды. Аннары, бик зур эш эшләгән кебек, озын итеп уфылдады, бер әйбер дә капмады, нәрсәнедер тыңлагандай, тавышсыз утырды. Берничә минуттан аның кулларының, гәүдәсенең һәм башының калтыравы кимеде, мәетнеке төсле ак чыраена сизелер-сизелмәс яшәү билгеләре ингән кебек булды.

—Үлгәндә дә рәхмәт укып үлärмен,—диде ул, күз яшьләрен бармагы белән сөртеп.—Чын кеше икәнсең.

—Исемең ничек, абзый?—дип сорады Ирек.

—Кәшифулла атлы мин.

—Минеке—Ирек. Каян кайтып килеш соң, Кәшифулла абзый? Әллә барышмы?

—Төрмә кошы мин. Күрәсеңме миңә бу кулларны? Тәнем дә шундый. Минем бер як күкрәктә Ленин, икенчесендә Сталин ясалган. Мин күргәннәрне күрергә язмасын.—Ул, кинәт башын күтәреп, Ирекка беренче күргәндәй карап тора башлады.—сөйләдеме ул сиңа? Минем хакта?

Ирек үзенең бу кешегә битараф каравына шаккатып утырды. Ул аннан җирәнергә, нәфрәтләнергә тиеш иде. Ләкин ни гаҗәп, бу тойгыларның берсе дә юк иде. Мин аны кызганмыйм да бугай, дип уйлады ул эченнән. Кәшифулланың соравына бер сүз белән генә:

—Сөйләде,—диде.

Аннан соң алар, бер-берсенә карамыйча, шактый вакыт сүзсез утырдылар.

—Сөйләгән икән, мескен...—дип сузды Кәшифулла.—Ирек, гомерең буе бер нәрсәне онытма: ул баланың энә очы кадәр дә гаебе юк. Аның мине бу өйгә якын да китермәскә хакы бар...—Ул урыныннан торды.—Ярый, рәхмәт, мин кая да булса юл тотыйм инде.

—Бу вакытта кая барасың?—диде Ирек.—Бездә кунарсың.

—Сөембикә кумаса, бик кунар идем дә. Әллә котельныегызда гына утырып йоклыйммы? Миңа бит барыбер.

—Юк, юк,—диде Ирек.—Хәзер урын әзерлим.

Ирек Сөембикә янына чыкты. Айгөл инде йоклаган иде.

—Сөембикә, аны ничек куып чыгарасың инде? Әйдә, берәр нәрсә салып бирик, раскладушкага.

Сөембикә, бер сүз дә дәшмичә, арты белән борылды. Ирек, йокы бүлмәсеннән алып чыгып, раскладушканы җәйде, аңа матрац салды, җәймә белән каплады, бер одеал алып чыкты, мендәр салды.

—Әйдә, Кәшифулла абзый, ят,—диде ул.

Кәшифулла өстәл яныннан кузгалмады, күзләрен кулы белән каплаган көе утыра бирде, ә кырынмаган битләреннән күз яшьләре тәгәрәде. Аннары ул лышык-лышык борынын тарта-тарта кузгалды һәм чишенми-нитми Ирек

җәйгән урынга барып ауды. Бүлмәдә таралган сасы искә чыдашлы түгел иде. Бер минут үттеме-юкмы, хырылдап йокыга да китте. Ирек, утларны сүндереп, тагын үзенең бүлмәсенә керде һәм Сиражи турындагы мәкаләсен язарга тотынды.

Төнге уникеләрдә Кәшифулла кинәт ыңгырашып кычкырып җибәрде, тешләрен шыкырдатты. Ирек йөгереп зал ягына чыкты һәм утны яндырды. Кәшифулланың күзләре пыялаланган, авызы ачылып каткан, бөтен чырае, сул як аягы көзән җыерган кебек тартыша иде. Бу тавышка Сөембикә дә йөгереп чыкты.

—Кәшифулла абзый, ни булды?!—дип, Ирек аны селкетергә, уятырга тотынды.

Ләкин ул әллә ансыз хәлдә иде, бер әйбер дә сизмәде.

—Әйттем мин сиңа кертмә дип!—Сөембикә тагын Кәшифуллага таба төкерде.—Урамда үләсе урында менә хәзер монда җан биреп ята. Фу, исе кабахәтнең!

Ул, борынын тотып, йокы бүлмәсенә кереп китте. Ирек ни кылырга да белмәде, ахырда ашыгыч ярдәм машинасы чакырды. Ул, өс-башына киенеп, ишекне ачып, өйалды утларын яндыруга, ашыгыч ярдәм килеп тә җитте. Ирек Кәшифулланы носилкага салып озаткач, раскладушканы җыйды, җирәнә-җирәнә мендәр-одеалларны җәймәсе белән уралы да, агач бакчасына ук чыгарып атты.

Иртән Сөембикә аны кайнар беләкләре белән кочып уятты.

—Ирек,—диде ул пышылдап.—Син әле Язучылар идарәсенә шылтыраттыңмы?

—Нигә сорыйсың?—диде Ирек, күзләрен угалап.

—Җибәрә алмыйм икән мин сине.

—Кайда җибәрә алмыйсың?—Ирек һаман берни дә аңыша алмады.

—Укырга. Ике ел мин синнән башка яши алмыйм. Мин менә хәзер генә аңладым. Мин синнән башка яши алмыйм. Мин сине яратам!—Ул Иректе үбәргә, иркәләргә кереште, чалкан әйләндереп, өстенә ятты.—Китмисеңме, китмисеңме, әйт? Әгәр син китсәң, мин куркам.

—Нәрсәдән куркасың?

—Без аерылышырбыз кебек тоела...

—Башыңа каян шундый уйлар килә?—диде Ирек, аның аркасыннан иркәләп.—Без беркайчан да аерылышмаячакбыз.

—Юк, Ирек, мин сине җибәрмим. Айгөл дә синнән башка бер көн дә тора алмый, үзең дә аны үлеп яратасың. Баланың ныгымаган күңеле ничек күтәрә алсын синнән башка яшәүне? Мин үзем дә аның хәлендә. Мин бит сиңа бер эш тә эшләтмим. Төн йокламасам, йокламам—сиңа язу өчен мөмкинлекләр тудырырмын. Мәскәүдә дә әллә нәрсә юк. Эчәргә өйрәнерсең, бозылырсың дип тә куркам...

—Ярар, ярар,—диде Ирек, эчтән аның белән килешеп.—Карарбыз әле, уйларбыз...

Ике көннән Кәшифулла үлде. Ирек машина табып, аны Минзәлә районында яшәүче энесенә илтеп кайтты.

## 23

Иреккнең «Ник кан койдың, Сиражетдин?» дигән мәкаләсе зур шау-шу тудырды. Инде мәкалә типографиягә җыярга бирелгәч, Зәбиров килеп керде.

—«Авангард»ның партком секретаре шылтырата,—диде ул.—Сездә анда безнең пенсионерларның бик начар хәлдә яшәве турында бер мәкалә чыга икән, зинһар өчен тоткарлый күрегез, ди.

—Ә нишләп соң ул миңа шылтыратмаган?—диде Ирек.

—Аңа мин дә шулай дидем. Редактор белән сөйләшегез, мин берни дә эшли алмыйм, дидем.

Зәбиров чыккач, Ирек уйга калды. Димәк, Хасбулатова тагын хәбәр иткән. Нишләп соң әле ул Батталов турыдан-туры Ирекка шылтыратырга

курка? Моның астында ниндидер этлек ятарга тиеш. Ләкин озак көтәргә туры килмәде, бүлмәгә Шәвәлиев килеп керде.

—Сез тагын нәрсә китереп чыгардыгыз инде, Ирек Хәйриевич?

Аның шул мәкалә буенча килгәнлеген белсә дә, Ирек аптыраганга салышты.

—Нәрсә турында сүз барганлыгын аңлатыгыз әле, Зөфәр Шәрипович.

—Ниндидер тәнкыйть мәкаләсе язгансыз ди бит.

—Кем әйтә аны?

—Ярар, анысын белмәгәнгә салышма инде,—диде Шәвәлиев, кул селтәп.—Мин синең янга юктан гына килмәгәнне беләсең.

—Турысын әйтүегезгә рәхмәт,—диде Ирек.—Әгәр дә теге вакытта бюрода редакциядән кем информация биреп ята дип мин мәсьәләне куйганда, сез мине яклаган булсагыз, менә мондый хәлгә төшми идек без. Болай ничек эшләп булсын? Һәр житәкче, газетада тәнкыйть чыга башлау белән Беренче янына йөгереп барып керсә, ни була соң ул?

—Анысы дөрес инде,—диде Шәвәлиев килешеп.

—Шулай булгач, материал чыгачак. Анда Батталов турында бер сүз дә юк.

—Сез миңа аны укытыгыз әле.

Ирек Шәвәлиевкә мәкаләнең үзендә, алай-болай киләчәктә кирәк булса дип, калдырылган өченче данәсен бирде. Ул, баш чайкый-чайкый, аны укып чыкты да:

—Ирек Хәйриевич, бу бит Батталовка гына түгел, Арсланов белән миңа да бик каты суга,—диде.

—Ә нишләп сезгә генә?—диде Ирек.—Әгәр дә алай карасаң, ул беренче чиратта СССР Министрлар Советына, Үзәк Комитет адресынадыр.

—Юк, юк, син моны чыгармыйсың!—Шәвәлиев мәкаләне бөкләп кесәсенә салды.—Типографиядәгесен дә алып менеп бирегез.

—Бирмим, шулай тиеш икән, үзегез алып чыгып китегез,—диде Ирек.

—Юк, син аны алып менеп бирәсең,—диде Шәвәлиев.

—Ярар,—диде Ирек, башына бер хәйләкәр уй килеп.—Әйдәгез, бергә төшәбез типографиягә.

Алар Шәвәлиев белән, типографиягә төшеп, линотип бүлмәсенә керделәр. Линотипистка әлеге гөнаһ шомлыгы мәкаләне җыеп утыра иде.

—Сеңлем, бу мәкаләне әлегә райкомнан токтарлап торырга кушалар, Зөфәр Шәриповичка бирегез әле аны,—диде Ирек.

Кыз мәкаләне биргәч, Шәвәлиев аны да бөкләп кесәсенә тыкты. Бер сүз дә әйтмичә китеп барды. Ирек тиз генә менде дә, әлеге мәкаләне алып, Хасбулатовага керергә кушты. Аларда мәкаләнең тәрҗемәгә бирелгән икенче данәсе бар иде.

—Тәрҗемә итеп бетердегезме әле, Изабелла Назаровна?

—Әйе, бетердек,—диде ул.—Әллә тәрҗемәсе белән танышасызмы?

—Кирәкми. Утырыгыз әле.

Хасбулатованың йөзенә борчылу-курку билгеләре чыкты. Ул ишек янындагы урындыкларның берсенә чүмәште.

—Изабелла Назаровна, мин сезне редакция серен читкә чыгарган өчен судка бирәм!—диде ул, һәр сүзен бүлеп, рәсми салкын тавыш белән.

Хасбулатова, кызарынып, урыныннан сикереп торды.

—Сүзегезне үлчәп сөйләгез!

—Утырыгыз!—диде Ирек, тимер тавыш белән.—Мин редакциягә килгәннән соң, сез инде икенче мәртәбә Батталовка газетада басылачак материал турында хәбәр иттегез. Минем кире кагылмаслык дәлилләрем бар. Сезнең Батталов белән нинди мөнәсәбәттә икәнегезне дә...

—Сез үзегезнең өстегезгә артык күп нәрсә аласыз!—дип кычкырды Хасбулатова, күзеннән зәһәр очкыннар чәчеп.

—Кычкырмагыз миңа!—диде Ирек.—Хәзер ирегезне чакырып, күз алдыгызда әйтимме? Һәм исбатлап та бирәм.—Ул ашыгып телефоннан номер җыя башлады.

Хасбулатова, йөгереп килеп, калтыранган куллары белән аның кулын

эләктереп алды һәм елап җибәрде:

—Кирәкми, зинһар, үтенәм сездән! Ул мине атып үтерәчәк!

—Шулай булгач, кычкырмаска кирәк,—диде Ирек, берни булмагандай, баягыча салкын тавыш белән.—Бүген мин сезне судка бирәм. Суд нәтиҗәсен газета аша бөтен халыкка җиткерәчәкбез. Башка җирдән эш эзли башлавыгызны сорыйм.

—Зинһар кичерегез, башка беркайчан да...—Хасбулатова күз яшьләренә буылып сүзен әйтә алмады.

—Ярый,—диде Ирек.—Мин сезне кичерәм. Янадан беркайчан да беркемгә дә...

—Юк, юк, мәңге...

—Мин сезгә ышанам. Хәзер менә бу сезнең кулдагы мәкаләне без җыярга төшереп җибәрәбез. Ул бүген төнлә басылачак. Беренче сынавыгыз шушы. Минем беләсем килә: хәзер сезгә йә райкомнан, йә «Авангард»тан кемдер чылтыратып, мәкалә турында белешер, сорашыр. Сез ни дип җавап бирерсез?

—Соң, билгеле инде...—Хасбулатова бераз аптырап торды.—Чыкмаячак дип...

—Дөрес. Ә чыккач, янадан ул кешеләр чылтыратса, мин белми калдым диярсез. Газетаны кул куярга кертkәндә күрдем, ләкин ул вакытта сон иде инде, диярсез. Килештекме?

—Килештек,—дип пышылдады Хасбулатова һәм кульяулыгы белән күзләрен, битләрен сөртә-сөртә чыгып китте.

Газетаны авылларга бүлгәләп җибәргән вакытта ук алып, барлык тиражны райкомның яндырту ихтималы да бар иде. Шуны булдырмау өчен Ирек район элемтә бүлегенә китте. Анын начальнигы бик тәвәккәл кеше иде, хәлне шундук аңлады, газетаны авылларга таңнан ук җибәрү, Болынкырның үзендә дә иртүк тарату хәстәрен күрергә сүз бирде.

Аларның планы барып чыкты. Газетаның сәгать иртәнге биштә үк райкомда, район Советы башкарма комитетында булырга тиешле данәләрен Ирек соңартып илттерде. Сигезләр тулганда, ана район үзәгендә яшәүчеләрдән бер хатын-кыз чылтыратты:

—Бу ни хәл бу, иптәш Сабитов? Бүген газетаны алып кереп укый гына башлаган идем, бик зур хата киткән дип, кулымнан тартып алып чыгып киттеләр!

Ирек барысын да аңлады. Димәк, район үзәгендә дә, авылларда да газетаны җыеп алмакчы булалар. Әмма бу мөмкин эш түгел, газета ике кешенең берсендә булса да барыбер калачак.

Озакламый аны Арслановка чакырдылар. Алар Шәвәлиев белән бергә утыралар иде. Икесенең дә йөзләре кара коелган.

—Син нәрсә, Сабитов?!—дип җикерде Арсланов, Ирек ишектән килеп керү белән.—Райкомга каршы авантюра оештырып ятасың?!

—Нинди авантюра, аңлатыгыз,—диде Ирек.

—Ә менә бу нәрсә!—дип кычкырды Шәвәлиев, мәкаләнең ике данәсен дә Ирекнең йөзенә ыргытып.

—Сезнеке авантюра түгел, минеке авантюрамыни?

—Бу пасквиль!—диде Арсланов.—Син моның хәзер халык арасында нәрсә тудырачагын беләсеңме? Синең бу мәкаләң районга ташланган атом бомбасы ул!

—Шулай зур бәяләвегез өчен рәхмәт,—диде Ирек.—Партия безгә дөреслекне язарга куша һәм мин шуны үтәдем. Әгәр сезгә ошамый икән, гафу итегез...

—Син үзеңнең күңелсез финалыңа якынлашасың, Сабитов,—диде Арсланов.—Безгә нинди дә оештыру чаралары күрмичә булмас. Электәге хезмәтләреңне искә алып, мин сиңа бер мөмкинлек бирәм: син бу мәкаләңне юкка чыгарган материал басарга тиешсең.

—Мин аны ничек юкка чыгарыйм?

—Күп өлешләре арттырылган, ул бик үк документаль әйбер түгел, фантазия белән өстәлгән урыннары да бар дип, бигрәк тә картның ике-өч

ай ит-май күрмәве турындагы өлеше дөрес түгел дип язасың да, шуның белән килешәбез,—диде Шәвәлиев.

—Сез кадрлар белән эшлибез, дисез, ә менә үз кадрларыгызны бөтенләй белмисез,—диде Ирек.

—Причем монда кадрлар?!

—Мин сезнең кадрыгыз түгелмени? Шушындый эшкә минем мәңге бармаячагымның сез белергә тиеш идегез. Хушыгыз!

Беренче белән Икенченең үзе артыннан туктарга боерып кычкыруларына карамастан, Ирек кызу гына чыгып китте. Эченнән тантана итә иде ул. Хәзер инде алар райкомның түбәсенә менеп, җиз торбалар кычкыртып, бу мәкалә дөрес түгел дип, әллә нинди сүзләр сөйләсәләр дә, файдасыз иде. Ирек халык күңелендәге дистә еллар буе борчыган авыр ярага кагылды, ана кагылу йөзләрчә, меңнәрчә кешеләрнең фикерен уятты.

Халык газетаны кулдан кулга йөртеп укыды. Редакциягә, ике-өч көн үтү белән, авыллардан бер-бер артлы хатлар килә башлады. Хатларның мәгънәләре әйттереп яздырылгандай бер иде: бик дөрес язгансыз, күптән кирәк иде. Безнең авылда да пенсионерларның хәле мөшкел... Аеруча интегеп көн күрүчеләрнең исем-фамилияләре санала...

Өч көннән иртәнге биштә райком бюросын җыеп алдылар. Анда бер генә мәсьәлә иде: редактор И. Сабитовның район газетасында басылган «Ник кан койдың, Сиражетдин?» дигән мәкаләсе турында. Мәкаләнең баштан ахырына кадәр безнең тормышыбызга кара ягу, фактларны күпертеп күрсәтү, әле соңгы атнада гына да пенсионерларга колхоз тарафыннан сатып икешәр килограмм ит бирелүе турында Батталов та, башкалар да чәчрәп чыгып сөйләделәр. Район социаль-тәэминат бүлеге җитәкчесе авыллардагы пенсионерларның тормыш хәлен яхшырту буенча күрелгән берсеннән-берсе әйбәт чараларны тезде. Шушылар барысы да бюро карарына кертелгәннәр, машинкада дүрт битлек бу документ пенсионерлар турында кайгыртуның күздән яшьләр китерерлек гүзәл үрнәге иде. Аның соңгы өлешендә мәкалә дөрес түгел дип табыла һәм карарны район газетасында басарга кушылган иде.

Ирек эченнән инде нишләргә кирәген үзе өчен хәл итеп куйган иде.

—Карарны киләсе санга ук бирәсез!—диде Арсланов.

Ирек бер сүз дә әйтмәде, карарны алды да чыгып китте. Ул ашыгакабалана өенә кайтты, яхшы костюм-чалбарларын киде, паспорты белән партия билетын алды. Беркемне дә шикләндермәс өчен кулына дипломат та тотмады, көрән папкасына шушы мәкалә буенча авыллардан килгән утызлап хатны, ике-өч данәдә мәкаләнең русчасын һәм татарчасын салды да аэропортка юл тотты. Билет яздыргач, беркемгә дә күренмәс өчен, аэропорттан ерак булмаган агачлык арасына кереп, уйланып йөрде, самолет киткәндә генә барып утырды.

«Кемгә керергә икән?» дип уйлады ул очканда. Әле күптән түгел генә редакторлар киңәшмәсендә партия өлкә комитетының идеология секретаре «Дөреслекне язарга, кимчелекләрне ачудан курыкмаска!» дип чыгыш ясаган иде. «Район газеталары тешсез, хәтта председательләрне дә тәнкыйтьләүдән куркалар, ә сез райкомнарның, район Советы башкарма комитетларының бүлек мөдирләренә, секретарьларына, урынбасарларына кадәр тәнкыйтьли аласыз», дип сөйләгән иде. Күп уйлана торгач, Ирек аның үзенә керергә булды.

*Дәвамы киләсе санда*

# ЗАМАНГА ИШ ИҖАТ

## ШАГЫЙРЬ ПОРТРЕТЫНА КАЙБЕР ШТРИХЛАР

«Алтмышынчы еллар буыны» вәкилләренә алтмышар яшь... Быел, гомумән, каләмдәшләр арасында «алтмышлылар» ишле: Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Фоат Галимуллин, Гәрәй Рәхим, Фоат Садриев, Рауль Мирхәйдәров, Ризван Хәмид... Исемнәрне дәвам итәргә мөмкин. Мәрхүмнәрдән—Рәшит Әхмәтҗанов, Тәүфикъ Әйди (бу юлларны язган кичне бакый дөньяга күчте, урыны җәннәттә булсын!). Исәпләсән, һәр ай саен—берәр юбиляр. Һәм исемнәре нинди әле! Һәркайсы үз эшләренең зур осталары. Һәрберсенең әдәбиятта үзенең абруйлы урыны, дәрәҗәсе бар. Шулай да, бу алтмыш яшьлекләр арасында әдәбиятыбызда «алтмышынчы еллар» дулкынын тәшкил итүчеләр бернечә генә. Бу термин-атаманы, асылда, ул вакыттагы яшь шагыйрьләр тудыртты. Ул шагыйрьләр арасында иң күренеклеләренең берсе, һичшиксез, Ренат Харис булды.



*Студентлар-сабакташлар (КДПИ). Сулдан—Ренат Харис, Фәрит Шәрифуллин (бүгенге көндә «Мәгариф» журналының баш мөхәррире), Җәүдәт Кәлимуллин (бүгенге көндә «Мәгариф» нәшриятының баш мөхәррире). 1961 ел.*

Морза әдип Әмирхан Еники әйтмешли, значится, Ренат Хариска да алтмыш икән!

Ходай язган булган: әдәби мохиттә бергә-бергә кырык еллап иҗат гомере кичерелгән. Гомерләребезнең өчтән икесе бергә үтелгән. Әйтергә генә ансат. Кырык ел бит ул, кырык көн түгел... Яшь чакта кырык-илледәге кешеләр дә бик өлкән, алтмыш тирәләрендәгеләре инде бик карт булып күренә иде. Хәзер кемнәрдер безгә дә шулай карыйлардыр. Җырдагыча «минем елларым—минем байлыгым!» дип әйтергә генә кала. Хәер, Яшәү дигән Бөек Халәтнең табигый агышын тойган-аңлаган кеше артык офтанмас. Гомер заяга узмаган бит! Утыртасы агачлар утыртылып ябаллашланган, балалар үсеп житеп дөнья кендегенә тоташтырылган, салынасы йорт-диварлар салынган... Өстәвенә, дистә-дистә китаплар язылган. Теләсән, өеп куй да аларны, бала сөйгән кебек, тышлыкларын сыйпап иркәлә, йә булмаса, өсләренә утыр да бер, чиксез офыкларга карап мәңгелек турында

уйлан... Ренат Харис, кайбер каләмдәшләре кебек, бу яктан тыныч һәм бәхетледер дип уйлыйм. Артта—тынгысыз, әмма мул җимешле, мәгънәле гомер, татлы һәм газаплы иҗат еллары...

Табигать Ренатка талант өеткысын мулдан биргән. Төрле яктан. Ул, теләгәндә, әти-әниләре шикелле, мактаулы педагог була алыр иде (заманында, пединститут бетергәч, Арча педучилищесында укытып та алды), теләгәндә, оста рәссам (ул рәсем ясау белән һәрдаим шөгыльләнә, берничә ел элек Казан музейларының берсендә үз рәсемнәреннән күргәзмә дә оештырды), теләгәндә, музыкант та була алыр иде (нәселләрендә атаклы музыкантлар бар, үзе дә гармуннарда көйләрне оста яңгырата)... Дөньялыкка ярарлык без белеп бетермәгән тагын бүтән сәләтләре дә бардыр. Әмма, ул иң әүвәл Шагыйрь буларак билгеле. Шагыйрь булу—бөек ләззәти биеклектер ул, мөгаен. Кешелек тарихын шагыйрьләр бизәкли. Гомер бакый шулай килгән. Ярты дөньяны яулап алган яугир ханнар, патша-корольләр дә Шагыйрь данына кызыккан. Һәр халыкта Шагыйрьнең үзгә бер символ-образы. Кызганыч, бездә шагыйрь образын стереотип рәвештә «тамга салынган» ходай бәндәсе итебрәк күрәләр. Шагыйрь—Тукай яки Мөдәррис Әгъләмов кыяфәтенә, холык-фигыленә генә сыеп бетә алмый. Шагыйрьләрнең төрлесе булган—дәрвиш-чичәннәре дә, хәким-хөкемдарлары да, бае-ярлысы да, кәрләсе-баһадиры да... Үзебезнең әдәбияттагыларын гына күз алдына китерик: әрвахлар сакчысы Мөхәммәдьяр, гомерлек мосафир Акмулла, зыялы миллионер Дәрдмәнд, гыйсъянчы Такташ, мәхбүс риясыз Туфан, башбирмәс Баттал... Менә калса, Р. Харис Гете тибындагы шагыйрьлекне үзенә өлге итеп алган. Шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе. Ай-һай!—бигрәкләр дә бөек биеклек! Бездә булырдай эшме бу?


*Иҗатташлар арасында. Сулдан—Хөснул Вәлиуллин, Ренат Еникиев, Бату Мөлеков, Илдар Юзеев, Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Ренат Харис, Резеда Ахиярова. 1983 ел.*

Ренат Харис гомере буе җаваплы хезмәттә булды. Бер ел педагог булып эшләүгә аны ВЛКСМ өлкә комитетына инструктор итеп алдылар. 60 еллар ахырында «Яшь Ленинчы» газетасының җаваплы секретаре, аннан—Язучылар берлегенең җаваплы секретаре, хәзергечә әйтсәк, рәис урынбасары, ун елга якын (1973-82) Татарстан культура министры урынбасары, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире (1982-89), соңгы дистә елларда—КПССның Татарстан өлкә комитетында идеология бүлеге мөдире, «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире, Татарстан Дәүләт Советының рәис урынбасары. 1990 елдан бирле (рәттән өч чакырылыш) Татарстан халык депутаты... Безнең арада болай озак еллар буе дәүләти вазифалар башкарган шагыйрь юк та сыман. Халыкча әйтсәк: түрә шагыйрь. Белүемчә, бу статусның күп җайлы яклары белән бергә, шактый үзгә кыенлык-тыенлыклары да бар: һәрдаим мәгълүм кысаларда тота торган рәсмилек, сәяси манипуляцияләргә әзер булу, мәҗбүри этикет... Таунын башынарак менгән саен, җилләр көчлерәк! Шундый юл сайлагансың икән... Әмма түрәлек китә торган нәрсә, шигырь кала, шагыйрь кала. Безгә шагыйрь Ренат Харис турында сөйләү дөрес булыр.

Иң әүвәл, ретроспектив планда, үткән еллар елъязмаларына күз салып алыйк әле. Моннан унбиш ел элек чыккан «Совет Татарстаны язучылары» дигән биобиблиографик белешмәдә *(төзүчеләре Р. Даутов, Н. Нуруллина)* Р. Харис турында менә нәрсәләр язылган.

«... Р. Харис—әдәбият мәйданына алтмышынчы еллар башында килгән һәм беренче адымнарыннан ук шигъриятә үз сөйләү формасын, үз стилен булдырырга тырышкан үзенчәлекле шагыйрьләрдән берсе... Р. Харисның шигъри әсәрләре заманча үткен яңгырашы, интернациональ рухы, образлы

фикерләүдәге янача алымнары, кыю метафоралары һәм чагыштырулары, форма өлкәсендәге оригиналь табышлары белән җәлеп итә. Ул поэзиянең тематикасын, жанр чикләрен төрләндерү, шигъри сүзнең җегәрен, эчке куәтен арттыру, чорның олы проблемаларын лирик чаралар ярдәмендә үтемлерәк итеп җанландыру юнәлешендә өзлексез эзләнә, фикер-хисне укучыга сурәтле итеп җиткерү өчен халык иҗаты символикасыннан һәм әдәбият-сәнгатьтәге шартлы алымнардан мул файдалана.

Шагыйрь үзенең шигырь һәм поэмаларында халкыбызның тарихи яшәеше, кеше шәхесенең тормыштагы урыны, җәмгыять каршындагы җаваплылыгы, буыннар дәвамлылыгы турында уйлана, заманның әхлакый, рухи, иҗтимагый күренешләренә, үзгәрешләренә үзенең фәлсәфи һәм гражданлык мөнәсәбәтен белдерә. Гомумән, халыкның тарихи үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге, кеше һәм табигать, аларның үзара бәйләнешы—шагыйрь иҗатында үзәк темалардан санала...»

Бу бәяләмәнең конкрет авторы кемдер, әмма төпле әйтелгән. Шагыйрьнең тоткан юлы, кредосы бүген дә шул. Бу Олы Юлдан баручы юлчы-мосафир гына бераз үзгәргән: гайрәтле ир-егеттән хәзер инде ул халык гамен күңеленә җыйган ил агасы—хәким-аксакалга әверелгән... Күп ил-җирләр күрелгән; дөнья тоткасы саналган күпме асыл затлар белән очрашылган, әңгәмә корылган; мәңгелек һәм беркөнлек кануннар турында күпме уйланылган; максат-идеяләрнең дөреслеген кат-кат исбатларга тырышылган... Һәм иң мөһиме: кайда гына, нинди вазифада булынса да өзлексез язылган, иҗат ителгән.

Бүгенге Ренат Харис—төрле телләрдә чыккан утызлап китап авторы, республиканың М. Җәлил премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Каракалпакстанның мәдәният хезмәткәре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Төрле жанрларда уңышлы эшләрлек сәләте булса да (матбугатта чыккан беренче язмалары тәнкыйть мәкаләләре иде), Ренат гомер буе шигырь язды. Тезмә әсәрдә булган бөтен мөмкинлекләрне файдаланып, бөтен форма-төрләрен сынап карады. Озын шигырь, кыска шигырь, сонет, баллада, хикәят, либретто... һәм поэма. Поэмаларны күп язды шагыйрь. Утызлап бар бугай. Төрле рухтагылар: һәм лирик, һәм патетик, һәм эротик, һәм публицистик. Менә кайберләренең исемнәре: «Мулланур», «Камил Якуб», «Рәссам», «Җәлилчеләр», «1972 ел икмәге», «Ат иярләү», «Ант суы», «Өч үбешү», «Гармунчы», «Сәйдәш яры», «Борылышта», «Чехов базары», «Идегәй», «Бүре күзе»... Күп бит! Композитор өчен симфония язу нинди зур фундаменталь хезмәт саналса, шагыйрь өчен поэма да шуңа тиң. Бүгенге шигъриятть шулай күпсанлы поэмалар язучылар сирәк. (Дөрес, бу жанрда да зур активлык белән эшләүчеләр бар. Мәсәлән, үзләре әйтүе буенча, И. Юзеев—утызлап, Ә. Рәшитов—унлап, Ф. Гыйззәтуллина дистәдән артык поэма язган. Тик аларның һәрберсе дә поэма микән соң? Бу хакта байтак бәхәсләр булса да, жанр, күпләр—һәм шагыйрьләр, һәм укучылар өчен—һаман ачыкланмаган булып кала бирә.) Заманында поэма сымак берничә озын нәрсә язган булсам да, бу жанрның чын хасияте, бу очракта, шагыйрьнең әсәрләре турында төпле сүз әйтеп, объектив бәяләмә бирә алмам. Бу эшкә көчем дә, вакытым да җитмәс. Махсус өйрәнүне сорый торган зур мәсьәлә. Каләмдәш хезмәтенә сокланырга һәм яхшы мәгънәдә көнләшергә генә кала.

Шагыйрьне җырлары буенча да яхшы беләләр. Аның сүзләренә йөзләп көй язылган. Арада менә дигән җырлар бар. Шулай булмый ни!—байтак еллар татарның иң талантлы композиторлары белән хезмәттәшлек итте бит ул. Н. Җиһанов, Р. Яхин, А. Монасыйпов, Р. Еникиев, Ф. Әхмәтов... Чагыштырмача яшьрәк буын вәкиле Резеда Ахиярова белән иҗади дуслыгы бигрәк тә нәтиҗәле булды.

Шагыйрьнең поэзиясе, җыр-көйләрдән тыш, музыканың катлаулырак сфераларына да үтеп керә алды. Аның либреттолары буенча дүрт оратория язылды. «Кеше» (М. Яруллин), «Казан» (Б. Мөлеков), «Кеше һәм машина» (И. Якупов), «Мулланур» (Е. Кожевникова). Үз вакытында алар композиторларның пленум-җыелышларында яңгырап, җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләнделәр.

Гомумән, шагыйрьнең иҗаты зур, бай, күпкырлы. Ул «кырлар» сәнгатьнең бүтән төрләре белән дә табигый тоташып китә, икенче төрлерәк әйткәндә, бер

зур сәнгать икенче сәнгатьне кузгата, үстерә, ягъни бер-берсенә керешә. Әдәбият-сәнгать тарихында моңа мисаллар бик күп. Ул гына да түгел, аерым бер шагыйрь-иҗатчы аша (зур иҗатчы булса, әлбәттә) тулы бер чорның, бер буынның «кардиограмма»сын күреп була. Алда әйткәнемчә, Р. Харис 60 елларда килгән шагыйрьләр плеядасының күренекле вәкиле. Ирексездән, яшьлекне искә төшереп, бүгенгедән киләчәкне күзалларга тырышып, әлеге буынның әдәбияттагы урыны турында уйланасың. Уйланыр өчен җирлек зур. Язылмады түгел, байтак язылды бу буын турында, алга таба әле күбрәк тә язылыр.

Тарихи закончалыктыр: җәмгыятьтә мәгълүм иҗтимагый шартлар тугач, аренада милли-рухи алгарышны тизләтүгә сәләтле көчләр пәйда була. XX гасырның икенче яртысындагы татар әдәбиятында, бигрәк тә аның шигъриятендә, шундый көч 60 еллар башында килгән бер төркем талантлы шагыйрьләр булды. Кемнәр иде соң алар дип, баш ватып торасы юк, исемнәре яхшы мәгълүм: Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Радиф Гаташ һәм без фәкыйрегез. Шау-шулы төркемнең үзәгендә булмасалар да, бу рәттә Рәшит Әхмәтҗанов, Айдар Хәлим, Кадыйр Сибгатуллин исемнәре дә бар. Хәзер—кырык еллар үткәч, бастырып әйтеп була: көчле булган икән бу буын! Берсе генә дә бит төшеп-югалып калмаган, һәммәсе, кем әйтмешли, үз казыгын каккан, үз биеклеген өйгән, арабыздан иртәрәк китеп барганнары да әдәбият тарихында җуелмас «автограф»—зур иҗади мирас калдырып киткән. Бу буынның иҗат башлангычы елларында—илленче еллар ахырында—татар шигъриятенең хәле шактый мөшкел иде. Чын мәгънәсендәге зур поэзия әсәрләре сирәк. Мәктәп елларында, күңел шигырьгә сусаган чорда, безгә күбрәк мөтәшагыйрьләрнең китапларын (ә китапларны су урынына «эчә» идек!) укырга туры килде. Дөрес, элгәрерәкләрдән Тукай, Такташ, Ф. Кәрим бар иде. Ә студент елларында без «максималистлар» ул чорда бик күп шагыйрь саналганнар арасыннан С. Хәким, Н. Арсланов, Ә. Давыдов, З. Мансур, С. Батталларның гына кайбер әсәрләрен таный идек. Тик кайберләрен генә! Бездән бер баш өлкәннәрдән И. Юзеев, Г. Афзал, Х. Камалов, Р. Гәрәй, М. Шабаев, Ш. Галиевләр яшьләр арасында популярлашып барсалар да, кызганыч, безнең буын иҗатчылар өчен кумир булып, поэзиядә кискен борылыш, сыйфатый яңарыш ясый алмадылар. Өлкән абыйларының бишмәтенә ябышу, дөресрәге сталинчыл идеология традицияләреннән арына алмау көчле иде булса кирәк. Туфан, Җәлилләр әдәбиятка кайтып кына киләләр иде... Әлбәттә, бу ретропанорама, билгеле бер бәяләмә шул чор өчен. Соңгы 30-40 ел эчендә заманалар нык үзгәрде. Шөкер, уңай якка.



*Ренат Харисның «Казан утлары»нда баш мөхәррир чагы. Редакциягә кунакка атаклы шахматчы Гата Камский (алгы рәттә уңнан беренче) килгән. 1988 ел.*

Кемнәр килүенә карамастан, әдәбиятта сыйфатый үзгәрешләр булу котылгысыз иде. Тормыш «көзгесе»—әдәбият тоныкланган яки күзне чагылдырырлык дәрәҗәдә көмешләндерелгән иде. Шул еллардагы шигырь китапларын алып карагыз. Баш өлешендә Ленин, Сталин, партия турында мәдхия куплетлары, аннан—хезмәт, бәхетле яшәү рәвеше турында патетик шигырьләр, ахырдарак—лирик-мәхәббәт шигырьләре, иң соныннан—эз-мәз юмор-сатира. Олылар шигърияте генә түгел, балалар поэзиясе дә бик нык идеологияләштерелгән иде шул. Тематик яктан грамоталы итеп укмаштырылган шигъри цикллар да сирәк иде (шулай да, С. Хәкимнең «Суд залында», Х. Туфанның сайланмаларындагы цикллар хәтердә калган). Хөр фикергә иркен мәйдан булмаудан килгән күренеш. Күрәсен, күпләрнең фәлсәфи-эстетик платформалары, үз принцип-кредолары да анык булмаган. Шигырьнең куплет-шакмак калыбыннан чыгып, ирекле строфалар итеп язу шигырьне «бозу» санала иде, хәтта куплет эчендәге юлбаш хәрефләрне кечкенәдән башлау да гайре табигый кабул ителә иде. Нигездә, партия органнары булган газеталарда фикерле шигырьләрне бастыру үзе бер проблема. Ярый ла, елына берничә шигырь бастыра алсаң! Эх, Замана! Үткәнгә бүгенгедән торып, акыллы булып, бәя бирү җинел. Ә үзен шул сугыш, культ тегермәннәрендә «тартылсаң», нишләр идең?

Алтмышынчы еллар буынының элгәргеләрдән бер өстен ягы шул: алар гали белем алып, шәрык һәм гареп мәдәниятын ярыйсы ук үзләштереп, үз тарихыбызның моңарчы яшерелгән сәхифәләрен белеп, өйрәнеп, әдәбиятка зур әзерлек белән килделәр, шуна күрә, беркадәр язу тәҗрибәсе тупланганч, тиз арада үз эшенең чын профессионаллары булып җитешә алдылар. Аларның беренче китаплары ук, юка гына булуларына карамастан, эчтәлек ягыннан булсын, җыентыкны тезү-төзү, хәтта иллюстрация-бизәү ягыннан булсын, уңай якка аерылып тордылар.

Ренат Хариска 60 яшь. Шагыйрь өчен аз гомер түгел. Шагыйрьнен олпатлык юбилее. Юбилей димәктән, мин Ренатның теге яки бу зур залларда иҗат кичәләре, юбилей тантаналары үткәргәнен хәтерләмим. Мәһабәт театр биналарында кемнәр генә, нинди генә кичәләр уздырмады соңгы елларда. Бер генә түгел, кат-кат, өч-дүрт мәртәбә. Теләсә, Ренат та үткәрә алыр иде. Иҗаты да бар, дәрманы-власте да бар иде. Күрәсен, фейрверклы шау-шуга караганда, сабыр гына язып ятуны мәгъкульрәк күргәндер. Бәлки, алтмыш еллыгы уңаеннан зур кичәләр узар? Узуын телибез, халык алкышлары зур иҗатына аваздаш булсын.

Һәр шагыйрь иҗатын төрле кеше төрлечә кабул итә. Р. Харис шигъриятен өнәп үк бетермәүчеләр барлыгын да беләм. Кемнәргәдер Р. Харис поэзиясе салкын, теле моңсыз тоелырга мөмкин. Хәтта, «Шигырендә үзеннән дә акыллы булмакчы!» диючеләр дә бар. Стиль ул—Кешенең үзе! диләр. Нишлисең, тормышта Харис үзе ничек булса, шигыре дә шул була инде! Әмма беркем дә аның зур фикер иясе шагыйрь икәнен инкяр итмәс. (Сүз уңаеннан Ренатка шуны да әйтәсе килә: татар әдәбияты тәнкыйтен кризис хәленнән чыгаруда өлеш кертергә иде бит! Синеке кебек теоритик әзерлекле, зур тормыш һәм язу тәҗрибәсе булган әдипләр үзләренең фәнни-тәнкыйди хезмәтләре белән активрак катнашсалар, әдәбияттагы хаос кими, иҗади атмосфера савыга төшәр иде. Шигырьдәгегә караганда тәнкыйтьтә идеолог булу, отышлырактыр, бәлки). Талантлар төрле була һәм аның һәрберсе ихтирамга лаек. Бездә артык шагыйрьләр юк. Максатлар бер булганда, һәркем үзенең кирәк урынында. Милләт, ил язмышы хәл ителә торган гасырда «Татар акыллары, татар шагыйрьләре җыелыгыз!» дип кычкырасы килә. «Карурман» җырындагы «заманалар авыр, еллар ябык» дигән сүзләр көннән-көн актуальрәк яңгырый...

Әтисе Мәгъсум (шөкер, ул әле исән-сау!) сугышка алынганда нәни Ренатка берничә ай гына була. Ата кеше сабыеның бердәнбер фоторәсемен үзе белән ала, фронтлар буйлап күкрәк кесәсендә йөртә. «Шушы сабый хакына исән үттем сугыш мәхшәрен», ди Мәгъсум ага. Әнә шул сабый хәзер булдыклы ир, алтмыш яшьлек олпат шагыйрь булып XXI гасырга аяк басты. «Яшим, эшлим, расльйм!» дип иҗат итә ул.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**,
*Татарстанның халык шагыйре*



# Ренат Харис

## ХЫЯНӘТ

ПОЭМА

**Аһ, беренче мәхәббәтләр!..**
**Тукта!.. Ничәү соң алар?**
**Алар хәтер ышыгына**
**гөл булып сыенганнар—**
**күзекмәскә ят күзләрдән,**
**тырналмаска гайбәттән,**
**күз яшенең саф чыкларын**
**койдыртмаска, әлбәттә...**
**Барысы да—беренчеләр!**
**Һәркайсысы—могҗиза!**
**Шуңадыр хуш исен яшьлек**
**гомер буйлата суза.**
**Барысы да беренчеләр...**
**Ә чыны, тормышчаны**
**асылда бер генә була.**
**Шунысы—тормыш җаны.**
**Ләкин аңа җитәсе бар**
**мең янып һәм мең туңып,**
**мең сокланып, мең уфтанып,**
**мең үлеп һәм мең туып.**

**Тулган Ай авыл өстенә**
**аптырап карап тора.**
**Билдән көрткә бата-бата,**
**бакча башларын урап,**
**ике кеше якынлаша**
**лар зурлыгы мунчага...**
**Анда ике гүзәл сылу**
**бер-берсен мунча чаба.**
**Мәтрүшкәле каен исен**
**җил бакча буйлап куа...**
**Егет хуш исле кар белән**
**маңгаен, түшен уа.**
**Сабантуйлар батырының**
**йөрәгендә таш кызган—**
**ул сүзгә сыймаслык гашыйк**
**мунчадагы бер кызга.**
**Ничә аңлатып карады!**
**Аңламый да, аңламый,**

минем Буада егетем
бар инде, дип алдалый.
Булмагае, була бирсен.
Аннан кемгә комачау?!.
Әгәр булса, күренер иде,
түзмәс иде моңача!
Миннән артык җире юктыр...
Йортым—хәлле, мин—таза...
Тәвәккәллим—язмышымда,
күрәсең, шулай язган...
... Мунча тәрәзәчегеннән
сузылып карга яткан
алтынсу яктылык аны
чалып екты аяктан.
Күзләре керде мунчага...
Ә карда каен исе.
Исерде аның бәдәне,
тилерде аның хисе.
Ботларга, билгә, беләккә
көч инде әллә каян—
терәк булса, ул Җир шарын
ыргытыр иде айкап.
Кызларның киенүләрен
көтәрлеге калмады.
Лар зурлык иске мунчаның
чатыннан тотып алды,
—Әйдә, булыш!—дип кычкырды,—
бер, ике, өч... бергәләп!
Аерылды усак мунча,
купты төпке ниргәдән,
авып төште, түнтәрелде—
бакчаны күмде болыт...
Шул болыттан, чиный-чиный,
ике фәрештә булып,
шәрә кызлар йөгереп чыкты
көмеш карлар эченә.
Хуҗа кыз әни, әни дип,
кычкыра бар көченә.
Кем ишетсен инде аны?!
Шашкан егет шул чакта
фельдшер кызны җәһәт кенә
тотты алды кочаклап.
Төрде кызны үз тунына,
кигерде үз катасын...
«Фатирга түгел, өеңә,
фәрештәкәй, кайтасың!»
Оекбаштан һәм күлмәкчән
көртләрне ера-ера,
тыкрыкка чыкты, ә анда
җигүле айгыр тора.
Тиктормас айгыр янбашын
чыбыркы алды ялмап...
Мунча болыты эчендә
шахтер лампасы яна...
Ә тулган Ай карап тора:
кара син бу юләрне!
Юләр... Юләр... Бу ут сүнәр,
ә йөрәктә сүнәрме?

Кышкы каникулга кайттым
мин Буадан авылга.
Ит кисәге түгел йөрәк,
ул сызланып сагына.
Әни-әтине, энемне
сагына аңны кушып.
Алар янында иркенлек,
алар янында ышык.
Ләкин яшь йөрәгемдә
тагы да бер сагыну.
Ул сагыну аңлы түгел,
ул сагыну—табыну
аңлашылмаган давылга!
Күзәнәкләргә үтеп,
ул җанны өшетеп ташлый,
аннары ала өтеп,
аннары «Көнләшү» дигән
яры яба күзеңә,
борыч өсти, бал-май өсти,
шигырь өсти сүзеңә;
тыелгысыз теләк булып,
җаныңа канат куя,
шик-шөбһәгә әйләнә дә,
аякка кургаш коя;
уй-хыялга тизлек бирә,
уя аңа күз, колак—
яшә Аның мең чакрымнан
йөрәк тибешен тыңлап,
Аның күзләренә кара,
сүзләрен Аның ишет...
Аһ, чынбарлык! Ник йозаклы
медпункттагы ишек?

Өйгә кердем... Кочып алдым
шактый үскән энемне.
Әти гөрли:—Улым кайткан,
тугыз ярым белемле!
Тагын ярты ел укыйсы
һәм унынчы—вәссәлам.
Аннары кая барырга?
Менә бусы—мәсьәлә!
Әни чыкты, болгый-болгый
камырлы-онлы кулын,
суганлы сызык сумсасы
ярата, диеп, улым...
Тәмле чәй, тәмле ризыклар...
Йөз сорау, туксан җавап.
—Беркөн әнә фельдшер кызны
урладылар мунчадан...
Буада егете булган...
Менә язмыш сындыру...
Шул сабантуй әзмәвере,
мөртәт, эче боргыры...
Ярәшелгән, дип караган,
елый-елый ялварган...
Үзенекен иткән мөртәт,
язга чыккан җанвардай...
... Мин чәйним сызык сумсасы,
йотарга да онытып...

Әни сөйли, сөйли, сөйли—
утырам шуны йотып...
—Буадагы егет белән
җаен өйләнешергә
булганнар. Аннан—Казанга,
институтка—бергә.
Бигрәк булган кыз иде шул...
Тылсым иде кулында.
Һәр көн дога укый идем:
шундыйны бир улыма...

—Мунча өлгергәндер...—диеп,
мин өйдән чыктым кышка...
Җанда шартлаган ачудан
ничек язмадым һуштан?!
Нинди хәйвани гадәт бу!
Нинди коточкыч хәшәп
яши татарда Сабантуй,
Нәүрүз белән янәшә?!
Өзеләләр мәхәббәтләр,
чөнки, ни генә димә,
тегәрҗеп белән ефәкне
булмый ул ныклап төйнәп.
Әти әйтмешли, ефәге
барыбер чыга шуып.
Баш йөрәккә беркайчан да
аңлата алмый шуны...
Ачуым әйләнде үчкә,
үч канны башка куды...
Тегене рисвай итәргә
мең төрле ният туды.
Хыялым белән мөртәтне—
сабантуйлар батырын—
мин айгыр булып таптадым,
әбрәкәйгә батырдым;
мунчадан киемен урлап,
анадан тума көе,
күзен бәйләп, көрт ердырып,
эзләтеп йөрдем өен;
татуировка ясадым
тушь белән маңгаена:
«Әй хатын-кыз! Мин—көчләүче!
Битемә төкер... Юма!...»
—Әле дә мунчада түгел...
Күлмәкчән... оекбаштан...
Безнең дә кирәсе бар бит...
Нишләп тора, саташкан?!
... Әни тавышы айнытты.
Җилгә ачык болдырда,
ачу давылында кайнап,
торам икән калтырап.
Мунчага кердем... Пар салдым...
Себерке пешекләдем.
Сагындырган каен исе,
баллы мәтрүшкә тәме!
Әй чабындым рәхәтләнеп...
Төсен үзгәртте хыял...
Мин Толымбай урманында.
Анда чикләвек җыям.

Бердән артык агач тими
биш-алты җыючыга.
Кайсы агачка үрмәли,
сындыра кайсы, ега.
Мин үрмәләдем өскәрәк.
Ботак сынды... Мәтәлдем...
Күзем ачтым... бер кыз тора...
«Мин кайда?» дип әйтәлдем.
Баш әйләнә... Кан да ага.
Кузгалдым авыр гына.
Мин башым белән төшкәнмен
зур имән тамырына.
Кыскалап канны туктатты...
Үзенең төсе качкан.
Тотып шәһәргә кайтарды,
алып керде врачка...
Буа медучилищесын
бетерә икән быел.
Бер ел авылда эшләгәч,
институтка—уе.
Тартылышу һәм тартыну...
Аларның көрәшләре...
Тартынуның җиңелүе...
Соклану күз яшьләре...
Хуш исләре чәчләренең,
биленең тыгызлыгы,
сагыну булып, йөрәкнең
бар тынычлыгын бозды.
Күрешкән саен күрәсе,
кочкан саен кочасы
килү арта. Аны алып,
йолдызларга очасым,
анда бер чатыр корасым,
икәү генә торасым
бәйләнчек төшкә әйләнде—
язмыш юшка юрасын...
Юравы юш килә язды:
укуын бетерешкә
бездә медпункт ачылды.
Сорады, кайтты эшкә.
Аһ бу авыл әзмәвере!
Аһ бу бәхет карагы...
—Син исәнме?—дип, мунчаны
эти ачып карады.
Сискәндем... Кайттым хыялдан...
Көч кергәндәй тоелды.
Хәзер чыгып җитәм, диеп,
юынмыйча коендым.
Яңа Ел каршыларга дип,
әни табын көйләде...
—Әни, фельдшер кыз турында
ник «иде» дип сөйләдең,
берәр нәрсә булды мәллә?
—Юк, әлләни булмады,
шул хәлдән өч-дүрт көн узгач,
ул авылдан югалды.
Төнлә киткәнме? Көндезме?
Җәяүме, олаудамы?
Беркем белми... Ә бәдбәхет

атна буе аунады
исерек килеш клубта.
Кешнәде айгыр кебек:
«Буада имеш егете—
табам, үтерәм тибеп...»
Буага да барып кайткан
теге иптәше белән...
Буа кызы түгел икән—
училищедан белгән.
Кайгыны бит әчкә генә
сеңдерә ул аракы.
Ул күңелле чакны гына
үртәр өчен яраклы...

Илле сигезенче елга
күченәсе төн иде.
Мин барлык җан иясеннән
түбән идем, ким идем:
хыялларым—челпәрәмә,
өметләрем—көл иде...
Бернәрсә дә эшли алмыйм...
Әйдә, язмыш, көл инде,
әйдә, салып тапта инде,
сыта алсаң, әйдә, сыт,
алдагы көннәрем өчен,
бәлки, булыр файдасы!..
Мин клубка барып кердем.
Мамык бизәкле нарат...
Егетләр көнбагыш чиртә
кызлар ягына карап.
Кызларның кайсыберләре
плюштан жакет кигән.
Андыйлар ияк очларын
түшәмгә таба чөйгән.
Эскәмиядә моңаеп
иске бер гармун тора.
Мине күргәч, теге кызлар
җәһәт алдылар урап,
тизрәк гармун тоттырдылар...
Көнбагыш кабыкларын
йотып бетерде биешкән
идәннең ярыклары.
Кызган уен уртасына
килеп керде әзмәвер:
—Авыл чибәрләре белән
биеп калыйк әле бер...
... Туктаттым гармунны... Белмим
алда ни итәсемне.
—Аннары шәһәр чибәрен
эзләргә китәсеңме?—
дип акырдым, көтмәгәндә
ни ул, ни мин, ни клуб.
Кайбер егет чыгып качты,
кайсы көлде егылып.
—Мин булам аның егете,
мин яшердем, инанып
сафлыгына... хатын итә
алмагансың син аны!..
... Идәнгә кадаклангандай

басты-катты әзмәвер—
һәр сүзем башына бәрде
әйтерсең килолы гер.
Һушына китермәс өчен
мин яңаларын өям:
—Синдәйләргә евнух диләр—
ирлеге кипкән кияү...
Шушы чирен больнисларда
дәваларга оялып,
ул фельдшер кыз урлап кайткан—
и надан, и хыялый...
Ул Буа сабантуенда
тарттырган шул тамырын—
бернишләтеп тә булмый шул
чиле-пешле камырны...
... Барысы да кинәт булды—
уйланылмады алдан...
Мине кызлар коткардылар
бармаклы кувалдадан.
Адресларын белә идем...
Кызны озак эзләдем—
урланган аты чыкса да,
аннан җаным бизмәде.
Ярым ятим иде бит ул
түм-түгәрәк бу Җирдә—
әтисе сугышта үлгән,
әнисе—башка ирдә.
Эзләдем... Таба алмадым,
бик килсә дә күрәсем,
җан җәрәхәтен дәвалап,
үзен назга төрәсем...
Институтта укыганда
бер хат алдым Ульяннан.
Укыймын... Сизәм—яңадан
иске хисләрдә янам...
«... Мин сине мәңге онытмам,
мин сиңа мең рәхмәтле,
бергә татый алмасак та
тулы сөю рәхәтен.
... Сезнең авылдан Цильнага,
әнием апасына,
китеп котылдым язмышның
коточкыч хатасыннан.
... Улыбыз бар... Тагын берне
йөрәк астында тойдым.
Булганына, исеңдә тот,
синең исемне куйдык.
... беләсеңме, ник рәхмәтле?
Хатны да шуңа язам—
син теге җинаятьчегә
биргәнсең каты җәза.
... Син мине үзең эзләмә,
бик җиткән мин тапкан да...
... Чык та кайчак тозлы була,
елап таңнар атканда...»
Каян белгән, кем җиткергән?
Әле булса белгесез...
Чынлап та үтемле булган
клубтагы минем сүз.

«Евнух» кушаматы аңа
ябышты һәм беректе,
котыла алмады аннан
кагып, сугып, эретеп.
«Мин—ир!» диеп, солдаткалар
янына да елышкан—
ләкин себерелеп очкан
мәсхәрәле сулыштан.
Тирә-як авылларга да
таралган яманаты.
Кызлар биергә чыкмаган...
Бу эчә икән ятып...
Түзалмагач, кубарылып,
авылдан китеп барган...
Әлегәчә беркем белми—
берекән нинди ярга?
Ун елдан соң кайткан, диләр,
ияртеп өч баласын—
янәсе, ул менә нинди!
Авыл күрсен—карасын!
Халык гөжләгән: балалы
хатынга йортка кергән...
Ике-өч көннән тегене
җил ишеткән, Ай күргән...

Аһ, беренче мәхәббәтләр!
Тукта! Ничәү соң алар—
хәтеремнең ышыгына
гөл булып сыенганнар?—
күзекмәскә ят күзләрдән,
тырналмаска гайбәттән,
күз яшенең саф чыкларын
болгатмаска, әлбәттә...
Барысы да беренчеләр,
барысы да могҗиза!..
Ул хис үзенең хуш исен
гомер буйлата суза.
Аһ, беренче мәхәббәтләр!
Телә-телә бәгырьне
югалалар... Шуның өчен
алар үтә кадерле.
Югалтасың... Шул мизгелдә
яшисе килми хәтта...
Ләкин яңа йолдыз яна,
яңа матур таң ата,
яңа җилләр күкрәгеңдә
яңа дулкын куптара.
Онытасың... Шул оныту
һәлакәттән коткара...
Аһ, беренче мәхәббәтләр—
уфтанулар һәм аһлар,
тыелганга кагылулар,
булмый калган гөнаһлар...
Кайчак шулар балкып ала
истәлек яктысында,
бүгенгегә көндәш түгел,
ә ерак йолдыз сыман.



**Тәүфикъ Әйди**

## ВЕНАДА ОЧРАШУ

БӘЯН

—Мистер Карагаев, Сезгә ашыгыч телеграмма!
—Кайдан?
—Венадан.

Шәмсир, карашын эш кәгазьләреннән аерып, радио йомышчысына төбәлде, чапкынның дәфтәрчегенә имзасын сырлады һәм ул кабинеттан чыгып киткәч тә телеграмманы укырга ашыкмады. Редакциягә халыкара телеграммалар еш килә. Милләттәшләре Төркиядән, Франциядән, гарәп илләреннән, хәтта ерак АКШ һәм Уругвайдан да хәбәр бирәләр, ә бусы күршедән генә диярлек.

Әйе, сугыш тагын татарны, бөтен дөньяга чәчте-таратты, аларның үзара хәбәрләшеп тора торган җире дә хәзер «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе генә. Чөнки ватанга юл ябык—тимер пәрдә аша хат та йөрми, йөрсә дә кичәге хәрби әсирләрнең илдәге туганнарына, якыннарына хәвеф-хәтәр генә өстәргә мөмкин. Моны исә берәү дә теләми!

Ниһаять, ул урындыгын өстәлдән арткарак этеп, сигарет кабызды һәм ашыкмый гына телеграммага сузылды.

«Иртәгә Штадтспаркта Штраус һәйкәле янында унбиш сәгатьтә көтәм. Василә. Вена».

Шәмсир үз күзенә үзе ышанмады. Василә?! Вена?! Штадтспарк. Көтәм!.. Мөмкинмени соң бу? Истә-коста булмаганда, күпме гомер узгач...

Ул сигаретын тирән-тирән итеп суырды, хәтта урыныннан сикереп торып, кабинетында арлы-бирле йөреп, тәрәзә каршына килеп басты.

Кайдан белгән ул аның монда эшләвен? Нишләп алданрак хәбәр бирмәгән? Ун ел узды бит, ун ел!

Ял көненә туры китереп чакыруы бик яхшы, сәфәр чарасын күрә башларга кирәк. Шәмсир икеләнмәстән автовокзалга шалтыратып, иртәнге рейска билет кайгыртып куйды. Аннары ул радио директорына кереп хәлне аңлатты. «Тимер пәрдә» артыннан юлчы бар, дүшәмбедә эшкә кайтып житмәсәм...

Рөхсәт алу кыен булмады. Хәзер инде ул көндәлек эшен тыныч кына башкара алырлык хәлдә түгел иде—юлга кичтән үк чыгып китәсе килә башлады. Ара шактый, вакытында барып өлгермәсә, тансык очрашудан коры калырга да мөмкин. Юк, юк, мона юл куярга ярамый. Аһ, Васил, Васил, алданрак хәбәр бирсәң, ни була?!

Ул тагын сигарет кабызып, өзлексез тарта башлады. Форточкасы ачык булуга карамастан, кабинеты зәп-зәңгәр төтен белән тулды. Шәмсир, шул зәңгәр пәрдә аша алмасарланып, ун-унбер ел элек булып узган вакыйгалар эченә кереп чумды.

* * *

...Сугыш. 1943 ел. Германия өчен хәвефле борылыш алды. Илгә алман гаскәре сыртында исән-имин кайту хыялы торган саен тоныклана башлады. Идел-Урал легионы үгетчесе Шәмсир мәңгегә Көнбатышта калырга туры киләчәген чамалап, киләчәк тормышын ничек көйлисен уйларга керешге. Үзенекен дә, башка легионерларныкын да кайгыртырга кирәк иде. Утлы нотыкларны сөйләү бер нәрсә, мөһажирлектә калачак милләттәшләренең көнкүрешен жайлау, аларны ят тирәлектә йотылудан саклау бөтенләй башка эш иде. Типсә тимер өзәрлек ир-егетләргә чит илдә нинди пар табылыр?

Менә шушы хакта уйланганда ул Польша татарларын искә төшерде. Аларның да ирләре кырылды, үз араларыннан пар таба алмаячак кызлары, тол калган хатыннары аз булмас.

Иптәшләре, бигрәк тә Берлин мөфтие белән дә киңәшкәч, ул үз уен тормышка ашыру эшенә дә керешге. Радомга еш-еш барып йөргәнлектән, аңа юл уңаенда моны кайгырту бик читен дә түгел иде.

... Варшауда ул, поездан төшү белән, кулындагы адрес буенча, Бәйрәшине эзләп китте. Госман мулла, адрес бирүдән тыш, кирәкле жиргә ничек барасын да өйрәтеп эшне жиңеләйткәч, Шәмсир тиешле трамвайга утырды да, текә түбәле, тар фасадлы биналар арасына кереп югалды. Бомба һәм снаряд тиеп шартлаудан зарарланган йортларның күпчелеге әле һаман төзәтелмәвенә игътибар итеп, «ярый ла мин табасы өй исән-сау торса», дип шомга калды ул. Госман мулла Польша басып алынганнан бирле Бәйрәши (ягъни Госман мулла тутырып әйткәнчә, Бәйрәшевский) белән хәбәрләшмәгән. Шәмсиргә булышу ниятеннән ул Варшау татарларының сугышка кадәр Карова урамындагы бер мәктәптә төштән соң мөселман балаларын укытуны оештыруларын, шунда дин сабагын Идел буе мөһажирләреннән Гали Гамбәрев, татар теле һәм тарихын Гаяз Исхакый укытуын искә алды. Димәк, татарлар Варшауда күбрәк шул тирәдә яшәгән. Шәһәр читендәге Повонзка мәхәлләсендә Татар урамы, шунда мөселман зираты да бар икән—бәлки, ул тирәдә яшәүчеләр жирле татарларның хәзерге әхвәлен беләләрдер? Саны ике йөзгә дә тулмаган Варшау татарларын гына түгел, полякларны да сугыш зир-зәбәр китергән, күпләре башкаланы дошманнан саклаганда һәлак булган. Шәһәргә Көнбатыш өлкәләрдән—Рейх үзенеке дип игълан иткән жирләрдән куып чыгарылган халык килеп сыенган. Монда хәзер милләттәшләрне эзләп табу салам эскертеннән энә эзләүгә тиң иде.

Адреста күрсәтелгән урында Шәмсирне җимерек түбәле корымланган кирпеч диварлар гына каршы алды. Янәшәдәге берничә йорт та хәрабә хәлендә. Ул беренче төзек йортның ишеген шакырга мәҗбүр булды.

Тавышка килеп чыккан карчык, каршысында алман офицерын күргәч, имәнеп китте.

—Курыкмагыз, пани, мин Сездән күршеләрегез хакында гына сорашмакчымын.

Анын полякча катыш урысча эндәшүе карчыкны тагын да гаҗәпләндерә төште бугай.

—Пани, Сезнең күршегездә Муса Бәйрәшевский яшәгән. Ул хәзер исәнме? Кайда икән?

—Мин... мин берни белмим,—диде карчык аптырап.

Ул арада анын артында таякка таянган карт та күренде. Карчык аңа тиз-тиз аңлатканда, карт Шәмсирне баштанаяк күздән кичереп, урамга да караштыргалап алды. Ниһаять, ул да телгә килде:

—Әйе, без берни дә белмибез.

Аларнын ишекне ябарга җыенуларын күреп, Шәмсир фуражкасын салды:

—Күрәсезме, мин алманга бөтенләй охшамаганмын. Курыкмагыз, мин татар. Миңа Муса Бәйрәшевский кирәк. Ягъни пан Мацей.

Ире ишарәләгәч, карчык эчкә чигенде, карт исә урамга чыгып басты да, тирә-якка янә бер күз салып алгач, тынычлыгын бозган офицерга төбәлде. Шәмсир сигарет кабызды һәм картка да тәкъдим итте. Карт баш тартмады, Шәмсир зажигалкасыннан кабызып, тирән итеп суырып, төтенне эченә йотты.

—Москальме?

—Русиядән, әмма москаль түгел.

—Без үз татарларыбызны беләбез: алар москальләргә дә, алманнарга да хезмәт итмәде.

Карт ят офицер бакчасына үзенчә таш атып маташа иде. Аны өркетүдән сакланып, Шәмсир исе китмәгән сыман тартуын белде. Ләкин карт та сүзен ары табан озайтырга ашыкмады. Шәмсир, төпчеген жиргә ташлап, үкчәсе белән аны изгәч кенә, хәрабәләргә баш кагып:

—Күптән яндылармы?—диде.

—Утыз тугызынчы елның сентябрендә.

—Мацей Бәйрәшевский исән калдымы?

—Әйе.

—Хәзер кайда икән ул?

—Белмим.—Карт тагын бер мәртәбә Шәмсиргә күз салды да өстәде:—Поляклар белмәс инде аны. Ике улы Татар эскадронында иде анын. Ә бу эскадрон Польша гаскәрләре арасында дошманга иң соңгылар исәбендә әсир төште. Кораллары бетеп, ярты эскадрон һәлак булгач кына. Моны поляклар оныта аламыни?

—Мин Польша татарларына зыян китерергә җыенмыйм,—диде Шәмсир.—Мин аларга Берлин мулласының сәламен генә тапшырмакчы идем. Үтенде.

Анын алман офицеры киемендә килүе гәпнең шулай кыска тәмамлануына сәбәп булды. Карт башка авыз ачмады. Ирексездән Карова урамындагы мәктәпне эзләп китәргә туры килде. Тик бу мәктәп хәзер алман гаскәре казармасына әйләндерелгән булып чыкты. Өметен өзмәстән, ул шул тирәдә яшәүчеләрдән татарлар турында сорашып йөрде. Әмма шәһәр жирендә кем кемне белсен соң? Бәлки, белгәч тә дөресен әйтергә теләмәгәннәрдер. Күпләр аңа сагаеп кына колак салды. Бары бер өйдә генә Маршалковская урамына аркылы бер тыкрыкта ниндидер бер татарның чәчтарашханә ачканлыгын хәтерләделәр, ләкин анын төгәл адресын әйтә алмадылар.

Суга батучы саламга ябышкандай, Шәмсир шәһәрнең үзәк урамы саналган Маршалковскаяга килеп, шунын якын-тирәсендәге парикмахерскийларга күз салгалап узды, тик ул аларны жентекләп тикшерергә базмады. Арган да иде бугай, шунлыктанмы, ул аларның берсендә тукталып, бераз ял итәргә, шунда чәчен дә алдырырга булды. Тукталыр өчен исеме

мәзәк тоелган «Пани Муха салоны»н сайлап алды ул.

Пани Васи Муха,—аның тулы исеме әнә шулай икән,—җыйнак салонда берүзе эшли иде. Утыз яшьләрендәге ханым бик сөйкемле, конгырт чәчләре дулкын-дулкын булып иненә кадәр төшкән. Кашлары бодай башагыдай калын, әмма бераз китәрелгән, керфекләренә исә сөрмә тартылган. Күзләре елтыр фирүзә. Озынча йөзле, нәфис гәүдәле. Әмма аның аеруча күнелгә яткан сыйфаты—туктаусыз хәрәкәттә булуы, кайчысының һәнүз көмеш тарак өстендә биеп, чыңгылдап торуында иде.

Шәмсир килеп кергәндә ул бер өлкән абзыйның чәчен ала иде. Ягымлы елмаеп, артындагы кәнәфиләрнең берсенә ишарәләп, Шәмсиргә аз гына көтеп утырырга тәкъдим итте. Аны матурларга керешкәч:

—Һерр оберст, Сезнең чәчегез карга канатыннан да карарак, корыч кылдан да катырак икән,—диде.

Шәмсир горур кыяфәттә:

—Бөтен Рейхта бердәнбер,—дип көлемсерәде.—Арийларның сайланма токымыннан мин.

—Күренеп тора. Мондый элита әһеленә хезмәт күрсәтер өчен кайчы-бритваларны кат-кат кайрарга туры килә.

—Кайгырмагыз, Скандинавия тулысынча Рейх биләмәсенә әверелгәч, мин Сезгә швед машинкасы бүләк итәрмен.

—Рәхмәт! Ярый ла инде ана кадәр мине онытмасагыз.

—Сезнеме? Беркайчан да!

Пани Васи башын чайкап көлеп җибәрде. Ак халат кигән җыештыручы карт идән себергән җиреннән тамак кырып куйды. Ул, күрәсең, чәчтараш ханымның алман офицерына болай ук якты чырай бирүен өнәми иде. Пани, аны-моны дәшми кайчысын уйната башлады, көмеш тарагы чәчләрне аралады, ә Шәмсир аның ачык изүенә төбәлде, күкрәк йомрылары иненә кагылып киткәндә тәне кымырҗып, күн кәнәфигә сеңеп, рәхәтләнеп утырды.

Әнә шулай хушланганнан соң, ул Седльцегә китеп барды, аннары инде бүтән лагерьларда тупланган, төрле җирләргә сибелгән легиончыларны агарту эшенә кереп чумды.

Шәмсир Дрезден янындагы Грайфсвальд шәһәрчегендә уздырылган «Идел-Урал төрек-татарлары корылтае»на да катнашты, шунда килгән вәкилләр белән аралашканда Познаньда тормыш корган Яушев әфәндедән һәм тагын кайберәүләрдән Польша татарлары турында шактый мәгълүмат алды. Шулай да ул Алтын Урда заманында ук Идел буеннан киткән милләттәшләренең ыруын Варшауда очратырмын дип һич тә уйламады.

Варшауга нәүбәттәге сәфәрендә Шәмсир аулакка туры килде—чәчтараш ханым ялгызы гына клиентлар көтеп утыра иде. Кунакны күргәч йөзе яктырып китте.

Шәмсир иплəп кәнәфигә урнашкач, көлемсерәп сорады:

—Ничек анда Скандинавия хәлләре?

Шәмсир аның яхшы хәтерле булуына, аннан да бигрәк, кыю сүз башлавына гаҗәпләнде:

—Сез мине онытмадыгызмыни?

—Бөтен Рейхта бердәнбер кап-кара чәчле алман офицерынмы? Ярамый, әфәндем!

Ханым ак җәймәне аның якасына кыстырып, көмеш тарагы белән кайчысын кулына алды да эшкә керешге.

—Ә Сез—кыю,—диде бераздан Шәмсир.

—Һәркем белән түгел.

—Әллә мин ышанычлы кешегә охшаганмы?

—Сез полякча да сөйләшәсез, димәк, безне дә санга сыйныйсыз. Сез, мөгаен, тагын бүтән телләрне дә беләсездер әле?

—Нигә алай уйлыйсыз?

—Мөгамәләгез зыялы. Маңгай чәчегезне тагын да кыскартыйммы, оберст әфәнде?

—Кирәкмәс. Менә бу юлы Сез дөресен әйтмәдегез.

Пани Васи сораулы карашын аңа төбәп, аз гына артка чигенде.

—Зыялылыкның монда катнашы юк. Шәрекъчәрәк йөз төзелешемә игътибар иттегез дә, монын туган теле алманча түгелдер, дип гөманладыгыз!

Пани Васи елмаеп:

—Сез—психолог,—диде.—Алманнарга кайчандыр һуннар каны кушылган, әмма аларның телен Дойчландта бирәү дә белми шикелле.

—Алманча үзегез дә яхшы сөйләшәсез, димәк, сез дә безне яратасыз?

—Һәй, Рейхта яшә дә яратма, имеш!

Шәмсир көзгедән уяу күзәтеп торды—бу сүзләрне әйткәндә чәчтарашның карашында хәтәр очкыннар кабынып киткәндәй булды, тавышында исә нечкә ирония төсмерләнде. Әмма аның кайчысы бер генә минутка да тынып тормады.

—Оберст әфәнде, мондый кап-кара чәчле егетләр Рейхның кайсы өлкәсендә туып үсә?

—Себердә.

—Себер?.. Сез Московия алманымыни? Ничек инде... Дойчландтан түгелмени сез? Юк-юк, шаяртасыз гынадыр.

Пани Васи, исе киткән төстә, оберстның каршысына чыкты һәм, чәчнең тигез алынуын тикшергән булып, бер мәл аның йөзенә төбәлеп торды. Шәмсир үтә белдекле кыяфәттә:

—Һуннарның бер тармагы шунда яшәп калган булган,—диде.—Хәзер менә тагын алманнарның канын яңартырга килдек.

—Шаяртасыз!

—Себер татары шаяртырга мөмкин, әмма алдашмас...

—Татар? Йә Ходаем, әйтәм аны йөзегез, чыннан да, безнекечә түгел. Әйтәм аны бер күрүдә үк сөйкемле тоелдыгыз. Ләкин бу киемнәрдән...

Шәмсир яхшы хәтерли: беренче тапкыр чәчен алдырганда ул пани Васига мул гына чәйлек калдырып чыккан иде. Биргән бигә яраган, бирмәгән нигә яраган, дигәндәй, юмартлык истә озаграк саклана шул. Хатын-кыз юмарт ирләрне аеруча ярата.

Пани Васи, сүзен өзеп, тагын эшенә тотынды—Шәмсирнең яңакларын, ияген мул итеп сабынлады, бритвасын озын каешка шап-шоп үткенләде дә әрсезләнеп бәреп чыккан кара төкләрне пөхтәләп кырып атты, мыегын китәрде, аннары сөлгесен кайнар суга манчып сыкты да яңакларда калган күбекләрне сөртеп алды, резин грушасын кыскалый-кыскалый бер яшел флаконнан Шәмсирнең чәчләренә һәм йөзенә хушбуй бөркеде, шуннан соң кылдай каты чәчләрне иплəп артка яткырып тагын тарап куйды. Йомшак күбекнең битенә сылануына, аннары үткен бритваның яңаклары буйлап шуыуына, кайнар сөлгенең тиресен сафландырып алуына кинәнеп утырган Шәмсир бу рәхәтлекнең әле озак, бик озак дәвам итүен тели иде.

—Менә хәзер, рыцарь әфәнде, Сез туйга да бара аласыз.

—Рыцарь? Туйга?

—Поляклар татарны рыцарь итеп кенә таный,—диде пани елмаеп, әмма җитди итеп.—Польшада яши башлаган татар хәрбиләре яңа ватанына һәрвакыт тугрылыклы хезмәт иткән. Каһарманнарча!

—Ә Сез күптән чәчтараш булып эшлисезме?

—Нәрсә, әллә начар хезмәт күрсәттемме?

—Мин бик канәгать. Ләкин Сезнең укымышлырак һөнәрегез дә бардыр шикелле тоела.

—Кайдан чыккан фараз ул?—диде пани.

—Сез уңайсызланмагыз, сугыш тормышка күп кенә үзгәрешләр кертте, кайбер һөнәрләр бөтенләй кирәксезгә әйләнде, алар белән тамак туйдырып булмый хәзер.

Шәмсир бу юлы да акчаны муллан түләде—кайтым кирәкмәвен ишарәләде. Пани Васи юмарт офицерның кадерен белеп:

—Бәлки, Сез кайнар каһвә эчәрсез?—дип тәкъдим итте.

—Мөмкин булса.

Хәрбиләр арасында поляк хатын-кызларының гыйшык уенына һәвәслеге, юмартлыгы, хәтта башка милләт ирләре белән чуалудан да баш тартмаулары хакында әллә нинди әкәмәт мәзәкләр сөйләнә иде. Янәсе, атасы унжиде яшьлек кызын: «Ул сине үбә башлагач, син нигә берәүне дә ярдәмгә чакырмадың?»—дип шелтәләгән икән. «Ул мина янады. Хәзер кычкырсаң, мин сине бүтән беркайчан да үпмәячәкмен, диде»,—дип акланган имеш, кызый.

Бу мәзәккә икенчесе ялгана. Ике дус кыз очрашкан. Үзара сөйләшәләр ди болар: «Сине кияүгә чыккан диләр». «Әйе». «Йә, ничек, яхшы булдымы?» «Юк ла, яхшырак түгел, ешрак кына!»

Солдатлар арасында мондый гәпләрнең телдән төшмәве, хыялый дәрәҗәләргә житүе табигый кабул ителә. Вакыт-вакыт Шәмсир дә күнелле типтереп алу хакында хыяллангалады. Әмма, тумыштан тәвәккәл булса да ул нигәдер мондый мажарага эләгүдән шушы көнгәчә сакланды. Поляк сылуларының байтагы астыртын милли-азатлык хәрәкәтенә катнашуын, алманнарга илбасар итеп каравын, шунын аркасында кайбер типтерүче офицерларның серле рәвештә югалгалауларын яки коралсыз калуларын белгәнгә генә түгел. Аның монда гыйшык мажаралары эзләмәве инде илдә чакта ук өйләнергә һәм өч баласын сөяргә өлгергән ир булуыннан иде. Хәзер инде ватанга кайтасы юллар киселгән, газизләре белән кавышу ихтималы тәмам юкка чыккан, монда типтерү хакында гына түгел, яңа оя кору турында да уйларга мөмкин иде. Бигрәк тә бу гарасатның ахыры якынлашуы чамалана башлаганда. Хәрби әсирләр лагеренда төп максат жан саклау булса, Шәмсирнең аннан котылуына һәм иреклe легиончы хәленә күчүенә, инде башка исәпләр белән яши башлавына да байтак вакыт үтте. Гәүдәсенә күптән ит кунды, ризыккием яклары шулай ук хәл ителде, кесәсендә хәтта бераз маясы да бар. Аннан да әһәмиятлерәге—ул күп кенә алман солдатлары һәм офицерларының түшенә дә кермәгән кайбер ирекка дә ия. Ара-тирә типтереп алу аның үз ихтыярында. Әмма мона ул һаман базмый—илдә сөеклесенең аңа тугрылык саклавына, балаларын багып, иреннән бер-бер хәбәр килүен зарыгып көтүенә ышана. Хәзер инде ул тормышның кире ялгануы мөмкин түгел, әмма Иртеш дәрьясының аны кочагына алып тирбәткән тыгыз дулкыннары, авылга ишелеп торган тайганың талгын һәм баһадирларча куәтле шавы күнеленнән чыкмый. Балаларының анасы булган кешенең аңа сафлыгы һәм пакьлыгы, чиксез ышаныч белән килеп сыенуы бер генә минутка да йөрәгеннән китми. Хәрби лагерьларның коточкыч пычрагында аунаганда, беткә батып, сасыдан укшып жәфаланганда да, хәтерендә яшәгән әнә шул матур хәят, сүрелмәгән тәэсирләр, назлы күренешләр аңа үзен ару, матур, пакь, яме бозылмаган шикелле хис итәргә көч бирә иде. Әмма шулай күпме яшәргә мөмкин булыр сон? Бу дөньяга ул мәңгегә килмәгән ләбаса, аның сулышы иртәгә яки бүген үк өзелергә дә мөмкин. Артка таба юл ябык икән, ни өчен алга карамаска, киләчәгенә хәзер үк нигез салырга керешмәскә? Моңа форсаты да туып торганда...

Шәмсир, пани Васига ияреп, арткы бүлмәгә керде һәм, ул кухняда мәтавыкланган арада, кызыксынып тирә-ягын караштырды. Юан аяклары борынгы стильдә сырлап ясалган зур өстәл, аның тирәсенә тезелгән биек артлы йомшак урындыклар, фарфор савыт-сабасы, бәллүр вазалары белән күңелле тойгылар уяткан чия төсендәге буфет. Биек тар тәрәзәдән яктылык саранрак кергәнлектән, дивардагы натюрмортны һәм кысалы пыяла астына тезелгән фотоларны яхшылап күрү мөмкин түгел иде. Түрдә тагын бер ишек бар, тик анысы ябык.

Күзләре бераз ияләнә төшкәч, Шәмсир тәрәзә буендагы диварга баскыч-баскыч итеп эшләнгән киштәләрдә тезелеп киткән китапларга да игътибар итте. Якынрак барып, аларның исемнәрен укырга керешә. Юзеф Крашевский, Стефан Жеромский, Генрих Сенкевич—барысы да латин хәрефле күптомлыклар. Соңгысыннан башка исемнәрне беркайчан да

очратканы, ишеткәне юк иде. Кызык ич: бер үк заманда яшиләр, бер үк һаваны сулыйлар, ашаган ашлары, кигән киемнәре охшаш диярлек, ә менә күнел азыклары бөтенләй башка! Шәмсир, касәләрне бер якка этәреп, Жеромский томнарын алды да актара башлады: «Сизиф эше», «Көл», «Тугры елга»—ниләр сурәтләнгән икән бу романнарда? Шушы язучыларның күптомлыклары арасына бер аерым китап—Фридрих Ницше әсәре дә кереп кысылган. Алман телендә. Менә монысын ишеткәне бар—Һитлерне илһамландырган фәлсәфәче, фашистларның яраткан галиме, дип таныттулары хәтерендә. Гаҗәп! Чү, аның болай актарынуын хуҗа ханым, мөгаен, өнәмәс, тизрәк куйсын әле Шәмсир бу китапларны урынына.

Буы бөркелеп торган каһвә алып кергән пани, ак халатын салып ташлагач, рәсми эш кыяфәтен җуеп, тагын да тансыграк төстә күренде. Көрән йон кулмәгенең кайтармалы киң якасына ак күбәләк сыман брошка кадалган. Билен кысып буып торган пута пани Васиның килешле күкрәген тагын да күзгә бәрелерлек итеп күрсәтә иде хәзер.

—Кызганыч, шикәр тәкъдим итә алмыйм.

—Солдат кайда да солдат ул,—диде Шәмсир, планшетыннан кул яссуы кадәр шоколад чыгарып.—Болай өйдәгечә утырулар онытылып беткән иде инде, кунак итүегезгә рәхмәт!

—Кунак итүемә? Бу йоланы онытып бетердек шул инде без. Әгәр сугыш мәхшәренә кадәр килгән булсагыз, күрер идегез менә.

—Хезмәтче картыгыз безнең килүгә хәзер дә бик сөенми бугай әле.

—Сезгә шулай тоеламыни?—диде, сагая төшүе йөзендә чагылган пани.—Әтием мундирыгызга карап кына хәвефләнә ич ул, кызына бәйләнә күрмәсеннәр, дип пошына.

—Сез кияүдә түгелмени?

—Аны белүдән берәр нәрсә үзгәрәме соң?

—Туй хакында үзегез сүз кузгаткач кына соравым.

Шәмсир, рөхсәт алып сигаретын кабызды. Кайнар каһвәне вак-вак кына йоткалаганда, алар гел бер-берсен күзәттеләр. Пани итәгатьле илтифат күрсәткәндәй генә итеп:

—Бәлки, Сез туган телегездә дә берничә сүз әйтерсез?—диде.

—«Сез—бик серле ханым. Дуслаша алырбызмы икән?» Анлашылдымы?

Йөзе яктырыбрак киткән пани, башын чайкап:

—Анламадым, әмма Сезнең миңа татарча эндәшүегез бик-бик кызык,—диде.—Шундый әфәнде чынлап та бөтен Скандинавияне Рейхка кертмәкчеме?

—Бәлки, Сезнең кебек сылуга сәясәт белән артык кызыксыну кирәкмидер дә?

—Гафу итегез, мин әле сездән швед машинкасын көтәм ич.

—Булыр. Әмма әүвәл Уралга барып җитәсе бар әле. Аннары—Себергә.

—Нинди еракка! Туган ягыгызны Өченче Рейхка кертергә ашкынуыгызның серен ачмассызмы икән?

—Коммунизм бацилласын сытарга кирәк, пани.

—Ә Скандинавия? Анда да шундый бацилла бармы?

Пани кунакка артыгракны ычкындыруын сизде, тик соң иде инде. Обер-лейтенантның тышкы кыяфәте белән һитлерчеләрнең арий билгеләмәләренә туры килеп җитмәве—ак йөзле, әмма кысыграк күзле, чәче, сакал-мыекларының сумаладан да карарак булуы саташтырды бугай аны. Ә бәлки офицерның үзен «татар» дип атавы кыюландыргандыр?! Ышанмаслык түгел, кыяфәте дә, үзен гайрәтле тотышы да, туган телен белүе дә татарлыгына дәлил. Фашистларның хәрби әсирләрдән милли легионнар оештыруы да билгеле—бу турыда газитләрдә дә язылды, радиодан да сөйләп торалар. Димәк, бу офицер да шул легионнан булырга тиеш. Ләкин кичәге хәрби әсирнең Рейхка шулкадәр бирелүен ничек анларга? Швецияне басып алырга хәтта фюрер үзе дә базмый бугай ич

әле. Нәрсә, юри үртиме ул Васины, аны сынап маташамы әллә бу обер-лейтенант? Аның полякча да сөйләшүе алманнарга гына табынучы түгеллеген раслый торган билге ләбаса. Әйе, бу әфәнде, тулаем алганда, чын табышмак, кызыксындыра да, шомландыра да.

—Шведлар—алманнарның кардәше,—диде офицер, ниһаять.—Кардәшләрнең бергәрәк булуы яхшы.

—Поляклар, иң зур зыянны кардәштән күрдек, дип саный.

—Кемне күздә тотуыгызны аңлыйм. Ләкин алманнар—башка, алар мәдәниятле халык. Менә Берлингә кунакка килегез әле, күрерсез. Безгә үзара якыннанрак танышу, дуслашу зыян итмәс.

—Сезгә анда парикмахер кирәкме, хатын-кызмы?

—Берлин бай, анда бернигә дә аптырамыйлар, пани. Остарбайтерлар арасында поляк чибәрләре дә аз түгел. Тик минем алар белән танышлык эзләгәнем генә булмады. Мин Сезне аздыру өчен хәйлә кормыйм.

—Кызык.

—Мин кызлардан куркам да бугай әле. Ә менә Сезнең белән танышлыкны дәвам итәсем килә.

—Мин башкаларга бөтенләй охшамаган өченме?

Йә Хода, мәхәббәттә аңлашу кайда да бер төслерәк, ахры! Шәмсир пани Васиның үртәвенә җавап бирмәскә тырышып, сүзне икенчегә күчерде:

—Бу китаплар Сезнекеме?

—Өлешчә.

—Укымышлы булуыгыз күренеп тора. Мин үзем дә сугышка кадәр мөгаллим идем. Ләкин Сездәге китапларның берсен дә укыганым булмады. Авторларын да белмим. Бөтенләй!

Пани кунагыннан күзен алмастан, төтен алкаларын очыруын дәвам итте. Аннары хуҗага аз сүзлелек килешеп бетмәвен ваемлапмы:

—Бу бик табигый хәл,—дип җавап бирде.—Поляк язучылары ич алар.

—Ницше дәме?

—Аның бабалары поляк.

—Һитлерчеләр табына торган Ницше шулмы инде?

—Шул. Ләкин ул күпьяклы фикер иясе, аннан һәркем үзенә юаныч таба ала.

—Кызык.

Пани Васи сүзен кабатлавын сизеп алган Шәмсир көлемсерәп куйды, аннары кулын хуҗа ханымның урындык аркасына салып:

—Ә мин кемнән юаныч табарга тиеш?—дип сорады.

—Бәлки, Генрих Сенкевичтәндер. Поляк язучысы булса да, татар морзалары нәселеннән ул. Күрәсез, поляк-татар бәйләнешләре дә борынгыдан килә.

—Аларны яңартырга вакыттыр инде. Форсатны ычкындырырга ярамый.

Шәмсир панины җилкәсеннән кочып алды. Әмма хуҗа ханым житез генә аның кочагыннан шуып чыкты да, артык ачуланмыйча гына шелтәләп:

—Һерр обер-лейтенант, мин әле Сезнең исемегезне дә белмим ич,—диде.

Шәмсир түш кесәсеннән куен дәфтәрен чыгарып, аннан бер бит ертып алды да, шуңа бишни карандашы белән исемен һәм адресын язып, кәгазьне панига сузды:

—Эш шуңа гына бәйләнсә, тотыгыз!

Пани, язуны алып укыгач:

—Рәхмәт!—диде.—Шәмсир исеме дә Рейхта бердәнбердер инде?

—Нәкъ шулай.—Аннары кунак, панининың күңеле булсын өчен, тагын өстәде:—Поляклар, татар кебек, авыр язмышлы халык. Ләкин сез әле күтәрелачәксез. Безнең серләребез дә килешер, менә күрерсез.

—О-о! Чәчегез каты булса да, мөгамәләгез йомшак икән.

—Сез каты чәчле арийларга ышаныгыз, пани. Үкенмәссез!

Пани Шәмсиргә күзләрен тутырып карап торды да, җиңел генә кузгалып, китап киштәләре янына килде, аннан калын бер томны алды:

—Бу бүлмәдә әлегә кадәр алман гаскәрие каһвә эчкәне юк иде.

—Ә мин моңа ничек лаек булдым икән?

—Хәзер аңларсыз.

Пани кулына тоткан китабын өстәлгә алып килеп куйды да аның эченнән берничә фото чыгарды. Фотоларның берсеннән сөйкемле кыяфәтле, әмма күзләре Шәрекъ кешесе икәнлеген күрсәтеп торган поляк офицеры карап тора иде. Үткен карашлы, өскә бөтереп куелган нечкә мыеклы. Биленә кылыч таккан. Әмма аның мундирына ай һәм йолдыз да чигелгән иде. Шәмсир әнә шул ай-йолдызга игътибар итеп, калын китапны кулына алгач, күн тышлык эчендәге гарәпчә язуга башта сәерсенеп кенә күз йөгертсә, аннары ашыгып титул битен ачты.

—Коръән?!

—Күргәнегезчә!—диде пани.—Ә бу гайрәтле улан—Сөләйман Муха, Польша гаскәрендәге Татар эскадроны командирларыннан. Татар эскадроны дошман белән куркусыз сугыша-сугыша, Венгрия чигенә кадәр барып җитә. Утлы кораллары беткәндә эскадронны дошманнар чолгап ала.

Тавышында горурлык яңгыраган, керфек очларына исә яшь тамчылары бәреп чыккан панидан Шәмсир: «Ул Сезнең ирегез идеме?»—дип сорарга талпынды, әмма бу сорауның мәгънәсезлеген тоеп, телен тешләде. Шулай да:

—Ул исәнме?—дими булдыра алмады.

—Белмим. Каршылык күрсәтүне Варшава бирелгән көнне генә туктатканнар. Чолганыштан берәмләп чыгарга карар иткәннәр.

—Гафу итегез, ә нигә «Муха?»

—Мөхәммәттән. Мин дә «Василә» ич.

Салонда ишек тавышы ишетелде, ул да түгел, арткы бүлмәгә панинын атасы килеп керде. Ул өстәл янында җәелеп утырган алман офицерына гаҗәпләнеп карап алды да, исәнләшергә дә онытып, кызына төбәлде.

—Кунак татар милләтеннән, полякча да аңлый,—дип искәртергә ашыкты пани.

Карт шуннан соң гына Шәмсир белән кул биреп исәнләште. Чынлыкта бу аларның икенче мәртәбә очрашулары иде.

* * *

«Мюнхен-Вена» автобусы асфальт юлдан җитез йөгерә. Юл Альп таулары итәгеннән уза. Ул әледән-әле тау сыртларына да менә, андый чакларда тәрәзәдән зәңгәр күлләр, бормалы инеш-елгалар күренеп кала. Октябрь ае булганлыктан, урман буйлары гаҗәп матур—биләннәрдәге каштан ябалдашларына алтын йөгертелгән, кайбер агачлар коба-кызыл, кызгылт-сары яфраклары белән күз явын ала. Монда һава искиткеч саф, еракта зәңгәрләнеп күккә ашкан, ак эшләпә кигән тау башлары мәһабәт күренеше белән күңелне алгысыта. Хәтфә чирәмгә кунган бриллиант чык бөртекләре мең төрле нур чәчеп, күзне камаштыра иде. Юлаучыларның байтагы шушы табигатькә хозурланып бара. Тик Шәмсирнең генә анда ваемы юк. Дулкынланудан төнге йокысы качкан иде, хәзер исә автобус тирбәтүеннән ойый башлады.

Мюнхен-Вена юлы аңа таныш дияргә була. Сугыштан соңгы беренче елларда Венага да, Инсбругка да, хәтта тау сукмаклары аша Италиягә дә аяк басты ул. Тамак хакына кырык тартмачы булып сәүдәгәрлеккә дә керешеп карады. Италиядән тәмәке алып кайта, аны Алманиянең төньягына илтеп сата, шуның акчасына азык-төлек юнәтә, ризыкны Бавария, Австрия калаларында берәр нәрсәгә алыштыра. Керем мулдан булмый әлбәттә, кайда да бөлгенлек, кыйммәтчелек. Ачтан үләсең килмәсә, михнәткә дә чыдыйсың икән.

Аңа сәүдәгәрлек кәсебен Әдһәм дусты киңәш итте. Ул үзе тегүчелек белән тамак туйдыра иде. Кереме мулдан түгел, түгелен, шулай да башлангыч капиталны әҗәткә ул биреп торды. Сугышта бер аягын югалтканлыктан, үзе еракка чыгып йөри алмый иде. Шулай да бервакыт ул Шәмсир белән Кильгә барырга риза булды. Шәмсир ул биргән акчага, Альп тауларын кичеп, Италиядән тәмәке алып кайтты. Юл хәтәр, качып-посып, карлы-бозлы тау сукмакларыннан көчкә Мюнхенга кайтып егылды. Әмма тырышлыгы Киль—Һамбург юлында жилгә оча язды. Тәмәкене Һамбургта саттылар. Кильгә барып бер чемодан балык кулга төшерделәр. Ипләп кенә кайту поездына да утырдылар. Әмма бераздан купеларында балык исе аңкый башлады. Анысына гына чыдарлар иде, фанер чемоданнан балык суы идәнгә саркып күлдәвек ясады. Вагон чайкалган көйгә берзаман ул купеның әле бер ягына, әле икенче ягына агып җәелде. Юлдашлары сәерсенеп аяк астына караштыра—пароходта баралармыни! Аптырагач, Һамбургта төшеп калырга булдылар. Шәмсирнең бик тә сыра эчәсе килгән иде, нигә тыелырга?!

Аларның икәүләшеп авыр күтәреп йөгенеп баруы вокзал полициясен шикләндерде, күрәсең, тәртип сакчыларының берсе килеп сорау алырга тотынды.

—Чемоданыгызда нәрсә бар?

Алдашырга җай юк, ачтыруы мөмкин. Шәмсир, икебез дә харап булмыйк, дип Әдһәмгә читкә китәргә ымлады, үзе караңгы чырай белән:

—Балык,—диде.

—Күпме?

—Сыйган кадәр.

—Полиция бүлегенә киттек, әйдә!

Кытлык заманда азыкны болай күмәртәләп җыйнау ярамый иде. Димәк конфискация ясаячаклар, хәбескә алулары да ихтимал. Әдһәмнең капиталын кайтара алмаячак Шәмсир, ач калачаклар! Хәлнең хөртиләнүен уйлап, тораташ булып катты сәүдәгәр.

—Йә, атла, әфәндем!—Шәмсирнең чемоданын калдырып китәргә җыенуын күргәч, полицейский:—Ә йөгеңне кем күтәрә?—диде.

—Минем хәлем бетте.

Полицейский, ачуланып һәм комарланып, чемоданга үзе килеп ябышты, әмма ун адым атлауга, аны җиргә куйды. Бик авыр иде балык, чыдамады закон сакчысы, бераз Шәмсиргә карап торды да кул селтәде:

—Бар, юлыңда бул, күземә башка күренмә!

Полицейскийның ераклашуын күзәтеп торган Әдһәм шундук дусты янына килеп житте. Җиңел сулап, көлешеп, алар Мюнхен поездын көтеп алдылар. Балыкның бер өлешен Шәмсир Венага алып китте. Ул чакта мондый комфортабельле автобуста йөрүне хыялланып та булмый иде—поездга эләксә дә, мең шөкер!

Ничә еллар узгач, менә ул тагын Вена юлында. Бу юлы кияү егетедәй көяз—костюмы менә дигән, туфлие ялтырап тора, галстугы килешле, әле аңа кыяфәте буенча кырыкны да бирерлек түгел. Югыйсә нәкъ кырык икене тутырды ул. Радио аны тәмам аякка бастырды, әмма бәхетлеме соң ул? Вәсилә белән оешып киткән булсалар, күңеле утырган булыр иде. Хәзер инде Шәмсир белми алда ниләр көткәнен. Сер берничә сәгатьтән ачылырга тиеш. Бәлки юкка баш ватканчы, черем итеп алыргадыр?

* * *

Шәмсир Польша башкаласына берничә айдан соң гына килә алды. Җәйнең матур чагы, гөлләр шау чәчәктә иде. Шәмсирнең дә кәефе яхшы, чөнки ул хәзер монда күпмедер дәрәҗәдә үз кеше—пани Васи гаиләсе аны әүвәлге аңлашудан соң якын итеп каршылаячагына икеләнәсе юк.

Кызык: чәчен алдырырга уйласа, пани Васи бу юлы да чәченә кагылып: «А-а, нинди каты!» дип сукранырмы икән? Шәмсир аның болай сукрануын соклану шикеллерәк кабул итә. Җитез хәрәкәтле, ыспай кыяфәтле бу ханым салонына кергән ир-атларга, бигрәк тә алман офицерларына, хуш килерлек бер сүз әйтмичә, салпы якларына салам кыстырмыйча калмый. Гадәттә ул моны зарланган сыман эшли, әмма инде күптән гаиләләреннән аерылган хәрбиләргә пани Вәсиның мондый сукрануы иң төче мактаудан да кадерлерәк тоела. Әгәр мөмкин булса, ул хәрбиләр чәчтараш кәнәфиендә иркәләнеп көне буе да утырырлар иде!

Хәер, аның һәм атасының кем икәнлеген ачыклап аңлашканнан соң, Шәмсир инде Вәсилә ханымга элеккечә чәчтараш итеп кенә карый алмый иде. Чөнки ул сугыш башланганчы университетның алман теле-әдәбияты бүлеген тәмамлаган, аннары нииндидер архивта һәм музейда хезмәт иткән. Аның атасы Муха, ягъни Мөхәммәт әфәнде исә, Польша-Литва татар ир-атларының күпчелеге кебек, ата-бабаларыннан мираска калган вазифага тугрылык саклаган—гаскәри булган. Ул Шәмсир эзләп табарга теләгән Бәйрәшине генә түгел, аның адресын биргән Госман мулланы да күреп белә икән, чөнки хәзрәт заманында Варшауга берничә тапкыр килеп, мондагы мәчеттә намаз укып, дин кардәшләренә вәгазь дә сөйләп киткән. Мөхәммәт әфәнде инде ул чакта ук хәрби хезмәтеннән яше буенча отставкага чыккан булган. Болай аңлашканнан соң, Шәмсирнең инде Бәйрәшине эзләп табу уе да сүнде, чөнки сугыш башлангач Белосток ягындагы утарына китеп төпләнгән ул картны Мөхәммәт әфәнде бик яхшы алыштыра ала иде.

Пани Васи эшен дәвам итәргә дип салонына чыгып киткәч тә, алар әле карт белән озак кына сөйләшеп утырдылар. Мөхәммәт абзый Шәмсирнең кемлеген белгәч, чын-чыннан куанган иде.

—Сезнең бу хәрби формагыз гына өркетә,—диде ул.—Алманнарның Польшага элек-электән китергән зыяны исәпсез-хисапсыз. Минә безнең кияү, ягъни кызым Вәсиләнең ире дә тигезсез сугышта һәлак булды, күрәсең. Алар Татар эскадроны әләмен, документларын һәм коралларын күмеп ятканда чолганышта калганнар. Гади солдатларны инде таратырга өлгергән булганнар, шуларның берсе офицерларының ачы язмышы турында безгә дә хәбәр итте.

—Бәлки алманнар хәрби әсирләргә тимәгәндер?

—Тимәсәләр, дүрт-биш ел дәвамында бер-бер хәбәр килгән булыр иде инде. Фашистлар Татар эскадронының бик каты каршылык күрсәтүенә җенләнгән булган. Ә сез әнә шул дошман ягына чыккансыз.

—Татарга ике як та дошман иде,—диде Шәмсир.—Без ике ут арасына ташландык—артта НКВД гаскәре, алда фашистлар иде. Сугыша-сугыша әсирлеккә эләккәч исә мөмкинлегебез тагын да чикләнде: йә әсирләр лагеренда ачлык-ялангачлыктан кырылырга тиеш идек, йә легионга язылып исән калырга. Без яшь идек, яшисебез килде.

Поляклар да гомер буе ике ут арасында яши,—диде Мөхәммәт абзый.—Башта Тевтон ордены, аннары Пруссия, Германия тынгы бирми, икенче яктан москальләр кысрыклый. Безнең нәсел биш гасырдан артык поляк бәйсезлегенә хезмәт иткән, 1863 елгы күтәрелештә дә алар ягыннан көрәшкән.

Шәмсир, Мөхәммәт әфәндедең горурлык төсмере чагылган сүзләренә колак салып, көенечле төстә:

—Әйтерсең, татарның үз ватаны, үз мәнфәгатьләре булмаган,—диде.

Мөхәммәт абзый тыныч кына искәртте:

—Польша икенче ватаныбызга әйләнде—безнең тәкъдирне Ходай шулай язган, күрәсең.

Шәмсирнең сүгенәсе, Полша бәйсезлегенә хезмәт итүе белән горурланып утырган картны утлы сүзләр белән көйдерәсе килде. Бер нәселнең егерме биш буыны ят халык хакына кан түксен әле! Татар бәйсезлеген менә кемнәр какшаткан икән. Ләкин ул шулай каты бәрелсә,

бу гаиләнең ишекләре үзе өчен ябык булачагын төшенгәнлектән, каты бәрелмәде.

—Кеше ашына катык катып яшәүдән дә ачы язмыш юк. Идел-Урал легионы да шундыйрак хәлдә бүген, ләкин ул бу юлга ватанын урыс коллыгыннан азат итү хакына басты.

Мөхәммәт абзый монын белән килешмәде, өстәлдәге касәләрне бер урыннан икенчегә күчергәләп, кунагын үпкәләтергә теләмичә генә:

—Сез, пан Шәмсир, фюрер вәгъдәсенә чынлап ышанасызмыни?—диде.—Күршесендәге мең еллык тарихка ия дәүләтләрнең бәйсезлеген аяк астына салып таптаганда, әллә кайдагы татарга мөстәкыйль дәүләт корып бирергә ашкынадыр ул, дип уйлыйсызмы? Сезгә большевиклар үзбилгеләнү хокукын вәгъдә иткән иде, нәрсәгә ирештегез сон?

—Вәгъдәләрнең кайберсе үтәлә дә. Поляклар белән финнәр шуннан әйбәт файдаланып калды түгелме?

—Ләкин күп тә үтми, бәйсезлекне саклар өчен, безгә тагын кулга корал алырга туры килде.

—Ә без алай оешырга өлгерә алмый калганбыз инде. Сез әйткәнне татар хәрби әсирләренең дә байтагы кабатлый. Күптән аерылып яшәсәк тә, йөрәкләребез бер рухта тибә, анда бердәй дип әйтерлек уйлар да ярала икән,—диде Шәмсир.—Бүген безнең өчен иң әһәмиятлесе—исән калу, теге яки бу як өчен утка кереп көймәү. Ничек ирешергә шуна? Москальләр дә, Польша җиренә кабат аяк баскач, поляк гаскәрендәге Татар эскадроны каһарманлыгына сокланып, шуңа табынып кына тормаслар ич инде.

—Аларның бер өлешен Хатынь ягында атканнар, калганнарын 1939 елда ук Себергә олактырганнар, имеш,—дип килеште хужа.—Москальләрнен Белосток ягын шул чакта ук тарап чыгуларын да ишеттек.

—Шулай булгач? Бәлки безгә котылу юлын бергәләп эзләргәдер?

—Ничек итеп?

—Тагын да көнбатышкарак күчәргәдер сезгә.

—Алманиягәме?! Утопия бу!

—Мин аннан да арырак илләрне күздә тотам. Идел-Урал легионының байтак өлеше Франция белән Һолландиядә хәзер. Сугыш тиздән тынар, безнең егетләр шунда урнашып калыр. Легиончылар өйләнерлек кызларыбыз үсә—ватаныбызда, аларга юл ябык. Польшадагы татар ирләре сафы да бу мәхшәрдә нык кына сирәкләнгәндер, тол калырга мәҗбүр хатын-кызларыгыз безгә әйбәт пар булыр иде. Без бергә кушылсак, ят мохиттә эреп юкка чыкмас идек. Легиончылар туган телен, милли гореф-гадәтләрен җуймаган, сез динне саклый алгансыз. Ике сынар бер бөтенне тәшкил итәр өчен моннан да әйбәтрәк нигез табуы кыен.

—Миңа сезнең бу ниятләрегез ошый,—диде. Мөхәммәт абзый, шактый уйланып торгач.—Бик кызыклы, ваемлы уйлар. Көтмәгәндә ишеткәнгәме, катлаулы һәм бик күп кенә сораулар уята алар. Карагыз әле, Сез—юл кешесе, хәзер инде мин сезне үземнең кунагым дип саныйм, бәлки Сез ваннада юынып чыгып, ял итәрсез? Без хәзер үк су җылыта алабыз.

—Сезгә мәшәкать ясыйсым килми.

—Менә монысы инде юк мәсьәлә!—диде Мөхәммәт абзый.

Кунагының вакыты барлыгын чамалапмы, ул шунда ук ванна әзерләргә кереште. Инде үзара болай якыная башлагач, Шәмсир азык-төлек кибетенә барып, бераз күчтәнәч алып килергә кузгалды—аның ризыкка дигән юл талоннары җитәрлек иде.

Шәмсирнең үзе һәм пан Мөхәммәт гаиләсе өчен бер бәйрәм ясап аласы килә иде. Варшауда хәзер соң дәрәҗәдә кытлык, Берлин вәкиле заманына күрә бай табын әзерләргә булыша ала. Анын «Идел-Урал» гәзитеннән алган каләм хакы да бар, үзе белгән баерак кибеткә кагылса...

Хәзерге Варшау Шәмсир беренче тапкыр күргән чагына охшамаган иде. Шәһәр үзәгендә җимерек биналар күбәйгән, костел-чиркәүләрне дә җәйге баш күтәрү сугышлары аямаган, бульвар-скверларның да яме-

коты калмаган иде. Әле дә хәтерендә, Шәмсир монда беренче тапкыр аяк басканда, күпер култыксасына таянып, шәһәрне ярып аккан Висла дәрьясын тамаша кылган иде. Ул шунда үзен табигатьнең бер өлеше, мәңгелекнең бер тузан бөртеге итеп тоеп, онытылып басып торды. Тузан бөртеге генә, әмма син бар, син тере, хәтта тамырларында мәңгелек хәрәкәтнең тибеше дәвам итә. Елга агымына төбәлеп карап торсаң, Варшауның Понятовский күперендә икәнеңне онытып, үзеңне Иртеш дәрьясының акчарлагы кебек, туган Себереңкинлегендә канат какмый гына һавада гизгәндәй бер хис кичерә башлыйсың икән. Агымсу тылсымы! Менә шул рәхәтне тоярга форсат тудырганы өчен Вислага рәхмәт укуың да бик урынлы.

Шәмсир Маршалковская урамындагы гастрономнан мул гына итеп кабымлыклар, шнапс, сыра һәм татлы сутлар алып, пани Васи салонына бик булдыклы кеше кыяфәтендә кайтып керде. Ванна инде әзер, Мөхәммәт абзый ана сөлге һәм хәтта ару эчке киемнәр дә элеп куйган иде. Чәч алдырганнан соң юынырга яраткан Шәмсир ваннада рәхәтләнеп чупырдады, үзе эченнән язмыш сәерлегенә гаҗәпләнүдән туктамады. Кызык ич: бер халык балалары, әмма төрле дәүләт илдәшләре алар, туган телләре дә үзгә, шулай да якынлыклары, туганлык тойгысы сүрелмәгән әле. Үлмәсә дә үлми икән милли хис!

Ул кызарынып, пакъланып ваннадан чыкканда Вәсилә ханым инде табын әзерләп йөри, аның атасы исә ниндидер кәгазь төргәген актара иде.

—Юындыгызмы?—дип каршы алды ул кунагын.—Бик яхшы. Ә мин шәҗәрәбезне барлап куйдым әле. Менә күрегез: Алтын Урда заманыннан ук килә ул.

—Һай,—диде Шәмсир, чыннан да гаҗәпләнеп.—Монда егерме буыннан да күбрәк, ахры.

Хуҗа аерым бер горурлык белән:

—Әйе, безнең тамырларда атаклы Идегәй әмирнең каны да ага,—диде.—Кайбер башка тарихи затлар белән дә кардәшлегебез бар.

—Безнең әти борынгы бабалары белән шулай мактанырга ярата,—диде Вәсилә ханым.—Сез аны, Шәмсир әфәнде, гаеп итә күрмәгез инде.

—Бу ни дигән сүз?—дип тавышын күтәрде атасы.—Моның өчен гафу үтенәләр димени?

Шәмсир шундук картны яклап сүзгә кушылды:

—Нәсел жебен барлау—өлкән буынның изге бурычы. Адәм баласы җил иркендәге тузан бөртеге генә түгел. Бу шәҗәрә нәкъ менә шуны күрсәтә дә инде. Аны тулыландыра барып саклавыгыз өчен рәхмәт!

Шәмсир бу шәҗәрәдән үзен аеруча кызыксындырган сораугa да җавап тапты—анда Мөхәммәт абзыйның өч оныгы, шул исәптән, Вәсиләнең алты яшьлек улы да теркәлгән иде.

Өстәл янына утыргач, табынга шнапсның куелмавына игътибар итте Шәмсир. Ул да түгел, хуҗа карт, үзенең хак мөселман икәнлеген раслар өченме, әллә инде күптән гадәтенә кергәнлектәнме, дога укырга тотынды:

—Әшһәдү әнлә илаһә илләл лаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһ...

Карт доганы бераз полякча акцент белән, әмма һичбер кыланусыз, тиз-тиз укыды, «Амин!» дип битен сыпыргач:

—Димәк, Сез Себердән?—дип сорады.

—Себердән.

—Әмма Алманиягә кадәр килеп җитеп, гаҗәпләнерлек дәрәҗәгә ирешкәнсез.

—Сталин карашы буенча, мин—хаин. Ике алман полкына каршы без бер батальон гына сугыштык. Командирыбыз яралангач, мин лейтенант башым белән аның вазифасын үз өстемә алдым. Ашарга юк, корал житешми иде. Туктаусыз яуган бомба, снарядлар астында көне буе биреш-

мәскә тырыштык. Аннары яраланып, анымны җуйганмын. Әсирлеккә мин менә шул хәлемдә эләккәнмен.

Хуҗа кызыксынгач, аңа сугышка кадәрге тормышын да искә алырга туры килде.

—Илдәге якыннарыгыз сезнең легионга язылуны хуплармы соң?— диде карт.

—Белмим. Урыс агай башкалар кулы белән утлы күмер чүпләргә остарды. Халкыбызны әсир иткән кавемгә без кайчанга кадәр корал булырга тиеш соң? Моннан баш тартып, без кемгә зарар китерәбез икән?

—Әгәр поляк халкына да зыян салмау әмәлен тапсагыз...

—Тырышабыз, ләкин бу бик тә катлаулы, кыен эш,—диде Шәмсир.— Татар легионының бер взводы Познаньда Искәндәр Яушев фабрикасын саклый. Шунда поляк эшчеләренең ниндидер гөнаһлары ачылган. Безгә шуларны кыйнарга кушканнар иде. Катгый рәвештә баш тарттык.

—Тик анда поляк эшчеләрен атканнар,—диде карт.—Аларны кулга алуда легиончылар да катнашкан, имеш.

Хуҗаның гадәттән тыш хәбәрдарлыгы Шәмсир игътибарыннан читтә калмады.

—Әйе, булды андый хәл,—диде ул.—Ләкин пулемет детальләрен урлаганда тотылган поляк эшчеләре белән бергә, аларга бу җинаятьне кылуда булышкан каравылчылар—ике татар легиончысы да атып үтерелде. Поляклар моны беләме икән?

—Белә.

—Сугыш вакытында гаеплегә җәза каты. Алманнар өчен үз иминлекләре кыйммәт.

—Җәза каты гына түгел, артык рәхимсез,—диде карт.—Үз өеңдә үзе хуҗа була алмаган кешенең язмышы аяныч.

—Үз өеңнән еракта яшәү дә ансат түгел. Ярый ла сез монда күнегеп беткәнсез.

—Күнектек шул. Полякларның безгә мөнәсәбәте москальләрнекеннән нык аерыла. Динебезне тотуда да, үз милли җәмгыятьләребезне, хәтта, үз милли гаскәребезне булдыруда да тулы ирек куела. Безгә монда ышанып, хәтта хөрмәт белән карыйлар. Польша хөкүмәте яна мөһаҗирләргә дә һичбер ил күрсәтмәгән ярдәмне бирергә тырышты. Исхакый әфәндегә «Милли юл» журналын чыгаруда матди ярдәмен кызганмады.

—Ә Сез Гаяз Исхакыйны таный идегезме?

—Әйе. Без Шәрекъне өйрәнү институты залында уздырылган татар кичәләрендә, ара-тирә мәчеттә җомга намазларында очрашкалый идек. Хөрмәтле язучыбыз Сез утырган урындыкта утырып, бервакыт бездә сыйланып та киткән иде.

—Ышанасы да килми!—диде Шәмсир, таң калып.

—Хөрмәтле Исхакый әфәнде Василәнең Шәрекъ телләрен өйрәнмәвенә кәефсезләнә иде. Аның бездә бер китабы да саклана ич, кызым?

Пани җиңел генә урыныннан торып, күрше бүлмәдән бер кечкенә брошюра алып чыкты. Язучының 1938 елда Варшауда поляк телендә басылган «Идел-Урал» әсәре иде бу. Титул битендә авторның Мөхәммәт әфәндегә атап язган багышлавы да бар иде. Шәмсир аны аеруча игътибар белән укыды.

—Гаҗәп!—диде ул, күңеле нечкәреп.—Татар кайда тамыр җибәрмәгән дә кая килеп башын ормаган. Иң мөшкел хәлендә дә кемлеген онытмаган ул. Мондый халык юкка чыга алмый, ул мәңге-мәңге яшәргә тиеш!

—Исхакый әфәнде дә безгә шул хакта сөйләгән иде,—диде Василәханым.—Безне һәрчак бергә булырга өндәгән иде. Исәнме икән ул хәзер?

—Исән. Аның теләкләрен онытмасак, гомере озын булыр.

Шәмсир сәгатенә карап алды: юлга чыгар вакыты якынлаша. Көтмәгәндә шулкадәр үз булып киткән кешеләрдән тиз генә аерыласы килмәгәнлектән, әле күп нәрсә, иң кирәге дә әйтелмәгән сыман тоелды

аңа. Бигрәк тә Вәсилә ханымга. Кайдан килгән аңа Себер күлләрен хәтерләткән зәңгәр күзләр? Себер карагайларыныкыдай зифа буй? Себергә юл ябык, ул инде Шәмсир өчен, ихтимал, мәңге ачылмас, андагы якыннарын, кадерлеләрен кочагына алып сөю түгел, зарыкканда да һич күрә алмас, «күз карашларым талганчы карыйсым калган икән», дип моңлану, ихтимал бары моңлану гына көтә аны киләчәктә. Әмма үткәнне уйлап кына, аны сагынып кына яшәү—яшәү түгел, газаплы булса да, аны хәтердән җуярга кирәк, юкса тәмам тилереп бетәргә дә мөмкин. Үткәнне бөтенләй онытып бетерү барып чыкмас, ләкин кышкы суыкта куырылган үсемлек язын тамырыннан яңа яшь үсентеләр чыгарган кебек, ул да алдагы гомеренең чәчәкле һәм җимешле булуын кайгыртырга тиеш. Юлында Вәсилә кебек сылулар очраганда ым какмый китеп бару гөнаһ—бу очрашу Ходайның бер шәфкать күрсәтүе ләбаса аңа!

Беркадәр кабатлау булса да, саубуллашыр алдыннан ул тагын Көнбатышка күчерүне телгә алды.

—Русиядә илдәшләр сугышы вакытында аңа һичбер катнашы юк татарлар да күп харап булды,—диде ул.—Авылга аклар керсә, алар үзләренә ошамаган кешеләрне чүпләп алып җәзалады; кызыллар килсә—алар да үзләре дошман санаган җаннарны юк итте. Зирәгрәкләр исә алар кан коя башлаганчы ук илне ташлап китеп отты—тормышын гына түгел, бераз малын да саклап калды. Большевиклар белән фашистлар көрәше тагын да шәфкатьсезрәк, алар инде ниндидер татарны кызганып тормаячак. Без болай да аз, без болай да инде тарихи ватаныбыздан читтә.

Шунда Вәсилә ханым:

—Без хәзер тарихи ватан өчен яттыр инде,—диде. Татар телен җуйганбыз, Польшага исә үз иркебез белән күчеп килгәнбез.

—Булмас,—диде Шәмсир.—Ватанны бирәү дә үз ирке белән мәңгегә ташлап китми. Аны бу фаҗигагә илдәге канлы эчке көрәшләр, гаделсезлекләр, тормышына зур хәвефләр янау мәҗбүр итә.

—Бәлки Сез хаклыдыр да, Польша безнең ата-бабаларыбызны әнә шулай хәвеф туган мәлдә үз кочагына алгандыр. Шунысы хак—бер кабул иткәч, ул инде безне беркайчан да артыксынмаган.

—Тирегез-каныгыз белән поляк җирен ашлагачмы?

Вәсилә ханым Шәмсирнең авырткан җиргә шырпы кыстыруын бөтенләй ишетмәгән шикелле дәвам итте:

—Шунлыктан, хәле кыен чакта Польшаны ташлап китү безгә килешми. Тарихи ватанга булса, әле бер хәл. Әмма анда хәзер москальләр туй итә. Безне башка беркайда да көтмиләр сыман.

—Дөньяда Төркия барлыгын да онытмыйк!—диде кәефе кырылган Шәмсир.—Польша татарлары арасында кяферлектән туйган җаннар юкмыни?

—Ил тыныч чакта Төркиягә китүчеләр булгалады, ләкин ата-бабалары телен оныткан кардәшләребез анда тамыр җибәрә алмый кире борылып кайттылар. Ни әйтсәң дә, без инде берничә гасыр эчендә мондагы шартларга ияләшеп беткәнбез, хәзер инде Шәрекъ гадәтләре һәм тәртипләре безгә ят шикелле.

—Әмма, кызым, Төркиядә яшәп калучылар да бар,—диде Мөхәммәт әфәнде.—Аларның кайберләрен Бәйрәши морза белә, шулай да очраштырырга иде Сезне аның белән. Бәлки, москальләр якынлашкач, Белосток ягында яшәгән кайбер кардәшләребез кебек, ул да Варшауга яки Познань ягына чигенергә уйлыйдыр?

—Мин әле сезгә тагын кагылырмын, эзләп карагыз аны, зинһар, табылмасмы? Абау, минем китәр вакытым да җиткән икән, Вәсилә ханымга әйтәсе сүзләрем дә бетмәде югыйсә.

Болай атап искәрткәч, пани Васи аны озата чыгарга мәҗбүр булды.

Көн инде кичкә авышкан, шулай да урамда җылы, якты иде. Узгынчылар җиңелчә киенгән, әмма алар әлләни күп түгел, урамда хәрбиләр генә еш күзгә чалына—Варшау фронт буе шәһәренә әйләнеп

бара иде, күрәсең. Бу тәэсир шартлап җимерелгән-ишелгән, янган биналарга очраган саен көчәя бара иде. Юлдашының тирә-якны күзәтеп атлавын шәйләгән Вәсилә:

—Тиздән безгә дә тынычрак почмак эзләргә туры килмәгәе әле,—диде.

—Ул чакта мин Сезне ничек эзләп табармын соң?

—Ихтыяҗы туармы икән?

Шәмсир туктап, юлдашын баштанаяк күздән кичерде, аннары һич тә икеләнмәгән төстә:

—Ул инде туды,—диде.—Бүгенге анлашудан соң. Сезнең ирегез тәгаен исән булса, мин бу сүзләрне әйтеп тә тормас идем.

—Ашыгып ялгыша күрмәгез!

—Юк, ашыкмыйм, нәкъ вакытында гына әйтеп калырга телим. Шушындый сылуның минем милләттәшем булуы могҗиза түгелмени? Минем мөмкин кадәр күбрәк татарны мәгънәсез кырылудан коткарасым килә, әмма шул афәттән беренче нәүбәттә Сезне йолып кала алсам, тагын да күнеллерәк булыр иде.

—Сезгә кем, нәрсә комачаулый соң?

Вәсилә аны үртәп елмая, димәк, юлдашы сүзләренә һич тә ачуланмый иде. Моны тоеп кәефе күтәрелгән Шәмсир:

—Комачаулаучылар җирдә генә түгел, күктә дә бар, ахры,—диде.—Кыскасы, минем Сезне һич тә югалтасым килми. Сез шуны анлап, белеп торсагыз иде.

—Шуннан соң нишләргә инде миңа?

—Әгәр бу мәхшәрдән котылып чыгу юлын бергә эзли алмасак, дәһшәтле давыл тынгач табышыр өчен адресларыбызны алмашырга килешик.

—Нинди романтик тәкъдим. Шулай да мин риза, рәхмәт!

—Әйтик, Варшау, Вена, Париж почтамтларына бер-беребез исеменә хәбәр җибәреп торырга. Берничә ел буе!

—Мөмкин.

—Димәк, вәгъдә. Менә хәзер инде мине бүтән озата бармасагыз да була. Мин әле салоныгызга бәлки тагын кагыла алырмын. Бәйрәши әфәнде элемтәгә керсә һәм Сез берәр катгый нияткә килсәгез, хәбәр бирегез. Хәзергә адресымны өстәлегездә язып калдырдым.

Шәмсир Вәсиләнең кулын каты итеп кысты да тәвәккәл адымнар белән вокзалга таба атлап китте. Борылып караса, ул пани Васиның әле бик озак аның ераклашуын күзәтеп торуын абайлаган булыр иде. Ирләр төрле планнар кора, хатын-кыз йөрәгенә өмет очкыннары сала, чәчләрне чәчкә бәйли. Әмма килә бер көн, аны шушылай тыныч кына озатып җибәрәсең дә башка күрешә алмыйсың! Вәсилә ханым мондый хәлнең тагын кабатлануын һич тә теләми иде, шуңа күрә дә бу саубуллашу сүзләрен әйтмәскә тырышты.

* * *

Варшау хәрабәгә әйләнгән иде.

Иртәнге поездан килеп төшкән Шәмсир, шомлы күренешләргә күнегә алмыйча: болай булгач, Вәсилә ханым салонының да исән калуы икеле, дип бик пошынды. Ул исә бүген нәкъ менә шунда Белосток ягыннан килергә тиешле Бәйрәшине көтеп алырга вәгъдәләшкән иде. Кеше аркылы сүз куешканда әле бу салонның исән-аман саклануына исәп иткән иде. Ләкин соңгы көннәрдә Варшау кабат бомбага тотыла башлады, бу юлы инде шәһәргә совет очкычлары ябырылды. Дөрес, хәзер Бәйрәши белән очрашуның да мәгънәсе кимеде сыман—Шәмсир Көнбатышка күчерергә хыялланган Польша татарлары нигездә Белосток тирәсендә яшәгәнлектән, алар инде соңга калдылар, анда инде күптән совет гаскәрләре килеп керде бугай. Һич югы Варшаудагыларны коткара

алсалар гына инде. Әмма монда да тонык күкрәү авазлары ишетелә. Зенит пушкалары бик еш телгә килә, туплар өзлексез гөрселдәп тора. Кемнәр ата—анык кына белерлек тә түгел. Сорашыр иде—поляклар аны алман офицеры киемендә күреп, провакациядән хәвефләнәчәк һәм дәшмәячәк, алманнарга мөрәҗәгать итәр иде—алар да сәерсенеп, җиде бабасын аныкларга тотынулары ихтимал. Курыкканга куш, дигәндәй, обер-лейтенантның йөз чалымнары, бигрәк тә әллә ни камил булмаган алманчасы белән өстәмә мәшәкатьләр чыгарырга мөмкин.

Шәмсир адымнарын кызулатты. Урамнарда машина юллары җинелчә төзәтелгән, хәтта уртадан трамвай хәрәкәте дә ачылган, әмма тротуарлар, скверлар хәрабә хәлендә—балчык, таш-кирпеч өемнәре, ватык машина калдыклары ярылган, ишелгән диварларга сыланып ята.

Очрашуга әле байтак вакыт бар, ашыкмаска да бик мөмкин иде. Трамвайга ул шуның өчен дә утырмады, әмма мәет чыккан йорт шикелле шомлы шәһәргә аяк басу аны дулкынландырганлыктан, тыныч кына атлый алмады. Бәлки, вәгъдәләшкән кешесе килеп җиткәнче Василә ханым салонында, әгәр ул исән-имин икән, күнегелгән гадәте буенча, чәчен кыскартып, сакал-мыегын кырдырып иркәләнә-назлана торыр?..

Октябрь ахырындагы очрашулары әле кичә генә булган кебек хәтерендә. Ләкин Шәмсир кышкы Варшауның күнелгә салкын өрүен, шәһәрдә давыл алдыннан була торган тынлык хөкем сөрүен дә ачык тойды. Хәрабәләргә күмелгән урамнарның әле кайчан гына күзләргә ямь биреп торуына да ышана алмассын—тиз арада дөньяның ничек шулай асты өскә килергә мөмкин? Хәер, нинди тылсым аркасындадыр, Мазовецкий урамына һичбер зыян салынмаган диләр. Ләкин Василә ханым салоны анда түгел иде шул.

Иртәнге сәгать ун тулганда Шәмсир хатта сүз куешкан урынга якынлашты. Варшауда снарядлар шартлый, бомбалар сызгыра, канонада шәһәр кырыеннан тоташ гөрелдәү рәвешендә яңгырап тарала иде. Урам чатыннан элемтә чыбыкларын сузып килүче телефончы ике алман солдаты, аның белән тигезләшкәч:

—Һерр оберст, совет танклары фронт сызыгын өзгән,—дип «сәлам» бирделәр.—Сак булыгыз, поляк хәшәрәтләре баш күтәрмәгәе!

—Беләм. Эшегезне дәвам итегез!

Хәлбуки, ул әле фронт сызыгының бүген дә Варшаудан ике йөз чакрымда узуына һәм анда каты сугышлар баруына исәп итә иде. Алман оборонасы кайчан өзелгән? Шәһәрне дошманга бирмәслек ышанычлы икенче саклану сызыгы әзерләнгәнме? Геббелснең гайрәт чәчүенә алданып, ваемсыз йөри торган заман түгел хәзер. Шәмсир ирексездән билендәге пистолетын капшап карады һәм адымын кызулата төште. Әмма бераздан нәкъ урам уртасында каккан казыктай туктап калды. Пани Васи салоны урынында аны таш-кирпеч өеме—яңа хәрабә генә көтеп тора иде. Аһ!

Йөрәге кысылып куйды Шәмсирнең. Монда фаҗига сагалап тору ихтималын исеннән чыгармаса да, югалту кешене тетрәтә. Ул бит инде монда да үз кешесен булдыруына ышана башлаган иде. Һәм менә жепләр тагын өзелгән.

Ул сәгатенә күз салганда, урамнан үзенә таба бер яшүсмер атлап килүен абайлады. Фетнәчегә охшамаган, коралы да юк шикелле. Шулай да Шәмсир бөтен уяулыгын туплап, үсмернең үзе белән тигезләшүен көтте. Юлаучының култыгына кыстырылган китап ымсындырды аны.

—Пан офицерга Ницше әсәре кирәкмиме?

—Сугыш кызганда нинди китап уку ди ул?

Пароль сүзләре иде бу. Шәмсир карашын яшүсмердән алмастан, хәрабәгә таба баш изәп:

—Бу йортларны кайчан җимерделәр?—диде.

—Ике көн элек.

—Исән калучылар бармы?

—Пани Васиның авылдагы туганнарына киткән чагы булган.

—Ә атасы?

—Белмим. Мин күршеләреннән генә сораштым. Һәлак булучылар хәрабәләр астында ятадыр. Аларны казып чыгарыр мөмкинлек тә юк—шәһәр өзлексез бомбага тотыла.

Яшүсмер Ницше китабын кулына алып, аның уртасына кыстырылган кәгазь кисәгенә ымлады. Шәмсир кәгазьне уч төбенә җәеп укыды—анда пани Васиның яңа адресы язылган иде.

Шул чак урамның аргы башыннан танклар гөрелтесе ишетелде, берничә минуттан алар үзләре дә күренде. Советныкылар! Шәмсир хәлнең болай кискен начарлануына инде үзе күреп ышанырга мәҗбүр калгач, яшүсмерне ашыктырды:

—Сезнең бүтән әйтер сүзегез бармы соң?

—Пан Бәйрәши кичә Варшауны ташлап китте. Сезнең белән килешенгән эшне үтәргә форсат калмавын белдерде. Мондагы татарлар кайсы кая таралышкан, бер өлеше бомбалар астында калып һәлак булган. Шәһәрдә хәтәр.

—Күреп торам.

—Киләчәктә ул Сезнең белән пани Васи аша бәйләнешкә кирәргә тырышыр. Пани күченгән авыл Познань воеводалыгына карый.

—Аңладым, рәхмәт. Син дә татармы?

Әлеге яшүсмер, Шәмсиргә ышанып, нык тавыш белән:

—Әйе!—дип раслады.

—Минем белән бергә шәһәрдән китәргә теләмисеңме?

—Рәхмәт, мин моннан китә алмыйм. Әнием белән сеңлемне карыйсым бар.

—Ярый, бирешмә энем. Сау бул!

Шәмсир житез генә күрше урамга ташланды һәм аннан узып барган трамвайга кузгалам дип торганда гына сикереп менде. Караса, вагон тулы хәрбиләр, барысы да—Польша гаскәре киемендә! Алар кораллы СС офицерына аптырап төбәлгәч, Шәмсир дә эсселе-суыклы булып китте. Димәк, шәһәр алманнар кулыннан ычкынып бара. Секунды белән чарасын күрмәсә, аны кулга алачаклар! Ул, каушап калуын йөзенә чыгармаска тырышып, үзенә тасраеп карап торучыларга елмаеп, полякча эндәште:

—Со паны хце?

«Алман киемендәге поляк икән, үзебезнең шымчы!» Вагондагыларның башына килгән беренче уй шул булды. Чын СС офицерының поляк солдатлары арасында үзен болай иркен тотуына, бигрәк тә полякча сөйләшә белүенә ышана алмый иде алар. Шунлыктан, хәлне аңлаган төсле, баш кактылар. Ул арада трамвай вокзал янына килеп туктады. Шәмсир күз ачып йомганчы вагоннан сикереп төште дә танкларга ышыкланып, саклау сызыгы барлыкка китергән һитлерчеләр тезмәсе арасыннан вокзал алды мәйданы буйлап йөгереп узды һәм төп бина аша елдам гына платформаларга таба юл ярды. Анда исә—качаклар ташкыны. Хәрбиләр, тынгысыз халык—һәммәсе Берлингә китәсе соңгы поездны штурмлап ята. Мәхшәр! Вагоннар шыгрым тулган. Алманнарга хас кырыс тәртип соңгы минутларда тәмам бозылган, совет танкларының шәһәргә бәреп керүе, бигрәк тә, аны чолгап алып, юлны өзеп ташлау ихтималы иң салкын канлы офицерларны да чыгырыннан чыгарган иде. Шәмсир бу тамашага бер күз ташлау белән, котылу әмәлен дөрес чамалады—кырыс, кискен тавыш белән:

—Һерршафтен, контролле! Әфәнделәр, контроль!—дип кычкыра башлады.

СС офицеры киеме һәм боеручан кыяфәт тиешле тәэсирне ясады—кысылыша-кысылыша аңа юл бирделәр. Ул кереп өлгергәч үк диярлек поезд да кузгалып китте, чөнки вагоннарда инде күптән буш урын калмаган, хәтта коридорларда аягүрә баручылар да, шушында эләгү аркасында хәтәр капкыннан котылулары өчен, үзләрен бәхетле санарга мәҗбүр иде. Монда утырып өлгерүенә Шәмсир дә сөенде, билгеле, әмма бу юлы да милләттәшләренә—Польша илдәшләренә булыша алмавына аеруча уфтанды.

Күчерергә иде аларны хәвефсезрәк җиргә—төрле мәмләкәт, төрле халык мәнфәгате өчен кырылмасын иде алар. Әмма бүген Ауропада хәвефсезрәк почмак калдымы соң? Швеция белән Швейцария дә үз иминлекләре өчен дер калтырап тора. Гомумән алганда исә, төрле җирдә миллионлап кырыла адәм баласы. Ватаным дип тә, милләтем дип тә кан түгәләр. Бары без генә кеше арбасына утырганбыз да шуларга койрык булып йөрибез, дип уйлады Шәмсир. Мәгънәсез язмыш!

Сәгать ярымнан Польша башкаласы Совет гаскәрләре һәм СССРда оештырылган Ләх хәрби корпусы кулына күчте. Һитлерчеләр сугыша-сугыша яңа саклану сызыгына чигенде. 1945 елның 17 гыйнвары Икенче Дөнья сугышы тарихында әнә шундый эз калдырды.

Хәер, Шәмсир әле бу көнне узган дип исәпләми иде. Варшауны дошманга калдыру да аның өчен тәмам җиңелүне аңлатмый. Алманиядә сугыша алырлык гаскәр әле һаман бик күп иде. Варшаудан бераз ераклашкач, дошман тырнагына килеп эләгү хәвефе бераз кимегәч, вагондагы саусәламәт хәрби алдагы стансаларда бик тиз коелып бетте—вагон шактый бушады, анда яралылар һәм госпиталь хезмәткәрләре, фронт кирәк-ярагын кайгыртып йөрүче әфәнделәр һәм алманнар белән тыгыз бәйләнештә булган, башкалардан китеп бармаган очракта, больше-виклар НКВДсы тарафыннан җәзага тартылудан курыккан аз санлы поляклар гына калды. Хәзер инде һушларын җыярга өлгергән юлаучылар, вокзалдагы коточкыч ыгы-зыгы, вагонга керү өчен купкан этеш-төртеш, шау-шу, утлы табага салынган борчактай, үрле-кырлы сикеренүләре өчен оялып, тынып калганнар иде. Паника дөрләткән өчен баштан сыйпа-маячакларын яхшы төшенгән хәрбиләр, гестапо шымчыларының һәр тарафта булуын онытмаганлыктан, СС киемендәге обер-лейтенант Шәм-сиргә вагонга кергәч үк урын тәкъдим итәргә ашыктылар, әмма ул купелар бушый төшкәнче басып барды. Моны инде юлаучыларның байтагы хәерлегә юрамады.

Идел-Урал һәм башка милли легионнар җирлегендә аеруча ышанычлы җаннардан төрек СС хәрби берлеге төзү фикере күптән туса да, бу ният нацистларга ошап җитмәгән иде. Ничек инде ул кичәге дошманнардан, җитмәсә, азиатлардан, чын арийлар гына хезмәт итәргә тиешле СС—Schutz Staffelне, ягъни «саклану гаскәре»н тупларга мөмкин? Әйтерсең, СС Һитлернең шәхси иминлеген кайгыртырга тиешле гвардия рәвешендә барлыкка китерелмәгән! Әмма Геббелс уздырган тоталь мобилизациядән соң да фронтлардагы югалтуларны каплап бетерү мөшкеллеге ачыклангач, 1944 ел ахырында фюрернең фикере үзгәрде. Сәяси СС бар—анысына чит дәүләт илдәшләрен, саф арий каныннан яралмаган бәндәләрне, әлбәттә, инде, якын да җибәрергә ярамый. Әмма алман штурм гаскәре үрнәгендә фронт хаҗәтенә махсус төрек ССын оештырып, нигә әле аны Совет гвардиячеләренә каршы тимер калкан итеп файдаланмаска? Ләкин бу эш чамасыз катлаулы, шанлы ССта хезмәт итәргә лаеклы хәрбиләрне эзләп табу бик кыен шөгыль булып чыкты. Төрек ССының Алмания мәнфәгатьләре өчен утка керергә әзерлеген тәэмин итү өчен үгет-нәсихәт эшләрен аеруча ышанычлы затлар алып барырга тиеш. Геббелс белән әңгәмәдән соң Шәмсиргә зур өмет баглаулары билгеле булды—аңа беренчеләрдән СС киемен кию тәкъдим ителде. Беткән баш—беткән, дип, ул моңа ризалыгын бирде. Ватанга кайту юлы барыбер киселгән, бәлки ул яңа сурәттә үзенә һәм милләттәшләренә болай күбрәк һәм яхшырак булыша алыр? Илдә кешечә иректә яшәргә большевиклар мөмкинлек бирмәгән икән, Шәмсиргә аларның дошманнары ягына кушылудан гайре юл калганмыни?

Вагон бушый төшкәч, ул планшеттан карта чыгарып, Польшаның Познань воеводалыгын күздән кичерде—Вәсилә барып сыенган Турек шәһәрчегенең Варшау-Берлин чуен юлы буендагы Коло стансасыннан утыз чакрым чамасы көньяктарак урнашуын чамалады. Юл унаенда диярлек, нигә әле эзләп тапмаска икән Вәсиләне? Фронтка алынганнан соң очраткан бердәнбер сөйкемле, күңеленә ут салган хатын-кыз ич ул. Инде Варшаудан бер купкан икән, бәлки Берлингә күчәргә дә риза булыр? Юкка гына

көнбатышка таба кузгалып, яңа адресын Шәмсиргә сәбәпсез генә хәбәр итәргә тәвәккәлләмәгәндер ич?

Коло стансасына поезд караңгылык куерганда гына килеп житте, әмма монда туктамады, йөрешен генә әкренәйтте. Шәмсир икеләнеп тормады, вагоны перронга тигезләшүгә елдам гына жиргә сикерде. Сөрлекте, ләкин егылмады, станса хезмәткәреннән хәрби комендатураның кайдалыгын белеште дә бик эшлекле төстә шунда юнәлде. Ниятен мөмкин кадәр тизрәк тормышка ашырыр өчен транспорт һәм озата баручылар сорарга иде исәбе. Чынлыкта ана озата баручылар кирәкми, бары үзенә карата шик уятмас өчен генә мөрәжәгать итәргә мәжбүр иде ул.

Аның таныклыгы ышанычлы булуга карамастан, комендант:

—Автомобиль бирә алмыйм, һерр оберст, диде. Бензин юк. Кыенсынмасагыз, атка атланып бара аласыз. Ничә озатучы кирәк булыр?

—Ике автоматчы житәр. Ашыгыч кузгалырга кирәк, иртәгә иртән мин Берлингә кайтып өлгерергә тиешмен.

Юлдашлары Турекка бару юлы белән таныш булганлыктан, Шәмсир өяз шәһәрчегенә мажарасыз гына барып житте. Киче суык түгел, юл такыр иде, ул күрешкәндә Вәсиләне ничек кочаклап алачагын һәм, бик каты сагынуын сиздерер өчен, үбеп тә куячагын күзаллап канатланды. Ләкин очрашу алай ук тантаналы һәм жылы килеп чыкмады. СС офицерының ишек шакуы суда пешкән алмадай жыерчыклы йөзле хужаларны тәшвишкә төшерде. Алар артыннан болдырда күренгән пани Васиның чакырылмаган кунак белән шактый үз итеп күрешүе һәм офицерның кемлеге хакында поляк телендә бер-ике сүз белән аңлатуы тиздән һәммәсен тынычландырды, билгеле, ләкин инде шулкадәр кеше алдында Шәмсир очынып күрешә алмады.

Автоматчылар тышта калды, кунак офицер исә милләттәше артыннан залга кереп утырды. Хужалар аларны аулакта калдыруны хәерле санап, башка бүлмәгә кереп югалдылар. Шәмсир чишенеп тормады, гәүдәсе ябыга, күзләренең зәңгәре уңа төшкәндәй тоелган Вәсиләнең моңайган йөзеннән карашын алмастан:

—Менә шулай, кайда да эзләп табам мин Сезне!—диде.

—Рәхмәт.

—Кайгыгызны уртаклашам. Мин Варшаудан кайтып киләм, барын да күрдем.

—Хәзер бер безнең өй генә түгел, бөтен Ләхстан хәрабә хәлендә.

—Ярый әле үзегез бәлагә тарымаган. Аннары Варшаудан китеп тә дөрес эшләгәнсез. Монда, олы юлдан читтәге кечкенә шәһәрчектә, бәлки, хәвефсезрәк булыр. Хужаларыгыз кемнәр?

—Иремнең коралдаш иптәше ата-аналары. Мин Белосток ягындагы кардәшләремнән аерылып калдым ич инде.

—Бер уйлаганда, бу әйбәт тә. Анда китсәгез, яныгызга барып житә алмас идем. Бу миңа тагын бер газап өстәгән булыр иде. Мин инде бик күпне югалттым, Сездән дә колак кагасым килми.

—Юл талчыктырдымы?

—Борчылмагыз. Монда тартырга мөмкинме?

—Әйе.

Вәсилә өстәлгә яшькелт пыяла көллек китереп куйды. Жиделе лампа бүлмәне начар яктырта, әмма Шәмсиргә ут яктысы күзенә төшкән каләрлесен караштырып утырырга житәрлек иде. Ул сигаретын суыра-суыра, күңеленнән панины ышандырырлык, үз тәкъдименә күндерерлек сүзләр сайлап әвәрәләнде.

—Вәсилә, мин монда озак утыра алмыйм, иртәгә иртән Берлинга кайтып өлгерергә тиешмен. Чамалыйсыңдыр, фронт бик тиз монда да килеп житәр. Әгәр син шушында калсаң, без мәңгегә аерылашачакбыз. Мин моны һич тә теләмим.

—Син, фронт Берлинга барып житмәс, дип уйлыйсыңмы?

—Нишләп инде? Әгәр без бергә булсак, аннан да көнбатышкарак чигенү ягын кайгыртыр идек.

—Мин әле хәзер үк Польшаны ташлап китә алмыйм шул.

—Ни өчен?

—Һаман шул бер сәбәп инде: ирем язмышын белмәгәнгә.

—Минемчә, Польша бәйсезлеге өчен артык үҗәт көрәшкән татар офицерын 1936 елда ук йә һитлерчеләр, йә сталинчылар юк иткәндер. Исән калган булса, җиде ел эчендә бер-бер хәбәрен ишеттергән булыр иде.

—Әгәр ул Себергә олактырылган булса? Аннары СССРда оештырылган поляк корпусына хезмәткә алынса? Совет зонасында калсам, бу тиз арада ачыкланачак ич инде.

—Хыялый икән син,—диде Шәмсир, йөзенә моңаю чыгарып. —Җиде ел узган инде югалтуыңа, җиде ел!

—Ул офицер—бердәнбер улымның атасы да әле. Улым да бүленеп, Белосток ягында калды.

Шәмсир өметләренең сүнә баруын сизеп, сүздән язды. Василә аның күңелсезләнүен тоеп:

—Бәлки, син үзең монда калырсың?—диде.—Фаразың дөрескә чыкса, мин тиздән бары синеке генә булачакмын.

Төпчегән көллеккә басып сүндергәч, Шәмсир ачынган төстә:

—Их, белмисең шул әле син НКВД сунарчыларын,—диде.—Сугыштан соң Польшада алар хуҗа булачак һәм үзләре теләгәнчә кыланачак. Миндәйләрне тотып алып, башта утлы табада кыздырачак алар, аннары җиде кат җир астында черетәчәкләр.

—Син шулкадәр гаеплемени?

—Җаныкаем, мактауга гына лаеклыларны да ватан кайчак үгисетә. Туган илдә бәяләнмәгәнне исә чит илдә күтәреп алырга мөмкиннәр. Аңларга тиешсең ич инде син: бер үк хакыйкать берәүгә—бал да май, икенчегә—агу.

—Мин радио тыңлаштыргалыйм, Мәскәү Польшаның бәйсезлеген тануын белдерә ләбаса. Син полякча сөйләшә аласың, әгәр хәзер үк поляк паспортын да юнәтсәк? Минем фамилиямә дә күчсәң, эзеңне югалтачаксың ич инде, сиңа берәү дә кагыла алмас монда.

—Юк, юк, бөтен кыяфәтем әллә кайдан ләх түгеллегемне кычкырып тора. Иң хәтәр юлга басмыйк, китик хәзер үк Берлингә. Еллар тынычлангач, бергәләп улыңны эзләп табарбыз.

Василә ханым, бу тәкъдимне кире каккандай, сүзсез генә башын чайкады. Бер мәл дәшми-тынмый утырдылар, аннары Шәмсир урыныннан торып, сердәшен кочагына алды.

—Мин бүген соңгы күрешүебез булмагае, дип куркам,—диде ул.—Их, син, каласың лабаса ятларга, сылукаем!

—Шулай инде, мин дә тиктомалдан ватанымны ташлап китә алмыйм.

—«Ватанымны»? Кыз-зы-ык!

—Ничә буын ата-бабам җәсәде шушында ята. Дөнья тынычлангач, хәлләр ачыклангач, бер-беребезне эзләп табышырга вәгъдәләштек түгелме? Ягъни ирем һәлак булган очракта... менә шушы өйдә...

—Син Советларның чик буйларында нинди тимер пәрдәләр корачагын күзалламыйсың шул әле, кадерлем,—диде Шәмсир көенечле төстә.— Социалистик лагерьның төрмәдән аерылмаячагын исеңә дә кертмисең. Шулай, син Варшауда тәмам панига әйләнеп беткәнсең.

Нәрсәне күздә тотып тезде боларны кунак? Татарлыгы какшаганлыгын искәртепме, буржуаз илдә яшәгәнлектән, киләчәктә үзенә большевиклар тарафыннан янаган хәвефне төшенмәвен белдерепме? Василә моны аңлап житкермәде, әмма Шәмсир суырып үпкәндә, һичбер каршылык күрсәтмәде. Төрле уйлардан башы катканлыктан, кунакның өметен акларга теләге дә, кодрәте дә җитмәвен тойганлыктан, хәлсезләнгән иде ул. Аннары, лампасын кулына алып, кунагын болдырга чаклы озата чыкты.

Тышта буран күтәрелгән иде. Шәмсир, сәгатенә карап алгач, күрешүнең егерме минуттан артыкка сузылуын чамалап, юлдашларына юлга кузгалырга боерды. Максатына ирешмәде, ләкин ул үзен тынычлан-дыра ала: киләчәген

кайгыртыр өчен кулыннан килгәнне үтәде. Әйе, ватылган чынаякны җилем белән ябыштырып кына янарту кыен шул. Чыгырыннан чыккан кеше язмышын җайга салу исә бигрәк тә катлаулы эш. Ул шушы хакта уйлый-уйлый, тиешенчә ял итәргә өлгермәгән атын куды да куды. Баксаң, дөрес ашыктырган икән. Чөнки Турек шәһәрчеген-нән ун чакрымлап ераклашкач, урман ышыгындагы хутор турысыннан узганда аларга аттылар, берничә мылтыктан.

Төне дошманга нәкъ менә тозак корыр өчен генә килгән диярсен—буранда эзне яшерү бик ансат. Җайдаклар ике автомат, бер пистолет белән коралланган иде. Ә партизаннар ничәү—монысын эт тә белми. Шушы хакта уйлап алуга, Шәмсир:

—Туктамаска! Шнель!!—дип кенә кычкырды.

Юлдашлары ике әйттермәде, камчыларын уңга-сулга уйнатырга кереште һәм алар тиз арада хутор турысыннан ераклашты. Әмма мылтык-ларның берничә тапкыр телгә килүе буран пәрдәсе аша Шәмсирнең инбашына сәлам бирде. Хәтәр җирдән ераклашкач, алар атларыннан төште, чөнки койрыкта юрткан солдат—тоталь мобилизация җимеше, әле мыегы да тибеп чыгарга өлгермәгән егет хәтәррәк яраланган иде. Яраларны ашык-пошык бәйләделәр дә, уяулыкларын югалтмыйча, алга томырылдылар.

Стансада Шәмсиргә дә тиешле медицина ярдәме күрсәттеләр, обер лейтенант Өченче Рейх мәнфәгатьләрен якларлык хәлдә, аның ярасы госпитальгә салырлык дәрәҗәдә түгел иде.

Берлин поездына утыргач та ул Васил͏ә һәм гомумән Польша татарлары хакында уйланып кайтты. Әйе, алар да татар, ләкин берничә йөз ел дәвамында шул милләттәшләргә күпме ят кан кушылган. Аларны чолгап алган күпчелекнең гореф-гадәтләре, мәдәнияте дә сугарган аларны. Язмышларын кискен үзгәртер өчен, Шәмсир кебек читтән килеп, бер-ике сүз әйтү дә җитәр, дип өметләнү чамасыз беркатлылык, күрәсең. Васиягә үпкәләргә ярамый, ул иренә тугрылык саклавы белән мактауга гына лаек. Шәмсиргә инде насыйп ярны башка җирдән эзләргә туры килер. Ләкин аңа чаклы үз башының исән-иминлеген кайгыртасы бар шул әле. Анысы да җиңел эш түгел. Әйләнәсе, гүя, ут дингезе, аның төне—дары кантары. Хәтәр!

* * *

Вена сугыш яраларыннан әле һаман савыгып бетмәгән иде. Көнчыгыш вокзал хәрабәләрен каштан агачлары куелыгы да каплап бетерә алмый. Әмма изге Стеван чиркәве манарасы, купшы, кин Ринг урамына аерым бер затлылык өстәп торган атаклы опера театры, ярты чакрымга сузылган Бельведер сарае, готика стилендәге башка купшы, затлы биналар исән, аларга караган саен карыйсы килә иде. Кайчандыр матурлыгы белән дан казанган шәһәр әле дә зәңгәр Дунай тасмасы, аллы-гөлле күзгә парклары белән күңелгә хозурлык бирерлек иде. Тик Шәмсир шәһәрнең архитектурасын тамаша кылу белән мавыкмады—алдагы очрашу аны әсәрләндереп, хәтта күңеленә кату салып, дулкынлан-дырып тора иде. Автобусларның төгәл расписание буенча йөргәнлеген белсә дә, ул очрашуга кичегүдән хәвефләнде. Әмма аның пошынуы юкка булып чыкты—Венага вакытлы килеп җитте.

Эшләпә, кара күзлек кигән, кулына кара зонтик кына тоткан Шәмсирне паркта сәйран чигүче веналылардан аерырлык түгел иде. Штадтспаркның Штраус һәйкәле янында гадәттәгечә туристлар кайный. Һәйкәл алдында карт музыйкант аккордеонда композиторның атаклы вальсларын яңгырата, илгизәрләр аны сокланып тыңлап тора иде. Якындагы эскәмияләр тамашачылар белән тулы. Шәмсир тыштан тыныч күренсә дә, эчтән тынгысызланып, таныш ханымны тизрәк күреп алырга тырышты. Үзен ансатрак танытыр өчен кара күзлеген кесәсенә салып куйды. Полякча сөйләшеп килгән туристлар төркеме күренгәч, чәчәк түтәлләре арасыннан һәйкәлгә якынрак килде. Әмма аңа танышын беренче күрү насыйп булмады—

аңа озын аксыл плащ, эшләпәсенә әллә нинди ясалма чәчкә кадаган ханым арттан үзе килеп кагылды. Шәмсир борылуга, ирененә бармак куеп, дәшмәскә кирәклеген ымлады. Пани Васи ишарәсе буенча, алар туристлар төркеменнән бераз читкәрәк кагылдылар. Бары шуннан соң гына ханым:

—Менә мин инде бу!—дип елмайды.

Шәмсир гаҗәпләнде дә, сокланды да.

—Ун ел узмаган да кебек, син... сез һаман сылу, чибәр икән.

—Рәхмәт. Сез дә гаярь кавалер булып калгансыз. Тик мине генә оныттыгыз бугай.

—Оныту мөмкин түгел иде. Әмма тимер пәрдә ихтыярга богау салды. Әле берничә ел элек, Австрия—Совет зонасына кергәндә, монда килүдән дә тыелырга туры килә иде. Мин бит бу хакта теге чакта ук кисәттем. Син ышанмадың гына.

—Хәтерлим. Син хаклы булып чыктың, мин киләчәкне башкача күзаллаган идем.

Шәмсир пани Васины күздән кичереп, аның гәүдәсе бераз тулылана төшүенә игътибар итте. Зәңгәр күзләре бераз монсурак, коңгырт бөдрәләре элеккечә җилкәсенә төшкән икән. Чәчләре бер дә үзгәрмәгән сыман. Ул да вакыт-вакыт Шәмсиргә кызыксынулы карашларын ташлый, туктаусыз елмая:

—Барыбер очраштык ич менә, исән кешеләр бер күрешми калмый.

—Турист булып килдегезме?

—Әйе.

—Мине ничек таба алдың?

—Таныш татарларым аша белдем. Аннары радиодан тавышыңны да ишеттем.

—Сезнекеләр ничек, исәннәрме?

—Исән булсалар, мин монда килмәгән дә булыр идем.

—Син төркемнән аерылып китә аласыңмы?

—Беразга гына. Яки бөтенләйгә.

Шәмсир пани Васины дөрес аңлады һәм күнеле актарылып, ни әйтергә белми, тынып калды. Аннары пани Васины култыклап, аллея буйлап парк түренә таба атлады. Узган еллар агышын хәтерләтеп саргайган яфраклар коела, алар Шәмсирнең сагышын тагын да куерта бара иде. Вак яңгыр сибәләргә кереште, Шәмсир зонтигын ачып, юлдашын чатыр астына алды. Их, узган елларны да кайтарып, аларны шушы кадерле кешесе белән бергә уза алса икән ул! Һич югы биш ел элегрәк очрашсалар икән...

—Йә, үз хәлләреңне сөйлә инде,—диде Вәсилә.—Скандинавияне азат итә алмадың бугай, швед машинкасын да бүләк итмәдең.

—Син хәзер башка эштәдер ич?

—Әйе.

—Ә миңа ул чакта башкача сөйләнергә ярамый иде. Сугыш язмышны меңгә түнтәрде. Кем генә булмадым мин...

—Мин сине бер тапкыр кинода күрдем. «Өйгә табан озын юл» фильмендә. Син тагын башка фильмнәрдә дә уйнадыңмы?

—Юк.

—Нигә?

—Режиссер миңа кияүгә чыгарга теләде. Мин өйләнергә җыенмадым. Шуннан карьерам да өзелде.

Пани Васи гаҗәпләнеп Шәмсиргә төбәлде:

—Шундый кызыктыргыч перспективадан баш тарттыңмы?

—Әйе. Мин Варшаудан хәбәр көтә идем.

Пани Васиның йөзе яктырып китте. Ул Шәмсирнең терсәген кысып, аңа сыланды:

—Ә юллар ябык иде, мин хат язарга да курыктым.

Алар Ринг урамы ягындагы буа буена килеп чыктылар. Монда да тыныч, буада үрдәкләр йөзеп йөри, берничә кызчык аларга ризык ташлап юана иде. Алар баш очында күгәрченнәр очып бөтерелә. Ринг урамында

халык мыж килә, саф-саф тезелешеп машиналар чаба—Венада тормыш агымы елдан-ел җанлана бара иде.

—Берәр кафега кереп утырабызмы?

Пани Васи сәгатенә карады.

—Безнең төркем паркта ярты сәгатьтән артык булмаячак. Без Бельведер сараена картиналар галереясенә барырга тиеш.

Сүз өзелде. Язмышны үзгәртә торган тәкъдимне Шәмсир әйтергә тиеш иде. Әмма аның теле әйләнмәде. Менә бит сабырсызлык нинди хәлгә китереп куйды аны! Тик ул гына гаеплеме соң?

Ул арада җил чыкты, буа өсте шадраланды. Күк йөзендә кургашын болытлар бөтен җилкәннәрен киереп йөзә башлады. Чебердек яңгыр коя, каштаннардан күз яше кебек тамчылар тамарга тотынды. Аяк астында юеш сары яфраклар кыштырдап, Шәмсирне шелтәле төсле тоелды. Башын иеп, юлдашының телгә килүен көтеп атлаган пани Васи:

—Юлга чыкканда сиңа сүзем шул кадәр күп иде кебек,—диде.—Ә хәзер кайдан нәрсәне башларга да белмим.

—Мина хәзер берни әйтмәсәң дә аңлашыла,—диде Шәмсир.—Мин үзем ашыкканмын. Өч ел элек кабат өйләндем. Кызым бар.

Пани Васи аның кулын бушатты. Күтәрелеп йөзенә карады:

—Кемне сайлап алдың инде?

—Ялгызлыктан арыган идем. Минем үземне сайладылар. Гап-гади бер алман хатынына тап булдым. Германиядә башка мөмкинлек табылмады.

—Менә монысын мин синнән һич тә көтмәгән идем.

—Үзем дә...

Пани Васи күңелсезләнеп кире борылды. Шәмсир аңа кулы белән кагылып:

—Мин монда кичкә кадәр кала алам. Теләсәң, сурәт галереясенә бергә барырбыз. Әмма элек Мария Хильферштрасседагы кибетләргә кагылыйк, мин хәзер бай, истәлеккә сиңа ошаган берәр затлы бүләк алырмын,—диде.

—Рәхмәт! Безнең төркем күзенә чалынмавың хәерлерәк булыр, күзәтчеләребез уяу.

Юешләнгән пани Васи хәзер инде сулган гөлне хәтерләтә иде. Шәмсир исә үзен аеруча унайсыз хис итте, аның хәбәре юлдашыннан мәңгегә аера торган хөкем карары кебек булды. Ул, һәйкәлгә таба теләр-теләмәс кенә атлады. Тагын ун адым, тагын йөз адым, аннары мәңгегә аерылышу...

Штраус һәйкәле тирәсендәге туристлар төркеме таралмаган иде әле. Карт музыйкант аккордеонда «Дунай дулкыннары»н яңгырата, вальс моңы бөтен тирә-якка җәелә иде. Кичен монда тынлы оркестр уйный, күктә йолдызлар кабынгач, паркта аеруча хозур, күңелле була, имеш. Тик Шәмсир Венада калса да аннан артык ямь таба алмас иде.

Чөнки пани Васи, аның белән юньләп саубуллашып та тормастан, канаты каерылган коштай, күз алдында боегып һәм үз эченә бикләнеп, чыраен төмсәләндереп, салмак адымнар белән мыштым гына иптәшләренә барып кушылды.

Сугыш күптән тәмамланган, әмма аның яралары Венаның көнбатыш вокзалында гына түгел, Шәмсир белән Вәсилә күңелендә дә мәңге сыкрап, кан елап торачак иде.

2000



## Лена Шагыйрьҗан

### ҮЗ ҖАНЫҢА ҮЗЕҢ ӘНКӘ БУЛСАҢ

**Шагыйрь шәҗәрәсе**

**Юк, бетәчәк түгел безнең токым.
Безнең орлык—рухи, мәдәни…
Шәҗәрәбез безнең бик борынгы,
Һәр тармагы—шигъри, әдәби…**

**Ул агачның тамырлары тирән,
Ябалдашы тигән йолдызга.
Елның елы мул уңышын биргән,
Өлеше тигән һәрбер Ул-Кызга.**

**Халык чишмәсеннән сугарылып,
Тормыш Үзәнендә үскән ул.
Үзәге нык, ботаклары яшел,
Күтәрелгән һаман өскә ул.**

**Бизи безнең нәсел шәҗәрәсен
Колгалиләр, Мөхәммәдъярлар.
Саклар шанлы Шигырь дәрәҗәсен
Гасырлардан калган ядкарьләр.**

---

Лена ШАГЫЙРЬҖАН—*шагыйрә, «Мөлдерәмә күңел» (1982), «Ышанам йөрәгемә» (1986), «Иман әлифбасы» (1993), «Шигырьләр һәм поэма» (1997), «Канатлы ат» (2000) һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Һәммәсен дә санап тормыйм бүген:
Халык үзе белә, яд итә.
Бер яфрагын ачып укысаң да,
Җан яктырып китә, ялт итә...

Мин дә бер җимеше шул агачның,
Буыны бер—җырлы зынҗырның.
Минем орлыгым да тезелер җепкә,
Бер бөртеге булып зур Җырның...

Үкенмим лә, юк дәвамым диеп
Таянырлык—җисми, бәдәни:
Бөреләнер шытып яшь күңелдә—
Безнең орлык—рухи, мәдәни...

Кемнәрдән мин алсам иҗат нурын,
Телим шуңар оҗмах әҗерен.
Тукай, Такташ, Җәлил, Хәким, Туфан—
Менә шулар,
Шулар минем шигъри шәҗәрәм!

*2000*

## Тәрәзәдәге пейзаж

...Тәрәз кысасында—түгәрәк Ай,
Гүя затлы нәфис картинадай...
Өйгә кергән кышның айлы киче,
Катып калдым күреп, ләззәт кичеп...

Күзләремә баккан айлы урам,
Күргәзмәгә килгән кебек торам:
Чын сәнгать ич—килгән бөтен яктан,
Буяулары ничек тигез яткан!..

Соклanудан, күз дә алмыйм Айдан,
Бу сурәткә калып тәмам хәйран.
Ясап куйган мәллә оста рәссам?!
Сүзең җитмәс, шигырь итеп язсаң...

Тәрәз өлгесенә сыеп кына,
Кышның гүзәллеген җыеп кына,
Үз урамым танымаслык булып,
Карап тора миңа оеп кына...

Тас кадәрле булып тулган Аем,
Күрсәң икән килеп, туганаем!
Бер Ходайның серле дәвамыдай,
Күзгә күренеп торды Тәңрем бугай...

Ай күрдем лә, шөкер, аман белән,
Җаным, рухым тулсын иман белән.
Ай нурында юдым бит-йөземне,
Ай күк балкып торсын диеп, гелән...

*1997*

## Сөрелгән

Мин—күктән дә сөрелмәгән,
мин—Җирдән дә сөрелмәгән,
мин—Илдән дә сөрелмәгән,
ләкин мин дә—сөргендә...
Мин—Хыялдан сөрелгәнмен,
инде бүре базында
кыш үткәрәм...
Үлгән минем
җәйләрем дә, язым да...
Качып китәм, дигән чакта,
эләктереп алдылар да,
«качып китү—ирек ул», дип,
җаныма богау салдылар ла...
«Үз-үзеңә биклән, әнә,
үз-үзеңнән шиклән, әнә,
тимер-бетон хөҗрәңдә кал,—
шуның белән чиклән, әнә!..»
Кая качмак идем соң мин?!
Юк ич тылым-арьягым да...
Менеп җитсәм тау башына—
кадап куяр байрагым да...
Мин сөрелдем хыяллардан,
мин сөрелдем—әкияттән,
Мин сөрелдем—Мәхәббәттән
һәм үз-үземнән, әлбәттә...
Мин качарга тиеш идем,
мин ачарга тиеш идем
могҗизалы тау тишеген,
бәхетемнең үз ишеген...
Чикләвек төше шикелле,
үз-үземә бикләнгән мин.
Кабыгы каты—юк ватучы,
шул ояда мүкләнгән мин.
Шул ояда йоклаганда,
пәһлеван керде төшемә:
җыена, имеш, ватарга,
куеп мине урт тешенә...

*1996*

## «Мәхәббәт романы»

«Мәхәббәт романы» укып ятам,
(Сагындырган, каһәр, юксындырган.)—
Яшүсмер кыз кебек, сулышым кабып,
Шуннан кызык нәрсә юктыр сыман...

Искә төште тансык, таныш хисләр,
Сусаганымны да онытканмын.
Кулдан төшермичә, йотылып укыйм,
Әйтерсең лә, асыл кош тотканмын.

Гыйшык тоткан кыз күк хыялланып,
Роман укыйм, юкка гына мәллә?—
Үз-үземнән кинаялап көләм:
Мәхәббәтсез тормыш—тозсыз әлбә...

Минем дә бит берчак мәхәббәтем
Чәчәк аткан иде гөлбакчамда.
Ул гөлчәчәк корый икән бер көн,
Сулар сибеп кенә гел баксаң да...

Кая китә икән ул серле кош?
Әйләнәме көлгә ялкын-уттан?
Юкка чыкмыйдыр ич бер булгачтын,
Бар булмаган кебек бер дә юктан?..

Нәрсә белән шулай сыешалмады,
Урынын тарсынгандай, йөрәгемдә?
Эзе дә юк хәзер, шәүләсе дә,
Пәйда булмый хәтта өрәге дә...

...Мәхәббәт романы укып ятам,
Егет белән кызга кызыга-кызыга...
Көнләшепме, ачуым килә тагын
Китаптагы шул бәхетле кызга...

Мәхәббәт гөлемнең таҗ-энҗесе
Тәгәрәп төште китап битләреннән.
Кибеп беткән, калмаган хуш исе—
Энҗе тама яңак читләремнән...

Сынган инде көмеш беләзекләр,
Алкаларның сынган бөгәлҗәсе.
Йөзек кашы төшкән. Күңел нурын
Томалаган болыт гөнҗәләсе.

Зәңгәр һаваларның төсе сеңгән
Фирүзә таш иде йөзек кашым.
Очып киткән корыган куагыннан,
Сөю якларына серле кошым.

Инде менә китап битләреннән
Җиде ятлар мәхәббәтен укыйм.
Алар кавышты да, юкка чыкты,
Күзләремне басты кабат йокым...

*1999*

## Дөнья—бер үк...

Синең хисләр—синең дөньяң,
минем хисләр—минем дөньям.
Тик бу ике дөнья кушылып,
үрелеп беткән бер-берсенә...
Җир шарының аръягында,
минем кебек—бирьягында,
кем уфылдый, кем көрсенә?
Кем ул сөенә—юлы уңган
кеше төсле иртә-таңнан?
Кем ул үкси—күз яшьләрен
яшерә-яшерә кысыр даннан?..
Кем ул анда—уйсулыкта
өзеп йөри өзгәләнеп,
дымлы давыл чәчәкләрен—
шашып җилсез моңсулыктан?..
Җир шарының һәр ягында
уй сулыккан... моң сулыккан...

*1999*

## Җәйсез калу

Җәй көтә дә, җәй көтәсең,
Әллә су-урманың бар?..
Минем шул елга-урмансыз
Җиде җәй торганым бар...

Сахрасы да, болыны да,
Суы да тормый көтеп,—
Җәй җитсә, таш йортта калам,
Һәммәсе бетә китеп...

Зәңгәр мәтрүшкәләр исен
Базардан сатып алам.
Кычыткан, әрекмәннәрен
Күрми дә, нәүмиз калам.

Җәйдән өлешсез калам мин,
Кышын кар тик тигезләп
Бирелә бүлеп миңа да,—
Торасы юк та эзләп...

Килсә икән шундый бер җәй,
Гүзәл бер җыр язарлык.
Шигырьләрдә сурәтләнгән
Җәй дә һуштан язарлык...

Минем җәйгә кояшта да
Эремәслек боз каткан.
Бүләк итче бер җәй миңа—
Шул бозларны кузгаткан!..

## Үксез җаннарга да бишек элсәк...

Әйтер сүзләремне әйтеп киләм,
тыңлаучылар булса, ишетер.
Мин үзем дә хәзер үз көемә
җырлап тирбәлүче бишек бер.

Шул бишеккә салдым халык моңын,
үзем тирбәткәнгә—тирбәләм.
Мин үземә үзем—бала инде,
иркәләнгән булам, тиргәләм...

Җиткән, ахры, һәркем үз җанына
үзе Әнкә булыр замана:
Каеннарга тиклем зар елыйлар,
чишмәләргә тикле зарлана...

Күпме җаннар илдә мәхрүм калып
бишегеннән, өши, күшегә.
Гөлдән авыр сүз дә әйтмәс идем
җан кадерен белгән кешегә...

...Таштан авыр чәчәкләр дә була,
гомер иткән кеше беләдер.
Үзе күтәралган хәтле җимешен
бишек итеп кеше эләдер...

Үз жаныңа үзең Әнкә булсаң,
дөнья әле ятим калмастыр.
Үксез җаннарга да бишек элсәк,
баса алмас рухны албасты...

*2000*

## *Казанның 1000 еллыгына*

# ЧАЛ ТАРИХЛЫ БАШКАЛА

Казансуның Иделгә коя торган җирендә, «Бөек Идел сәүдә юлы»нда урнашкан Казан каласы гомер бакый төрле ил галимнәренең игътибар үзәгендә булды. Урта гасырлардагы зур һәм шанлы татар дәүләте башкаласының тарихы, аның барлыкка килү вакыты хакында берсеннән-берсе каршылыклы фикерләр соңгы елларга кадәр яшәп килде. Моның сәбәбе, мөгаен, Казан тарихының гаять драматик характерда булуындадыр. Европа һәм Азия кыйтгалары тоташкан урында бер-бер артлы төрле дәүләтләр оешкан, чәчәк аткан һәм сүнеп юкка чыккан. Әллә бу җирләрнең, кайчандыр бер тарихчы әйткәнчә, «җәннәт почмагы» булуыннанмы, Идел-Кама төбәкләрендә күп гасырлар буе сугышлар тынып тормаган. Тарихи кыйммәткә ия документлар, архивлар югалган, мәчетләр, һәйкәлләр җимерелгән, халкының матди культурасы тулаем диярлек тар-мар ителгән. Мондый ил-дәүләт тагын бар микән җир йөзендә?

Казанның урыслар басып алганчыга кадәрге чоры моңа кадәр рәсми тарихта бик аз яктыртылды. Ул бары тик халык риваятьләрендә, әдәби истәлекләрдә генә сакланып калган хатирәләрдән, чит ил сәяхәтчеләренең юлъязмаларыннан гыйбарәт. Фәкать соңгы елларда гына бу өлкәдә шактый кызыклы ачышлар күренә башлады. Шуларның иң зурысы, дөньякүләм әһәмияткә ия дип табылганы— Казанга 1000 яшь тулуны ачыклау булды.

Узган елның декабрендә, Австралиянең Кернс шәһәрендә уздырылган сессиясендә Мәгариф, фән һәм культура мәсьәләләре буенча Берләшкән милләтләр оешмасы—ЮНЕСКО Казан Кремлен «Бөтендөнья тарихи мирас һәйкәле» дип игълан итте. Шулай итеп, Казан Кремле бөтендөнья җәмәгатьчелеге тарафыннан танылу алды.

Тарихчы-археологларның соңгы елларда ирешкән кызыклы ачышлары хакында тулырак мәгълүмат алырга теләп, без «Казан Кремле» археология экспедициясе җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты **Фаяз Хуҗинга** мөрәҗәгать иттек.

***Фаяз әфәнде, Казанның юбилеен уздыру мәсьәләсе моннан йөз унбиш ел элек—1884 елда ук кузгатыла. Ул чагында Дәүләт Думасы җирле бер газит («Волжский вестник») язмаларына нигезләнеп, «Казанга—500 ел» дигән датаны күтәреп чыга һәм бу хакта тулырак мәгълүмат бирүне сорап Император университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә мөрәҗәгать итә. Әмма, җитәрлек дәрәҗәдә материаллар булмау сәбәпле, Казанның юбилее ул чагында уздырылмый калына. Бер гасырга якын вакыт узгач, 1977 елда бу мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайталар. Әмма бу юлы да, «Казанга—800 ел» дигән дата Үзәк тарафыннан яклау тапмый.***

***Бүген инде дөнья җәмәгатьчелеге «Казанга—1000 ел!» дип шаулый. Әлеге ачыш нинди җирлектә туды? Галимнәр, бигрәк тә Мәскәү тарихчылары тарафыннан каршылыклар булмадымы? Кайчан гына Казанга 800 ел мәсьәләсенә дә шикләнеп караган Үзәк ничек таныды моны, ничек риза булды? Гомумән, бу дата нинди чыганакларга, нинди ачышларга таянып билгеләнде?***

**Фаяз Хуҗин:** Бу датага тиз генә киленмәде. Моның чишмә башы бик ерактан башлана. Әлеге сорауга тулырак җавап бирү өчен, иң элек, Кремль территориясендә алып барылган казу эшләренең тарихына күз салу зарур.

Кремльгә игътибар XIX йөздә үк башлана. Шул гасырның икенче яртысында

биредә кечкенә генә археологик казынулар үткәрелә. Кызганыч, әлеге хезмәтләрнең нәтиҗәсе турында бернинди документ сакланмаган.

1920 нче елларда, Кремльдәге төзү-реставрация эшләре вакытында, Татарстан археологиясенә нигез салучы олы галим Николай Калинин күзәтүләр алып бара. 1953-1954 елларда ул биредә шактый гына казу эшләре дә үткәрә. Н. Калининнын хезмәтләреннән күренгәнчә, Кремль территориясендә Алтын Урда чорыннан элгәрерәк табылдыклар—XII-XIII гасырга караганнары да булган. Шунысы кызык—бу табылдыклар турында язса да, Калинин Казан бу вакытта инде яшәгәндер дип уйламый—очраклылыкка сылтый. Мөгаен, моны раслаучы материалларның аз булуы шундый фикергә этәргәндер аны.



1970 елларда кабат археологик казу эшләре башлана. Аңа Н. Калининның шәкерте,Казан университеты профессоры Альфред Халиков житәкчелек итә. «Казанга—800 ел» дигән датаны да нәкъ менә ул күтәреп чыга. Аның белән берүк вакытта эзләнүләр алып баручы археологлар—Әзһәр Мөхәммәдиев һәм Лев Шавохин да XII-XIII гасырга караган табылдыкларга юлыгалар. Кызганыч, материалларның азлыгы бу юлы да Казан төзелә башлау елын билгеләүне тоткарлый. Дөрес, ул чакта Мәскәү Казанга 800 ел тулуны билгеләп үтүгә махсус киртәләр куймый. Шулай да: «Әлегә табылдыкларыгыз азрак, эзләнүләрегезне дәвам иттерегез, материаллар туплагыз, аннан карарбыз»,—диләр.

Шуннан соң озак вакытлар Кремльдә казу эшләре булмый торды. Әлбәттә, моның сәбәпләре сәясәткә килеп тоташа. 70 нче елларда Альфред Халиков шактый кызыклы әйберләр табуына карамастан, материалларын газета-журнал битләрендә бастыра алмады. Ачыктан-ачык әйтергә ярамаса да, моның ни өчен икәнен татар тарихчылары эчке бер тоемлау белән сизделәр. Элек-электән Мәскәүнең көндәшләре булып Болгар, Алтын Урда саналган. Әгәр ныклабрак казына, тикшерә башласаң, Казанның Мәскәүгә караганда борынгырак, ныграк үскән, зуррак мәдәниятле булып чыгуы бар иде. Билгеле, бу ачыш Мәскәүгә шатлык өстәми. Аннан соң Кремльдә махсус рөхсәт кәгазе белән генә кереп була торган һәртөрле югары оешмалар урнашкан. Ул вакытта хәрби гарнизон да биредә иде әле. Ягъни, Кремль территориясе үзенә күрә бер кагылгысыз җир, тыюлык булып саналды.

1994 елны Президент Минтимер Шәймиев Указы нигезендә «Казан Кремле» тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы оештырылды. Аның максаты—Кремль территориясендәге тузган биналарны реставрацияләүдән, кайберләрен бөтенләй җимереп, яңача корудан гыйбарәт иде. Әлеге эшләр барышында төзүчеләр җир казыганда күп кенә кызыклы табылдыкларга юлыктылар һәм безгә—тарихчыларга мөрәҗәгать иттеләр. Төзүчеләргә хәтле җирне археологлар тикшерергә тиешлеге хөкүмәт җитәкчеләре тарафыннан расланганнан соң, ниһаять, без җиң сызганып эшкә керештек...

Шушы чорда, «Пушечный двор»да казу эшләрен башлап җибәргәндә, мине фәкать бер генә сорау борчый иде: минем яраткан, хөрмәт иткән укытучым, татар археологларының остазы мәрхүм Альфред ага Халиков теге вакытта дөрес фикердә булдымы икән, Казанга 800 ел дип?.. Әлеге датаны Мәскәү тарафыннан рәсми рәвештә тану булмагач, ул бик кайгырып йөрде, Казаннан бөтенләй китү турында уйлады хәтта...

1994 елда ук без кайбер әйберләр таптык. Казылган җирнең иң аскы өлеше чынлап та монгол яуларына кадәр тупланган булып чыкты. Шул рәвешле тарихчы-галимнәрнең, археологларның игътибары әкренләп Кремльдәге казу эшләренә юнәлә башлады. Һәм шушы елда ук инде мин Альфред аганың фикере

дөрес булуына инандым. Алай гына да түгел, «безнең бабаларыбыз Кремль тирәсендә элегрәк тә яшәмәделәр микән?» дигән яна караш та формалашты.



*Болгар каеш прәшкәсе (X гасыр ахыры).*

Аннан соң тагын да кызыклырак, борынгырак табылдыклар чыга башлады. Әйтик, датасы хәзәр, элгәреге болгарлар чорына карый торган чүлмәк китекләре. Алар, нигездә, кулдан ясалган, тупас эшләнмәләр, бизәкләре дә юк диярлек. Әмма бу чүлмәкләрнең археологик кыйммәте гаять дәрәҗәдә зур. Ни өченме? Чөнки кулдан ясалган чүлмәкләр X гасырга гына хас. XI гасырда инде аларны ыстаннарда ясый башлаганнар. 1997 елда без X гасырга караган чех тәңкәсе таптык. Аның шаукымы бик көчле булды (бу хакта алдарак әйтелер). Датасы X гасырга карый торган табылдыклар арасында гарәп дирһәме, гәрәбәдән, пыяладан ясалган муенса төймәләре, каеш прәшкәсе һ. б. күп кенә кызыклы әйберләр дә бар. Менә шулай итеп, әкренләп, «Казанга нигез X гасырда ук салынган икән» дигән уртак фикергә килә башладык.

Югарыда сөйләнгәннәр—болар тикшерүнең археологик ягы. Моннан тыш әле без төгәл фәннәрнең нәтиҗәләреннән дә файдаландык. Ягъни, табылдыкларга физик, химик анализ үткәреп.

Җирнең иң аскы, борынгы катламыннан табылган күмерне радиоуглерод ысулы белән тикшерү өчен Санкт-Петербургта һәм Венадагы махсус лабораторияләргә мөрәҗәгать иттек. Бигүк төгәл булмаса да, әлеге ысул 50 елдан да артыкка хата җибәрми.

Термолюминисцент ысулы да без көткән нәтиҗәләрне бирде. Бу ысул белән борынгы чүлмәкләрнең кайсы елларда ясалганлыгын ярыйсы ук төгәл билгеләп була. Аның лабораториясе әлегә Германиядә генә бар. Берничә чүлмәк кыйпылчыгын Берлинга алып барып тикшертеп кайттык.

Палинология ысулы исә X гасыр климатын, табигатен ачыграк күзалларга ярдәм итте. Бу—биологик ысул. Чәчәк атканда үсемлекләр очырган серкә җиргә төшә һәм шунда миллион еллар буе саклана. Туфракны микроскоп аша күзәтеп, шул гасырның климатын, үсемлекләр дөньясын күзалларга була.

Табылдыкларга анализ ясауның әһәмияте зур. Бая телгә алынган чех тәңкәсе табылгач күпләр мона ышанмады. «Үзегез ташлагансыз!» дип үзәккә үттеләр. Моны исбат итү өчен спектраль анализ үткәрергә туры килде. Бу анализның асылы түбәндәгедән гыйбарәт: теләсә нинди тәңкәнең өслегендә чак кына күгәрек сыман катлау тупланган була. Шул катлауны тикшереп, тәңкәнең чынлап та озак еллар җир астында ятканмы, әллә «витринадан алынганмы» икәнлеген билгеләргә була. Күрәсез, безгә менә шул дәрәҗәгә үк барып җитәргә туры килде.

Төгәл фәннәрнең нәтиҗәләреннән тыш, биредә тагын логика дигән нәрсәне дә истән чыгарырга ярамый. «Бөек Идел сәүдә юлы» турында ишеткәнегез бардыр. X гасырда аның бик актив чоры була. Инде IX гасырда ук Иделдә бер-бер артлы зур сәүдә портлары барлыкка килә: Болгар, Әҗмер, Семеновка, Түбән Новгород тирәләрендә һ.б... Шундый актив сәүдә юлы өстендә бу чорда Казанның булмавы мөмкин түгел! Моннан берничә ел элек, әле житди археологик табылдыкларыбыз булмаган вакытта да без: «Казанга X гасырда ук нигез салынган, ул чорга караган әйберләрне әлегә таба алганыбыз гына юк» дип фикер йөртергә тиеш идек. Тиеш идек... шулай фикерләргә рөхсәт булган булса...

Соңгы елларда өч-дүрт халыкара конференция үткәрелде. Алар, гадәттә, август аенда була. Анарчы, җир кардан арчылу белән, көне-төне дигәндәй, казынабыз. Конференциягә килүчеләрне шул казылмаларга алып барабыз, табылдыкларны күрсәтәбез, сөйлибез, сорауларына җавап бирәбез. Кешеләрне

ышандыру җинел түгел. Хәтта үзебезнең татар галимнәре арасында да каршы килүчеләр булды. Урысларныкын аңларга була инде—шовинизм галәмәте, ә менә татарныкын фәкать көнчелек дип кенә бәяләргә була. Бәхәсле мәсьәләләр берсе артыннан берсе туып кына торды. Мәсәлән, борынгы таш стеналар. Аларнын датасын һич кенә дә билгели алмадык. Үзебезчә, монголларга кадәрге чорныкы булсын иде дип бик каты телибез, күңел белән ишанабыз, ә исбатлап булмый...

1999 елда «Борынгы Казан: барлыкка килүе һәм үсеше» дигән темага халыкара конференция үткәрдек. Егермеләп илдән, Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан шушы чор буенча шөгыльләнүче галимнәр килде. Мин анда Казанның барлыкка килү вакыты турындагы доклад белән чыгыш ясадым. Конференциядә катнашучылар «Казан X гасыр ахыры—XI гасыр башында барлыкка килгән» дигән карашны яклап чыктылар. Шулай итеп, тарихка кереп калган әлеге конференциядә без Казанга 1000 яшь тулуны исбатлый алдык.

Аннан соң Татарстан Фәннәр Академиясе Татарстан Президентына, Казан шәһәр Советына, Казан шәһәр хакимиятенә мөрәҗәгать итте. Тиздән бу мәсьәлә Россия Фәннәр Академиясендә тикшерелде һәм алар тарафыннан Россия Президентына җиткерелде. Ниһаять, 1999 елның сентябрендә, Россия Президенты Борис Ельцин һәм Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Казанның 1000 еллыгын үткәрү турындагы Указларга кул куйдылар.

*Бүгенге көндә күпләрне Сөембикә манарасының тарихы кызыксындыра. Манара, кайбер тарихчылар фараз иткәнчә XVII гасырда төзелгәнме, әллә элегрәкме?*

**Ф. Х.:** Дөрес, әлегә безнең кулда Сөембикәнең ханнар чорында төзелгәнлеген исбатлый алырлык чыганак юк, әмма кайбер фаразлар бар.

Альфред Халиков 1976-77 еллардагы казу эшләре вакытында Сөембикә манарасы янында таштан төзелгән, әмма бик начар сакланган корылма тапты. Бу корылма монголларга кадәрге чорга карый иде. Ул нәкъ менә Сөембикәнең элгәресе булырга тиеш дип фикер йөртте Альфред ага.

Биредә бик борынгыдан ук ниндидер манара булган, әлбәттә. Монысы—бәхәссез. Чөнки аның урыны шундый—стратегик яктан караганда Кремльнең функциясе биредә ниндидер бер күзәтү манарасы булуны таләп итә. Ләкин бүгенге манараның борынгы корылма булуы—әлегә тулысынча исбат ителмәгән. Фаразлар күптөрле. Бүгенге Сөембикә—бәлки Казан ханлыгы чорында булган манараның күтәртелгән, реставрацияләнгән вариантыдыр. Элек аның бәлки бер яисә ике ярусы гына булгандыр.

Моны ачыклау өчен Сөембикә манарасын максатчан өйрәнергә кирәк. Алдагы елларда Сөембикә белән аның янәшәсендәге Нурали мәчете арасын казу планга кертелгән. Байтак сорауларга җавапны шуннан соң табарбыз дип уйлыйбыз.



*Сөембикә манарасы һәм Нурали мәчете*

Аннан соң, Сөембикә манарасының датасын билгеләү—гаять тә чагыштырмача төшенчә. «Сөембикә XVII гасырда төзелгән» дип әйтү, манара шул вакытта салынган булса да, дөрес түгел. Чөнки аның нигезендә нәрсәдер булган бит инде! Манара буш урында барлыкка килмәгән ләбаса!

*Без борынгы Казан Кремленең стеналары агачтан ясалган дип беләбез. Һәрхәлдә, тарих дәреслекләрендә шулай язылган. Бу чыннан да шулаймы?*

**Ф. Х.:** Әйдәгез, сүзне X гасыр ахырындагы борынгы Казаннан башлыйк. Археологик казынулардан күренгәнчә, биредә жирдән ясалган вал (өеп куелган дамба сыман жир) һәм аның өстендә агач стена булган. Еллар үтү белән агач черегән, ләкин вал сакланып калган. Нәтиҗәдә, XII гасырда шул ук вал өстендәге стеналарның кайбер урыны таштан, кайбере агачтан булган.

Игътибар итсәгез, Кремльнең бер ягы текә, берсе сөзәк. Иң көчле ныгытмалар, хәлбуки, сөзәк ягында—кыр ягында төзелгән. Текә һәм биек ярлардан үзеннән-үзе табигый ныгытма барлыкка килгән.


Инде XIII гасырга күз салыйк. Болгардагы бөтен ныгытмалар Алтын Урда ханнары тарафыннан җимертелә. Бу хәл Казанны да читләтеп үтми, әлбәттә.

XIV гасыр ахырларында Алтын Урда таркала, Казан әкренләп күтәрелә башлый. Шушы чорда таш стеналарны кабаттан торгызалар.

XVI гасырда әлеге стеналарны Явыз Иван тагын җимерә. Бераздан янә ремонт эшләре башлана...

Күрәсез, гасырлар дәвамында Кремль стенасы гел үзгәрешләр кичереп торган. Хәзерге стеналар исә XVI гасырда төзелгән. Ләкин бөтенесе дә түгел. Кайбер өлешләре элгәргерәк чорга да карый.

Баярак телгә алып үтелгән Сөембикә манарасының датасын билгеләү кыен булган кебек, стена-диварлар белән дә шул ук хәл. Стенаның нигезе бик борынгы чорларда салынган. Ягъни, ватканнар-төзегәннәр, ватканнар-төзегәннәр, ә нигез шул ук калган...



*XII гасыр ахырында төзелгән таш стена калдыклары.*


Хәзер төзелеп ятучы Кол Шәриф мәчете янында элек казармалар урнашкан иде. 1994 елда мина шул төшне казырга туры килде. Төп максат—Кремль стенасының төбенә кадәр төшеп житү иде. Төшәбез, төшәбез, һич төшеп житеп булмый. Жир астындагы стена ташларының матурлыгын, төзеклеген күрсәгез сез! Боларны хәтта тикшерәсе дә юк, бу—ханлык чоры! Псков урысларының төзү ысулы түгел бу!.. Төшә торгач жир өслегеннән 12 метр (!) аска төштек. Шуннан соң гына стена бетте. Безгә ерактан балкып күренеп торган Кремль стенасы—ул аның бер өлеше генә икән ләбаса! Тагын да зуррак кисәге жир астында ята икән аның.

Шуннан соң инде миндә Кремль стенасы хакында яңа фикер формалаша башлады. «Юк, моны урыс архитекторлары Постник Барма белән Иван Ширәй төземәгән... Өске өлешен бәлки алар төзегәндер, ләкин нигез—Казан ханлыгы чорыныкы! Борынгырак та булмаса әле!..» Казылган урынны тикшергәч бу фикер белән Мәскәү археологлары да килеште. Алайса, күп кенә тарихчылар монарчы берьяклы гына фикердә иде: «Иван Грозный килгән дә, крепость төзеп куйган», янәсе...

*Борынгы Кремльне күз алдына китереп карыйк әле. Ул хәзергесеннән нык аерыламы? Мәйданы, ныгытмаларның урнашу тәртибе...*

**Ф. Х.:** Кайбер тарихчылар Кремлебезне «Урыс Кремле формасында» диләр. Без моңа кискен каршы төшәбез. Әгәр аның топографиясен алып карасак, элек хан сарае булган төштә соңрак губернатор утырган, бүгенге көндә исә анда президент аппараты «шәһәрчеге» урнашкан. Территорияләрдәге аерма 3-4 метрдан артмый. Хәзерге «Пушечный двор»да элек ханның дружинасы, арсеналлар булган. 1812 елда биредә туп койганнар. Кыскача гына итеп әйткәндә, Кремльнең һәр почмагы элек нинди функция башкарган булса, нигездә, бүген дә шуны үти.

*Фаяз әфәнде, Сөембикә манарасыннан ерак түгел урнашкан Благовещение соборы хакында бүген шактый бәхәсләр бара. Берәүләр аны Иван Грозный салдырган чиркәү дисә, икенчеләре—кайчандыр ул Кол Шәриф мәчете булып, Явыз Иван аны чиркәү итеп үзгәрткән дип тәкрарлыйлар. Моның дәлиле итеп, Благовещение соборының кыйблага карап урнашуын күрсәтәләр...*



*Казан Кремле планы.*

**Ф. Х.:** Благовещение соборы мәчет булмаган, дисәң, тагын безнең халыкка ярамыйсың инде!..

Урамда зәмһәрир кыш булуга карамастан, күптән түгел генә шушы чиркәүнең подвалында казу эшләре алып бардык без. Бинаның нигезенә кадәр төшеп життек һәм аның «төзелеш горизонты» дигән нәрсәсен, ягъни, чиркәүне төзегәндә тупланып аерым катлау булып сакланган төзелеш чүп-чарын таптык. Катлам 1552 елгы янгын өстендә ята иде... Димәк, чиркәү 1552 елдан соң гына төзелә башлый дигән сүз була бу.

Соңгы елларда, Кремль территориясендә элекке Кол Шәриф мәчетенең нигезен эзләп йөргәндә, кайберәүләр безне файдасыз шөгыль белән маташуда гаепләделәр. «Эзләмәгез, әнә бит ул!»—дип Благовещение соборына төртеп күрсәттеләр. Мин моның белән килешмим. Кайбер фаразлар буенча без Кол Шәриф мәчете хәзерге Президент резиденциясе каршындагы бакча урынында булган дип уйлыйбыз. Шул ук вакытта, Благовещение соборына кагылышлы бер шигем дә бар. Бәлки Кол Шәриф дөрестән дә собор урынында булып, аны бөтенләй җимереп ташлаганнар, яндырганнардыр? Һәм янгын катламы өстендә шушы чиркәүне салып куйганнардыр. Ничек кенә булмасын, бер генә мәсьәләдә фикерем нык—Благовещение соборы баша ук чиркәү итеп төзелгән.

*Борынгы Казан астында җир асты юллары булган дип сөйлиләр. Алар бүгенгә кадәр сакланганмы?*

**Ф. Х.:** Җир асты юллары булган, әлбәттә. Булмыйча мөмкин түгел—алар тарихи документлар белән раслана. Ләкин, бүгенгә кадәр ул юлларны таба алган кеше юк. Кызганычка каршы, без җир асты юлларын археологик ысул белән ача алмыйбыз. Ни өченме? Без культура катламын гына казыйбыз һәм кызыл балчыкка житкәч туктыйбыз—анда инде археологик табылдыклар чыкмый. Ә бит җир асты юллары нәкъ менә кызыл балчык катламында, хәтта 5-6 метр аскарак та төшеп булырга мөмкин. Аннары, шулай зурдан кубып актарынырга безгә кем рөхсәт итсен?.. Бу—бөтен Кремльнең астын-өскә китерү булачак лабаса! Әмма, ничек кенә булмасын, җир асты юлларын табу—киләчәк бурычларның берсе. Моны яна бер ысул белән тикшерергә уйлап торабыз. Казан дәүләт университетының геология факультеты профессоры, геофизика буенча зур белгеч З. М. Слепак белән яхшы гына хезмәттәшлек итәбез без. Слепак җир катламын ватмыйча гына, электромагнитик ысуллар белән җир астынданиләр барлыгын «күрә торган» кеше. Куышлыкларны, су катламын һ. б... Алдагы елларда Казан посадының җир катламын аның белән берлектә тикшерү күздә тотыла.

Җир асты юллары хакында минем кайбер фаразларым да бар. Кремльдән җир асты юлы Нурали манарасы аша үткәрелгән булырга тиеш. Анда элек чишмә булган, суга йөргәннәр. Шушы ук юлны Казансуга чыгу өчен дә файдаланган булулары ихтимал. Качу өчен, мәсәлән. Бик озын булса да, коридор тибында гына Кабан күленә дә юл баруы мөмкин.

Баярак әйтеп үткәнемчә, монарчы бездә максатчан тикшерү үткәрелгәне

булмады. Шул ук Кол Шәриф мәчетен алыйк. Аның элекке урынының кая булуы турында күпме шаулыйбыз, әмма ныклы, максатчан тикшерү уздырылмагач, дөрес нәтиҗәгә килә алганыбыз юк. Сөембикә манарасы белән дә шул ук хәл. Берәр кирпечен Берлин лабораториясендә тикшертсәк, нәрсә дә булса ачыкланыр иде югыйсә.

*Археологик казулар вакытында табылган экспонатлар кайда туплана, кемнәр тарафыннан өйрәнелә һәм киләчәктә аларны кайсы музейларда күрергә мөмкин булачак?*



*1552 елгы янгын катламыннан чыккан таш ядрәләр.*

**Ф. Х.** : Без, әлбәттә, китаплар, фәнни хезмәтләр язабыз. Ләкин алар халык өчен түгел. Алар тар даирә, тарихчы-галимнәр өчен эшләнә. Халыкка тышына «XII гасыр Казанының таш дивары» дип мәрмәр такта эленгән борынгы стенаның эчен ярып күрсәт син, табылдыкларыңны: чүлмәкләреңне, тәңкәләреңне күрсәт! Һәм кулына иң кызык материаллар, рәсемнәрдән торган нәни генә бер буклет тоттыр!.. Әлегә бу хыял гына. Әмма башкалабызның 1000 еллыгына ул чынга әверелер дип уйлыйм. Төгәлрәк әйткәндә, түбәндәгеләрне эшләү күздә тотыла.

1. Президент резеденциясе каршындагы бакчаны казыячакбыз һәм анда ачылган борынгы корылмаларны, табылдыкларны махсус эшләнгән пыяла идән сыман әйбер аша халыкка күрсәтергә уйлыйбыз. Ул чагында инде жир катламнарында Кремльнең бөтен тарихы ярылып ятачак.
2. «Пушечный двор»—иң борынгы биналарның берсе булып санала. Биредә Казан тарихындагы төрле сугыш коралларына багышланган музей булачак.
3. Урыны әлегә билгеле булмаса да, Кремльдәге кайсыдыр бер бинада «Татарстан археология музее» оештырылачак. Анда табылдыклар, төрле археологик материаллар тупланачак.
4. 1977 елгы казулар вакытында ук Сөембикә манарасы янында ике Казан ханы—Мәхмүд белән Мөхәммәт Әминнең сөякләре яткан төрбә табылган иде. (Ул сөякләр тарих институты фондында саклана). Әлеге төрбәне заманча, матур итеп реставрацияләү күздә тотыла.
5. Бүгенге көндә Кол Шәриф мәчете фонды урнашкан бинада «Татар халкының дәүләтчелек тарихы» музее оештырылачак.
6. КДУның геофакультетыннан бирегә минерология коллекциясен күчерәчәкләр. Бу дөньядагы иң бай коллекцияләрдән санала.
7. Кремльдәге хәзерге ашханә урынында «Дәүләтчелек символлары музее» оештырылачак. Анда безнең әләмнәребез, герб, мөһер ише әйберләр сакланачак.
8. XVI-XVII гасырларда Бауман урамы бүгенге урынында булмаган—аның бер башы кыегаеп туп-туры Кремль «авызына» килеп чыккан. Күптән түгел Бауман урамының бер өлешен ике катлы итеп үзгәрттеләр. Һәм төзелеш эшләре вакытында без әлеге иске «кыек»урамны, шул урамга тротуар итеп түшәлгән борынгы бүрәнәләрне таптык. Ике катлы жир асты урамындагы бер подвалны безгә—археологларга бирәчәкләр. Теге иске урамның ни рәвешле булганын шул подвалда диорама рәвешендә күрсәтергә уйлыйбыз.

*Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Фаяз әфәнде! Сезнең сөйләүләрдән күренгәнчә, алдагы елларда Кремль, гомумән, Казан посады үзенә бертөрле тарихи мемориаль-комплекска әйләнергә тиеш. Сезгә—шушы бөек датаны ачучыларга—тарихчы-археологларыбызга уңышлар телибез. Тагын да зуррак ачышлар, кызыклы табылдыкларга юлыгу насыйп итсен!*

**Ф. Х.:** Рәхмәт. Йомгаклап шуны әйтәсем килә: Казан—Татарстанда бердәнбер борынгы шәһәр түгел. Андый шәһәрләр Казаннан башка да булган. Әйтик, соңгы елларда Алабугада бик кызыклы казу эшләре үткәрелде. Баксаң, Алабуга да Казан белән чордаш икән бит! XI гасырда барлыкка килгән! Казанның моннан 1000 ел элек үзе генә яшәве, әлбәттә, гайре табигый хәл булыр иде. Алай гына да түгел, Казан һәм Алабугадан да борынгырак шәһәрләр бар әле. Мәсәлән, Болгар. Аңа 1100 яшьне бернинди шикләнүләрсез бирергә була.



*Кремль тавы итәгендә ачылган борынгы урам (Ханлык чоры).*

Төптәнрәк уйлап карасаң, Казанның 1000 еллыгы татар халкы өчен гаҗәеп дәрәҗәдә әһәмиятле, гаҗәеп дәрәҗәдә кадерле дата. Россиядә бер генә халыкның да (урыстан кала) шундый бай тарихы, мәдәнияте булмаган. Казанның 1000 еллыгын билгеләп үтү, бердән, рухи байлыгыбызны дөньяга таныту булса, икенчедән, гасырлар буе кыйналып та, сынмыйча, сыгылмыйча XXI гасырга китереп җиткергән ныклыгыбызны, горурлыгыбызны дәлилләү символы ул.

Әңгәмәдәш **Алмаз ГЫЙМАДИЕВ**

## Авторлар игътибарына

Кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН таныклыгы номеры
7. Телефоныгыз *(шәһәр кодын да күрсәтеп)*

# Ədəbi tənqit
# Әдәби тәнкыйть

## Фәрит Хатипов

## РУХИ КУӘТ

Нурихан Фәттах иҗаты турында минем элегрәк тә язгалаганым бар иде. Башка авторларның да мәкаләләре күренгәләп тора. Ләкин шулай да әдипнең соңгырак елларда халык кулына килеп кергән әсәрләрен тәфсилле анализлаган хезмәтләрне очратмадым. Хәлбуки, әдипнең иҗаты бер вакытта да тукталып тормады. Нурихан Фәттах—бар сәләтен, белемен, рухи көчен әдәбиятка багышлаган талантлы язучыларыбызның берсе. Бирелеп, онытылып иҗат итүдән, даими киеренке уй хезмәтеннән ул чын ләззәт таба, тормышын мәгънәле, эчтәлекле итеп тоя. Әйтүенә караганда, язарга утыру сәгатен ул иң бәхетле мизгелләрдән саный. Язучы әдәби әсәрнең ил тормышында никадәр җитди, хөрмәтле урын биләвен тирән аңлый. Шунлыктан китап язуга, аның сыйфатына үтә җаваплы, таләпчән карый, аны халык эше, намус гамәле дип саный. Иҗатында ул чынбарлыкның мөһим якларына туктала, яшәешнең, инсан күңеленең яңа катламнарын актарып күрсәтә, тормышны, кешеләрне чын итеп, җанлы итеп гәүдәләндерә, әсәрләрен сәнгать камиллеге дәрәҗәсенә җиткереп эшкәртә. Бу мәгънәдә ул үзебезнең татар әдәбияты, рус һәм дөнья әдәбияты традицияләрен уңышлы дәвам иттерә. Шул ук вакытта туксанынчы елларда басылган әйберләре аның үзенең элегрәк чыккан әсәрләреннән дә нык кына аерылып тора. Биредә сүз әнә шулар хакында барачак.

* * *

Илленче еллар узып, алтмышынчы еллар уртасы җиткәч, Н. Фәттах, заманга яраклашуны кирәксенмичә, аяусыз, кырыс реализм җирлегенә күчте, авыл чынбарлыгының гади кешегә рәхимсез мөнәсәбәтен бар булганынча сөйләп бирде. «Кичү» романы, «Кырык дүртнең май аенда» повесте әнә шундый рухта язылган иде.

Дөрес, боларда да әдип үзенә бик таныш, якын булган, үзе кичергән, бәгыре, күңеле аркылы узган мәгыйшәткә туктала. Әдипнең күңеле ул хәятка бик тирән үтеп керә, язучы моңарчы тыелган, йөрәген сызлаткан якларга игътибар итә, шул хасияте белән әсәрләре укучыларны сискәндереп җибәрә.

---

Фәрит ХАТИПОВ *(1930)—әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, әдәбият белеме буенча китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

«Кичү»дә геройларның характеры көндәлек тормыш күренешендә ачыла. Биредә кырыгынчы еллар ахырында урта мәктәпне тәмамлап чыгучы яшьләрнең уй-хисләре, аеруча дулкынланган, хыял канатларында очкан чаклары сурәтләнә. Әсәр баш герой Габделхәйнең тирә-юньне ничек күрүенә, ни рәвешле кабул итүенә нигезләнеп хикәяләнә. Ул шагыйрь булырга хыяллана. Табигате белән бик нечкә, сизгер күңелле, ипле егет. Вакыйгалар барышында аның кәеф-халәте сизелер-сизелмәс йогынты тәэсирендә бик тиз үзгәреп, алмашынып тора. Ләкин әле ул җиһанга китапчарак карый, якты, бәхетле киләчәк турындагы вәгъдәләргә ихлас ышанып, өметләнеп яши. Шул ук вакытта тормышларының бер дә алга киткәне күренми. Киресенчә, фронтта үлеп калган әтисе өчен сугыш елларында аларның гаиләсенә пособие килеп торган. Ә җиңү яулангач, ул да туктатыла, кирәге беткәч, дәүләт аның өчен акча сарыф итәргә теләми. Инсан гомеренең бәясе әнә шундый. Ул бер тиен дә тормый.

Тагын да мәрхәмәтсезрәк мохтаҗлыкны Габделхәй авылдагы дәү әтиләренә баргач күрә. Аның туганнары колхоз эшенә бер гаиләдән өч кеше йөри, печән чаба, шуларның өйләрендә ашарга ипиләре юк, иген үстерүчеләр ачлы-туклы гомер кичерәләр. Өстәвенә әле финагент сигезенче дистә белән бара торган картны чабата ясаган өчен налог түләтергә тели. Шуңа күрә ул, өлкән яшьтәге ил карты, нәтиҗә ясагандай «эшләү план белән, ашау гырам белән», дип әйтеп куя *(Н. Фәттах. Кичү.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1995, 200 б.)* Алар инде хәзер басудагы иген торышына да битараф карый башлаганнар: «Ничек булса да, безгә буласы түгел,—ди Кәрим карт, Габделхәйнең бабасы.—Урак вакыты гына җитсен, килерләр дә ялмап та алырлар, бөртеген калдырмый алып китәрләр».

Шулай итеп, егет күңелендә китап сүзләре белән тормыш фактлары арасында даими бәрелеш чыгып кына тора. Эчке конфликт яшәешнең күп кенә өлкәләрендә хасил була. Әйтик, рәсми документлар безнең илдә халыклар дуслыгының чәчәк атуы турында әйтә. Чынында исә «өлкән ага»ның гына бөеклеге раслана, татар халкының исә һәр адымда теле, мәдәнияте, мәгарифе кысрыклана. Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Антонина Семеновна башкалар арасында үзен, бөек милләт вәкиле буларак, барлык татар укытучыларыннан өстенрәк, дәрәҗәлерәк дип белә. Бөеклек, өстенлек тойгысы аның канына сеңгән. Татарча берәр сүз ычкындырган коллегаларына ул ярсып, карчыга булып ташлана.

Мәктәп директоры «Василий Михайлович» (Вәсби Муллаханович) та аның көен генә көйли, җан тырышып татарлыкны бетерергә омтыла, татар балаларына урысча укытуны гамәлгә кертә, тик катлаулы мәсьәләләрне төшендергәндә генә укытучылар аңлаешлы, якын татар теленә күчәләр. Директор киләчәктә немец теле дә, француз, инглиз теле дә булмас, тик бер тел—урыс теле генә торып калыр дип фараз кыла.

Бу җәһәттән военкоматта эшләүче капитан Зверевның аң-белем, интеллект дәрәҗәсе гыйбрәтле. Ул мәктәптә берничә рус шагыйренең генә исемен ишетеп калган. Төрки-татарларның исә инде моннан мең еллар элек үк язма поэзиясе булганлыгы, классик югарылыкка күтәрелгәнлеге турында ул белми һәм Габделхәйгә шундый сорау белән мөрәҗәгать итә: «Әнә Пушкин булган, Лермонтов булган. Шулай да, әйтегез әле, сезнең телдә, татар телендә шигырь язып буламыни?» Г. Тукай турында ишеткәч, ул шагыйрьнең исемен юри бозып, «Такой-сякой дигән кебек» дип мыскыллый. Бу романда район масштабындагы, ләкин ил сәясәте белән тоташкан шовинизмның конкрет күренешләре тасвир ителә.

Автор моның һич тә абстракт күренеш кенә булмавын, бәлки турыдан-туры шәхес язмышына китереп сугуын күрсәтә. Борынгы милли китапларны, бәндә кальбенә бер дә зыян салмастай, «юаш» әсәрләрне: «Йосыф—Зөләйха», «Бүз егет», «Кисекбаш»ны саклаган өчен Габделхәйнең әтисе Котдусне кулга алалар, атарга хөкем итәләр. Соңыннан үлем җәзасы унбиш ел төрмә һәм гомерлек сөрген белән алыштырыла. Котдус, шуннан фронтка китеп, батырларча сугышып үлә.

Габделхәйнең әнисе балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.

Көннәрдән бер көнне ул татар авылында «балалар бакчасындагы татар группасын ябачаклар» дигән хәбәр алып кайта. Алга бөтен аяусызлыгы белән (хәзер күпләргә таныш булган) эшсез калу куркынычы килеп баса. Милли телне кысрыклау, шулай итеп, рухи тормышка гына түгел, турыдан-туры кесәгә дә китереп суга, кешене юк итәргә тырыша.

Кысрыклау сәясәтенең кәсафәте Габделхәйне дә читләтеп үтми. Урта мәктәпне тоташ «отлично»га тәгәлләгән өчен аңа алтын медаль бирелергә тиеш була. Ләкин хакимият гади татар баласын андый дәрәҗә белән билгеләүне мәслихәт тапмый. Күренә ки, милли җәбер, кыерсыту мәсләге яшәешнең бик күп өлкәләрен иңләп ала икән.

Медальнең тәтемәве генә Габделхәйнең университетка керү, белемен күтәрү хыялын сүндерә алмый, әлбәттә. Ләкин моңа ирешү юлында тагын, албасты, өрәк булып, мохтаҗлык, фәкыйрьлек басып тора. Әмма егет моның каршында аптырап калмый, эшләп, үз көнен үзе күрергә ышана.

«Кичү»—төсләргә бай, күп бизәкле әсәр. Тормыш кыенлыклары, читенлекләре белән беррәттән анда яңа гына канат чыгарып килүче яшьләрнең үзләренә генә хас якты хисләре, моңсу-ләззәтле кичерешләре тасвирлана. Монда самими холык-фигыле, үзенчәлекле сөйләме, сылулыгы, чибәрлеге белән Былбыл әсәргә үзенә бер төрле нур сибеп, ямь биреп тора. Анда М. Әмирнең «Агыйдел»ендәге Артыкбикә чалымнары да, Ә. Еникинең «Туган туфрак» хикәясендәге Кларага тартымлык та бар кебек. Әсәрдә Габделхәйнең Былбылга үтә тыйнак, җылы мөнәсәбәте сурәтләнә, кызның да бу егеткә битараф булмаганлыгы сизелә. Тик шулай да мондагы мөнәсәбәтләр ягымлы елмаюдан, җылы караштан, бер-берсен юксынудан ары китми. Автор укучыга әнә шундый эчке халәтнең тыйнак гүзәллеген тойдырырга тырыша.

Бу әсәрнең тәүге вариантын Н. Фәттах «Сезнеңчә ничек?» романыннан соң, әдип булып танылгач, 1956—63 елларда яза. Ләкин дөньяга чыгармый. Моны әдип үзе «Ул елларда бар нәрсәне буып торган милли террор һәм рәхимсез мохтаҗлык» белән аңлата. Ләкин сәбәп тагын да тирәндәрәк түгел микән? Бөтен рухы, стиле, әдәби сурәтләре белән моңарчы чыгып килгән шома әсәрләрдән кискен аерылып торуында, аларга контраст булуында түгел микән? Утыз елдан артыграк вакыт үткәч, тагын да күбрәк тәҗрибә туплагач, барыннан да бигрәк рухи хөрлек тугач, әдип кабат «Кичү»гә әйләнеп кайта, ике-өч ел буена аны эшкәртә һәм, ниһаять, укучы кулына тапшыра.

«Кичү»не язудан туктаганнан соң Н. Фәттах «Кырык дүртнең май аенда» повестен иҗат итәргә керешә һәм аны «Артта калган юллар» исеме белән «Казан утлары»ның 1965 елгы уникенче санында бастырып та чыгара. Шуннан соң бу әсәр утыз ел чамасы китапка керә алмый ятты. Китап хәлендә ул «Кичү» романы белән бергә безнең көннәрдә, 1995 елда гына нәшер ителде.

Биредә Хәмдиянең ачы язмышы бәян ителә. «Кырык дүртнең май аенда» аеруча киеренке сюжетлы әсәр. Ләкин монда ике яктагы тигез көчләр бәрелеше тасвирланмый. Асылда ул гаять зур, куәтле дәүләт аппаратының аерым шәхесне бөтен авырлыгы белән басып торуын, яньчү-изүен, һәлакәткә китерүен сурәтләүгә корылган. Бер караганда совет власте сөекле үз кызын, колхоз ударнигын хөрмәтләп, олылап кына торырга тиеш иде кебек. Чынында исә бөтенләй башкача килеп чыга. Аны Себергә урман кисәргә, торф чыгарырга җибәрәләр. Биредә ул тоткын хәлендә кала, аларның бараклары да төрмә өчен дип салынган була. Эшкә дә алар тоткыннар белән янәшә баралар. Шулай да Хәмдия норманы бер ярым, ике тапкырга үтәп килә. Шунда аның улы туа. Бу шартларда нарасыйны тик ач үлем генә көтә. Моңа юл куймас өчен Хәмдия яшь баласы белән үз иленә кайтып китәргә мәҗбүр була.

Ул еллардагы әдәби тәнкыйть социалистик реализм әдәбиятын саф килеш, кара бизәкләр кертмичә сакларга тырыша иде. Шуңа күрә әлеге әсәрдә тасвирланган күренешләр тулы дөреслек дип түгел, ә аның бер өлеше генә дип бәяләнде. Хәмдия гамәле турында күренекле тәнкыйтьче Р. Мостафин болай яза: «Кем белән дер бәхәсләшергә, полемикага керергә теләү әсәрнең төп героен сайлаудан ук күренә. Әгәр Нәфисә—алдынгы бригадир, Миңлекамал—колхоз председателе, Сания—шәһәр Советы председателе, икенче төрле әйткәндә, алар барысы да билгеле бер мәгънәдә башкалардан

өстен торган, абруйлы, билгән постлары белән үк мактаулы һәм хөрмәтле кешеләр булсалар, Н. Фәттах повестеның төп герое Хәмдия исә—иң гади бер колхозчы. Алай гына да түгел, ул качак, хезмәт фронтыннан качкан дезертир; шул чорның кырыс законнары буенча аны суд, төрмә көтә» *(«Казан утлары». 1969, № 2).*

Бу мәсьәләгә беркадәр төгәллек, ачыклык кертү сорала. Әсәрдән аңлашылуынча, Хәмдияне алты айга җибәрәләр. Ярты ел эшләгәч, көчләп, мәҗбүри рәвештә тагы алты айга калдыралар. Анысын да тутыргач, сез монда сугыш беткәнче эшләячәксез, диләр. Шулай итеп, Хәмдия авырлы килеш, аннары күкрәк баласы белән алты ай урынына бер көн калдырмыйча ел ярым эшли. Әгәр аның бер ярым, икешәр норма үтәп баруын да исәпләсәң, аның мондагы эш стажы тагын да күбрәк булып чыга. Шуңа күрә, бу очракта дезертирлык турында гәп кузгатуга караганда, Хәмдиянең кушканны өч йөз процентка үтәве, дәүләт аппаратының сүзендә тормавы, өч тапкыр вәгъдәсен бозуы хакында сөйләү дөресрәк, урынлырак булыр иде. Аннары Хәмдия шул ук хезмәт фронтына кайта бит. Аның колхоз эшенә омтылышын, аны сагынуын автор поэтик күтәренкелек белән хикәяли. Алай гына да түгел: Хәмдия эш сорап колхоз рәисе хозурына бара. Эшнең теләсә кайсы төрен башкарырга, чәче белән җир себерергә риза булуы турында сөйли. Дөресен әйткәндә, фронт өчен икмәкнең әһәмияте утын белән торфныкыннан һич тә ким түгел иде. Ләкин мәсьәләнең әнә шул аеруча мөһим ягы искә алынмый, дәүләт аппараты аны чыннан да кулга алу хәстәрен генә күрә. Хәмдия, сабыен күтәреп, бу юлы туган йортыннан, авылыннан качып китәргә мәҗбүр була. Ләкин документсыз кая барасың? Хәмдия иң соңгы чарага ябыша: ичмасам балам исән калсын, ачтан үлмәсен дип, берәр мәрхәмәтле бәндә очравына өметләнеп, сабыен юл буендагы салам эскерте янында калдыра һәм якындагы урманга кереп китә: «Шомырт, чикләвек куаклары, килүчегә юл биреп, ботакларын аерып җибәрделәр. Карт чыршы, пошынып, сагышланып, әкрен генә шаулап алды. Ул да аңа үз яныннан юл бирде һәм, арттан куа-нитә калсалар дип, ботакларын сузып аны каплап калды».

Әдәби җәмәгатьчелектә кайберәүләр «әсәргә яктырак төсләр өстәргә иде» дигән теләк белдерделәр. Н. Фәттах караңгыны яктырту, караны агарту юлы белән китмәде. Тик шулай да финалны беркадәр өметлерәк итеп тәмамлады. Ниндидер бер миһербанлы бәндә җае табылыр дип, ана белән баланы атына утыртып алып китә. Әлбәттә, журнал финалы да оста художник, психолог кулы белән язылган. Ләкин ул бөтен әсәрнең кырыс стиленнән кискен аерылып тора, сюжетның логикасына берекми. Кара җирлектәге ак ямаулык кебек, аның цензура күзен томалау өчен генә вакытлыча теркәп куелганлыгы ачык сизелеп тора. Китап вариантында Хәмдия баласын югалту хәсрәтеннән акылыннан шаша, туган колхозының салам эскерте куенында мәңгегә тынып кала.

Ә бит ул туган авылына якты хыяллар белән кайткан иде. Әмма аны соңгы чиккә җиткән хәерчелек, кайгылы хәбәрләр көтеп тора. Хәмдиянең әтисе белән абыйсы фронтта үлгән, җиңгәсен бер кесә яшел кузак алып кайткан өчен төрмәгә ябып куйганнар, үзе үстергән шул бер кесә борчак өчен әйберләрен дә конфискацияләгәннәр. Хәмдиянең фронтта яраланган энесенең аягын кисканнәр. Әнә шул фронтовик гаиләсенә, әнисе Камиләттәйгә, идарәгә барып сорагач, бер умачлык он бирмичә кайтарып җибәрәләр. Гаилә, кәҗә-сарыклар кебек, әлмә кабыгы ашарга керешә. Шул ук вакытта Камиләттәйне, ачлыктан хәлсезләнгән карчыкны, баруы-кайтуы уналты километр җирдән күтәреп егерме кило чәчү орлыгы алып кайтырга җибәрәләр. Өстәвенә әле көймәчегә түләү өчен ике сум акча да алырга кушалар. Бригадир Факия болай ди: «Кичәгенәк Яңавылдан хәбәр алынды: бер көн эчендә ташып бетерергә дигәннәр. Хөкүмәткә рәхмәт инде, иптәш Сталинга—ул бирмәсә каян алырыең бу вакытта?!» Камиләттәй бу сәфәрдән ярым үлек хәлдә кайтып егыла.

Әсәрнең сурәтле төс-бизәкләрендә аеруча контрастлылык күзгә чагыла. Авылдан качып киткәч, Хәмдия туган ягына, тирә-юненә текәлеп, сокланып карый: «юк, беркайда да җирнең өсте мондагыдай гүзәл, мондагыдай якын түгел» дип уйлый ул. Әнә шушы якты фонда эшлекле, гадел, күндәм

кешеләрнең, инсафлы, сабыр колхозчыларның кара язмышы хикәяләнә. Биредә бер Хәмдиянең генә түгел, бөтен бер гаиләнең фаҗигасе, бәхетсезлеге тасвирлана. Бу дәрәҗәдәге кырыс реализм безнең әдәбиятта булса шул Г. Ибраһимовның 1921 елгы ачлыкны сурәтләгән «Адәмнәр»ендә, М. Гафуриның «Ачлык тырнагында» поэмасында булгандыр. Хәтта илдән читтә яшәп иркеле рәвештә иҗат иткән Г. Исхакыйда да совет чынбарлыгыннан алынган андый җан өшеткеч күренешләрне очратмыйбыз. Ул бәлки халыкның шундый хәлен белеп тә җиткермәгәндер.

Совет чоры әдәбият белемендә «фаҗигале ситуацияләр тик антагонистик җәмгыятьләрдә яки социализм өчен көрәш барышында гына булалар, социализм чынбарлыгына алар хас түгел», дип раслана иде. Н. Фәттах исә трагедиянең нәкъ менә социалистик җәмгыять эчендәгесен чагылдырды. Һәм моны очраклы хәл дип тә әйтеп булмый. 1978 елда Н. Фәттах «язучы хезмәте искиткеч батырлык һәм кыюлык таләп итә. Язучыга батырлык даими рәвештә кирәк!» *(Н. Фәттах. Яшь язучы белән әңгәмә. // Идел, 1978, №9)* дип язып чыккан иде. Монда ул барыннан да бигрәк рухи батырлыкны күздә тота.

Повесть үтә тыгыз, җыйнак бизәкләр, тирән мәгънәле сурәтләр белән тукылган. Кол хәлендә тормыш кичергән Хәмдия Себердә туган улына «Ирек» исеме куша. Автор бер җирдә дә моның мәгънәсен, азатлыкка омтылышны шәрехләп тормый. Асылда бу исем үкенечле, бәхетсез язмышка ирония кебегрәк яңгырый.

Китап вариантында атлы кеше, кобуралы начальник, кибәк өстендә яткан биләүдәге сабый янында тукталып кала, аны танырга тели, «итек очы белән аңа төртеп» карый. Әнә шул тышкы хәрәкәт аның эчке рухын, нindирәк кеше булуын ачык төсмерләтә.

Җитмешенче елларда Н. Фәттах **«Итил суы ака торур»**, **«Сызгыра торган уклар»** романнарын һәм **«Кол Гали»** трагедиясен язган иде. Ә инде туксанынчы елларда ул тарихның тагын да тирәнрәк катламнарына кереп чумды. Бу юлы инде фактларны кешелек тарихының күз җитмәстәй иң ерак төпкелләреннән мул чумырып алган, киң колачлы **«Шәҗәрә»** исемле тарихи-лингвистик хезмәт язды *(Н. Фәттах. Шәҗәрә.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.—325 б.)*. Ул монда телләрнең килеп чыгышын, үзара бәйләнешен, таралышын өр-яңа ысул белән тикшерә һәм, шуның нәтиҗәләренә таянып, төрки халыкларының борынгы кешелек цивилизациясендәге урынын билгели, күченүләрне аңлатуда үз концепциясен тәкъдим итә. Китапны язуга ул ун еллык киеренке хезмәт багышлады. Автор бу эзләнүләрне милли инкыйразга, йотылуга, бетүгә каршы юнәлгән көрәш дип атады. Бу көрәш гыйльми батырлыкта, акыл куәтендә үзенең гәүдәләнешен таба, нәтиҗәсен бирә. Шуның белән бергә авторга җәмгыятьтәге куркаклык психологиясе, ул-бу булмагае дип кан калтырап тору халәте белән дә бәрелешергә туры килде. «Шәҗәрә»не автор 1982 елда тәмамлады. Китап булып исә ул сигез елдан соң, 1990 елда гына чыкты. Автор әле моның белән генә дә тукталып калмады. Хезмәтнең тагын да масштаблырак, тулырак русча вариантын язуга керешә. Шулай итеп, «Шәҗәрә»нең татарча-русча ике басмасын әзерләүгә, бастыру өчен көрәшүгә Н. Фәттах чирек гасыр гомерен багышлады. Хәзер бу капиталь хезмәтне инглиз, төрек теленә тәрҗемә итеп чыгару, аның белән киңрәк даирәне таныштыру бурычы тора.

Бу китаптагы караш үзгәлеге нәрсәдән гыйбарәт соң? Хәзер киң таралган рәсми фән раслаганча, иң элек янәсе «Һинд-европа» халыклары барлыкка килгән, алар имеш аңлырак, мәдәнирәк булганнар, ә башка халыклар, шул исәптән «алтай» кабиләләре, төркиләр исә барлык башка кавемнәрдән соңрак формалашкан, «артта калган» булып чыга аларча.

Моның шулаймы, түгелме икәнлеген ачыклау өчен Н. Фәттах иң әүвәл кешеләрнең сөйләшә башлау тарихын, авазларның, сүзләрнең, телләрнең, алфавитларның килеп чыгышын тикшерергә керешә. Ул «барлык телләр өчен дә кануннар бертөрле» дигән карашка нигезләнеп эш итә. Бер тел өчен—бер закон, икенчесе өчен—бүтән закон була алмый.

Хезмәтнең икенче бүлеге Фест дисбесен ничек укуга багышланган. Түгәрәк такта рәвешендәге ул дисбе 1908 елның 3 июлендә, Крит утравындагы

Фест шәһәре янында, борынгы сарай калдыкларын казыганда табыла. Ул моннан ким дигәндә 3700 еллар элек барлыкка килгән дип уйланыла. Кызыл балчыктан изеп җәелгән бу түгәрәкнең ике ягына да, ребус шикелле, кеше, кош, балык, балта, ишкәк, көймә, калкан, кувшин, тун, сарык башы, ими, шөшле рәсемнәре төшерелгән. Җәмгысе кырык биш төрдәге 242 рәсем бар. Алар кызыл балчыкка агач яки металл штамплар басу ярдәмендә төшерелгән. Бу рәсемнәрне дөньяда штамп белән басылган иң беренче язу үрнәге дип санылар. Туксан ел эчендә аның турында дистәләрчә хезмәт басылган. Йөзләгән галим аны укырга тырышып караган. Ләкин дисбе үзенең серен ачарга теләмәгән. Чөнки аның нинди телдә язылуы билгеле түгел. Аны грекча, семитча, баск, луви, «Һинд-европа» телләрендә укымакчы булганнар. Н. Фәттах аны төрки телдә язылган булырга ошый дип фараз итә. Һәм дисбедәге рәсемнәрне төрки сүзләре белән атап чыга. Әйтик, кеше башы белән калкан янәшәлеген «алыб» дип укый. Шул сүзләрнең баш хәрефләрен бергә тезгәч, дисбедә басылган сүз килеп чыга. Мәсәлән, беренче шакмактагы билгеләрдән «антым» кәлимәсе барлыкка килә. Тулаем бу дисбе борынгы гыйбадәтханәдә хәер-сәдака биргәндә, кайбер бүтән дини йолаларны башкарганда кулланылган дога булырга тиеш дип саный. Аның фикеренчә, сәдака бирүче зат мифик ата-бабаларына, якын туганнарына, аллаларга мөрәҗәгать итә, корбанның, сәдаканың кемнәргә багышланганын белдерә, мәрхүмнәргә оҗмах, исәннәргә—акыл тели. Ошбу дисбе хәзер дә киң таралган тәсбих вазифасын үтәгән булса кирәк. Бер үк вакытта әлеге исем-атамаларда Крит чоры төркиләренең тормыш-көнкүреше дә чагыла (диңгездә йөзү, мал асрау, тире иләү, ук-җәя, калкан, балта, тарак ясау һ. б.). Аеруча мөһиме, әлбәттә, борынгы дисбенең төркичә язылганлыгын ачыклау, аны шушы телдә укып чыгу.

Сорау туа: моны язган төркиләр Крит утравына каян килеп чыкканнар соң? Беркайдан да түгел. Н. Фәттах раславынча, алар башка халыклар белән бергә бик борынгы заманнардан бирле шушында яшәгәннәр, югары цивилизациягә ирешкәннәр.

Археологик ачышлар раслаганча, бөек Крит мәдәнияте борынгы дөньяның цивилизация үзәкләре Шумер һәм Мисыр белән бер үк вакытта диярлек барлыкка килгән һәм бер үк гасырларда яшәгән. Крит утравындагы бөек мәмләкәт үтә көчле вулкан атылуы нәтиҗәсендә моннан 3500 еллар чамасы элек һәлак була. Әлеге вулкан көле астында мәет калдыклары табылмый,—кешеләр вулкан атылганчы качып котылганнар булса кирәк. Антик чор галимнәре Геродот, Платон, Плутарх та Греция территориясендә грекларга кадәр башка халыклар яшәгәнлеге хакында язалар.

Грек мифларында сөйләнгәнчә һәм грек язучылары раслаганча, борынгы грекларның тәүге шәһәрләрен Криттан күченеп килгән кешеләр салганнар, беренче дәүләтләрен оештырганнар. Геродот раславынча, дәүләт төзелешендәге яңалыклар Криттан күчереп алынган булган. Грекларның күп кенә аллалары, мифик геройлары да Крит заманында уйлап чыгарылганнар. Грек дине Крит кешеләренең дине тәэсирендә көчәеп киткән.

Н. Фәттах Крит утравында төркиләр дә яшәгәнлеген раслый һәм моны грек теленә бик күп төрки сүзләренең үтеп керү факты белән нигезли, моңарчы грекныкы, латинныкы дип йөртелгән байтак сүзләрнең төрки сүзләр булуын дәлилли. Ул, мәсәлән, Басилевс (Басилий) сүзенең килеп чыгышын болай аңлата: бас—баш; эй—өй. Димәк, Басилей—өй, йорт башы, хуҗасы, хакиме була. Уртаклык шулай ук Алла исемнәрендә (Аполлон, Афина, Зевс, Пан, Гея), язма чыганакларда сакланган кабилә атамаларында, йола, гореф-гадәттә (карга боткасы пешерү), Гомер дастаннарында урын алган татар исемнәрендә (Гали, Галия, Фирүзә, Фәрит, Сәлмән, Әсән һ. б.), бу поэмаларның сюжетында, этнография, мифология, фольклорда, тышкы киемдә, баш, йөз төзелешендә чагыла. Н. Фәттах шулай ук борынгы Урта диңгез илләре белән хәзерге татарлар яши торган җирләрдәге топонимия уртаклыгын күрсәткән бик күп мисаллар китерә.

Туфан калкып бөтен нәрсәнең асты өскә килгәннән соң Крит, Мисыр, Кече Азия кешеләре иминрәк, тынычрак җирләргә, Алтай якларына күченәләр, югары дәрәҗәгә ирешкән дәүләт системасы төзиләр, мәдәниятен

үстерәләр. Алар монда элекке ватаннары Кече Азия, Төньяк Африка һәм Урта диңгез буендагы утрак дәүләтләрнең меңәр еллык тәҗрибәсен, дини идеологиясен, һөнәргә осталыгын алып киләләр. Монголия, Кытай тирәләрендәге сөннәрнең дәүләт төзелешендә, мәдәниятендә Крит-Атлантида, Мисыр дәүләт төзелеше һәм культурасы тулы чагылыш таба. Сөннәр көнкүрешендә күчмә тормыш шартларында да элеккеге утрак яшәешнең билгеләре саклана. «Сызгыра торган уклар» да әнә шул Көнбатыштан күчкән халыкның хәяты сурәтләнә.

Борынгы тарихның кайтавазы хәзерге татарлар сөйләмендә дә ишетелә. Безнең телдә «кызыл кар яугач» дигән әйтем бар. Ләкин Алтай, Идел-Урал төбәкләрендә беркайчан да вулкан атмаган, кызыл кар яумаган. Мондый сүзләр Атлантидадагы вулкан атылу күренешенең халык күңелендә саклануы нәтиҗәсендә әлегәчә җанлы телдә яши дип әйтергә була.

Бу хакта уйланып утырганда күз алдына кызык кына бер күренеш килеп баса. Авыл кешеләре яхшы белә: кәҗә бәтиләре гадәттә сәкегә, мич башына, кучкарга сикерүчән була, кайчак хәтта, мичкә кереп, йоннарын да көйдереп төшкәлиләр. Җәен малның бу төре—кәҗә халкы—тау битләрендә чемченеп, утлап йөрүне хозуррак күрә. Нилектән бу? Чөнки аның кыргый бабалары тау-таш, кыялар арасында көн күргән. Гәрчә кулга ияләштерелгәннән соң инде берничә мең ел үтсә дә, әнә шул яшәеш рәвеше аларның канында, геннарында сакланып калган, үз-үзләрен тотышында, гамәлләрендә әле хәзер дә күпмедер дәрәҗәдә сиздерә киләләр. Әгәр дә хайван табигатендә тормыш шартлары белән бәйле сыйфатлар, гадәт-кыланышлар шулай озак яши икән, халык хәтерендә тәҗрибә, акылның бүгенге көннәргә килеп җитүе гаҗәпмени?

Крит мәдәниятенең йогынтысы хәзерге халыкларның алфавит элементларында да чагыла. Мәсәлән, Фест дисбесендәге дулкынлы өч сызык гарәп, шумер, мисыр һ. б. язу системаларында с, ш хәрефләрен белдерә, ишкәк, сайка, җәя рәсемнәре борынгы мисыр язуында да очрый. Грек, латин алфавитларындагы Б(В), М, J, T, N, S хәрефләре дә дисбедәге билгеләрдән, төрки сүзләрдән күчерелгән.

Дисбенең беренче шакмагындагы «А» хәрефенең аталышын Н. Фәттах, күреп үткәнчә, «алаб» дип укый. Моннан соң Көнбатыш семит алфавиты, аның йогынтысында грек, гарәп язу системалары барлыкка килә. Аларның һәммәсендә дә әлеге «А» хәрефе дисбедәгечә атала: семит әлифбасында ул—«алеф», грекнныкында—«альфа», гарәптә—«әлиф» дип йөртелә. Бу факт үзе генә дә дисбедәге билгенең дөрес укылганлыгын, рәсемнәрнең төрки сүзләрне аңлатуын дәлилли. Латин, гарәп алфавитларындагы кайбер башка хәрефләрнең дә исеме хәзерге вакытта безгә бик таныш булган төрки сүзләр белән атап йөртелә.

Тарихтан билгеле булганча, б. э. к., VIII йөзләрдә аренага римлылар килеп чыга һәм Урта диңгез буе халыклары арасында, хәтта бөтен дөньяда иң көчле һәм югары культуралы җәмгыять төзүгә ирешә. Бу дәүләтне ныгытуда, үстерүдә төп өч халык: этрусклар, латиннар һәм ... сабалар катнаша. Саба турындагы мәгълүматлар башлыча грек-латин телле истәлекләрдә сакланып калган. Ул Библиядә дә телгә алына. Алардан сабаларның борынгы дәвердә иң куәтле, иң атаклы халыкларның берсе булганлыгы беленә. Шул ук саба исеме безнең якларда да очрый. Татарстанда Саба авыллары, Саба елгасы, Саба районы бар. Бу сүз, күрәсең, халык хәтерендә бик борынгыдан сакланып калган, күченгәч тә кабилә үз исемен саклаган. Моннан тыш борынгы сабалар өлкәсендә Мангела, Мутуска, Нерсы, Нурсия дигән шәһәрләр булган. Алар хәзерге Мәндил, Мәмдәл, Мәтәскә, Нырсы, Нурсия дигән авыл, елга, кеше исемнәренә туры килә. Мәтәскә, Нырсы авыллары хәзерге Саба районына урнашкан. Әнә шуларга һәм тагын башка күп кенә фактларга нигезләнеп Н. Фәттах борынгы Рим дәүләтендәге сабалар төрки кабиләләр булган дигән нәтиҗәгә килә. Ул сабалар белән бергә яшәгән латиннарның телендә дә бик күп төрки сүзләр таба, илле мең лексик берәмлекнең өч меңнән артыгы төрки һәм төркигә охшаш дигән фикер әйтә, шуларның мисалларын китерә.

Борынгы дәвердә тагын Африкада, Нил елгасы буенда Мисыр цивилизациясе барлыкка килгән. Анда кеше моннан 200 мең еллар элек яши

башлаган дип исәпләнә. Ун мең еллар элек анда сазлы җирләрне үзләштереп иген игә, мал асрый башлаганнар. Һөнәрчелек, төзелеш, фән, әдәбият-сәнгать югары үсешкә ирешә. Н. Фәттах, уртаклык мисалларына таянып, Мисырда төрки телле халыклар да яшәгән диген фикер әйтә. Мәсәлән, Нил буендагы күлне һәм Татарстандагы Минзәлә елгасын, Минзәлә шәһәрен искә төшерергә була. Автор безнең телгә гарәптән кергән дип уйланылган бик күп сүзләрнең үз сүзләребез булуын исбатлый. Уртаклык этнография, йолаларда да күренә. Мәсәлән, борынгы мисырлылардагы кебек, безнең кавемдә дә бик ерак заманнардан бирле сөннәткә утырту йоласы булган. Мисырлылар да, төркиләр дә дуңгыз асрамаганнар, аның итен ашамаганнар.

Безнең эра башларында халыклар, шул исәптән Алтай төркиләре Көнчыгыштан элекке ватаннары ягына, Көнбатышка таба күчкәннәр.

Н. Фәттах тел күренешләренә еш кына гадәти булмаган яктан якын килә, көтелмәгән нәтиҗәләр ясый. Ләкин алар ифрат күпсанлы реаль фактларга нигезләнә. Кабилә, халык, дәүләтләр тарихы, мифология, йола турында сүз барганда ул борынгы һәм хәзерге абруйлы галимнәрнең фикерләренә таяна. Ул яңа карашның җиңел генә кабул ителмәвен, кире кагылу, бәхәсләр кузгату ихтималын яхшы белеп эш итә. Шуңа күрә үзенең концепциясен ныклы нигезгә корырга тырыша. Хезмәт күпсанлы мисалларга таянып дәлилләү, исбатлау рәвешендә язылган. Н. Фәттах йөзләрчә телләргә мөрәҗәгать итә. Китапта югары гыйльми культура күзгә ташлана. Лексик берәмлекләрнең мәгънәсен ачуда, этимологиясен юллауда фәнни чыганаклар белән беррәттән борынгы халыкларның дини карашлары, гореф-гадәтләре, мифлары да дәлил буларак файдаланыла.

Шул ук вакытта бу җитди, төпле фәнни хезмәтнең сүз остасы, әдип тарафыннан язылганлыгы да сизелеп тора. Тел, тарих күренешләре җиңел аңлаешлы гади формада, детектив әсәрләрдәге кебек, мавыктыргыч шәкелдә бәян ителә.

Бер хезмәт, әлбәттә, бөтен сорауларга да тулы җавап биреп бетермәскә, кайбер аңлатмалар бәхәсле тоелырга мөмкин. Фән үсеше өчен бу—табигый хәл. Ләкин аны бөтенләй читләтеп үтү, күрмәмешкә салышу мөмкин түгел. Фәндә гипотезаның әһәмияте чиксез зур.

* * *

Ярты гасырлык иҗат дәверендә Н. Фәттах безнең әдәбиятта үзенә хөрмәтле урын яулап алды, күп кенә әсәрләрендә кеше кулы тимәгән өлкәләргә барып керде, мәгыйшәтнең яңа якларын ачты, сурәтле фикерләү культурасын үстерүгә, аны дөнья классикасы дәрәҗәсенә җиткерүгә зур өлеш кертте. Ул бер шәхес эшчәнлегендә, Н. Исәнбәт кебек, әдәби талант белән гыйльми сәләтнең бергә кушыла алуын уңышлы раслады. 1998 елда Татарстан Президенты указы белән аңа хаклы рәвештә «Татарстанның халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелде.



# ЗИРАТ КОЙМАСЫНА ТИЯР–ТИМӘС...

## БҮГЕНГЕ ӘДӘБИЯТЫБЫЗДАГЫ БЕР КҮРЕНЕШ УҢАЕННАН

*Яшәү белән шаккаттырып булмаганны,*
*Үлем белән баш катырып инде булмас.*

**Мөдәррис Әгъләм.**

...Авыл янгыр көтә. Июньнең башыннан бирле кояш рәхимсез кыздыра инде. Бик матур тишелеп, мул уңышка өмет уяткан игеннәрнең башаклары куырылды, бәрәңге чәчәге атар-атмастан көеп төште, җир сусызлыктан кибеп яргаланды. Урамда йә хезмәттә ике кеше очрашса, сүзне иң элек һава торышыннан башлый:

—Казанда бик каты яуган, кичә шофер Шәүкәт үзе күреп кайтты.

—Безнең басу артындагы Күлтәстә дә ярты сәгать буе койган, диләр.

—Инде Миржәм, Пешәңгәрләрдә дә яуган... Апазның бу ягында гына шушындый корылык, нинди гөнаһларыбыз өчен аерып җәзалыйдыр безне...

Беркөнне шул Апаз ягыннан Шушма өсләтеп янгыр килә башлагач, халык әй куанышкан иде, әмма болыт Хәсәншәехны чыккач сулга каерып, урманнар артында югалды. Бер-ике көннән нәкъ шундый хәл тагын кабатланды. Инде бу корылык ике-өч авылны эченә алган кечкенә түгәрәктә генә калды. Ә кешеләрдә борчылу, шөбһә арта гына барды. Бәрәңге дә уңмаса нишләргә кирәк, кош-кортының да, симертәсе малының да ярты ризыгы шул ич. Уңышына өметләнеп, бакчаларны да зурайтканнар, бер елны авылга хакимият башлыгы Марат Әхмәтов килеп тә шуна өндәгән иде бит. Быел яз көне шул җир өчен чак кына зур хафа чыкмый калды. Карадуган җирле үзидарәсе кишәрлекләрне көзен сукалаткан, тирес түктергән хуҗаларыннан тартып алып, яңадан бүләргә ниятләде. Җир башында үзидарә рәисе Гарәфетдин Гыйльметдинов үзе кайнашты, ызаннарны сөрергә «Т—150» тракторы килде. Яманатлы утызынчы еллар, диярсең! Тик Күмәк хуҗалыктан җибәрелгән трактор гына ул чактагыдан күпкә куәтлерәк иде. Шул елларда кулак дип каһәрләнгән, әмма күмәк хуҗалыкка иң күп ат һәм җир биргән Нәби Ибраһимовның, Даут Әхмәтҗановның, Ибени Галимовның, гаепсезгә иленнән сөрелгән беренче колхоз рәисе Закир Габсәләмовның хәзерге нәсел-нәсәбәсе биләгән түтәлләр иң элек киселәсе булып чыкты. Гауга сәбәпчесе булган бу бакчалар үр өсте корылыгыннан бигрәк тә җәфалана.

Килгән бер болытның бу тирәне урап үтүен халык нәрсәгә юрарга да белмәде. Карадуганның әлегә каләр мәчетсез, ә иске мәчет урынының буш торуы да, чит әдәп көчәеп, авыл тормышының бик гаугалыга әверелүе дә, гөнаһлы гамәлләрнең инде ачыктан-ачык эшләнүе дә телгә алынды. Һәр сөйләшү исә бер ай элек кенә булган шомлы вакыйганы искә төшерү белән тәгәлләнде:

—Васил абыйның үлгән урынын белеп, кырык чиләк су сибәргә кирәк, шунсыз яңгыр яумастыр.

Васил Тукачев, бу авылга читтән килеп яшәүче өлкән кеше, элекке шахтер, авылның Сабан туе көнне югалды да, бер атна узгач Шушма сайлы-

гыннан табылды. Аны Кукмара районындагы авылына илтеп жирләделәр, ә биредә үлемнең сере һәм шомы калды.

Июнь ае... Шушма инеше... Кеше үлеме... Васил Тукачев вакыйгасыннан тыш, тагын кайсы хәтәрлекне хәтерләтәләр соң әле болар? Әйе лә, «Казан утлары» журналының бишенче саны авылларга нәкъ июньдә килде. Язучы Мәгъсум Хужин хикәясе бар анда—«Ак төенчек». Дастаннарда гына сөйләнерлек соклангыч гыйшык пары: Гайфар белән Сәрвиназ берсе кышын, берсе язын Шушманы кичкәндә һәлак булалар. Менә хикәянең соңгы җөмләләре: «Шушма бүген тын ага. Әмма агымында шом куера. Яңа хәвеф килмәгәе».

Һәм менә «яңа хәвеф» килде дә. Тик нәрсә соң әле бу: өлкән әдипнең илаһи сиземләвеме, әллә «урыс—улап, татар юрап китерер», дигән сүзләрнең чынлыгымы? Шулай икән, нилектән хәвефле юрамаларыбыз гына юш килеп тора? Яисә без бүтән төрлене юрый да белмибезме инде? Шушы ук елның май аенда Балтач хакимиятенең аппарат житәкчесе Дания Әхмәтхан кызы Казаннан ашыгып кайтышлый юл казасында һәлак булгач, кемдер «быел хакимият йортыннан барысы өч мәет буласы икән» дигән шомлы сүз таратты. Һәм озак та үтми мәгариф бүлеге мөдире «үзе теләп» якты дөнья белән хушлашты, аннары, дәртләнеп эшләп йөргәндә, районның ветераннар оешмасы рәисенең йөрәге туктады. Исләрең китәр... Әдип Мәгъсум Хужинга әйләнеп килсәк, ул хикәяләрне болай тәмамламый иде бит, аның каһарманнары бәхетсезлек килгәндә дә яшәү омтылышы белән чәчрәп торалар иде. Тормышмы, әдипме үзгәрде? Дөньябызда шомнар күплегеме әдип ижатын сагышлар сарылыгына күмде, әллә, киресенчә, әдәбиятта өметсезлек, гажизлек төсмеренең куера баруы (коммунистик идеология мона юл куймый килде) безнең чырайларны һәм гамәлләребезне каралтып, рухыбызны, яшәү омтылышыбызны зәгыйфьлиме? Мәгъсум Хужинның шушы ук журналдагы икенче хикәясе «Әманәт»тә баш каһарман Габдиярнең һәлакәте белән тәмамлана. Аның үлеме бигрәк тә аянычлы һәм «заманча»—яшь бер хатын явызлыгыннан һәм комсызлыгыннан жан бирә сукыр карт. Хикәядә өченче кеше юк—Йомшакжан кушаматлы көчек кенә бар. Габдияр «чокыр төбендәге наратка күкрәге белән сыланганда» көчек аның куенында була.

Үзебезне ничекләр таныйк, без боларның кайсысы хәлендә бүген? Әманәтне изге күреп үтәве өчен үлемгә дучар ителгән Габдиярмы, әллә ни теле, ни исеме татарча булмаган ертлач Нифакамы? Бәлки әле бабайлар әманәтен үтибез, киләчәк бәхетебезгә иң ышанычлы нигез булырлык мөстәкыйль милли дәүләт төзибез, дигән мөкатдәс хыялыбыз да изге күңелле сукыр карт хәленнән уза алмагандыр һәм без дә аның куенындагы Йомшакжан кебек кенәдер...

Соңгы бер-ике елда әдипләребез үз геройларын «югалту», һәлак итү, әсәрләрен шундый фажигале хәлләрдә төгәлләү белән мавыгып киттеләр. Нилектән әле бу, нәрсәгә ишарә? Марат Әмирхановның «Тәкъдир», Флүс Латыйфиның «Ишелеп төшкән бәхет», Айдар Хәлимнең «Татар вакыты», Рафаэль Сибатның «Атлар рәнжеше», Адлер Тимергалинның «Игезәкләр», Гөлчәчәк Галиеваның «Тулгак» роман-повестьлары, Рафаил Газизовның «Кичер, кичерә алсаң», Мәгъсум Хужинның, югарыда телгә алынганнарыннан тыш, «Кангый илендә», Азат Ганиевның «Сөмбел» хикәяләре, Рөстәм Мингалим белән Эсфир Яһүдиннең «Ак метеор» киносценарие, Илдар Юзеевның «Эзләдем, таптым, югалттым», Аманулланың «Жәйге кырау», Рәдиф Сәгъдинең «Сынган беләзек» драмалары... Карагызсана, бүгенгенең барлык әдәби каһарманы диярлек үлеп бара түгелме? Тамашачы һәм укучыларга аларның кайсына иярергә, үрнәккә нинди... үлем сайларга? «Бәхетсез егет», «Бичара кыз» ише күз яшьсез укып булмый торган кыйссалар, Сәрвәр белән Исмәгыйль, Галиябану белән Хәлил, Хәмдия белән Бакыйның фажигале язмышлары, узган гасыр азагындагы көзләр сагышы һәм шәфәкъ моңсулыгы нилектән әдәбиятка ябырылып кайтты? «Бөтен хикмәт әнә шул гасыр азагы булуда инде», дип мәжүсиләнү урынлы булмас, еллар санын күктәгеләр түгел, жир кешеләре исәпли һәм кешелек язмышын бу саннарга шулай нык бәйләп аңлату һич ышандырмый. Бәлки, укучы ихтыяжыннан чыгып туадыр мондый әдәбият? Алай икән, ник без фажигалар яратабыз соң әле—үз хәләтебезгә тәңгәл килгәнгәме, мөлдерәмә тулы күңелләребезне бер бушату өченме? Мирхәйдәр Фәйзиләребез дә заманында нилектәндер сәхнәгә азагы үлем белән төгәлләнә торган бәхетсез язмышлар күтәреп танылганнар һәм нәкъ шулар белән әдәби осталыкка ирешкәннәр, әдәбият тарихында жуелмас

урын алганнар. Үз «үткәнебездән көлә-көлә аерылышса» торган комедияләр чоры да юк безнең. Мәшһүр драматургның «Галиябану», «Ак калфак» әсәрләре сәхнәдән төшмичә менә ничәнче буын тамашачыларын елата инде, ә оптимистик рухтагы «Кызыл йолдыз» әсәре, китапта кабатланмагач, сәхнәдә уйналмагач, инде онытылып та бетәр. Заман тәнкыйте дә бу драманы «идеология заказы белән язылган ясалма әсәр», дип кире какты. Театр сәнгатебез өчен дә фаҗигаләр генә табигый булып чыгамыни инде? «Заман хисләренә кагылам да, Галиябану, Сезне сагынам»—дип язганда шагыйрь Илдар Юзеев нәрсәне күздә тота? Галиябануның күңел пакьлеген, мәхәббәткә тугрылыгынмы? Ләкин ник әле безнең әдәби каһарманнар, безгә яшәү үрнәге булырга тиешле затлар, шагыйрьләр сокланырлык илаһи сыйфатларына фаҗигаләр, үз бәхетсезлекләре аша гына ирешәләр—бүтән юл бер дә юкмыни? Бәлки бардыр, без генә күрмибездер. Киләчәгебездән өметне өзеп, инде бәхетле буласыбызга да, үз көчебезгә дә ышанмый башлаганбыздыр, шуна күрә яшәү дә гел авыр тоеладыр.

Туфан Миннуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасын сәхнәдән беренче тапкыр карагач, безнең күңелдә нәрсә калды? Ае гына түгел, бар яктылык чыганагы бер-бер артлы сүнгәндә, күзләре дөм сукырайганда да караңгылык аръягындагы ерак йолдыздан яшәү чаткысы алган, аяусыз язмыш сынауларына бирешмәгән Мәдинәгә соклануммы? Әллә Мәдинәнең чиктән ашкан чыдамлыгын гайре табигый санау юшкынымы? Һаман хәвеф көтүме?

Әйе, шулайрак булды, чөнки әдәбиятның «бичара» һәм «бәхетсез» каһарманнары йогынтысында тәрбияләнгән, аларда үз язмышын күргән тамашачыдан бүтәнне көтәргә дә кирәкми иде. Хәвеф көтүебез исә язмыш каршында сынмас-сыгылмас Мәдинәне бөтен җаны-йөрәге аша уздырып, тетрәндергеч осталык белән уйнап, халкыбызның Габдулла Тукай исемендәге бүләген алган Дамира Кузаеваның һич көтелмәгән үлеме белән «расланды». Әйе, һич уйламаган урыннан булса да, барыбер өзелдек-сындык, тәсбихнең бер төймәсе төшеп югалды. Идеалыбыз, безнең заман герое була алмады Мәдинә. Җиңүчеләрне түгел, җинелеп, чабыш азагыннан килгән яисә юлда янып егылган атны әйбәтрәк аңлыйбыз һәм үз итәбез ич без. Туфан Миннуллин бу әсәрендә сабырлык-чыдамлык үрнәген без күреп күнекмәгән күләмдә, артык дозада биреп рәхимсез сынады сыман безне.

Күләмле һәр ике-өч яна әсәрнең берсе югалу-югалтулар белән тәгәлләнә башласа, моның кадәр гаҗизлекне укучы күңеле ничек сыйдырып-йотып бетерер? Йотылмый калганы күңелләрдән-күңелләргә күчсә? «Беттек!» дип күбрәк кеше уйлаган, өметсезлеккә төшкән саен бетүебез тизләнә барачак ич. Болай да читлектәге кош кебек боеклар-зарлылар бит без. Шуның өстенә әдәбиятыбыз да безне чарасызлык, тәкъдирнең аяусызлыгы белән өзлексез өркетеп торса, басымга ничек түзмәк кирәк?! Халыкның кәефе, ихтыяр һәм яшәү кече, хыял-омтылышлар кинлеге һәм рух сәламәтлеге өчен җаваплылык дигән нәрсә дә бар, булырга тиештер бит әле. Мисалга, Адлер Тимергалинның «Игезәкләр» повесты, (*«Казан утлары», 6 сан, 2000 ел*) баш каһарманның үлеме белән тәгәлләнүенә карамастан, укучы алдында шундый җаваплылыкны тоеп язылган, дигән фикер кала. Азат Сәйдәшевнең заяга узган, шулай узарга мәҗбүр ителгән гомере укучыны авыр уйларга салырга тиеш булса да, автор безне гаҗизлектә калдырмый. Азат Сәйдәшевнең Чәчкә исемле кызы үсеп килә икән бит! Алай гына да түгел, сабый инде әтисенең кемлеге, нинди кеше булуы белән кызыксына да башлаган. Бу инде бәләкәй булса да бәхет дигән сүз.

Зират коймасына тияр-тимәс
Очып үтте, әнкәй, казларың,—

дип язган иде бер шигырендә Рәшит Гәрәй. Нилектән әле бүгенге әдәби геройларның байтагы әнә шул казларны хәтерләтә? Кемдер бу дөньяда яшәп калырга һәм бәхетле булырга да тиештер бит. Иң элек әдип хыялында һәм китапларда гына булса да! Иншалла, китаплардан реаль тормышка да күчәрләр аннары...

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

بسم الله الرحمن الرحيم



# 9—ТӘҮБӘ (ТӘҮБӘ) СҮРӘСЕ

*(Тәүбә сүрәсе 129 аятьтән тора. Бу—бисмилласыз башлана торган сүрә. Кайберәүләр: бу Ганимәт-Әнфәл сүрәсенең дәвамы; аерым, мөстәкыйль сүрә түгел, дип бәхәсләшәләр. Шуңа күрә, аның башында бисмилла укылмый, диләр. Һиҗрәтнең тугызынчы елында хәзрәти Әбү Бәкер хаҗ әмире буларак тәгаенланды һәм мөселманнар хаҗга китте. Бу сүрә иңгәнче Рәсүлулла (с.г.с.) Аллаһның әмерләрен хаҗдагы инсаннарга җиткерер өчен, хәзрәти Галине вазифалы итте. Хәзрәти Гали хаҗ кәрванына якынлашкач, хәзрәти Әбү Бәкер: әмир буларак килдеңме, әллә йомышчы буларакмы?—диде. Хәзрәти Гали исә бары тик Мәккәдәге хаҗиларга сүрәне китерүче, йомышчы гына икәнен әйтте.*

*Хәзрәти Гали бәйрәмнең беренче көнендә Акабә Җәмрәсе янында аягүрә басып, үзенең Пәйгамбәр тарафыннан күндерелгән илче икәнен белдерде һәм хөтбә укыды. Соңыннан, шушы сүрәнең башыннан утыз-кырыклап аять укыгач, әйтте: мин дүрт нәрсәне сезгә җиткезергә бурычлымын. Беренчесе: бу елдан башлап, бер генә мөшрик тә Кәгъбә янына килергә тиеш түгел. Икенчесе: бер генә кеше дә ялангач килеш Кәгъбәне зиярәт итәргә тиеш түгел. Өченчесе: мөселманнардан башкалар җәннәткә кермәячәк. Дүртенчесе: мөшрикләр тарафыннан бозылмаган килешүләр, антлашмалар, килешү вакыты чыкканчы үз көчендә калачак».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**1.** Мөшрикләр белән булган солых-килешүләрегез Аллаһ белән Рәсүлулла тарафыннан катгыян кисәтелә.

*(Мөселманнар гарәп мөшрикләре белән солых төзеде. Ләкин мөшрикләр бу солыхны бозды. Өзлексез рәвештә килешүләрне бозганнан соң Мөхәммәд мөселманнарга да килешүләрне бозарга кирәклеген игълан итте.)*

**2.** *(Әй, мәҗүсиләр)* Җир йөзендә дүрт ай буе *(теләгәнегезчә)* йөреп торыгыз. Тик аң булыгыз, сез Аллаһны чарасыз калдыра ала торганнардан түгел. Аллаһ үзе кяферләрне тар-мар китерәчәк.

**3.** Хаҗ-и Әкбәр көнендә Аллаһ белән Рәсүлулланың инсаннарга белдерүе:
—Аллаһ вә аның илчесе мөшрикләр белән араны өзә. Әгәр тәүбә итсәгез, сезнең өчен иң хәерлесе булыр. Йөз чөерсәгез, белеп торыгыз ки, сез Аллаһны чарасыз хәлдә калдыра алачак түгел. *(Ий, Мөхәммәд)* ул кяферләргә биреләчәк җәза барлыгы турында әйтеп, «сөенче» ал.

**4.** Сезнең белән антлашма корган мөшрикләр сезгә хөсетлек кылмаса, сезнең мәнфәгатьләрегезгә каршы гамәлдә булмаганнар бу хөкемгә керми. Килешүне азагынача бозмагыз. Аллаһ гаделсезлек эшләүдән сакланганнарны сөя.

**5.** Харам айларның мөддәте чыккач, *(хыянәт иткән, ант бозган һәм сезгә өзлексез зыян салган)* мөшрикләрне кайда күрсәгез, шунда юк итегез. Аларны әсирлеккә алыгыз, поскын булып, аларны сагалап торыгыз; тәүбә итсәләр,

---

**Журнал өчен Рабит Батулла әзерләде.**

намазларын дөрес укысалар, зәкят бирсәләр, аларны үз ирекләренә куегыз. Аллаһ ярлыкаучы, гафу итүче.

**6.** Берәр мөшрик килеп, синнән сыеныр урын сораса—сыендыр. *(Синең янда, синең авыздан)* Аллаһның сүзен тыңласын. Соңыннан *(иман китермәсә дә)* аны куркыныч булмаган җиргә илтеп куй. Шундый хәбәрсез *(надан)* кавем булганнарына күрә, шулай эшләү кирәк.

**7.** Мәсҗед-и Харам янында сезнең белән килешү төзегән мөшрикләрдән башка, Аллаһ вә аның Рәсүле янында нинди ант-вәгъдә бирешү булсын, ди? Алар ант бозмаса, сез дә бозмагыз. Аллаһ *(ант бозудан)* сакланганнарны сөя.

*(«Кураеш вә алар белән бергә башка мөшрикләр антлашманы боздылар. Мөселманнар һөҗүмгә күчте һәм Мәккәне яулап алды. Килешүләрен бозмаган мөшрикләргә кагылмадылар».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**8.** Ничек була инде ул? Алар сезне җиңсә, антларын да, вәгъдәләрен дә үтәми. Авызлары белән ризалык белдерәләр дә, күңелләре белән каршы торалар. Аларның күбесе юлдан язган. **(9)** Аллаһның аятьләрен дөнья малына сатып, тугры юлдан чыктылар. Чынлап та, аларның кылганнары никадәр начар гамәлләр. **(10)** Алар мөселманнар белән булган бәйләнешләрне да, килешүне дә танымый. Алар хәттин ашкан халык. **(11)** Бары тик тәүбә итсәләр генә, намаз укыр булсалар гына, алар сезнең дин кардәшләрегез булып китәр. Аңлы кавемгә Без аятьләребезне шулай ачыклап бирәбез. **(12)** Килешү төзегәч, соңыннан антларын бозсалар, динегезгә һөҗүм итсәләр, кяферләрнең житәкчеләренә каршы сугышыгыз. Чөнки алар—вәгъдәсез бәндәләр. Бәлки алар хаинлектән ваз кичәр! **(13)** Вәгъдәләрен бозган *(мөэминнәргә)* Пәйгамбәрне *(йортыннан)* якалап чыгарырга маташкан һәм сезнең белән башлап сугышучы бер кавемгә каршы орышмаячаксызмыни? Әллә сез алардан куркасызмы? Әгәр чын мөселман икәнсез, белегез, сез алар нәселеннән куркырга тиеш түгелсез, бәлки Аллаһның җәзасыннан куркырга тиеш. **(14)** Алар белән сугышыгыз, сезнең кулларыгыз белән Аллаһ аларга җәза бирер; аларны хур итәр, сезне җиңүче кылыр, сез—мөэминнәрнең күңеленә дәва бирер. **(15)** Мөэминнәрнең күңеленнән ризасызлык нәфрәтен юар, Аллаһ тәвәккәл кешенең тәүбәсен кабул итәр. Аллаһ—белүче вә хикмәт иясе. **(16)** Юкса, Җиһадта катнашканнарны Аллаһ белми, дип уйлыйсызмы? Аллаһтан, аның Рәсүленнән, хак мөэминнәрдән башканы сердәш итмәгәннәрне белми һәм аларны Аллаһ ташлап калдырачак, дип уйлыйсызмы? Сезнең кылмышларыгыз турында Аллаһ хәбәрдар. **(17)** Аллаһтан башка тәңре эзләүчеләр үзләренең кяфер булганлыгына үзләре шаһитлек иткәнгә күрә, Аллаһның йорты—мәчетне торгызырга йөрүләренең файдасы тимәс. Аларның бөтен бу эшләре заяга китәр. Һәм алар мәңгегә ут эчендә калачак.

**18.** Аллаһка иман китергәннәр, Ахирәт көненә инанганнар, намаз калдырмаганнар, зәкят биргәннәр вә Аллаһтан башка берәүдән дә курыкмаганнар гына мәчет кордырырга тиеш. Аларның тугры юлда булачагына өмет бар.

**19.** *(Әй, мөшрикләр!)* сез хаҗиларга су биреп торуны, Мәсҗид-и Харамны төзеткәнегезне, Ахирәт көненә иман китереп, Аллаһ юлында Җиһадта сугышкан мөселманнарның кылган гамәле белән тигез, дип уйлыйсызмы? Хактыр ки, Аллаһ катында алар бертигез түгел. Аллаһ залим халыкларны тугры юлга күндермәс.

**20.** Иман китереп, һиҗрәт иткәннәр, Алла юлында маллары белән, җаннары белән Җиһадта катнашканнар дәрәҗә ягыннан Аллаһ каршысында бик тә өстеннәр. Киләчәктә котылучылар шулар булыр. **21.** Раббы аларны рәхмәте, ризалыгы белән, эчендә бетмәс-төкәнмәс нигъмәтләр булган җәннәте белән куандырыр. **(22)** Алар анда мәңгегә калачак. Шик юк ки, Аллаһ катында зур бүләкләр бар.

**23.** Әй, иманлы кешеләр! Атагыз, кардәшләрегез иманнан ваз кичеп, кяферлеккә күчсә, аларны остаз итмәгез. Аларны остаз иткән кеше үзе залим булыр.

**24.** Әйт син:

—Әгәр аталарыгыз, угылларыгыз, кардәшләрегез, хатыннарыгыз, якын туганнарыгыз, җыйган байлыгыгыз, бөлүдән курыккан сәүдәгез, рәхәт кичә торган йортларыгыз сезгә Аллаһтан вә аның Рәсүленнән, Аллаһ юлындагы Җиһадтан да кадерлерәк икән, Аллаһның хөкемен көтегез. Аллаһ фасикълар токымын тугры юлга чыгармас.

*(«Мөхәммәде Рәсүлулла (с.г.с.) Мәккәне яулап алганнан соң, унике мең кешелек гаскәре белән Таифтәге Һәвазин һәм Сакиф кабиләләренә каршы китте. Ислам гаскәренең күплеген күреп, кайбер мөселман сугышчылары: бу гаскәр беркайчан да җиңеләчәк түгел, диделәр. Һәм кәперәеп киттеләр. Хунәен үзәгенә җиткәч, алар мөшрикләрнең аз санлы төркеме белән очрашты. Мөселманнар каушап калды. Киләсе аять шул вакыйгага ишарә ясый».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**25.** Әйе, Аллаһ байтак урыннарда вә Хунәен сугышында да сезгә ярдәм итте. Күпсанлы гаскәр булуыгыз белән масайдыгыз. Ләкин сезнең күп булуыгыз файда китермәде. Киң ялан сезгә тарайды *(дошманнар каты кыса башлагач)*, сез борылып качарга мәҗбүр булдыгыз.

**26.** Соңыннан Аллаһ Рәсүленә һәм мөэминнәргә тынычлык китерде, сезнең күзгә күренми торган гаскәрләр *(фәрештәләр)* төшерде дә, кяферләрне җәзалады. Кяферләр өчен менә шундый газап.

**27.** Аллаһ тәүбә иткәннәрнең тәүбәсен кабул итә. Аллаһ ярлыкаучы, гафу итә белүчедер.

**28.** Әй, иманлы кешеләр! Мөшрикләр—шакшылыкның үзедер. Шуңа күрә, бу елдан соң алар Мәсҗед-и Харам янына килмәсеннәр. Фәкыйрьлектән курыксагыз, Аллаһ ихтыяр итсә, сезне үз мәрхәмәте илә баетачак. Шик юк ки, Аллаһның гыйлеме чиксез, Ул хикмәт иясе.

**29.** Аллаһка вә Ахирәт көненә иманмаган, Аллаһ вә аның илчесе харам иткән нәрсәләрнең харам икәнлегенә ышанмаган, хак дингә буйсынмаган китап әһелләре рисвай булып, сезгә баш орып, салымнарын үз куллары белән китереп, сезгә тапшырганнарына чаклы сугышыгыз.

**30.** Яһүдиләр:

—Гозәер—Аллаһның углы,—диделәр.

Христианнар да:

—Мәсих *(Гайсә)*—Аллаһның углы,—диделәр.

Бу аларның авызы белән әйтелә торган элеккеге кяферләрнең сүзенә бик тә охшаган. Аллаһ аларны Үзе каһәрләячәк. *(Гаҗәп!)* Ничек итеп, алар пакьтән нәҗескә керәләр?

**31.** Алар Аллаһтан баш тартып, үзләренең галимнәрен, руханиләрен вә Мәрьям углы Мәсихне *(Гайсәне)* илаһ итеп табына башладылар. Гәрчә, аларга: бары тик бер Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз, дип әйтелде. Аннан башка тәнре юк! Ул Үзенә тиң санаганнардан югары тора.

**32.** Аллаһның нурын *(алар)* авызлары белән *(өреп)* сүндермәк булалар. Ләкин, имансызларга бу ошамаса да, Аллаһ нур *(Коръән)* иңдерүен туктатмас.

*(Тәфсирчеләрнең күбесе «Аллаһның нуры» тәгъбирен Коръән белән Ислам нуры, дип шәрехлиләр.)*

**33.** *(Бу эш)* мөшрикләргә ошамаса да, Ул динен бөтен диннәрдән өстен куяр өчен, һидаят вә хак дин белән Рәсүлен юллады.

**34.** Әй, иман китергән адәмнәр! *(Кяфер)* руханилары, галимнәренең күбесе адәмнәрнең малларын хаксыз юллар белән ашыйлар вә аларны Аллаһ юлыннан яздыралар. Алтын-көмеш җыеп та, Аллаһ юлында сарыф итмәгәннәр арагызда юкмыни? Менә, син шундыйлардан «сөенче» ал: аларга хәтәр җәза биреләчәк.

*(«Яһүд равиннары белән христиан руханилары Мокатдәс китаплардагы: Инҗил,*

*Тәураттагы аятьләрне дөнья рәхәте өчен, ришвәт алыр өчен үзгәрттеләр. Бигрәк тә, хәзрәти Мөхәммәднең Пәйгамбәр булып киләчәгенә бәйле аятьләрне боздылар. Югарыдагы аять менә шуларның җирәнгеч эшләренә ишарә ясый. Аятьнең икенче өлеше исә алтын-көмеше, туплаган акчасы, малы булып та, мохтаҗларга, игелекле гамәлләргә, халык өчен кирәкле эшләргә сарыф итмәгән, ягъни, зәкят бирмәгәннәрнең Ахирәттә дәһшәтле җәза күрәчәкләре турында хәбәр итә».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**35.** *(Бу алтын-көмеш акчалар)* җәһәннәм утында кыздырылып, маңгайларына, янбашларына һәм аркаларына ябыштырылачак Көнне:

—Менә бу *(туймас)* нәфесегез туплаган нәстәләрегез. Инде туплаганыгызга күрә, тәмен дә татыгыз,—дип әйтеләчәк.

**36.** Күкләрне вә Җирне яралткан көннән алып, Аллаһның хисабына күрә, айларның саны уникe; аларның дүртесе *(сугышу)* харам айлар булып хисаплана. Диннең дөрес хисабы шулдыр. Ул айларда *(харам айларда)* үзегезгә золым итмәгез, мөшрикләр үзара берләшеп, сезгә каршы сугыш башласа, сез дә берләшеп аларга каршы сугышыгыз. Белеп торыгыз, Аллаһ *(яманлык кылудан)* сакланганнар белән бергә.

**37.** *(Харам айларның)* урыннарын күчерү көферлекне арттыру, дигән сүз. Бу гамәл кяферләрнең азгынлыгын арттырыр; Аллаһ харам кылганны бозу вә Аның харам кылганын хәләл кылмак өчен *(харам айны)* алар бер елны хәләл, икенче елны харам айга санадылар. *(Шулай итеп)*, аларның яман эшләре үзләренә яхшы булып күренде. Аллаһ кяфер халыкны тугры юлга күндермәс.

**38.** Әй, иманлы кешеләр, сезгә ни булды?—Аллаһ юлында сугышырга чыгыгыз,—диелгәч, авыраеп, җиргә сарыласыз. Фани дөньядагы бу тормышны сез Ахирәттәге бакый тормышка алмаштыгызмыни? Ләкин фани дөнья тормышының файдасы, Бакый дөньяныкына караганда бик тә аздыр.

*(«Тәбүк сугышына чыгарга әмер килгәч, җәйнең бик тә эссе вакыты булганга күрә, сәхабәләр сугышка чыгарга авырыксындылар».*

Шәех Ногмани тәфсиреннән.)

**39.** Әгәр дә сез *(кирәк чакта дин өчен)* сугышка чыкмасагыз, *(Аллаһ)* сезне сызландыручы газапка дучар итәчәк вә сезнең урынга башка бер кавемне китерәчәк; сез сугышка чыкмады, дип кенә Аллаһка зарар килмәс. Аллаһ бар нәрсәдән дә кодрәтледер.

**40.** Сез аңа *(Рәсүлуллага)* ярдәм итмәсәгез дә, аңа Аллаһ ярдәм иткән иде бит инде. Мөшрикләр аны *(Мәккәдән)* куып чыгарды, куылганнар икәү иде, берсе ул *(Рәсүлулла)* иде. Менә алар мәгарәгә кереп качты. Ул юлдашына:

—Кайгырма, Аллаһ безнең белән,—диде.

Аллаһ аңа Үзе тарафыннан сабырлык һәм күзгә күренмәс гаскәр иңдерде, кяферләрнең сүзләрен юкка чыгарды, Аллаһның сүзе исә бөектер. Аллаһ өстендер вә Ул хикмәт ияседер.

*(«Һиҗрәт заманасында мөшрикләрнең изүенә чыдый алмаенча, хәзрәти Әбү Бәкер белән хәзрәти Пәйгамбәребез Сәүер тавындагы мәгарәгә кереп кача. Куа килүче мөшрикләрнең аяк тавышларын ишеткәч, Әбү Бәкер бик нык курка. Аллаһ Тәгалә мәгарә авызын пәрәвез белән каплап куя. Куа килүчеләр: монда пәрәвез сарган, күптән кеше кермәгән куыш икән, дип, мәгарә эченә кермичә китә».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**41.** *(Әй, мөэминнәр)* җиңел булса да, авыр булса да, малларыгыз, җаннарыгыз белән Аллаһ юлында Җиһад сугышында катнашыгыз. Шулай гамәл кылсагыз, белеп торыгыз, сезгә бик тә хәерле булыр. **(42)** Сугышта табыш алу форсаты мәгълүм булса, барачак яу юлы якын булса, һичшиксез, алар синең белән яуга чыгар иде. Ләкин мәшәкатьле юл ерак иде шул. Шуңа күрә, алар яуга бармады. Аллаһ исеме белән ант итеп алар:

—Их, көчебез булса, без дә синең белән яуга барыр идек,—дип үзләрен үзләре һәлак итте. Гәрчә, Аллаһ аларның ялганчы икәнен тәгәл белә иде. **(43)** Аллаһ сине гафу итте. Тугры кешене сынап, аның тугры икәнлеген яки ялганчы булганын ачыкламыйча, ни өчен син аларга сугыштан калырга рөхсәт иттең? **(44)** Аллаһка вә Ахирәт көненә инанганнар маллары, җаннары белән сугышыр өчен синнән рөхсәт сорамас. Аллаһ тәкъва *(чын)* мөселманнарны бик тә яхшы белеп тора. **(45)** Бары тик Аллаһка вә Ахирәт көненә ышанмаганнар сугыштан калырга синнән рөхсәт сорарлар һәм аларның күңелләрен шом басар, алар шуңа аптырап йөрер. **(46)** Сугышта катнашырга теләгән булсалар, алар, һичшиксез, алдан ук хәзерләнгән булыр иде. Ләкин Аллаһ аларның бу кылмышларын *(ягъни, ихлас түгеллекләрен)* ошатмады, аларның сугышка баруларын теләмәде. Аларга:

—Өегездәгеләр белән бергә утыра калыгыз,—диде. **(47)** Алар сезнең белән бергә сугышка чыккан булсалар да, арагызны бозудан һәм фетнә чыгарудан башка нәрсә эшләмәгән булырлар иде. Аларның *(фетнәви)* сүзенә колак салучылар да арагызда табылыр иде. Аллаһ гөнаһлыларны гаять яхшы белә. **(48)** Хактыр ки, алар элек тә фетнә чыгарырга йөрделәр вә сиңа күпме мәкер кордылар. Ниһаять, дөреслек инде, аларның көенечено, Аллаһның әмере җиренә җиткерелде. **(49)** Аларның шундыйлары да бар:

—*(Сугышка бармаска)* миңа рөхсәт бир, мине фетнәгә *(вәсвәсәгә, ягъни мал талау, әсир хатыннар белән зина кылуга)* юлыктырма,—дип хәйлә корганнары да. Белеп торыгыз ки, алар чынлыкта үзләре фетнәчеләрдер. Кяферләрне, һичшиксез, җәһәннәм уты чолгаячак. **(50)** Сиңа бер игелек *(җиңү, ганимәт, үлҗә малы)* килсә, алар ачудан кабарыр. Башыңа берәр бәла *(җиңелү, талану)* килсә, алар:

—Ярый әле, без алдан әмәлен күрдек *(сугышка бармадык)*,—дип, борыннарын чөеп китәләр.

**51.** Әйт син:

—Аллаһ язганнан башка нәрсә безнең өскә килмәс. Ул—безнең химаячебез. Шуңа күрә, сез—мөселманнар, бары тик Аллаһка инаныгыз,—диген. **(52)** Әйт син:

—Сез: безгә ике игелекнең берсе килер, дип көтәсезме? Без дә: сезнең башыгызга ике яманлыкның берсе килер, дип көтәбез. Сезгә Аллаһтан җәза килер яки Аллаһ сезне безнең куллар белән һәлак итәр, дип. Сез дә көтегез, без дә көтәбез,—диген.

***(Мөселманнар сугышта үлсә дә, бәла түгел, шәһидләр турыдан-туры җәннәткә керер, исән калсалар да, сөенеч. Кяферләргә икесе дә афәт, Аллаһ биргән җәза да, мөселманнар кулыннан күргән җәза да.)***

**53.** Әйт син *(монафикъларга)*:

—Үз теләгегез белән биргән чыгымнаргыз *(садакагыз)* да, ирексездән биргәнегез дә кабул ителмәс, чөнки сез юлдан язган токым,—диген. **(54)** Аллаһка вә аның Рәсүленә ышанмаулары аркасында, намазны теләр-теләмәс укыганга күрә, садаканы рыя белән, *(авырыксынып)* биргәнгә күрә, аларның садакалары кабул булмады.

**55.** *(Ий, Мөхәммәд)* аларның *(кяферләрнең)* байлыгы вә балаларынын күплеге сине кызыктырмасын, Аллаһ фани дөньяда ук аларның газапларын күбәйтеп, аларның кяфер буларак җан бирүләрен тели.

**56.** *(Монафикълар)* без дә сезнең кебек *(мөселманбыз)*, дип Аллаһ исеме белән ант итә. Гәрчә, алар сезнең кебек *(мөселман)* түгел, алар бары тик *(сезнең кылычтан)* курыккан бер кавемдер. **(57)** Сыеныр урын яки качарлык мәгарә яки кереп котылырлык бер тишек тапсалар, алар *(сездән, диннән качып)* шул тарафка ыргылырлар иде. **(58)** Садакалар хакында сине гаепләгәннәр дә бар. Садакалардан аларга да *(бер өлеш)* бирелсә, разый булалар, шаять, аларга садакалардан *(өлеш)* бирелмәсә, ачуланалар. **(59)** Әгәр алар Аллаһ белән Рәсүле биргәннәргә разый булып:

—Аллаһ безгә житә, озакламый Аллаһ нигъмәтен бирәчәк, Рәсүлебез дә

безгә игелекле булачак; без бары тик Аллаһтан гына өмет итәбез,—дип әйтсәләр, бик яхшы булыр иде дә соң. **(60)** Садака *(зәкят)* Аллаһтан бер фарыз буларак, бары тик юксылларга, мескеннәргә, *(зәкят эшләрен башкаручы)* йомышчыларга, күнелләре *(Исламга)* ятканнарга, *(ирекка чыгу өчен җан аткан)* колларга, бурычка батканнарга, Аллаһ юлында көч сарыф итеп, Җиһадта катнашканнарга, юлчыларга бирелергә тиеш. Аллаһ барысын да бик яхшы белеп торучы һәм хикмәтләр ияседер.

**61.** *(Монафикълар)* арасында Пәйгамбәрне кимсетеп сөйләүчеләр дә бар, алар:

—Ул—колак *(ягъни бөтен нәрсәне тыңлап-ишетеп торучы)*,—диделәр.

Син аларга:

—Ул сезнең өчен яхшылыкның колагы,—диген.

Ул Аллаһка иман китерә һәм иман китергән кешеләргә ышана; арагыздан иман китергән кешеләргә рәхмәт. Аллаһның илчесен рәнҗеткәннәргә хәтәр җәза булыр,—диген. **(62)** Сезнең ризалыгыгызны алмак өчен, алар Аллаһ исеме белән ант итә. Әгәр алар чыннан да мөселман булсалар, Аллаһ белән Рәсүлулланың ризалыгын казансыннар. **(63)** Алар шуны да белмиләрме икәнни соң, кем дә кем Аллаһ белән Рәсүлуллага каршы гамәл кыла, шул җәһәннәм утында мәңге калачак. Менә шушы була инде рисвайга калу. **(64)** Монафикълар күнелләрендә булган *(мәкерне)* ачып сала торган аять индерелүеннән куркалар. Әйт:

—Сез көлегез, Аллаһ эчегездәге хөсетлекне ачып салачак,—диген. **(65)** Әгәр алардан *(мыскыллы көлүләре турында)* сорасаң, шик юк ки:

—Без бары тик шаяртабыз гына,—дип әйтәчәкләр.

Әйт син:

—Аллаһтан, Аның аятьләреннән, Аның Пәйгамбәреннән көләргә җөрьәт итәсезме?—диген. **(66)** Акланып маташмагыз, чөнки сез иман китереп тә соңыннан кяферлеккә күчкән затсызлар булдыгыз. Тәүбә иткәннәрегезне ярлыкасак та, гөнаһларына күрә, башкаларына җәза бирәчәкбез. **(67)** монафикъ ирләр белән монафикъ хатыннарның барысы да бер чыбыктан сөрелгән; алар бозыклыкка йөз тотучылар, игелектән баш тартучылар, саранннар. Алар Аллаһны онытты. Аллаһ та аларны онытты. Чөнки монафикълар нәжеслекнең үзедер.

*(Аллаһ та аларны онытты тәгъбиренең мәгънәсен тәфсирчеләр болай аңлата. Монафикъларга ярдәм итмәү, аларны тугры юлга күндермәү, монафикълыклары, ягъни икейөзле булулары аркасында алар Аллаһның нигъмәтеннән, Аның игътибарыннан читтә калу, дигән сүз. Әлбәттә, Аллаһ аларның гөнаһларын онытмады, онытмаячак та, киләчәктә аларга җәза бирәчәк.)*

**68.** Аллаһ икейөзле ирләрне дә, икейөзле хатыннарны да, кяферләрне дә җәһәннәм утында мәңге яндырырга вәгъдә итте. Аллаһ аларга җитәр, Аллаһ аларга ләгънәт орды. Аларга бетмәс-төкәнмәс җәза хәзерләп куйды. **(69)** *(Әй, монафиклар, кяферләр)* сездән элек яшәгәннәр кебек, сез дә көферлек кылдыгыз. Сезнең белән чагыштырганда, алар куәтлерәк тә, баерак та, балалары да күбрәк иде, рәхәт яшиләр иде. Элек яшәгәннәр кебек, сез дә үз өлешегездән рәхәт күрдегез, алар кебек, сез дә азгынлыкка чумдыгыз. Шундыйларның гамәлләре фани дөньяда да, Ахирәттә дә файда бирмәс. Алар зур югалтуларга дучар. **(70)** Әллә соң аларга әүвәл яшәгәннәр *(нең гөнаһлары)* турындагы хәбәр барып ирешмәдеме? Нух, Гад һәм Сәмүд халыклары, Ибраһим кавеме, Мәдьян кешеләре, асты өскә килгән шәһәрләр турында хәбәр аларга ишетелмәдеме икәнни? Аларга пәйгамбәрләр ачык мәгънәле аятьләр алып килде. Аллаһ аларга җәбер бирмәгән дә булыр иде, ләкин алар үзләренә үзләре җәза алды.

*(«Пәйгамбәрләр алып килгән ул аятьләрне тегеләр ялганга чыгарды. Нух пәйгамбәр үз халкына күндерелде, үз халкы аны инкарь итте, Аллаһ илчесе буларак танымады, Аллаһны бер дип санамады. Һәм Нухның халкы суга батып һәлак булды. Гад кавеменә исә Һуд пәйгамбәр җибәрелгән иде. Гөнаһлары өчен аларны Аллаһ дәһшәтле җил-давылда һәлак итте. Хәзрәти Салихны үз халкына пәйгамбәр итеп юллады. Аның халкы да җир тетрәвендә юкка чыкты. Хәзрәти Ибраһим кавеме эшәке чебен һөҗүменнән үлеп бетте. Мәдьян халкына Шөгаеб илче*

*булып килде. Гонаһлы халкы утта янып һәлак булды. Лут пәйгамбәрнең халкы шәһәр хәрабәләре астында юк булды».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**71.** Мөэмин ирләр белән мөэминә хатыннар бер-берләренең дустыдыр. Алар игелек юлына өнди, яманлыклардан баш тартырга үгетлиләр, намаз калдырмыйлар, зәкят бирәләр, Аллаһка һәм Аның Рәсүленә итагать итәләр. Менә шундыйларга Аллаһ рәхмәтен бирер. Шик юк ки, Аллаһ бөек һәм хикмәт ияседер. **(72)** Аллаһ мөселман ирләренә, мөслимә хатыннарга мәңге яшәү өчен арыкларыннан сулар ага тора торган җәннәтләр һәм Гаден оҗмахларында яхшы урыннар хәзерләп куйды. Аллаһның ризалыгы һәрнәрсәдән дә өстендер. Менә бөек котылу шушы булыр.

**73.** Ий, Пәйгамбәр! Кяферләргә һәм монафикъларга каршы Җиһад ит. Аларга кырыс бул. Аларның барыр җире—җәһәннәм. Бик тә хәтәр ул—алар барачак җир. **(74)** *(Ий, Мөхәммәд)* алар:

—Валлаһи, көфер сүз әйтмәдек,—дип Аллаһ исеме белән ант итә.

Гәрчә, көфер сөйләделәр һәм мөселман булганнан соң янә кяферлеккә кайттылар. Кулларыннан килмәгән эшкә алындылар. Аллаһ белән Рәсүл аларны *(мөселманнарны)* үз нигъмәтләре белән баетканы өчен үч алырга тырышалар. Әгәр алар *(бу эштән)* тәүбә итсәләр иде, үзләренә яхшырак булыр иде. Иманнан йөз чөерсәләр, Аллаһ аларны фани дөньяда да, Ахирәттә дә әрнүле җәза бирүче, газапка дучар итүче булыр. Җир йөзендә аларның ярдәмчесе дә, дуслары да юк.

*(«Мәдинә халкының бер кавеме фәкыйрь яши иде. Рәсүлулла килгәч, баеп киттеләр. Монафикълар алардан көнләшеп, Пәйгамбәргә каршы фетнә кора башладылар».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**75.** Алар арасында:

—Әгәр Аллаһ безгә байлык бирсә, һичшиксез, садака бирер идек һәм, әлбәттә, без дә изгеләрдән булыр идек,—дип Аллаһ каршысында ант итүчеләр дә бар. **(76)** Ләкин Аллаһ хәзинәсеннән аларга байлык бирелгәч, саранланып *(Аллаһ әмереннән)* баш тартып, биргән антларын боздылар. **(77)** Ниһаять, Аллаһка биргән вәгъдәләре һәм ялган таратулары аркасында, Аллаһ Тәгалә аларның күңеленә Ахирәткә хәтле ияреп бара торган нифак-монафикълык *(фетнәче һәм икейөзлелек)* гадәтен салды. **(78)** Аллаһ аларның *(монафикъларның)* серен, яшерен пышылдашуларын һәм гөнаһ кылганнарын бик яхшы белеп торганын *(монафикълар үзләре)* белмиләрме икәнни соң? **(79)** Үз теләге белән садака биргән мөселман кешесеннән вә ничардан бичара тапкан малыннан әз генә садака биргәннәрдән *(монафикълар)* мыскыл итеп көләләр. Аллаһ аларның үзләрен мәсхәрә итәчәк. Вә аларны әрнеткеч газапка салачак.

*(«Монафикъларның башлыгы Гобәй үлем түшәгенә егылгач, аның улы Габдулла хәзрәти Мөхәммәд янына килеп, атасы өчен гафу сорап, Аллаһка дога кылуын үтенде. Габдулла саф мөселман булганга күрә, Рәсүлулла, аның хәтере калмасын дип, Гобәйне ярлыкавын үтенеп, Аллаһка дога кылды. Шуннан соң сиксәненче аять иңдерелде».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**80.** *(Ий, Мөхәммәд)* алар өчен гафу сорасаң да, сорамасаң да, аларны ярлыка дип, җитмеш тапкыр ялварсаң да, Аллаһ аларны гафу итмәячәк. Аллаһны вә аның илчесен инкарь иткәннәренә күрә, шулай мәгъкуль. Аллаһ фасикълар өерен туры юлга ирештермәс.

**81.** Аллаһның Рәсүленә карышып, сугышка бармыйча калганнар *(монафикълар)* куаныштылар. Аллаһ юлында маллары, җаннары белән сугышуны хуп күрмәделәр:

—Бу эсседә яуга баралармыни?—дип бер-берләрен котырттылар.

Син әйт:

—Тәмуг уты моннан да хәтәр эссе булачак,—диген.

Их, алар шуны аңласалар иде. **(82)** Һәйдә! *(Монафикълар)* бераз көлсеннәр, кылганнарына күрә *(икейөзлелек өчен)* күп еларлар. **(83)** Әгәр

Аллаһ сине аларның төркеменә кире кайтарса, алар синнән *(синең белән бергә яуга)* чыгарга рөхсәт сораса, аларга әйт:

—Һичбер вакытта да сез минем белән *(яуга)* чыкмаячаксыз вә һичбер вакыт сез минем белән дошманга каршы сугышмаячаксыз. Сез узганында да өегездә утырырга риза булдыгыз, өйдәгеләрегез белән рәхәтләнеп утыра бирегез,—диген. **(84)** Аларның бер генә мәрхүменә дә намаз укыма; андыйларның кабере очында торма; чөнки алар Аллаһ белән Рәсүлне инкарь иттеләр вә фасикъ булып үлделәр. **(85)** Аларның байлыгы һәм балаларының күплеге сине хәйранга калдырмасын. Чөнки Аллаһ аларны шушы дөнья байлыгы белән *(сынап)* җәзаларын күбәйтә вә кяфер буларак җаннарын алырга тели. **(86)**—Аллаһка иман китерегез, Рәсүле белән бергә Җиһадта катнашыгыз,—дип бер сүрә индерелгәч, алар арасындагы байлар:

—Зинһар, безне өйдәгеләребез янында калдыр,—дип үтенделәр. **(87)** Алар хатыннары янында, өйдә калганнарына куанышты. Аларның күңелләренә *(язмышларына монафикъләр дип)* мөһер сугылды. Ләкин алар моны аңламый. **(88)** Әмма Пәйгамбәр белән бергә иман китергәннәргә, маллары белән дә, җаннары белән дә Җиһад сугышында катнашканнарга бөтен нигъмәтләр бирeләчәк вә алар гына бәхет тантанасында булачак. **(89)** Аллаһ аларга мәңге яшәр өчен арыкларыннан чишмәләр агып торучы җәннәтләр хәзерләп куйды. Менә, бөек казаныш шушы булыр. **(90)** Баш иеп, синең янга килгән бәдәви гарәпләре сугышка бармас өчен синнән рөхсәт сорадылар. Аллаһ турында, Рәсүл хакында ялган таратучылар да *(сугышка бармыйча)* утырып калды. Шулар арасындагы кяферләргә әрнүле җәза һәм газап биреләчәк. **(91)** Аллаһка вә аның Рәсүленә ихлас иман китергәннәр арасында зәгыйфьләргә, чирлеләргә, сугыш кораллары сатып алырга җае булмаганнарга *(сугышта катнашмасалар да)* гөнаһ юк. Игелек кылганнарга шелтә юк. Аллаһ ярлыкаучы, кичерүчедер. **(92)** *(Синең белән бергә сугышка барырга ат, дөя сатып алырга акчалары булмаганнар)* килгәч:

—Сезне атландырып сугышка җибәрергә мөмкинлегем юк,—дидең. Алар *(сугышта катнаша алмаган кайгыдан)* күз яшьләре белән елап өйләренә кайтып китте. Андыйларга да *(сугышта катнашмаганнары өчен)* гөнаһ юк. **(93)** Бай булып та *(сугышка бармаска)* рөхсәт сораганнарны җәзага тартырга юл бар. Алар өйдәгеләре янында калганга куандылар. Аларның күңеленә *(кара)* мөһер орылды, ләкин алар моны белми. **(94)** Сез сугыштан кайткач, алар гафу үтенер. Әйт:

—Гафу үтенмәгез; без сезгә ышанмыйбыз. Аллаһ сезнең *(кем икәнлегегез)* турында безгә хәбәр итте инде. Аллаһ та, илчесе дә сезнең гамәлләрегезне күрер. Аннан соң сез яшеренне дә, ачыкны да белүче Аллаһ хозурына кайтарылачаксыз. Шулчак Ул сезнең кылмышларыгызны фаш итәр. **(95)** *(Сез сугыштан кайткач)* алар: безгә кагылмагыз, дип Аллаһ исеме белән сезне каргаячак. Алардан ваз кичегез, кагылмагыз. Чөнки алар—нәҗес кешеләр. Аларның ятагы—җәһәннәм. *(Яман)* гамәлләренә күрә аларга шул тиеш. **(96)** Үзләреннән риза булуыгызны теләп, алар ант итәчәк. Сез алардан риза булсагыз: Аллаһ фасикъларны хуп күрми. **(97)** Бәдәвиләр *(чүл гарәпләре)* көферлектә, икейөзлелектә тагын да хәтәррәк, Аллаһның Рәсүле аша иңдергән *(хөкемнәр)*нең чиген белмичә яшәү аларга хас. Аллаһ бөтен нәрсәнең асылын белүче, хикмәт ияседер. **(98)** Бәдәвиләрнең бер кавеме: *(Аллаһ юлында)* сарыф ителгән малларыбыз әрәмгә китте, дип уйлый; сезнең башка бәла килүен көтә. Аларның үз башына бәла төшәчәк. Аллаһ чынын ишетеп, чынын күреп торучы. **(99)** Бәдәвиләрнең бер төрлесе исә, Аллаһка, Ахирәт көненә иман китергәннәренә күрә, *(Аллаһ юлында)* сарыф иткәннәре аркасында, Аллаһка якынаябыз, Пәйгамбәрнең догаларына лаек булабыз, дип өметләнә. Шунысы хактыр ки, сарыф иткәннәре үзләре өчен якынлыктыр. Аллаһ аларны рәхмәтендә йөздерәчәктер. Аллаһ ярлыкаучы, чиксез мәрхәмәтледер. **(100)** Мөһаҗирләрдән *(ватаннарын ташлап күченергә мәҗбүр булганнардан)* вә әнсарилардан *(Ислам юлында ярышучылардан, Исламны иң беренче кабул иткәннәрдән)* элек килгән һәм аларга ияүчеләрдән Аллаһ канәгать калды; алар да Аллаһтан разый булды. Аллаһ аларга мәңге яшәр өчен бәреп чыккан чишмәләре булган җәннәтләр вәгъдә итә. Менә, бу—иң бөек котылыш булачак.

*(Әнсарилар—Исламны кабул иткәннәргә, һиҗрәт иткәннәргә ярдәм итүчеләр.)*

**101.** Тирә-ягыгыздагы бәдәвиләрнең һәм Мәдинәдә яшәүче халыкның бер кавеме монафикъ һәм киребеткән икейөзле халык. Сез аларны белмисез, бары тик Без беләбез. Аларга икеләтә җәза бирәчәкбез. Ахырда да зур газапларга дучар итәчәкбез. **(102)** Бүтән бер кавемнәре дә бар, алары гөнаһларыннан ваз кичеп, тәүбә итеп, кылган яман эшләрен яхшы эшләре белән аралаштырды. Ихтимал, Аллаһ Тәгалә аларның тәүбәләрен кабул да итәр. Аллаһ чиксез мәрхәмәтле ярлыкаучы. **(103)** *(Ий, Мөхәммәд)* мөселманнарның малларыннан *(мәгълүм бер күләмдә)* садака ал. Шуның белән алар пакьләнер, канәгать калыр. Аларны доганнан ташлама, чөнки синең догаларың аларга юаныч ләззәте бирә. Аллаһ барысын да ишетеп, белеп торучы.

**104.** Бәндәләрнең тәүбәсен кабул итүче, садакаларны алучы Аллаһ икәнен алар белмимени? Шик юк ки, тәүбәләрне кабул итүче, чиксез мәрхәмәтле бер—Аллаһ.

**105.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син:

—Теләгәнегезчә гамәл кылыгыз. Аллаһ та, Рәсүлулла да, мөселманнар да кылганнарыгызны күрәчәк. Яшеренне дә, ачыкны да белүче Аллаһ хозурына кайтарылачаксыз. Ул сезнең ниләр кылганыгыз турында хәбәр бирәчәк,—диген.

**106.** Аларның бүтән бер кавеме исә Аллаһның хөкеменә калдырылды. Аллаһ аларга җәза бирер яки аларның тәүбәсен кабул итәр. Аллаһ барысын да белүче хикмәт ияседер.

*(«Сугышка бармый калганнарны Аллаһ Тәгалә өч төркемгә аерды: монафикълыкны (икейөзлелекне) үзләренә гадәт-холык итеп алганнар. Гөнаһларын инкарь итмичә, тәүбә иткәннән соң, игелек юлында малларын сарыф иткәннәр. Гөнаһларын танымаганнар, тәүбә итмәгәннәр».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**107.** *(Мөселманнарга)* зарар эшләмәк, көферлекне арттырмак, мөселманнарның арасын бозмак һәм тагын, элгәре заманда сугышкан кебек, Аллаһка вә аның илчесенә каршы сугышканны *(Әбү Гамирның килгәнен)* күрер өчен, мәчет кордылар . һәм:

—Игелектән башка берни дә кылмадык,—дип ант иткәннәр дә монафиклар арасында бар. Гәрчә, аларның ялганчы икәненә Аллаһ катгыян шаһитлек итә.

*(«Монафикълар мәкер илә бер мәчет бина кылдылар. Әбү Гамир исемле бер монафикъны Рум кайсәренә, мөселманнарга каршы сугышыр өчен, гаскәр сорарга юлладылар. Шул икейөзле Гамирның гаскәр белән килүен монафикълар үзләре төзегән мәчет манарасыннан биш күз белән көтә иде. Бу аять иңгәч, Мөхәммәд ул мәчетне җимертте».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**108.** *(Ул мәчет эчендә)* зинһар, *(намазда)* басып торма *(гыйбадәт кылма)*. Элек заманнарда тәкъвалык белән корылган мәчеттә намаз уку мең өлеш арттык. Анда пакьләнергә теләгән адәмнәр генә керә. Аллаһ та пакьләнгәннәрне сөя. **(109)** Аллаһ каршысында гөнаһ эшләүдән куркуы аркасында бина корган кешеме игелекле, әллә бинасын ишелергә торган яр кырына корып, бинасы белән бергә җәһәннәм утына җимерелеп төшкән кешеме игелекле булыр? Аллаһ игелексезләрне тугры юлга күндермәс.

**110.** Алар *(монафикълар)* төзегән ул мәчет бинасы йөрәкләре ярылып үлгәнчегә чаклы күнелләрендә шом булып торачак. Аллаһ барысын да бик яхшы белеп торучы хикмәт иясeдер.

**111.** Аллаһ мөэминнәрне малларын, җаннарын *(үзләренә биреләчәк)* җәннәт бәрабәренә сатып алды. Чөнки алар Аллаһ юлында сугышыр, үтерерләр, үлерләр. Тәүратта, Инҗилдә вә Коръәндә Аллаһ шулай вәгъдә иткән иде. Аллаһтан башка үз сүзендә нык торучы тагын башка бер зат бармы? Шуңа

күрә, Аның белән алыш-бирешегезгә сөенегез. Менә бу бөек бер казаныш булачак.

*(«Мәккәдә Акабә кичәсендә әнсарилардан җитмеш кеше Рәсүлулла (саллаллаһү галәйһи вә сәлләм)гә тугры булырга ант иткәндә араларыннан Габдулла бине Рәваха: Йа, Рәсүлулла, Раббың өчен вә синең өчен шартлар ничек була инде?—диде. Рәсүлулла әйтте: Раббым өчен шартым: Аңа гыйбадәт кылуыгыздыр. Аңа тиң башка бер зат та эзләмәгез. Үзем хакында шартым: үзегезнең җаныгызны, малыгызны ничек саклап (кадерләп) тотасыз, мине дә шулай яклагыз (ярдәм итегез),—диде. Янә сорадылар: шулай кылсак, безгә нинди әҗер?—диделәр.— Җәннәт,—диде Пәйгамбәребез. Нинди файдалы алыш-биреш. Моннан соң без сүзебездән чыкмабыз, чыгарга теләмәбез дә, диделәр әнсарилар. Югарыдагы аять менә шушы хакта сөйли».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**112.** Тәүбә итүчеләр, гыйбадәт кылучылар, *(Аллаһка)* дан җырлаучылар, *(Аллаһ юлында ураза тотучы)* сәяхәт итүче *(галимнәрне)*, рөкүгъка иелгәннәр, сәҗдәгә егылганнар, игелеккә өндәп, яманлыктан тыйганнар вә Аллаһ боерган чикләрне бозмаучылар—мөселманнар. Шулардан *(сез җәннәткә керәчәксез, дип)* сөенче ал.

**113.** Мөшрикләр өчен, хәтта кардәшегез булса да, аларның җәһәннәмгә керәсе мәгълүм булгач та, аларның гөнаһларын гафу иттерер өчен Аллаһка ялварып дога кылу пәйгамбәрләргә дә, башка иманлы кешеләргә дә ярый торган эш түгел.

*(«Рәсүлулла (с.г.с.) абыйсы Әбү Талип өчен Аллаһтан ярлыкау сорый. Ләкин аның догасы кабул булмый. Өстәге аять шул турыда».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**114.** Атасына вәгъдә биргәнгә генә Ибраһим атасы өчен Аллаһтан гафу сорап, дога кылырга ниятләде. Атасының Аллаһ дошманы икәнлеге беленгәч, ул догадан баш тартты. Шик юк ки, Ибраһим бик йомшак холыклы, бик тә сабыр бер адәм иде.

**115.** Аллаһ бер халыкны тугры юлга бастырганнан соң, сакланырга кирәкле нәрсәләр турында үзләренә хәбәр иткәненә кадәр, аларны юлдан яздырачак түгел. Аллаһ һәрнәрсәне үтәли күреп торучы. **(116)** Күкләрнең һәм Җирнең хуҗасы бер Аллаһтыр. Ул тереltер вә үтерер. Сезнең Аллаһтан башка химаячегез дә, ярдәмчегез дә юк. **(117)** Күңелләре бозыклыкка таба кәкрәйгәч, Пәйгамбәрне һәм кыен вакытларда *(Тәбүк сугышына барганда)* аңа ияргән мөһаҗирләр белән әнсариларның бер төркемен Аллаһ гафу итте. Чөнки Ул аларга чиксез шәфкатьле, хәтсез мәрхәмәтле.

*(«Тәбүк сугышына чыгар алдыннан, монафикълар килеп, хәйләләп, сугыштан калырга рөхсәт сорадылар. Пәйгамбәр аларга рөхсәт итте. Шуның аркасында Аллаһ Тәгалә Пәйгамбәрне катгыян кисәтте. Монафикъларның коткысына бирелгән кайбер мөселманнарның да эченә вәсвәсә төште. Ләкин алар соңыннан тәүбә итте. Тәбүк явында катнашмаганнар арасында Кягаб бине Малик, Һилял бине Өммия белән Мәмарә бине Рабин исемле сәхабиләр дә бар иде. Киләсе аятьтә шуларга ишарә бар».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**118.** Һәм *(сугыштан)* калдырылган өч кешенең тәүбәсен дә кабул итте. Җир йөзе никадәр киң булуына карамастан, аларга тар кебек тоела башлады, алар вөҗдан газабында интегә башлады һәм, ниһаять, алар Аллаһның газабыннан бары тик Аллаһның Үзенә сыенып кына котылып була икәнен аңлады. Соңыннан Аллаһ аларның тәүбәсен кабул итте. Аллаһ тәүбәләрне күпләп кабул итүче, ярлыкаучы.

**119.** Әй, иман китергән кешеләр, Аллаһ каршысында гөнаһ кылудан куркыгыз һәм тугры юлдагылар *(иманында, гамәлендә, антында, сүзендә, Үзенә тугры булганнар)* белән бергә булыгыз.

**120.** Мәдинә халкына һәм аларның әйләнә-тирәсендәге бәдәви гарәпләренә

Аллаһның илчесе—Рәсүлдән аерылып *(сугыштан)* калмаска, аны саклаудан битәр үз жайларын гына кайгыртмаска кирәк иде. Алар Аллаһ юлында сусау, жәфа, ачлыкка дучар булып, кяферләрнең ачуын китерелек жиргә басып керсә вә жинсә, бу изге гамәлләре өчен аларга савап язылган булыр иде. Аллаһ игелек кылганнарның әжерен юкка чыгармас.

**121.** Аллаһ аларны иң гүзәл гамәлләренә күрә бүләкләү, кечкенә һәм олы чыгымнары, кыен юллар узганнары өчен савап язар.

**122.** Мөселманнарның бөтенесе берьюлы яуга чыгулары мәжбүри түгел. Һәр төркеменнән берничәсе дин гыйлеме алыр өчен, сугыштан кайткан, туганнарына дин өйрәтер өчен өйдә калды. Шуннан соң, мөгаен, алар сак булыр.

*(Тәбүк сугышында катнашмаганнар турында кырыс аятьләр иңгәннән соң, мөселманнар күпләп сугышка чыга башлады.)*

**123.** Әй, иман китерүче халык, якыныгызда булган *(һөҗүмгә әзер торучы)* кяферләр белән орышыгыз вә алар сезнең кодрәтегезне татысын. Белеп торыгыз ки, Аллаһ *(гөнаһтан)* сакланганнар белән бергәдер.

*(«Ислам диненең максатларыннан берсе—солых, тынычлык саклау. Ниса сүрәсенең 128 нче аятендә, солых тагын да яхшырак, дип боерылды. Ләкин югарыдагы аять исә, диннең һәм дәүләтнең ышанычлы мохиттә яшәешен саклар өчен, мөселман булмаган башка күршеләр сугыш башларга җөрьәт итмәс дәрәҗәдә аларга каршы торырлык кодрәтле һәм кырыс булырга кирәклеге искәртелә».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**124.** Берәр сүрә иңдерелгән саен, аларның бер кавеме:

—Бу *(сүрә)* кайсыгызның иманын арттырды соң?—дигән булалар. Иман китергәннәрнең иманын арттырыр һәм аларга куаныч бирер. **(125)** Эчләрендә хасталык *(кяферлек, монафикълык чире)* булганнарның да *(бу сүрә)* инкарьларын арттырыр һәм алар чын кяфер булып үләчәк. **(126)** Ел саен бер-ике тапкыр *(төрле бәлаләргә дучар булып)* сынау узып торганнарын алар аңламыйлармыни? Соңыннан тәүбә итмиләр, гыйбрәт алмыйлар. **(127)** Берәр сүрә иңдерелгәч, алар бер-берсенә карашып:

—Сезне кем дә булса күрмиме?—диләр һәм *(мәкерләре ачылып, рисвай булудан куркып)* шыпан-шыпан таялар. Аңламый торган бер кавем булганнарына күрә, Аллаһ аларның күңелләрен *(иманнан)* читләштерде.

**128.** *(Ий, мөселманнар)* хактыр ки, сезгә үз арагыздан чыккан Пәйгамбәр килде; сез бәлагә тарсагыз, ул хәсрәтләнә. Ул сезнең өчен җаната, тәкъваларга ул чиксез шәфкатьле, мәрхәмәтле.

**129.** *(Ий, Мөхәммәд)* йөз чөергәннәргә әйт:

—Аллаһ миңа житәр *(миңа башка—уйдырма илаһ кирәк түгел)*, Аннан башка Илаһи кодрәткә ия һәм тәнре булырлык һичберкем юк. Мин бары тик Аңа гына инанып сыенамын, Ул мәһабәт Гарешнең *(Күктәге тәхетнең)* хуҗасы,—диген.

صدق الله العظيم

**Вил Ганиев**

# ХХ ЙӨЗ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

## ТАРИХИ-БИБЛИОГРАФИК КҮЗӘТҮ

Бөек Ватан сугышы темасы бу дәвердә автибиографик яисә документаль әсәрләрдә чагыла: фашистлар әсирлегендә үзе кичергән михнәт-газапларны Әнәс Галиев «Йолдызлар шаһит» (1968) повестенда тасвирлый; С.Шакир (1924—1998) «Үлемсезләр» (1964) һәм «Легенда егетләре» (1965), Ш.Рәкыйпов (1929) «Кайдан син, Жан?» (1969) һ.б. авторларның документаль әсәрләре басылып чыга.

С.Баттал бу елларда һәм чәчмә, һәм тезмә әсәрләр белән балкып ала: фашистлар кулына әсир төшкән һәм зур батырлык кылган хәрби очучы образын «Сигезенчесе кем?» (1965) дигән повестендә бирсә, авылдагы тормыш-көнкүрешен «Чирмешән ярларында» (1967) шигъри романында сурәтли.

Сугыштан соң килеп, татар әдәбиятында якты эз калдырган Ә.Давыдовның «Дәверләр диалогы» (1969) китабына иҗатының бөтен җәүһәрләре тупланып та, автор үзе вафат булганнан соң гына дөнья күрә.

60—80 еллар поэзиясендә өлкән буын шагыйрьләреннән капма-каршы диярлек позициядә торучы ике шагыйрь алдан бара: хакимияткә якын С.Хәким белән тоткынлыкта (1940—56) булып кайткан Х.Туфан. Аларның һәркайсы үзенчәлекле шагыйрь буларак танылган һәм яшь буынны үз артыннан ияртеп барырга сәләткә ия шәхес.

Тарихи романның яңа дәверен «Ител суы ака торур» (журнал варианты 1969 елда, китап булып 1972 дә, яңасы 1980дә) романы белән Н.Фәттах башлап җибәрә.

1944 елның августында партиянең Үзәк Комитеты махсус Карар чыгарып җөмһүриятебездә сәяси һәм идеологик эшләрнең торышына канәгатьсезлек белдергәннән һәм милләтчелектә гаепләгәннән соң партия өлкә комитеты тарихчылар белән әдипләрнең һәр мәкаләсен, һәр әдәби әсәрен җиз иләктән иләргә керешә — урта гасырлар тарихына, Алтын Урда белән бәйләнешләргә кагылудан тәмам читләштерә. Шуның аркасында бу жанрда вакуум барлыкка килә. Фәкать алтмышынчы елларда гына милли мәсьәләдә хәлләр үзгәреп китә, вакуум акрынлап тула башлый.

Һәм иң әүвәл Н.Фәттахның «Ител суы ака торур» исемле романы дөнья күрә. Әхмәд ибн Фазланның сәяхәтнамәсенә һәм бүтән тарихи чыганакларга таянып, автор гаять үзенчәлекле әдәби әсәр иҗат итә. Монда ул Болгар ханлыгы дөньясын, халкыбыз тормышында зур роль уйнаган бер вакыйганы — 922 елда ислам динен кабул итүне киң колачлы, мавыктыргыч күренешләрдә тасвирлап күрсәтә, ягъни, без кемнәр соң, дигән сорауга җанлы образлар ярдәмендә оста итеп җавап бирә.

Тарихи темага кереп киткән әдипләребез мәшһүр шәхесләр тормышына багышлап та зур-зур әсәрләр иҗат итәләр. «Хөсәен Ямашев» трилогиясендә (1 нче китабы — 1968) А.Расих татар халкының XIX йөз ахыры һәм XX йөз башындагы тормыш-көнкүреше фонында бөек революционер образын ышандырырлык итеп гәүдәләндерә.

Ш.Маннур исә халкыбызның бөек улы, үзе әйбәт белгән каләмдәшенең

Дәвамы. Башы 2, 3, 4 саннарда.

гомер юлын һәм каһарманлыгын күрсәтүгә «Муса» (1968) дигән романын багышлый.

Әлеге дәвер драматургиясендә Ш.Хөсәеневнең иҗаты игътибарга лаек: «Зөбәйдә — адәм баласы» (1961), «Әниемнең ак күлмәге» (1968). Шәхеснең рухи яктан таркалуын автор искиткеч зур осталык белән сурәтли.

70 елларда татар әдәбияты, аннан алдагы дәвердә әхлакый сабак алганнан соң, тормышыбызда әледән-әле килеп чыга барган четерекле хәлләрдән арыну юлларын ашкынып эзләргә керешә, ничек тә аларны табарга тырыша. Чөнки дөньяның экологик катастрофа алдында торганлыгы аның аңына барып җитә. Бу өлкәдә иң беренче булып әдәбиятыбызның аксакалы Г.Бәширов ныклап торып чаң суга: аның «Җидегән чишмә» романы (1 китабы — 1977, 2 нчесе — 1978) дөнья күрә. Аксакалга ияреп бүтәннәр дә баш калкыта — җөмһүриятебездә җирне вәхшиләрчә эксплуатацияләү, рәхимсез рәвештә ермачлап бетерүнең зур фаҗига китереп чыгаруына шаһит булган язучылар дәшмичә кала алмыйлар. Шуның нәтиҗәсендә безнең әдәбиятта яңа юнәлеш барлыкка килә. Бу юнәлештә М.Хәбибуллин, Б.Камалов, Ф.Бәйрәмова һ.б. язучылар активлык күрсәтә.

Хезмәт темасы 70 елларда гүя кабат яңарып та яшәреп китә. Чаллыда автогигант корылуы моңа сәбәп була (КамАЗны төзергә хөкүмәт карары 1969 елда чыгып, беренче машиналар 1976ның февралендә конвейердан төшә). Татар язучылары гасыр төзелешен гүя шефлыкка алалар. КамАЗга багышланган күмәк җыентыклар да, аерым авторларның китаплары да әледән-әле чыга тора: Ә.Баянов — «Ут һәм су» (1973) романы, С.Хәким — «Дәверләр капкасы» (1974) поэмасы һ.б.

Командировкага барып кына юньле китап язып булмый дип, Э.Касыймов исә 1972 елны Чаллыга күченә. Төзелештә барган эшләрне дә, шунда эшләгән кешеләрне дә бөтен нечкәлекләренә кадәр өйрәнә. Якын-тирәдәге авылларда гомер кичергән һәм хәзер автогигант коруда катнашкан крәстиәннең эчке кичерешләрен бөтен тирәнлеге белән күрсәтү өчен, әлбәттә, еллар сорала. Әдип «Шиңмәсен гөлләрең» (1986) дилогиясен иҗат итә. Зур күләмле әнә шул китабын үзенә күрергә генә насыйп булмый...

Ш.Бикчуринның «Каты токым» (1974) романы нефтьчеләрнең газаплы, әмма файдалы хезмәтен бөтен нечкәлекләренә кадәр тасвирлаган әсәр буларак зур популярлык казана.

Җитештерү һәм хезмәт темасына тугрылыклы Г.Ахунов укучыга үзенең арада бер камил әсәрен — «Чикләвек төше» (1975) повестен тапшыра. Анда ул уңган һәм акыллы җитәкче образын гәүдәләндерә. Безнең әдәбиятта әле бертөрле өмет, юньле җитәкче, әйтик, колхозны яхшы юлга алып чыгарга сәләтле, дигән ышаныч яшәп килә. В.Нуруллинның «Аккан су юлын табар» (1979) повесте дә моңа мисал була ала.

Татар әдәбиятының классигы Ф.Хөсни бу заманда да үзенең кыйбласына тугрылыклы булып кала. «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» (1971) дигән повесть һәм хикәяләр җыентыгында ул үзен халкыбызның сөйләм телен искиткеч шәп белүче, тирән психологик кичерешләрне гаҗәеп оста ачып бирергә сәләтле әдип итеп күрсәтә.

Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» повестендә күтәрелгән мәсьәлә М.Юныйсның «Табу һәм югалту» (1979) повестендә дәвам иттерелә. Бу фәлсәфи әсәрнең кыйммәте — автор һәм аның каһарманнарының милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау турында уйлануы, милләт язмышын хәл итүдә авыл һәм шәһәрнең тоткан урыны турында әңгәмә корып җибәрү.

М.Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала» (1979) повесте дә зур яңгыраш ала. Әсәрнең каһарманнары—гади авыл кешеләре. Аларны аңлау өчен татар халкының милли үзенчәлекләрен бик әйбәт белү зарур.

Бу елларда аеруча яратып укылган әсәр — ул да булса Ә.Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1977). Даһи композитор Салих Сәйдәшевнең яшьлеген, беренче мәхәббәтен, шәхес буларак җитлегүен сурәтләгән бу әсәренең жанрын автор үзе «кечкенә роман» дип билгели.

Тарихи роман яңадан-яңа дәверләрне үзләштерә. Татар халкының тарихын тагын да борынгырак итү ниятен күздә тотып, Н.Фәттах «Сызгыра торган уклар» романын (1 китабы — 1977) иҗат итә. Монда автор безнең

эрага кадәр III йөздә яшәгән төрки кабиләләрнең көнкүрешен тасвирлый. Тарихи чыганакларны яхшылап өйрәнү нәтиҗәсендә бүгенге тарих фәнендә ныклап тамыр җәйгән кайбер фараз кылуларны инкяр итә.

Җитмешенче еллар поэзиясендә Х.Туфанның таланты яңа шигъри үрләрне яулап ала, туган якларын, сабый чакларын сагынып язган «Кармәт истәлекләре» (1971) циклында искиткеч зур камиллеккә ирешә. Урта буын шагыйрьләре Г.Афзал, Ш.Галиев, Ә.Баян, И.Юзеев, Х.Камалов, Ә.Маликов яңадан-яңа шигырь һәм поэмалар иҗат итәләр. Алардан соң килгән буын да милли поэзиябездә ныклы урын яулап ала: Р.Фәйзуллин — «Наз» (1973), Р.Гатауллин — «Ирләр булыйк» (1978), Р.Харис — «Баскычлар» (1976).

Драматургиядә комедия-сатира юнәлеше өстенлек ала. Яшь драматург Т.Миңнуллинның таланты ачылганнан-ачыла бара; аның драма һәм комедияләре Г.Камал исемендәге Татар дәүләт драма театры репертуарында төп урынга чыга: 9 пьеса арасында — «Әлдермештән Әлмәндәр» (1976), «Дуслар җыелган җирдә» (1977) һ.б. пьесалар. Драматургиянең ветераннары Р.Ишморат, Ю.Әминев, Х.Вахит һ.б. да иҗат итүдән туктамыйлар.

Алтмышынчы елларда әдәбиятка килгән яшь талантлар янә 20—30 ел буена әдәбиятның үсешенә гаять зур өлеш кертсә, җитмешенче елларда дебютантлар ул чаклы ук булмый. Шулай да бу елларда өметле генә яшьләрнең килүе бәхәссез. Прозаиклар: Ә.Гаффар (1948) — «Әҗәт» (1975) повестьлар, хикәяләр җыентыгы, Г.Кашапов (1942—91) — «Сәмум җиле» (1978) повесте, тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Р.Мөхәммәдиев (1948) — «Яңа елга күчтәнәч» (1979), А.Вергазов (1932) — «Дулкыннар ни сөйли?» (1978) повесте, Т.Әйди (1941—2001) — «Бөҗра» (1978) повесте, Д.Зөбәерова (1930—2000) — «Кичер, сөеклем» (1971) хикәяләр һәм повестьлар җыентыгы, М.Насыйбуллин (1925) — «Телсез шаһитлар» (1974) детектив хикәяләр, повестьлар җыентыгы; шагыйрьләр: Р.Миңнуллин (1948) — «Бәхетле булыгыз!» (1976), З.Мансуров (1949) — «Васыять» (1974), Зөлфәт (1947) — «Язмышлар ярында» (1971), М.Әгъләмов (1946) — «Кыңгырау» (1970), Ә.Рәшитов (1936) — «Хатирә» (1972), М.Галиев (1946) — «Еллар чалымы» (1979), Ф.Сафин (1948—92) — «Кеше юлга чыкса...» (1976), Ш.Мәхмүтов (1938) — «Көтелмәгән очрашулар» (1971, башкорт телендә элегрәк чыга); балалар язучысы Җ.Дәрзаман (1945) — «Илбатыр» (1975) әкиятләр җыентыгы; драматурглар Р.Хәмид (1941) — «Синең урыныңа кайттым» драмасы (1978 елда сәхнәгә куела), Ю.Сафиуллин (1948) — «Әллә өйләнергә инде» (1977дә сәхнәгә куела).

Җитмешенче елларда татар әдәбиятына Ч.Айтматов иҗатының тәэсире чиксез зур була. Аның әсәрләрен тәрҗемә итәләр, аннан үрнәк алалар, аңарга иң кыю иҗатчы дип, киң колачлы әдип, милли мәсьәләгә тирән үтеп керергә сәләтле шәхес дип карыйлар. Татар язучылары үзебезнең милли әдәбиятыбызда да шундый киң колачлы әдипнең булуын, башкаларны әйдәп алып баруын телиләр. Ч.Айтматов иҗатына багышланган мәкаләсен галим-әдип Мөхәммәт Мәһдиев юкка гына «Кайда соң безнең «Ак пароход»ыбыз?» дип атамагандыр (1971).

Сиксәненче еллар — татар әдәбияты үзгәрешләр кичергән дәвер. Ләкин баштагы яртысы шактый тыныч кына уза, әдәбиятыбыз такыр юлдан җилдерә.

Элгәречә үк игътибар үзәгендә — эшчеләр сыйныфы, ниләрдер җитештерү, хезмәт. Г.Кашапов «Язмышыңа ышан» (журналда — 1985) дигән романын атом электр станциясе төзүчеләргә багышлый. Э.Касыймовның «Чулман — оныклар дәрьясы» (1984) дигән дилогиясе дә эшчеләр сыйныфына багышланган. Дилогияне тәшкил иткән бу романнар элегрәк аерым-аерым дөнья күреп, әдәбиятыбызда зур шау-шу кубарган, русчага да тәрҗемә ителеп, 1976 һәм 1980 елларда Мәскәүдә чыккан иде инде. Р.Кәраминең (1942) «Очар кошлар белән янәшә» (1980) исемле повесте төзелештә эшләүчеләрнең тормышын тасвирлый. Җ.Рәхимов (1935—96) «Тәвәккәл таш яра» (1981) дигән күләмле генә повестендә нефтьчеләрнең көнкүрешен сурәтли.

Ә.Баянов сүзләре белән әйткәндә, татар әдәбиятында «мәңгелек тема» булып киткән авыл язмышы И.Салаховның «Имәннәр тамыр җәйгәндә» (1984) кебек тарихи роман, Ф.Шәфигуллинның «Ак яллы аргамаклар» (1980) повесте, М.Мәһдиевнең «Мәңгелек яз» (1982) дигән повесте, Ф.Садриевның пьесалары шикелле күркәм әсәрләрдә чагыла. Әдипләр әле дә булса замандашларның

игътибарын экологиягә, табигатьне саклау зарурияtенә юнәлдермәкче булып талпынып карыйлар. Бу өлкәдә иң әүвәл Гарәфи Хәсәневнең (1921—92) «Җир ул уртак йортыбыз» (1981) дигән исемдә Г.Бәшировның кереш сүзе белән чыккан хикәя һәм повестьлар җыентыгын, Альберт Хәсәневнең (1937) «Тугрылык» (1980) исемле хикәяләр китабын, Гомәр ага Бәшировның «Күзге ачы җилләрдә» (журналда — 1984) дигән истәлекләрен әйтеп үтү дөрес булыр.

Ул елларда Бөек Ватан сугышы темасын аеруча саллы итеп яктырткан ике генә китапны телгә алмакчы буламын. Боларның берсе — Х.Камалның «Безне өйдә көтәләр» (журналда — 1985) дигән романы булса, икенчесе — М.Юнысның җырдан алынган исем белән «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» (1983) дип дөнья күргән повесте.

Сиксәненче еллар башындагы прозабызда аеруча зур вакыйга буларак кабул ителгән әсәр — М.Хәбибуллинның «Кубрат хан» (журналда — 1984) романы. Әсәрнең үзәгендә Бөек Болгар дәүләтенең VI—VII йөзләрдә Иделнең түбән өлеше һәм Төньяк Кавказларга җәелгән биләмәләрен бергә туплап идарә итүче, күпне күргән, зур тәҗрибә җыйган олуг акыл иясе булган Кубрат хан. Ул үлгәннән соң мәмләкәтнең таркалуы мәгълүм. Шулчагында Идел буйлап өскәрәк менеп яшәгән болгарлар — безнең бабаларыбыз, хәзерге татар этносына нигез салучы халыкларның берсе. Бу роман журналда күренү белән, Идел буе татарларының каян килеп чыгуы хакындагы бәхәсләр яңадан күтәрелә. Дөресен генә әйткәндә, М.Хәбибуллин «Кубрат хан» романын чыгаруы белән татар халкының этногенезын төптәнрәк фәнни өйрәнүгә этәрә.

Поэзиябез бу дәвердә зуррак мәсьәләләрне күтәрә, лироэпикага мөрәҗәгать итә, һәм нәтиҗәдә мәшһүр шәхесләребезгә багышланган поэмалар дөнья күрә. Даһи композиторыбызның образын Р.Фәйзуллин «Сәйдәш» (1980) поэмасында иҗат итә; И.Юзеев «Очты дөнья читлегеннән...» (1980) поэмасында бөек Тукаебызны гәүдәләндерә; Роберт Әхмәтҗанов исә беренче сәхнә йолдызыбызга багышлап «Сәхипҗамал» (1985) поэмасын яза; М.Әгъләмов XIX йөздә яшәгән шагыйрьгә «Акмулла арбасы» (1981) дигән поэмасын багышлый; Р.Харис милли каһарманнарыбыз турында ничәмә-ничә поэма иҗат итә.

80 еллар башында безнең әдәбиятка яшь шагыйрьләр күбәү килә: Х.Әюпов (1946да туган, 1нче китабы 1980дә чыга), Л.Шагыйрьҗан (1945, китабы — 1982), Н.Әхмәдиев (1946, китабы — 1980), Ш.Маннап (1938, китабы — 1981), Р.Низамиев (1950, китабы — 1980), Б.Сөләйманов (1938—91, китабы — 1980), Э.Шәрифуллина (1941, китабы — 1984), Н.Измайлова (1950, китабы — 1981), Ә.Мәхмүдев (1947, китабы — 1983), Ямаш Игәнәй (1938—1997, китабы — 1981), Л.Зөлкарнәй (1962, китабы — 1984) һ.б. Дебютантлар арасында прозаиклар бармак белән генә санарлык: Мансур Вәлиев (1948, «Дулкын» повесте — 1984), С.Шәмси (1946, «Көмеш чылбыр» җыентыгы — 1984), Ф.Гыйльми (1947—93, «Урсай тау итәгендә» — 1981); драматургларның аз булуы гадәти хәл инде: Р.Хәмид (1941, «Кайтыр идем...» — 1982), Ю.Сафиуллин (1947, «Менә без дә үсеп җиттек...» — 1983).

80 елларның икенче яртысында, үзгәрешләр дәверендә татар әдәбияты күп милләтле бөтен совет әдәбияты кичергән хис һәм хәлләрне кичерә (кайчандыр читкә атылган олуг әдипләрнең исемнәре һәм иҗатлары әйләнеп кайта, моңарчы кире кагылган әсәрләр дөнья күрә, гадәтләнгән кысаларга ни язылышы, ни эчтәлеге ягыннан сыешмаган әсәрләр хакында бәхәс куба һ.б.). Поэзия, бигрәк тә публицистик поэзия, аңа ияреп бүтән жанрлар да татар халкының үткәнен һәм бүгенгесен өр-яңадан аңларга тырышуда аеруча активлашып китә; язучылар әле күптән түгел генә ил күләмендә тыелып килгән, шул исәптән милли мәсьәләне дә күтәрергә фатиха алалар.

Бу яктан караганда Н.Фәттахның «Кичү» романы аеруча гыйбрәтледер. 1954 елда автор сугыштан соң авылдагы тормышның җан өшеткеч булганын тасвирларга ниятли. Тик 1963 тә киң планда яза башлаган эшен ташларга мәҗбүр була, чөнки ул күрсәткән аянычлы хәлләрне бирәү дә китап итеп чыгармаячагын яхшы аңлый. Фәкать яңа шартларда гына авторга ышаныч килә. Роман 1989 елда тәмамланып, 1995 елны дөнья күрә.

Ул заманга хас янә бер мисал. 1988 елда А.Гыйләҗев «Балта кем кулында?» дигән символик исемдәге романын язып бетерә. Автор бик кискен

рәвештә бер кеше белән хакимият арасында барган низагны сурәтли һәм укучыны: һәркем хакимият иркендә, балта шуның кулында, дигән күңелсез фикергә китерә.

Әдәбият кай арада иҗтимагый климатның үзгәрүен абайлый, тиз арада авыл белән шәһәрдәге хәлләрнең гаять мөшкел икәнен читтән генә суктырып тормыйча, турыдан-туры сурәтләп бирү юлына баса. К.Тимбикованың Брежнев заманаларын тасвирлаган «Табылган хатлар сере» (журналда — 1988) повесте, Ә.Гаффарның дөреслекне эзләүгә багышланган «Олы юлның тузаны» (1990) дип аталган романы һәм тагын әле сиксәненче еллар азагында язылган күп кенә тезмә әсәрләр әнә шундыйлардан. И.Нуруллинның (1923—95) «Фатих Әмирхан» (1988) китабында әдәбиятыбызның классигы образы бөтенләй үзгәчә, олуг әдипнең яшәү рәвешенә һәм иҗатына тәңгәл килердәй итеп гәүдәләнә.

Шактый күңелсез хәлләр 1987 елның башында килеп чыга: кайбер язучылар һәм әдәбият галимнәре, шулай ук Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар халкының гасырларга сузылган рухи мирасын барлау, өйрәнү һәм пропагандалау комиссиясе Гаяз Исхакыйны аклау һәм XX йөз башындагы әдәбиятыбызның классигы булуын тану мәсьәләсен күтәрәләр. Янә дә ике елдан соң гына әлеге тарткалашу уңай хәл ителә: газета-журнал битләрендә бер-бер артлы әдипнең йә моңарчы рәсми органнарда сакланган, йә Төркиядән кайтарылган әсәрләре күренә башлый, ә инде 1991 елда проза һәм драма әсәрләре бергә тупланган китабы дөнья күрә (даһи язучының әсәрләрен 15 том итеп чыгару хәстәренә дә шунда ук керешәләр).

1988 елда, ниһаять, «Идегәй» дастаны аерым китап булып басылып чыга. Халкыбыз иҗат иткән бу поэма XIX йөздә үк тюркологларга мәгълүм була. Бер нөсхәсен хәтта академик В.В.Радлов та кәгазьгә төшерә. 1919 елда журналист, галим һәм педагог Нигъмәт Хәким (1889—1937) Себердә чичән Ситдыйк Зәйнетдиновтан (1854—1927) «Идегәй»нең тулырак текстын язып алып кайта. Әнә шул нөсхәгә таянып, күренекле фольклорчы, шагыйрь һәм драматург Нәкый ага Исәнбәт бу дастанны 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында чыгара. «Идегәй» дастанын аерым басмада чыгарырга әзерлек эшләре алып барганда, сугыш башлана. 1944 елның 9 августында ВКП(б)ның Үзәк Комитеты кабул иткән карарда турыдан-туры «Идегәй» — байлар һәм феодалларга мәдхия җырлаган дастан дип игълан ителә... Шуннан соң инде ярты гасырга якын беркемнең авыз ачарга батырчылык итмәве аңлашылса кирәк.

Җилләрнең яңачарак исүен, замананың яңа таләпләр куюын яшь язучылар шундук абайлап ала. Аксакалларның котын алып торган хакимият яшь иҗатчыларны әлләни өркетә алмый икән ләбаса! Яшьләр хәтта әле үз таләпләрен язып, листовка таратуга чаклы барып җитәләр. Нәкъ әнә шул юл белән алар үзләренә трибуна булырдай журнал яулап алуга ирешәләр: 1989 елдан ике телдә «Идел» журналы чыга башлый. Анда заманына күрә иң кыю, иң әрсез фикерләр әйтелә. Тезмә һәм чәчмә, драма һәм публицистика әсәрләрендә. Гәрчә редакция әдип һәм шагыйрьләрнең барчасына мөрәҗәгать итсә дә, яңа әсәрләр сораса да, журнал башлыча яшьләрнеке буларак оеша. Бүгенге танылган әдипләрдән Н.Гыйматдинова (1956), Ф.Сафин (1948—92), З.Хөснияр (1961) һ.б.; шагыйрьләрдән Р.Зәйдулла (1962), Л.Зөлкарнәй (1962), Л.Лерон (1961), Г.Морат (1959),Р.Сүлти (1969); драматург һәм прозаик З.Хәким һ.б. нәкъ әнә шул «Идел» журналында чирканчык алалар.

К.Лат[illegible] [illegible]ман кәрваны» [illegible] .Гат[illegible] [illegible]атау[illegible] — «[illegible]

*Дәвамы киләсе санда*

11*

# НӘРСӘ УЛ «ХӨРРИЯТ»?

БУ ХАКТА язмый булдыра алмадым.

Кулга каләм алуымның да сәбәбе шул —«Хөррият» тирәсендә купкан караш-фикерләр, кайбер даирәләрдә аңа карата булган аеруча «игътибар»лылык. Ят кешене бер карауда белеп булмаган кебек, «Хөррият» исемен алган Азатлык Сынын да бер караштa гына аңлап бетереп булмыйдыр, мөгаен. Шуны истә тотып, «Хөррият» урнашуга байтак вакыт үтсә дә, автор буларак кайбер нәрсәләрне аңлатып-ачыклап китүне кирәкле дип таптым. Нәрсә соң ул «Хөррият»? Нәрсәне аңлата ул? Нигә кирәге бар аның?

Баштарак, моныңише сораулар еш кына колакка да житкерелде. Яналык нинди генә, кайчан һәм ничек кенә булмасын, берьяклы тигез генә кабул ителми. Кешелек табигате, күп еллар дәверендә, үзен әйләндереп алган көндәлек әйберләргә ияләшә. Әгәр дә шулар арасында «ят» нәрсә килеп чыга икән, ул инде кыргый итеп кабул ителә. Урам әсәре буларак, «Хөррият» ул безнең өчен ят нәрсә. Символ аша чишелүе һәм бертуктамый хәрәкәттә булуы белән ул монументаль сәнгатебезгә яңалык алып килде. Ә яңалык, нинди генә булуына карамастан, ин әүвәле кызыксыну тудыра. Аннары, эчтәлегеннән чыгып, йә этәрә, йә үзенә тарта. Әмма күңел жылысы белән сугарылган «нәрсә» этәрә алмый... Дөрес, ияләшү дигән нәрсә дә бар. Ияләшү—яман гадәт. Яхшыга да, яманга да ияләшергә була. Әлеге яңалыкка карата бара торган ияләшү «яман» булуы хисабына түгел, дип уйлар идем.

Биредә табигый ике сорау туа. Беренчесе—дөнья практикасында моның ише очраклар, куелган «урам әсәрен» ят-кыргый итеп кабул иткән очраклар бармы? Алар бар. Эйфель манарасы (Париж), Азатлык статуясы (Нью-Йорк), О. Цадкинның «Җимерелгән Роттердам» һәйкәле (Роттердам), «Бабур» аталышындагы Сәнгать Үзәге (Париж) әнә шундыйлардан. Инженер Эйфельнең Бөтендөнья казанышлары күргәзмәсе өчен махсус эшләгән өч йөз метрлы манарасы күргәзмә барышында «гажәеп челтәрле» булуы белән игътибарны жәлеп итсә дә, күргәзмә ябылгач сүтү-жыю эшләре бик күп вакыт соралу сәбәпле, ул шул рәвешле кыргый нәрсә булып тора бирде. Париж халкы аны ят күреп, баш күтәрде, хөкүмәткә ризасызлыгын житкерде. Авторын эт итеп тиргәде, манараны шартлатырга ниятләде. Янә вакыт үтте. Күп сулар акты. Манара элеккечә тора бирде. Халык аның кыргыйлыгына акрынлап күнегә-ияләшә барды... Ә хәзер? Ә хәзер, Эйфельнең манарасы булмаса, Париж—Париж булмас иде. «Эйфель» Парижның «визиткасына» әверелде...

Йә булмаса, Цадкин һәйкәлен алып карыйк (бронзадан коелган, 4,5 м. чамасы биеклектә). Нигездә—коточкыч фажигагә дучар ителгән (тойгы менә шундый) бүленгән-теткәләнгән килбәтсез гәүдә-сын. Бәгырьләргә үтеп керерлек, артка каерылып үкереп тора торган башы гына аның ни тора! Күп вакытлар үзенең «коточкычлыгы» белән ул, шулай ук, Роттердам халкы өчен «ят» иде. Ә хәзер... дөнья күләмендә сугыш корбаннарына багышланган һәйкәлләр арасында ул беренче (!) урынны алып тора. Үзенең коточкыч тәэсир калдыруы белән!

Икенчесе... Яшәп килә торган корылма-бинага «тыкшыну» мисалы, «Хөррият» белән булган кебек, кайда да булса тагын бармы? Бөтенләй «Хөррият»чә үк булмаса

---

Кадим ЖӘМИТОВ (*1946*) - *сынчы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Ижауда һәм чит илләрдән Австралиядә, Германиядә, Чехословакиядә үткәрелгән күргәзмәләрдә катнашты; әсәрләре чит ил музейларында һәм галереяларында саклана. Мәскәүдә яши.*

да андый хәлләр дә бар икән. Аны табу-күрү өчен ерак барасы да юк—үзебезнен Казан Кремле, яисә Мәскәү Кремле анын ачык мисалы булып тора. Барыбызга да мәгълүм булганча, Казан Кремленен Спасс манарасы биш канатлы йолдыз белән тәмамлана. Ә менә анын шушы тирәлек өчен, гомумән, Кремль ансамбле өчен яткыргый булуы барыбызга да билгеле түгел. Дөресрәге, барыбыз да аны күрмибез-тоймыйбыз. Анын үзенеке (герб, шәһәр символы) бөтенләй башкача—шул ук «бер калыптан» башкарылган булган. Анлашыла, совет империясенә яраклашырга туры килде. Шушы чорнын балалары булып, гел аны күреп үсеп, анын мәгънәсезлегенә-кыргыйлыгына игътибар итәргә безнен вакыт та булмады. Анын өстәвенә, империянен символы да бит! Ул безнен күнелләргә шул кадәр сенгән, без аны «шулай булырга тиеш» дип кабул итәбез дә. Нәтижәдә, Кремльнен кыяфәте, мәгънәсе бозылды. Мемориалнын да кыяфәте үзгәрде, әмма бозылмады. Һәм киресенчә, «кыяфәтсез» бина, үз өстенә «Хөррият» символын алып, балкышлы-нурлы булды дип ышаныч белән әйтә алам.

Хөррият Кошы үзенен дүрт ел яшәү дәверендә, шөкер, күпләр тарафыннан кабул ителде. Күнегү-иялә шү хисабына гына түгел. Эчке торышы булу хисабына. Көчле символлар булу хисабына. Тәнречелектән килгән тамга көче хисабына.

Хөррият—күп мәгънәле гарәп сүзе: азатлыкка-ирекка, күккә ыргылу; үсешкә-яналыкка, киләчәккә юл алу; гүзәллеккә, сәнгать матурлыгына омтылу дигәнне анлата.



Һәйкәлнен төп билгеләнеше шуннан гыйбарәт: ул—азатлык сыны (статуясы). Анын нигезендә Тәнречелек чорыннан безнен көннәргә кадәр житкән хикәят-риваять ята. Күктә яшәүче төп Аллабыз-Атабыз мәнгелек Тәнре булса, Жир-Анабыз Умай булган. Кайбер очракларда ул Хумай кош итеп сурәтләнә.

Азатлык символын чагылдыру өчен Коштан да яхшырак символ бармы икән бу доньяда? Ә хатын-кыз буй-сыны?..

«Хөррият» нигезендә Жир-Ана символы да бар. Кешелек яшәеше символы. Жир-Анабыз безне (кешелек доньясын) тудыручы. Мәжүсилек чорында тикмәгә генә, Жир-Анага табынмаганнар... Ил-Ананы да символлый ул. Доньяга чәчелгән улларын-кызларын жыю өчен күтәргән куллары белән ишарә ясый. Салмак кына әйләнеп, һәръякка тигез карашын ташлап, безгә «Хәерле көнне» башлап жибәрә.

Кайчандыр, көмеш кош булып, Милли мәдәният үзәгенә керү ишеге өстендәге уентыкта «утыру» өчен туган иде ул. «Үзәк»нен символы булып. Ана сонрак «жаваплырак» вазифа бирелдә: Азатлык символын чагылдырып, жөмһүриятебезнен мөстәкыйльлек юлына чыгуын чагылдырырга тиеш иде...

Менә шушы кече чишелештәге «Көмеш кош», тиешле күләмгәчә зурайтылып, әлеге вакыйганы символларга тиеш булды. «Хөррият» исемен алып. (Ә бу исемне ана сәнгать белгече Розалина ханым Шаһиева уйлап тапты. Рәхмәт ана.)

Нәрсә мәжбүр итте сон мемориал иттереп төзелгән архитектура корылмасына «тыкшынырга?» Аны «борчырга?»

Монда ике сәбәп бар.

Сәбәпләрнен сәбәбе—бинанын тышкы яктан замана таләпләренә жавап бирерлек булмавы. Икенчесе—Азатлык һәйкәле (статуясы) өчен шушы урын-тирәлекнен кулай булуы. Совет империясе жимерелү белән, Ленинның даһилыгы да, шәүлә кебек, сүрелде—юкка чыкты. Шунын белән бергә, зурлыгы-мәйданы буенча Хөкүмәт йортыннан калышмаслык итеп, Ленинның бөеклеген сонгы мәртәбә мәнгеләштерү уе белән төзелгән мемориал-музей да әһәмиятен югалтты. Ягъни, беркемгә кирәк булмаган «ятим» бер бинага әверелде. Бай жиһазландырылган бинаны мемориалнын кирәге калмады дип ташландык хәлдә калдырып булмый, лабаса! Ул ничек тә халык файдасына хезмәт итәргә тиеш иде. Әлбәттә, бөтенләй башка вазифа

йөкләнеп. Мәсәлән, Мәдәният учагы иттереп. Ул «Милли Мәдәният Үзәге» исемен алып, «дөрләп кабынган учак» булды. Бу—әчтән. Ә тыштан? Аның иседе дә җисеменә туры килергә тиеш иде. Күпләрнең фикере-кичерешләре буенча, яшермим, иң беренче тойгым минем дә шундый иде, ул крематорийны хәтерләтә иде... Бигрәк тә стела-баганасы крематорийның төтен торбасына ишарәле иде шул. Ничек иттереп булса да бинаның йөзенә нур сибәргә, аңа җан кертергә иде, дигән фикер күптәннән яшәп килде. Әлбәттә, архитектурасының гомуми чишелешенә бераз «тыкшыну» юлы белән. Әмма гомуми торышына зыян китермичә. Автор идеясен бозмыйча. Артык чыгым тукмичә... Аңлашыла, без аңа хәзер ничек кенә карасак та, теге чорга яраклаштырып башкарылган архитектура әсәре ул. Шуңа күрә аңа саклык-хөрмәт белән карау безнең бурычыбыз иде. Шунысын да әйтү кирәк: «без варварлар түгел, дөрләтеп учак кабыздык» дип, без аны (Ленинны) тарих битеннән алып ташлый алмыйбыз—мемориалында аның истәлеге өчен лаеклы урын—бер бөтен зал калдырылды. Әлеге «тыкшыну» мәсьәләсендә, мондый чагыштыру урынлы булыр дип уйлыйм.

... Олы капкалы авыл йорты. Капка баганасында сыерчык оясы. Ул гомуми корылманың, күләме-торышы белән, сизелмәслек бер өлеше булып тора. Ул гомуми кыяфәткә йогынты ясый алмый. Шул ук вакытта, йортка да, тирә-юньгә дә ямь биреп, аны җанландырып тора. Йорт житкергәндә, ул «планга» кертелмәгән, аерым куелган. Ул булырга мөмкин, булмаска мөмкин... Безгә менә шушы караштан чыгып эшләргә туры килде дә инде.

...Җөмһүриятебезнең бәйрәм көненә өч ай вакыт калып бара. Моның эше эшләр өчен бу бик кыска вакыт. Өлгерә алмау шиге бик көчле иде.

...Җиде метр биеклектә булган гипс хәлендәге булачак «Хөррият», берничә кисәктән булып, юлга чыга. Мәскәүдән—Казанга. Бронзадан кою өчен.

Юлда көтелмәгән хәл була—гипс хәлендәге «Хөррият» зыян күрә. Кисәкләрнең байтагы ватыла-җимерелә. Вакыт болай да тар. Гаепләләрне эзләргә вакыт юк. Тиз арада торгызып, элекке хәленә кайтарырга кирәк. Ничек кенә булмасын. Кабат осталар яллап-чакырып. Монда инде фидакарьлеккә генә таянып булмады: изгелеккә һәркем бушлай хезмәт итә алмый. Әмма, нәтиҗәдә, барыбер «Хөррият» җиңде. Калган вакытны тыгыз файдаланып. Дөрес һәм төгәл оештырылып. Һәрбер оста үзенең эшен тиешенчә, тоткарлыксыз башкарды, эшсез тору булмады. Йокы-ял вакытлары минимум булды. Шулай ук кызыксындыру дигән нәрсәне дә киң кулланырга туры килде... Бу—ышанычлы, күп гасырлар дәверендә кулланыла торган сыналган ысул.

**Монда аеруча игътибарга лаеклы бер нәрсә бар. Өч яшемдә мин Кояш урынында балкып торучы, канатларын ике якка җәйгән Көмеш кошны төшемдә күргән идем... Бу төшем соңыннан, «Хөррият» үз урынына утыргач исемә төште. Ул, чыннан да, «Хөррият»кә бик охшаш иде.**

**...Кояш урынында, караңгы күктә ялтырап-балкып торган Көмеш кош. Канатларын өскә күтәргән, җилпенми, ә үзе каядыр, өскә күтәрелә. Мине дә күтәрә сыман...**

Әйләнештә булуы нигә кирәк булды дисезме?

«Хөррият», тамга-символ буларак, яссы чишелештә эшләнде. Шунлыктан, алдан һәм арттан караганда тулы булып күзалланса да, ян-яктан күзәткәндә «чыра» тойгысы калдыра кебек иде. Әлеге күнелсезлекне бетерү өчен, маяк рәвешен көчәйтү өчен, аның туктаусыз хәрәкәттә булуы кирәк булды. (Әлбәттә, мондый ысул-яналык башкача чишелештәге һәйкәлләр өчен урынлы булмас иде.)

Символ-һәйкәл үзенең яшәү чорында күпне «күрде», күпне «ишетте». «Иртән торып чыктым—күрәм, канатларын җәйгән күбәләк кебек. Бераздан караганда ул инде канатларын җыйган кебек иде». Бу—бер танышымның «Хөррият» ачылганнан соң кичергәннәре. Христиан динендәге икенче берәү: «Тәрегә охшашлык бар. Патриарх белән кинәшү-сөйләшү кирәк. Күнелсезлек килеп чыкмагае»,—диде. Ә бер депутатыбыз аны бөтенләй «башкача» күргән. Үзенең бер интервьюсында болай дигән: «Идән юганнан соң киртәгә элеп куйган әбиемнең идән чүпрәге бу...» «Яшен яшәгән, ашын ашаган» бер әбигә аңлатырга туры килде моның нәрсә икәнен. «И-и, улым,—диде,—кем булса да риза—сугыш кына чыгармасын, оныкларым байтак».

«Хөррият» урынына утыргач та, мине автор буларак, төп ике мәсьәлә борчып килде. Нәрсә бирер ул шәһри Казаныма? Автор индергән символларны ачып сала алырмы? Әйләнештә булуы, биектә утыруы тиешле нәтиҗә бирерме? Әйләнеш механизмы озакка чыдармы? Һәйкәлнең «җилкәнле» булуы көчле җил-давыл вакытында фаҗигагә китермәсме?

Беренче мәсьәлә буенча нәтиҗә ясау әле иртәрәк—еллар үтү кирәк. Икенче мәсьәләдә күп нәрсәләр инде ачык.

Әйләндерү механизмы үзлегеннән туктап карамады. Туктатырга, дөрес, туры килде. Бернәрсә дә мәңгелек түгел: җайлау-майлау эшләрен үткәрми булмый. Еллар дәверендә, туктаусыз хәрәкәттә булып, ашалган-кыршылган урыннарын яңартырга туры килә. Өстендә бит, күне-төне хәрәкәттәге алты тонналы «йөк»! «Җилкәнле»леге белән дә зыян күрмәде.

Тәүлек сәгатьләрен максимум эшкә җигүләр, автордан өстәмә чыгымкорбаннар, күңел тетрәнүләре—барысы да, шөкер, акланды. Иншалла, «Хөррият»ебез яши!

«Хөррият» хакында кызыксынучылар булды, хәзер дә булып тора. Шулардан еш очрый торганы—гонорар күләме. «Күпме бирделәр» белән «күпме алдың» тирәсендә. Башта шунысын әйтим. Бер генә автор да моның өше сорауга төгәл җавап бирә алмас иде. Эш куелган сорауның тыйнаксыз булуында гына түгел. Сер булуда да түгел. Гонорар—ул даими рәвештә бирелә-алына торган эш хакы түгел. Мин—Олы Сәнгатьнең иҗат иясе. Олы сәнгать ташкынында үзеңне «тота алу» өчен туктаусыз эзләнүләр, үз өстеңдә эшләүләр таләп ителә. Болай эш иткәндә, гонорар артыннан гонорар булып тора алмый. Бер алынган гонорар айларга, кайвакыт елларга бүленергә мөмкин. Эш заказларның булмавында яисә шул ук авторның алга табан булдыксыз булуында түгел. Башкарыла торган эш никадәр җаваплырак, никадәр күләмлерәк, никадәр яңачарак чишелештә булса, автор шулкадәр күбрәк «таушала», күңел тетрәнүләрен (стресс) кичерергә туры килә. Мондый «таушалулар» үзеңне кабат торгызу өчен (ял итүләр, дәвалану, иҗади уйланулар) байтак кына матди чыгымнар таләп итә.

Кыскасы, тормышка ашырасы әсәрең үзең өчен дә кадерле икән, өстәмә чыгымнар таләп ителәсенә әзер бул. Андый чыгымнар һәр адым саен булып торды. Шуңлыктан, күпме «алдың», яисә «бирделәр»—бу очракта урынсыз сорау.

Шунысын ачык әйтә алам: менә, автор буларак, нык борчыганы— бәһасе күктән төшмәде. Һәрьяклап өйрәнелде-уйланылды. Автор тарафыннан гына түгел—һәрьяклап. Үз эшеңне, бигрәк тә, һәйкәлгә кагылышлы «урам» әсәрләрен бәяләү бик кыен эш. «Хөррият»не дә компетентлы белгечләр ярдәменнән башка бәяләү бөтенләй мөмкин түгел иде. Теге заманда махсус «Бәһаләр кеңәшсе» яшәп килде. Бик сирәк очракта гына гауга чыгып, экспертка мөрәҗәгать ителә иде. Замана хәзер икенче: «Бәһаләр кеңәшсе» күптән юк, ә эксперт, әле шөкер, яшәп килә. Бу очракта да нәкъ менә әлеге эксперт ярдәмгә килде дә инде. Объектив бәһасен бирде. Ә мин исә, автор буларак, эксперт бәһасен нигезгә алып, аны өчтән беренә кыскартып, үземнекен билгеләдем...



һәйкәл гомерлеккә куела. Гасырларга. Ана инделрелгән уй-фикер алдагы ерак буыннарга житкерелсен өчен. Ата-бабаларының рухы итеп.

Әйләндерү механизмының барабанын куюга шик калмагач, аны тиз арада тормышка ашыру кирәк иде. Мондый эшләр һәрвакыттагыча проекттан башлана. Вакыт аз—ике атна. Өстәвенә, гадәттән тыш төгәллек таләп ителә торган эш. Кечкенә генә ялгышу да бу очракта мөмкин түгел иде. Механизм, ике сәгатькә бер мәртәбә әйләнеш биреп, туктаусыз әйләнеп торырга тиеш. Тәүлекләр буе. Айлар, еллар буена...

Үзебездә батырчылык итүче табылмады. Төрекләргә мөрәҗәгать иттек. Алар өчен вакытның гаять тар булуы киртә түгел иде. Алар әзер иделәр. Ул арада үзебезнең «Татгражданпроект» институты үзенең әзер булуын белдерде. Куелган мәсьәләнең изге булуын аңлапмы, көчләрен сынап карау уе беләнме, алар эшкә керештеләр һәм заказның проектын үз вакытында, тиешле югарылыкта башкарып чыктылар.

Әлеге проектны «Гипронииавиапром»нын вертолет заводы шундый ук тар вакыт эчендә, шундый ук югары сыйфат белән тормышка ашырды.

Механизм барабанынын диаметры ике метр булып, биеклеге бер метр тәшкил итте. Моны урнаштыру өчен «багана» башында урын-мәйданчык әзерләү кирәк иде әле. Очы кыйгач булганлыктан, аны туры-тигез иттереп кисәргә туры килде. Багана дигәнебез, тоташ тимер-бетон. Беләк юанлыгындагы иксез-чиксез арматуралар. Безгә шушы мәсьәләдә Германиядә эшләнгән махсус пычкы ярдәмгә килде.

Әлеге мәшәкатьләр белән шашып йөргәндә, «Хөррият»ебез язмышы һәлакәт астында кала язган иде.

«Халыкара автор хокукларын яклау» дигән бик тә мөһим документны искә төшерергә туры килде безгә. Кайчандыр ишетеп белә идек без аны... Бу күзлектән чыгып карагандa, безнен башбаштаклыгыбыз автор эшенә тыкшыну булып карала. Закон нигезендә. Бик тиз арада «мемориал»нын авторларын эзләп табу кирәк иде безгә... алар безне тапканчы...

Музей бинасын проектлаучы—Ленинградның проект институты «Гипрогор» иде. Авторы-архитекторы академик Полянский вафат булу сәбәпле, «түгәрәк өстәлгә» чакырылучылар—проектлау остаханәсе житәкчесе Синев М. Ф. һәм башкалар булды.

Эш артык тирәнгә киткәнче, алар белән ничек тә килешергә кирәк иде. Чакырдык. Очраштык. Сөйләштек. Бернинди нәтижә бирмәде. Сөйләшүләрне янартып карадык—нәтижә шундый ук. Алар катгый рәвештә каршы булдылар. «Бу—жинаять, әгәр туктатмасагыз, суд аша туктатылыр. Автор буларак, беренче Сез баш тартырга тиешсез!»—диелде алар тарафыннан.

Тегермәннән тукталып кала алмаган су куласасы кебек, замана таләпләре буенча көчле импульс алган әлеге хәрәкәтне туктату мөмкин түгеллеге ачык иде инде. «Аргументларга» таянып, «фактлар» китерергә туры килде. Ни эшләргә кала? ... Сыерчык оясы белән булган мисал алар өчен ышандырырлык булды кебек. Теге чор өчен яраклы булса да, музей итеп төзелгән архитектура «әсәрен» бүгенге көндә крематорий кыяфәтендә күрү, автор буларак, алар өчен дә күнелле хәл түгел иде шул.

Көтелмәгән хәлләрдән мондые да булды. (Белмим, дөрес эшләгәнмендерме, мин моны «бәйрәм мәзәге» иттереп кабул иттем.)

...Ачылу тантанасы бара, Жөмһүриятебез бәйрәм көне дә бит. Мәйдан тулы халык. Ачылачак һәйкәл төбе. Күпмедер вакыт, Президент белән янәшә басып торабыз... Безнен артта «Хөррият»тә катнашучыларнын кайберләре. Тантананы шәһәр хакимияте башлыгы Камил Исхаков ачып жибәрде. Барыбызны да икеләтә бәйрәм белән тәбрикләгәннән сон, анын тарафыннан ук, катнашучыларга мактау грамоталары тапшыру башланды. «Катнашучылардан» беренче буларак, минем исем янгырый... Автор буларактыр, диеп уйларга тулы нигез бар. «За активное участие в создании...» Әле игътибар итмим. Мәгънәсенә төшенмим. Уй андамыни! Тарихи вакыйга бит! Мондый истәлекле көн автор тормышында гел булып тормый, лабаса!

Әлбәттә, Камил әфәнде Исхаков, мона үзе дә игътибар бирмәде. Анлашыла: монын ише чүп-чарга игътибар итә башласа, Казан каласы кадәр кала белән идарә итәргә анын вакыты калмас иде.

Грамотаны «элдереп», кабат урыныма басам. Эчтәлегенә күз йөртеп чыгам, нәкъ шулай: «За активное участие в создании памятника «Хоррият» почетная грамота вручается скульптору Замитову К. З.» Көнен-аен кабат-кабат искә төшереп, күз алдыма китереп чыктым. Юк, 1 апрель түгел иде бу көн. Күрәмсен, моны шулкадәр мәзәк иттереп, тирәнтен, бөтен тәнем-күнелем белән кабул иткәнмен, кычкырып көләсем килде... әмма булмады, һәръяклап халык урап алган бит. Өстәвенә, Президент та янәшәдә генә басып тора.

Шулай да Грамотаны тутырган-төзегән «авторнын» мәзәкчел кулын кысасым килгән иде. Апрельчә шаяртканы өчен. Шулай ук, шаяртып кына... Бәлки әле сон түгелдер?

... Бронза һәйкәлнен биеклеге жиде метр, кинлеге бишкә якын, авырлыгы — алты тонна. Мондый галәмәтне гадәттән тыш биеклеккә—илле метрга күтәрү өчен махсус кран кирәклеге ачыкланды. Вертолет башкара ала, әлбәттә, ләкин... бик күп сорыйлар—200 мен сум! Түбән Новгородта мондый эшләр өчен автокран барлыгы мәгълүм булды. Аны Казанга кадәр куунын, шөкер, кирәге булмады. Тәкъдимнәре буенча, үзебездә булган көчле краннын угын озайту да житте.

Кран кирәгенчә, озайтылды-көйләнде. Жентекләп исәп-хисаплар үткәрелде. Стрелка-ук—төп-төгәл озынлыкта! Эш башланды. Башта әйләнеш барабаны унай

гына «менеп утырды». Аның өстенә «Ирек Кошы» утырырга тиеш бит. Күтәреп урынына җиткергәч кенә, кран тукталып калды. «Кош» нәрсәгәдер тереләде. Ни булды? Ялгышу булырга тиеш түгел иде, берничек тә!

Барабаннан чыгып торган болт исәпкә алынмаган булып чыкты... Нибары—10 сантиметр!

Әйтелде ки, «Хөррият»тә күп кенә оешмалар, берләшмәләр иҗат төркемнәре, аерым осталар-белгечләр катнашты. Барлыгы сиксәннән артык кеше. Автор буларак, аларның барысына да олы рәхмәтемне белдерәм.

«Хөррият» фикерен хуплап, теләктәшлек белдерүчеләр, котлаучылар булды. Шуларның берсе, якташым Өлфәт Хаҗиев, авторга багышлап шигъри юллар белән «Хөррияткә дан» дип атап, болай яза:

Килер вакыт, богауларын өзеп,
Татар Иле чыгар иреккә;
«Хөррият»кә ингән һәйкәл нуры
Барып җитәр һәрбер йөрәккә!..

Телгә алынмаган әле тагын бер «катнашучы» бар. Үзенең серле көче белән. Аның исеме—Матурлык. Хатын-кызга индерелгән табигать Матурлыгы. Әлеге Матурлыкка сокланмыйча, аны тоймыйча-сизмичә бер генә иҗат әсәрем дә туа алмас иде. Сүз дә юк, «Хөррият», шулай ук, шушы Матурлыкны тоеп иҗат иткән әсәрем. Үземнең рәхмәтем белән сәламемне тапшырам мин бу Матурлыкка!

Азатлык символы кирәклеген тирәнтен аңлап, аны тормышка ашыруда, Казан хакимияте һәм аның карамагындагы «Милли мәдәният үзәге» дирекциясе зур көчен куйды.

Калабызның күп кенә гасырларны үз эченә алган, үзенчәлекле архитектурасы бар. Безне борынгы чорга алып кайта ала торган, күз күремендәге икешәр-өчәр катлы, пөхтә йортлары белән Казаныбызны бизәп торган, тыкрык-урамнары бар. Казан каласы Тукай, Сәйдәш, Шаляпин, Урманче кебек шәхесләрне бирде. Көчле тавышы белән дөньяны яулаган Шаляпин, бүгенгә көндә иң яхшы һәйкәлләрнең берсе булып, безнең арага—үз Иленә кайтты.

Бакый Урманче алдында да изге бурычыбыз үтәлде кебек—истәлеге мәңгеләштерелеп, лаеклы урынга ул һәйкәл булып утырды. Алга таба да халкымның горурлыгын тәшкил итүче Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Мәрҗани, Сәйдәш кебек шәхесләрнең истәлекләре мәңгеләштерелер дип, ышанасы килә.

Калабыз ямьләнә, янара. Шулай ук, яңа йорт-корылмалар төзелү хисабына үсә дә. Ата-бабаларыбызның изге рухында сугарылган, күпләр хезмәтен үз эченә алган «Хөррият» калабызны тагын да ямьлерәк-нурлырак итүдә өлешен кертер. Илебез күгең тыныч «тотар», Азатлыкка чыгу юлында чын маяк була алыр дигән өмет кала авторда.

«Хөррият» һәйкәл булып утыргач, дустым—Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин болай дигән иде: «Син үзеннән казыгыңны кактың». Бу бик мәгънәле сүзләр. Рәхмәт. Шулай булсын.

Бу сүзләрне мин татар Илендә яшәүче һәммәбезгә борып әйтер идем: «Без азатлыкка ирешүдә үз казыгыбызны кактык!»

**Кадим ЖӘМИТОВ**,
*сынчы.*
*Мәскәү—Казан*

Ғәп
Фән

# ЗАМАН ЧАТКЫСЫ

Егерменче гасыр башы. Татар дөньясының кайнаган, социаль, сәяси һәм милли уяну кичергән, янарышка, алгарышка томырылган чоры. Табигый, төрле кыйблалы сәяси, милли, дини хәрәкәтләрнең калкып чыгуы, бер-берсе белән көрәше, бәрелеше хас бу чорга. Россиянең татарлар яшәгән күпсанлы төбәкләрендә шушы халәтне чагылдырган дистәләрчә яңа газета-журналлар ачыла, китаплар басыла, аларны нәшер итүче зур типографияләр барлыкка килә. Бу исә, үз чиратында, туып килүче давыллы-фаҗигале гасырга татар иҗтимагый фикерен хәзерләүдә, аны чарлауда, сафландыруда һәм ныгытуда, татар халкының милли үзаңын формалаштыруда искиткеч зур роль уйный.

Ул чор татар мәдәниятенең иң зур үзәкләреннән берсе булган Оренбург та бу хәрәкәттән читтә калмый. Танылган татар китабы белгече Әбрар Кәримуллин мәгълүматларына караганда, XX гасыр башында биредә 400 гә якын исемдәге татар китаплары басыла, аларның гомуми тиражы бер миллион данәгә җитә. Шушында ук «Вакыт», «Шура», «Кармак», Мөгаллим», «Чүкеч», «Яз», «Урал» һәм башка шундый газета-журналлар нәшер ителә.

«Дин вә мәгыйшәт» журналы менә шушы дулкында Оренбургта дөньяга килгән даими басмаларның берсе һәм иң озын гомерлесе. Ул 1906 елның декабреннән 1918 елның язына кадәр 16 бит белән айга дүрт мәртәбә чыгып килә. Коммунистик идеология хакимлеге дәвамында журнал кадимчелек һәм карагруһлык коралы дип кенә каралып бәяләнде. Мәсәлән, шул ук Ә. Кәримуллин «Китап дөньясына сәяхәт» *(Казан, ТКН, 1979)* исемле китабында «Татар демократик китабына, татарлар арасында барган социаль һәм милли уянуга каршы көрәш йөзеннән 1906 елда Оренбургта карагруһ дин әһелләре «Дин вә мәгыйшәт» дигән журнал чыгара башлыйлар, шуны басу өчен типография оештырып, анда китаплар да чыгару эшенә керешәләр»,—дип язды *(А. Каримуллин. Татарское государственное издательство и татарская книга в России (1917—1932).—Казань, ТКИ, 1999.—С.—235)*. Атаклы әдәбият һәм матбугат белгече, язучы Исмәгыйль Рәмиев «Татар вакытлы матбугаты (1905—1925)» *(Казан, Гяжур басмасы, 1926)* китабында «Дин вә мәгыйшәт»кә тагын да караңгырак бәяләмә бирә: «Бу журнал—карагруһлык, искелек, кадимлек, һәр яңага каршы килүчәнлек, иң әшәке клерикаль. Үзенең мәсләге, бөтене белән, ул мөселман погромщикларының нәшере булып барды».

Әмма журналның шушы катлаулы һәм буталчык, төрле идеяләр һәм фикерләр көрәше чорында барлыкка килүе бик тә табигый, халкыбызның иҗтимагый фикерен чарлауда аның роле бәхәссез. Октябрь инкыйлабына кадәр нәшер ителгән басмалар арасында иң озын гомерле булуы да, киң таралуы да нәкъ менә шул турыда сөйли.

Журнал 14 санга кадәр (бер елдан артык чорда) «Дөнья вә мәгыйшәт» исеме белән чыга. 1906 елның 31 декабрендә чыккан беренче санында ук ул журналның эчтәлек асылын, максатларын билгеләгән һәм 17 пункттан торган киң программасын тәкъдим итә. Программа дини һәм дөньяви хаят мәсьәләләрен дә, ислами милләтләргә кагылышлы мәгълүматларны да, сәяси, сәүдә, милли, рухи мәсьәләләрне дә, авыллар һәм шәһәрләр тормышын да, хөкүмәт, Дума эшчәнлеген дә, бәйге, җыен, бәйрәм хәлләрен дә, техника һәм машина яңалыкларын да киң яктыртып барачагын, әдәби әсәрләр бастырачагын вәгъдә итә, сорауларга җаваплар бирәчәген белдерә, саннан-санга журналның соңгы битләрендә күпкырлы һәм кызыклы «Ырынбур хәбәрләре»н биреп бара. Күренә ки, журнал тормыш-яшәешнең бик күп өлкәләрен үз эченә алган һәм алардан шактый бай мәгълүмат биреп баручы матбугат чарасы булып торган. Ә иң мөһиме, журналның

шушы күпкырлы программасы, шуңа нигезләнгән бай эчтәлеге аның үзенең беренчел һәм төп максатына ирешүдә—җәмгыятьтә диннең һәм яшәешнең оптималь пропорциясен югалтмау өчен хезмәт итүдә гаять зур роль уйнаган. Димәк, аны «карагруһлык, искелек, кадимчелек» таянычы дип кенә тамгалау хакыйкатькә хилафлык кылу булыр иде.

Әмма үзенең асыл максатларыннан берсе итеп ислам динен пропагандалауны, аның сафлыгын саклауны билгеләгән «Дин вә мәгыйшәт» янарыш чорына хас булган диннән бизү, аннан читләшү, ислам динен кимсетү һәм мәсхәрәләү күренешләренә битараф кала алмый. Шушы нигездә ул җәдитчеләр белән кискен бәхәс-полемикага керә. «Мәхәллә имамнарын сүгә-сүгә мәхәллә халкы белән алар арасына дошманлык салып, галимнәр белән халык арасына суыклык төшереп, халыкка әйткән нәсихәт вә вәгазьләренең тәэсирен бетереп, дини бер нәрсә сөйләгән вакытта гавамны ишетмәслек һәм ишетсә дә голәмә сүзен тотмаслык дәрәҗәгә китерделәр»,—дип гаепли ул җәдитчеләрне *(«Дөнья вә мәгыйшәт», 1907, № 9)*. Һәм халыкны дингә, ислам юлына чакыра. «Әй мөселман җәмәгате! Сезгә вә безгә иң әүвәл дин кирәк. Дин безне бетмәс-төкәнмәс, очы-кырые юк бер сәгадәткә, изгелеккә, рәхәткә ирештерә торган нәрсәдер, динсезлек исә бетмәс-төкәнмәс, очы-кырые юк җәһәннәм газабына алып барадыр» *(«Дин вә мәгыйшәт», 1907, № 14)*.


дين ومعيشت
Оренбургъ, журналу „Динъ ва Магишетъ" тем
16 „Динъ ва Магишетъ". (دين ومعيشت) 4 мая 1907 г.
Оренбургъ, Харченію Фазлутдина Гайнут

Журнал битләрендә җәдитчеләрнең кайбер әрсезлеге һәм бозыклыгы фаш ителә. «...Алар мәдрәсәдә йә башка җирдә берничә яшел вә зәңгәр билбаулы яшьләрне җыйнап, тәмәке тартып, очраган җирдә аяк астыннан тәбәвелләп вә моның кебек гадәтләрне өйрәтеп, кылган бөтен эшләренә китап шулай куша диеп, җәмәгатьне агулыйлар» *(«Дин вә мәгыйшәт», 1908, №3)*. Мондый язмаларны күпләп укырга мөмкин. Билгеле, алар һич тә урынсыз түгел, чөнки янарышалгарыш чоры халыкның аның ояту, аның җәмәгать активлыгын үстерү белән бергә бозыклыкларның, әхлаксызлык чалымнарының үтеп керүенә дә китерә. Бу хәл татар тормышын да читләтеп узмый. Журналның 1908 елгы 11 санында басылган мәкалә бу нәүбәттән игътибарга лаек. Анда Эстәрлетамак шәһәреннән 55 хатынның Дума депутаты Шәрәфетдин Мәхмүдевкә язган үтенеч-зар хаты китерелә. «Безнең ирләребез һәм угылларыбыз шул кадәр эчү белән мөбтәләләр (мавыгалар—Р. М.), безне һәм балаларыбызны тәрбия урынына, һәр көн кәсепләрен эчеп бетереп торалар... Эчеп кайталар, тавыш чыгаралар, ялган кабахәт сүзләр белән сүгенәләр, ач, ялангач утырган балаларыбызны хафалыйлар. Бу гына да җитми, юк хакка киемнәребезне көчләп алып саталар, яисә заклад салалар... Сез хөрмәтлеләрдән үтенәбез, мөмкин кадәр шул эшкечелекне бетерергә тырышсагыз ла, тәмам бетерү мөмкин булмаганда, һич булмаса, азайтырга тырышыгыз» *(«Дин вә мәгыйшәт», 1908, №11)*.

Мондый мисаллар журнал битләрендә күп китерелә, журнал шуңа борчыла, чаң суга, бу хәлне туктатуның төп юлын ул динне, ислам әхлагын ныгытуда күрә, шуңа чакыра, өнди. Дөрес, бу инде «Дин вә мәгыйшәт»нең мәсьәләне берьяклы, тар күзаллавын да дәлилли. Юкса, мондый халәтнең нигезендә ул чорда хәерчелектә, изелүдә яшәгән татар халкының тормыш авырлыгы, киләчәккә ышанычы сүнүе, өметсезлеккә бирелүе яткан. Журнал фаш итә торган җәдитчеләрнең дә омтылышы халыкны нәкъ менә шул халәттән чыгу юлларын эзләүгә, яктылыкка омтылуга өндәү бит, югыйсә. Шушы максаттан, җәдитчеләр үзләренең төп игътибарларын яшьләргә, мәдрәсә, уку йортлары шәкертләренә юнәлтәләр, чөнки халкыбызны мәгърифәт юлына чыгаруда нәкъ менә яшьләрнең төп роль уйнаячагын аңлыйлар. Шушы ук максатка омтылган, әмма җәмгыять әхлагын сафландыру чарасын бары тик динне ныгытуда күргән «Дин вә мәгыйшәт»нең җәдитчеләр белән төп бәрелешләре дә шушы юнәлештә аеруча кискен чагыла.

Чор рухына бәйле рәвештә бу елларда мәдрәсә һәм мәктәпләрнең уку программаларын яңарту, ислах итү, аңарга дөньяви фәннәрне киңрәк кертү мәсьәләсе киң бәхәс нигезе булып әверелә. Әлеге журнал да беренче санынан бу мәсьәләне үзенең игътибар даирәсенә ала. Бу нәүбәттән беренче санда басылган «Ислах мәкатиб вә мәдарис» («Уку йортлары һәм мәктәпләрне үзгәртү») мәкаләсе гыйбрәтле: «...дини гыйлем өйрәнелә торган мәдрәсәләргә яңа фәннәр вә дөньяви мәгарифне кертү дини гыйлемне мөмкин кадәр киметү вә аны киметү хисабына фәннәрне вә мәгарифне арттыру тиешле булачагы ачыктыр. Бу юл белән барганда, дини гыйлемнең әһәмияте төшеп калып барылыр, һәркем фәннәр вә дөньяви мәгарифне өйрәнүгә әһәмият биреп, ахырда диннең әһәмияте бетүе бик мөмкин» *(«Дөнья вә мәгыйшәт», 1906, №1)*. Күренә ки, монда дөньяви мәгърифәтнең кирәклеген, аның котылгысызлыгын аңлау да, ахыргы тискәре нәтиҗәләре өчен борчылу да ярылып ята.

Әлеге көрәш журналның ул чорда күпләп нәшер ителгән башка, бигрәк тә җәдиди басмалар белән кискен полемикасында нык чагыла. Үзенчәлекле бер деталь—тәнкыйть буш җирдә ятмасын өчен «Дин вә мәгыйшәт» башта аларда чыккан мәкаләләрне тулысынча китерә, аннан соң аларга карата үз фикерен әйтә. Аеруча социал-демократлар гәзитәсе «Урал» белән, иҗтимагый-сәяси «Вакыт» гәзитәсе белән полемика кызыклы. Менә «Урал» гәзитәсе бастырып чыгарган «Шәкертләргә ачык хат». «Татар шәкертләренең хәлләре вә тормышлары авыр вә кызганыч бер тормыштыр. Болардан да кызганыч, болардан да авыр тормышлы шәкертләр бармы икән?.. Шәкертләрнең укыган вә белгән нәрсәләре дин, дин вә диндер. Бу бичаралар һичкемгә кирәкмәгән юк-бар нәрсәләр белән башларын ваталар, зиһеннәрен киметәләр, гомерләренең иң кыйммәтле яшь вакытларын сасы мәдрәсәләрдә уткәрәләр.

... Русиядә бара торган революция татар шәкертләренең дә күзләрен ачты. Алар—дин, дин вә дин укучылар—фән, фән вә фән диеп кычкырдылар».

«Дин вә мәгыйшәт», шәкертләрнең авыр яшәешен ил тормышының гомуми халәте чагылышы булуын искәртеп, «Урал»ның дингә каршы позициясенә кискен бәяләмә бирә: «... мөселманлык белән «Урал» язган сүзләр ут белән су кеби һичбер вакыт икесе бергә җыйналмый торган нәрсәләрдер» *(«Дин вә мәгыйшәт», 1907, №14)*,—дип нәтиҗә ясый.

«Вакыт» гәзитәсе үзенең 15 санында «Дин мәдрәсәләре, фән мәктәпләре» исемле мәкалә бастыра. Анда сүз шулай ук укыту өлкәсендәге үзгәртүләр турында бара һәм ул «Иттифак әл-мөслимин» мөселман партиясе эшләгән яңа укыту программасын анализлауга багышланган. «Дин вә мәгыйшәт», ул мәкаләне бастырып, бу программага карата үз фикерләрен белдерә, «Вакыт»ның кайбер бәяләмәләрен кире кага, тәнкыйтьли.

Җәдитчелекнең яшьләрне бозыклыкка илтүен журнал үтә зур борчылу белән бәян итә, аның мисалларын китерә: «... кызганычка каршы, авыл халкы әхлак гадәтләреннән китеп, көз булды исә, яшьләре төркем-төркем ал вә яшел билбаулар бәйләп, өч-дүрт кешегә бер гармун алып, исерек көенчә урам буйларында кычкырып җырлап йөриләр» *(«Дин вә мәгыйшәт», 1908, №3)*.

Журнал яңа мәктәпләр, мәдрәсәләр ачылу турында даими информация биреп бара. Аны татар авылларында ачылган мәдрәсәләр аеруча сөендерә. Мәдрәсә-мәктәпләрне салдыруга булышкан химаячеләрне рәхмәт сүзләре белән телгә ала. Мәсәлән, журналда язылганча, Орск өязенең 3 нче Үсергән волосте Ялчыбай авылында 1907 елның май аенда «...гаять дәрәҗәдә яхшы вә күркәм мәдрәсә эшләнде. Авылның волостной старшинасы Фәйзулла Зәйнулла улы Жагурзин һәм авылның карт имамы Дилмөхәммәт хәзрәт тырышлыгы белән мәдрәсә тәмам булынды»*(«Дин вә мәгыйшәт», 1907, №43)*.

«Дин вә мәгыйшәт» татар теле язмышына янаган фаҗигане дә иң алдан күрә, аның алдагы язмышы өчен борчыла. Бу җәһәттән ул кайбер җәдитчеләрнең ана теленә булган салкын мөнәсәбәтен гаепли. «... Алар әз генә укый-яза белсәләр, татар безграмотный диюдән чирканмыйлар. Икесе-өчесе бер җиргә туплансалар, татарча сөйләшергә гарьләнеп, русча сөйләшәләр. Аларга ана телен саклау шулай имеш»*(«Дин вә мәгыйшәт», 1908, №6)*.

«Театр» рубрикасы астында бирелгән мәкаләләр дә кызыклы. Аларда кадимчеләрнең бу мәсьәләгә карашы, тәкъдимнәре ачык чагыла. Бу—татар театрының тууы, беренче адымнарын ясау чоры һәм журнал ана карата үз фикерен әйтми кала алмый. Димәк, журнал җәмгыять тормышындагы бер генә

күренешкә дә игътибарсыз, битараф булып калмаган, аларга карата үз позициясен ачык һәм аңлаешлы итеп әйткән. Театрның тууы, үсүе, көннән-көн киңрәк таралуы турында журнал ачынып яза: «20 октябрьдә изге җомга көнендә Оренбург татарлары, хөррият дип, нәкъ җомга чорында театр уйнарга керешеп, халыкны нәкъ азан әйткән вакытта театрга чакыралар» *(«Дин вә мәгыйшәт», 1917, №41)*. «Хөррият тугач, дин тотылмау мода булды. Гает көннәрендә дин кушмаган театрлар уйнала башлады... Мөкатдәс динебездәге мөкатдәс бәйрәм көнне иблис боерыгы булган театр белән пычранырга, җәһәннәмгә якынлашырга ярамый»*(«Дин вә мәгыйшәт», 1907, №21)*, «...моның *(театрның—Р. М.)* ахыры мөселманнарны диненнән, җенесеннән аерып, исламияткә башка булган дингә тартудыр» *(«Дин вә мәгыйшәт», 1917, №41)*. Күренә ки, төрле саннарда басылган бу мәкаләләрнең, аларның авторларының фикере бер—театр динсезлеккә, әхлаксызлыкка алып бару коралы. Әмма журналда башкачарак фикердәге мәкаләләрне дә очратырга мөмкин. Мәсәлән, 1907 елгы 20 санында исеме куелмаган авторның шактый кин мәкаләсендә: «Ләкин шул Аллаһыга каршы булган, ирләр вә хатын-кызларның уеннарында, кыланышларында, аларны кырыйдан карап торган кешеләр өчен файдалары да бар. Хатын-кыз аралашып ясалган театрны хатын-кызларга якынлашуга сәбәп булган ният белән карамау, бәлки, шул театрның үзеннән булган файданы күзләп караудыр. Һәм бу һәрбер мөселман өчен гөнаһ булмас» *(«Дин вә мәгыйшәт», 1907, №20)*,—дип раслана.

Театр мәсьәләсендә кадимчеләрне, ә журналның төп авторлары алар, тамашаның үзеннән бигрәк анда кылына торган әхлаксызлык мисаллары (эчү, тәмәке, әфьюн тарту, хатын-кызларның әдәпсезлеге, дингә карата тупаслык, дин әһелләренең образларын бозып күрсәтү) һәм башка күренешләр күбрәк борчый һәм ачындыра. Журнал битләрендә шул нигездә аерым тамашаларның тыелуы, аларның игъланнары юк ителүе, кайбер театр группаларының таратылуы турында да мисаллар китерелә.

Журналның беренче саннарыннан башлап, хатын-кызның тормыштагы, җәмгыятьтәге урыны игътибар үзәгендә. Бу мәсьәләдә аның фикере ике төрле, хәтта капма-каршы, дияргә була. Беренчедән, журналдагы мәкаләләрдә татар хатын-кызларының авыр тормышы өчен ачыну чагыла, аның сәбәпләре күрсәтелә. Икенчедән, хатын-кызлар, бигрәк тә яшьләр арасында бозыклык, әхлаксызлык, җенси тотнаксызлык күренешләренең ешаюы, хатын-кыз иреге, аның хокуклары өчен көрәшнең активлашуы унае белән борчылу ярылып ята. Әмма, шул ук вакытта, журнал авторлары хатын-кыз мәсьәләсен хәл итү юлларын күрсәтмиләр, хатын-кызларга ирләр белән тигез хокук таләп иткән җәдитчеләр карашына шөбһә белдерүдән ерак китмиләр. «Хәзерге заманда үзләренә тәрәккый пәрвәр дип исем биргән образованныйлар хокуклар тигезлеге һәм хатын-кыз иреге мәсьәләсен уртага куйдылар. Хокуклар тигезлеге, димәк, ир белән хатын арасында аерма булмыйча, иргә никадәр хокуклар бирелсә, хатын-кызга да бәрабәр хокуклар бирелсен... Болай булганда хатыннарыбыз француз хатыннары кебек үзләре ирләрен әсир итәрләр» *(«Дин вә мәгыйшәт», 1907, №15)*,—дип яза журнал үзенең унбишенче санында «Мусавәт хокук вә хөррият ниса» *(Хокуклар тигезлеге һәм хатын-кыз иреге—Р. М.)* исемле мәкаләсендә. Һәм төрле саннарында төрле төбәкләрдән килгән шушы шөбһәне нигезләүче мисаллар китерә.


Шунысы кызык, хатын-кызның җәмгыятьтәге роле, аның җәмгыятьтә тотарга тиешле урыны турындагы бәхәсләрнең әле бүген дә тынганы юк. Һәм еш кына ул бәхәсләр гасыр башында җәдитчеләр һәм кадимчеләр арасындагы бәхәс белән аваздаш. Ничек кенә булмасын, Россия җәмгыяте өчен бу мәсьәлә бүген дә үзенең актуальлеген югалтмаган.

«Дин вә мәгыйшәт» үзендә чагылган һәм күтәрелгән мәсьәләләрне шул чорның башка агымдагы басмаларындагыча кистереп, раслап, «бердәнбер хакыйкать» итеп түгел, ә фикерләү, уйлану, киңәшү өчен нигез буларак тәкъдим итә һәм бу аның зур бер отышы. Ул заман өчен бигрәк тә. Шушы алымы белән ул шул заманның укымышлы кешеләрен, зыялыларын татар тормышының төрле яклары турында уйланырга, эзләнергә, бәхәсләшергә этәргән, димәк, татар дөньясын хәрәкәтләндерүче бер чара булган. Аның тарихи кыйммәте дә кадимчелек яки җәдитчелек таянычы булуда түгел, әнә шул үз кыйбласын, үз фикерен, үз алымын тапкан басма булуында.

**Рөстәм МӨХӘММӘТШИН,**
*Татарстан фәннәр академиясенең тарих институты аспиранты*

# КӨЧЛЕ РУХ, ТЫНГЫСЫЗ ҖАН, КЫЗЫКЛЫ ИҖАТ

РАФАЭЛЬ МОСТАФИНГА 70 ЯШЬ



*Россия күләмендә танылган әдәби тәнкыйтьче һәм галим, җәлилчеләр каһарманлыгын озак еллар буена армый-талмый өйрәнүче һәм халыкка пропагандалаучы, тормышка һәм әдәбиятка карата һәрвакыт актив позициядә яшәүче тынгысыз каләмле, талантлы язучы-публицист Рафаэль Мостафинга бу айда 70 яшь тула.*

*Баулы бистәсендә туып-үскән егет урта мәктәптән соң Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала, аннары укытучы, комсомол райкомы секретаре, редакция хезмәткәре булып эшли. Ә 1957—1960 елларда Р. Мостафин Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурада укый, аны тәмамлагач «Литература и жизнь» газетасының Идел буе төбәгендәге махсус хәбәрчесе булып эшли, аннары Казан телевидениесендә иҗади хезмәттә була. Татарстан язучыларының 1963 елгы V корылтаенда ул идарәнең җаваплы секретаре итеп сайлана, ә 1965 елдан алып 1968 елның апреленә кадәр «Казан утлары» журналының баш редакторы булып эшли. 1971 елда ул «Муса Җәлилнең Моабит чоры тормышы һәм иҗаты» дигән темага диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.*

*Рафаэль Мостафин әдәбият мәйданына илленче еллар ахырында, алтмышынчы еллар башында аяк баса. Шуннан соң аның үзәк һәм республика матбугатында күпсанлы әдәби тәнкыйть мәкаләләре, китаплары дөнья күрде. Татар әдәбиятының күренекле шәхесләре Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Ш. Галиев, И. Юзеев һ.б. лар турында җитди хезмәтләре басылып чыкты.*

*Тынгысыз рухлы, эзләнүчән әдип Рафаэль Мостафин җәлилчеләр батырлыгын өйрәнү һәм халыкка таныту буенча чын мәгънәсендә фидакарьләрчә тырыша. Бу хакта аның үзәк нәшриятларда гына да «По следам оборванной песни (берничә басма), «Муса Джалиль: очерк о детстве и юности поэта», «Красная ромашка», «Маленький Муса» һ.б. китаплары булды.*

*Р. Мостафин бу юнәлештә хәзер дә актив эзләнү эшләре алып бара: ул архивларда актарына, төрле шәһәрләрдә һәм чит илләрдә йөри, җәлилчеләр батырлыгына бәйле күп санлы кешеләр белән очраша... Болар өстенә, Рафаэль Мостафин көндәлек матбугатта кайнар рухлы публицистик язмалары белән укучылар йөрәгенә салынган юлны да онытмый.*

*Бу санда без журнал укучыларга юбиляр әдибебезнең җәлилчеләр батырлыгына багышланган өр-яңа язмасын тәкъдим итәбез.*

# ХӘРБИ ӘСИРЛӘР ИҖАТЫ

*«Сугышалар татар егетләре*
*Дер селкетеп бөтен дөньяны...»*

Бөек Ватан сугышы елларында фашистик Германия җирендә милли легионнар төзелә: грузин, әрмән, азәрбайҗан, Төркестан, татар легионы... Соңгысын немецлар, Кырым татарларыннан аерыр өчен, «Вольга-Татаришен легион» дип, ә татарлар үзләре исә «Идел-Урал» легионы дип йөртәләр. Власов армиясен дә кушсаң, милли легионнарда ул елларда бер миллионнан артык хәрби әсир туплана.

Легионерлар һәм власовчылар арасында пропаганда эшен алып бару өчен махсус басмалар да оештырыла. Мәсәлән, татар телендә генә дә андыйлар берничә була: «Идел-Урал» газетасы (соңыннан ул «Тюрк бирлиги» исеме белән дә чыга), «Татар әдәбияты» һәм «Германча-татарча белешмә» журналлары.

## «Идел-Урал» газетасы

«Идел-Урал» газетасы 1942 елның 15 ноябрендә чыга башлый. Кече форматта, дүрт (кайвакыт алты яки сигез) биттә, атнасына бер тапкыр, латин шрифтында басыла. Редакциянең адресы: Беренштрассе, 63, баш мөхәррире Кыям Галиев була.


Idel-Ural
Tatar legionınıŋ atnalıq gəzitəse
Inglizlər əcen kətelməgən xəl

Кызганычка каршы, безнең илдә бу газетаның тулы җыелмасы юк. Германия архивларында да «Идел-Урал»ның аерым саннары гына сакланган. Кайбер саннары Төркиядә, элекке әсирләр кулында бар. Күп еллар буена мин бу газетаның исән калган саннарын җыеп, ксерокопиясен алып тикшердем. Максатым: Муса Җәлилнең яки аның иптәшләренең безгә билгеле булмаган әсәрләрен табу иде.

Кайбер әсирләр истәлегенә караганда, Муса Җәлил бу газетада үзенең әсәрләрен «Гумеров» имзасы белән бастырган. Мәсәлән, шундый имза белән Татар опера театры тарихы, Габдулла Тукай, Каюм Насыйри һәм башка атаклы кешеләребез турында мәкаләләр басылган дип сөйлиләр. Ләкин минем кулыма мондый саннар эләкмәде. Һәм, гомумән, Җәлил яки аның иптәшләре имзасы белән басылган шигырьләр табылмады.

Шулай да, тикшерүләрем бушка китмәде: «Идел-Урал» газетасында басылган дистә ярым шигырь (барлыгы 400 юлдан артык) табылды.

## Авторлары кемнәр?

Ни дисәң дә, «Идел-Урал»—фашистлар тарафыннан чыгарылган, Совет иленә, Сталинга, большевикларга каршы юнәлдерелгән газета. Татар әсирләре моны яхшы аңлаган. Шуңа күрә, газетада катнашкан тәкъдирдә дә (хәтта мәхәббәт яки табигать турында язылган лирик шигырьләр белән булса да),

алар чын фамилияләрен күрсәтмәскә, псевдоним астында яшеренергә тырышканнар.

Әйтик, исән калып иленә кайта алган, Җәлил оешмасына да катнашы булган Гарәф Фәхретдинов үз шигырьләрен «Дим Алишев» имзасы астында бастырган (Мондый имза белән басылган берничә шигырь минем күземә дә чалынды). Башкалары исә «лег. Г», «лег. Фока», «М.Г.Б.», лег. Х», «А. Хасиб» һ. б. шуның ише псевдонимнар астына яшеренгән.

Шулай да арада чын исемнәре белән басылган авторлар да бар. Шундыйлардан Шиһап Нигъмәтине күрсәтергә була. Ул, күрәсең, баштан ук туган иленә кайтырга җыенмаган, немецларга хезмәт иткән. 1944 елның ахырларыннан 1945 елның мартына хәтле ул «Тюрк бирлиги» («Идел-Урал») газетасының баш редакторы вазифасын башкара, газета битләрендә шактый еш үз фамилиясе белән шигырьләр һәм мәкаләләр бастыра. Сугыштан соң Германиядә кала, татар телендә бер-ике шигырь җыентыгы да бастырып чыгара.

Газета сәхифәләрендә басылган әсәрләр арасында хатын-кыз исемнәре дә очраштыргалый. Мәсәлән, «К. Хәдичә», «К. Шәмсекамәр». Алар ничек монда килеп чыккан? Әсирләр сүзләренә караганда, Германиягә көчләп китерелгән эшчеләр арасында Донбасс һәм башка урыннарда яшәгән татар хатын-кызлары да шактый була. Алар Берлинда төпләнгәч, татар легиончылары белән аралаша, редакциядә дә булалар, газетада үз шигырьләре белән катнашалар.

## Шигырьләрнең әдәби кыйммәте

Баштан ук әйтим: мин тикшергән шигырьләрнең әдәби эшләнеше әллә ни югары түгел. Кайвакыт вәзен-ритмикасы аксый, кайчакта рифмасы артык гади, примитив, сурәт-образлары да искитәрлек түгел. Кыскасы, бу әсәрләр татар шигъриятенә нииндидер яңалык, табыш бирә алмый. Бу аңлашыла да: аларны профессиональ шагыйрьләр түгел, гади әсирләр язган. Алар халык иҗатына таяналар, фольклор рухында язалар. Шул ук вакытта бу шигырьләрне халык авыз иҗаты дип тә булмый, чөнки аларның авторлары бар, алар матбугат битләрендә басылган. Бу—чын мәгънәсендә һәвәскәр шигърият. Шулай караган очракта гына аларга дөрес бәя биреп була.

Ничек кенә булмасын, бу шигырьләрдә әсирләрнең уй-тойгылары, йөрәк хисләре чагылыш тапкан. Нәрсә турында язган соң алар, нинди хис аларны кулларына каләм алырга этәргән? Төп хис—туган якларын сагыну тойгысы.

Идел-Урал!
Текә ярларыңа басып синең
Һәр таның сагынып карадым.
Күксел томаннарың чолгап алды
Гүзәллегең белән камалдым.
...Мин ишеттем: офык иңнәреннән
Күтәрелгән зәңгәр тауларның
Уйсу итәгеннән башын иеп,
Наратларның көчле шаулавын.
Тыңладым мин чиксез уйга калып
Һәм күзәттем авыл буйларын,
Яшьлек хыялларым кире кайтты,
Еракларга китте уйларым.
Хыялларны җиңеп башны куям
Җәйнең җиләс йомшак җиленә,
Хөр илемнең таны ата инде,
Нурлар уйный офык читендә...

*(Лег. Фока, «Идел-Урал», 17 гыйнвар. 1944 ел)*

Туган илне сагыну, аның чиксез матурлыгына соклану мәхәббәт хисләре белән үрелә. Әсирләр туган якларда калган сөйгән кызларын, гаиләләрен, ата-аналарын сагынып искә алалар.

Мин адаштым юлдан, төн караңгы,
Белмим, нидер көтәм...
Кайда икән минем якын дуслар?
Кайда минем иркәм?

*(Лег. Г. «Идел-Урал», 2 май 1943 ел)*

Тын далада үскән ак каенның
Яфраклары тавышын тыңладым,
Аңа ошатып, татар кызкаенның
«Сине сагынам» җырын тыңладым.

*(Лег. А. Хасиб, Шул ук санда)*

Авторларның күпчелеге авылдан чыккан булса кирәк, чөнки алар туган авылларын, аның табигатен, кешеләрен сагынып язалар. Әсәрләрендә дә халык җырларына хас чагыштырулар, фольклорча фикерләү сизелә. Әмма арада шәһәр темасына язылган, башкалабыз Казанны искә алып язылган шигырьләр дә очрый. Мондый әсәрләрдә авторларның милли хисләре дә бик ачык һәм төгәл чагылыш таба:

Күз алдымда тора Идел-Урал,
Урманнары, болын, кырлары...
Торган кебек иленең чиген саклап
Татарымның батыр уллары.

Күрәсезме горур манарасын
Сөембикә ханның, Казанның?

Болытларга сузып мәгърур башын
Әйтә кебек чакыру азанын.

Чакыра кебек татар угылларын
Ярдәм сорап татар иленә.
«Бабаларың данын даула», диеп,
Ымлый кебек күренә күземә.

*(М. Г. Б.» «Идел-Урал», 15 ноябрь 1942 ел)*

Кайбер шигырьләр исә башкалабызга мәдхия рәвешендә яңгырый. «Казан» исемле әсәр—шундыйлардан.

Аерылып синнән еракка
Китсәм дә, туган калам,
Һич онытмыйм, күңелемдә
Балкып янасың һаман.

Чөнки синдә беренче кат
Бабамнар ханлык төзеп,
Яшәгән булса шатланып,
Коллык чылбырын өзеп...

*(Л. Хәйруллин, «Идел-Урал», 30 декабрь 1944 ел)*

Шунысы да игътибарга лаек: әсирләрнең ачы язмышы, ачлыктан интегүләре, меңләп-меңләп кырылулары газета битләрендә басылган шигырьләрдә бөтенләй диярлек чагылмаган. Хәтта «Хәрби әсирләр лагере» дип аталган шигырьдә дә сүз нигездә мәхәббәт, сагыну хисләре турында бара:

Көтә микән?
Яшь егеткәй китте чит илләргә,
Туып үскән илен калдырып.
Ят - милләткә хезмәт итте,
Сагыш белән йөрәк яндырып...

*(Ш. Нигъмәти. Шул ук санда)*

Бу аңлашыла да—дошман кулында булган хәлдә аны фаш итеп булмый ич! Әсирләрнең яшәгән мохитлары караңгы төн икәнлеге читләтеп, киная белән генә әйтелә. Менә, мисал өчен, «Язны каршылау» дип исемләнгән шигырьдә көнчыгыштан күтәрелеп килә торган кояш әсиргә болай дип эндәшә:

Төн артыннан көннең туарына
Ышанасың тирән,
Китәр кайгың, килер шатлык тизлән,
Тизлән, тизлән, иркәм!

Барыр юлың синен—минем, иркәм,
Торып чыккан якта.
Ыргыт йөрәгеңнән кайгыларны,
Улым, минем хакка.

Шунда синең дуслар, якын анаң,
Шунда синең иркәң.
Һәр көн саен кайнар сәламеңне
Мин аларга илтәм...

*(Лег. Г «Идел-Урал», 2 май 1943 ел)*

Бу тема—салкын кышның котылгысыз үтүе, матур язларның якынлашып килүе—бик күп шигырьләрдә кабатлана.

Идел-Урал!
Синең гөл-бакчаңда
Әллә булса ак кар ябынып,
Гаҗәп матур гөлләр йоклыйлармы,
Яз кояшын өзелеп сагынып?
Нинди генә каты кыш булмасын,
Нинди ачы җилләр исмәсен,
Төн ягының нинди генә усал
Сукмаклары бәгърең кисмәсен,
И, туган ил!
Барыбер язлар килер,
Шаулап-шаулап сулар агарлар,
Киң кырларың кар юрганын ташлап,
Зәңгәр күккә яшьнәп багарлар...

*(Лег Х, Шул ук санда)*

Тагын бер нәрсә күзгә ташлана. Бик күп шигырьләрдә—кирәксә-кирәкмәсә дә—Идел-Урал сүзләре әледән-әле кабатланып килә. Кайбер әсирләрнең аңлатуынча, редакциянең таләбе шундый булган: теләсәң нәрсә турында яз, тик Идел-Уралны гына ешрак искә ал! Моның тел төбе: фашистлар татарларга вәгъдә иткән «бәйсез» Идел-Урал дәүләтен зурлау, аңа дан җырлау... Ләкин, чынлыкта исә мондый шигырьләрдә, бик тырышып эзләсәң дә, берниндн сәяси мотивлар очрата алмыйсың, Илне сагыну, аның матурлыгына соклану, үз халкы, аның батыр уллары белән горурлану бар. Әмма сәясәт,



*Рафаэль Мостафин безнең көннәрдә исән -сау яшәүче бердәнбер җәлилче Фәрит Солтанбәков белән. 1980 ел.*

бигрәк тә фашистлар күрергә теләгән сәясәтнең эзе дә юк.

Бу яктан «Безнең батыр» исемле озын шигырь бик характерлы. Ул табигать күренешеннән башланып китә:

Әнә, күрәсезме, киң Уралның
Тармагында тора бер авыл.
Күмелсә дә карга кыш көннәре,
Җәй житкәчтен ямьле була ул.
Чит-читләре аның яшел урман,
Чәчәк белән тула җәй көне.
Чылтыр-чылтыр ага чишмәләре,
Сандугачлар сайрый көн-төне.
Шул авылның аргы бер читендә,
Җыйнак өйдә матур кыз бала
Карап тора айга онытылып,
Бик моңаеп кына сызлана...

Бу шигырьнең тарихы турында Г. Фәхретдинов болай сөйләгән иде: Легионда бер һәвәскәр рәссам да табыла. Ул төсле буяу белән киндергә татар авылы күренешен төшерә. Өй кырында матур кыз, моңаеп, яңа туган айга карап, сөйгән егетен сагынып тора. Шул күренештән башлап китеп, автор татар сугышчыларының батырлыгын тасвирлый:

Әнә күрәсезме, көнбатышның
Даласында сугыш мәйданы.
Сугышалар татар егетләре
Дер селкетеп бөтен дөньяны.

Дошманнарның көче күп булса да,
Чигенмәгез артка башкалар.
Ул чигенми, Урал каһарманы,
Тик кычкыра: «Качма, алга бар!»

Бу юлларда (аларны легиончы Борисов язган, «Идел-Урал»ның 28 май, 1943 ел санында басылган) берникадәр Муса Җәлил тәэсире дә сизелә. Шигырьдәге акбүз ат образы әнә шундыйлардан:

Акбүз атка менгән, кылычын болгап
Алдан бара егет баш булып.
Курыкмый икән дошман гаскәреннән,
Йөрәге каткан аның таш булып... *(Лег. Борисов)*

Бәлки бу очраклы гына аваздашлыктыр. Ләкин шулай да легионерлар арасында да сәләтле кешеләр аз булмаган. Гомумән, «Идел-Урал»да басылган әсәрләр халкыбызның шигъри җанлы, нечкә тойгылы булуын тагы бер раслый. Нинди авыр шартларда да тоткыннар төшенкелеккә бирелмәгән, якты өметләрен югалтмаган, чын кеше булып кала алган... Алай гына да түгел, алар милли тойгыларын да җуймаган, ана телен күз карасы кебек саклый белгән:

Тарих шаһит безнең данybызга,
Безнең исем дөнья шаулаткан,
Безнең кояш зенит ноктасында
Гасырларча торып яктырткан.
Идел-Урал—безнең төп йортыбыз,
Безнең нәсел анда күмелгән,
Үзенең илен, ирегең саклап,
Халкым каны анда түгелгән...

*(«М. Г. Б.» шигыре)*

Бу юллар язылуга инде алтмыш елга якын вакыт узган. Аларның авторлары, сугышта исән калган булса да, күптән инде дөнья куйгандыр. Кайчандыр бу юлларны газетада укыган кешеләр дә бик сирәктер инде... Ә шигырьләр, шулай да, яши, уйландыра, алардагы йөрәк хисләре безне әлегәчә дулкынландыра.

**Рафаэль МОСТАФИН**

# ОЧКАНЫНДА НИ БУЛСА...

ӘХӘТ МУШИНСКИЙГА 50 ЯШЬ

Язучы, гомумән, шәхес буларак, Әхәт Мушинский турында сүз чыктымы, татар халкының шушы акыллы, күпъеллык тормыш тәҗрибәсен сыйдырган гыйбрәтле сүзләре искә килеп төшә. Хәер, Әхәт моны үзе дә яшерми, җае туры килгәндә: «Мин Казанның интеллигентлы татар гаиләсендә тәрбияләнеп үстем,—ди эчке бер нәзакәтлек белән. Әтием—Хәй Хафиз улы Мушинский була инде, танылган профессионал фокусчы-иллюзионист иде, җыйнак кына гәүдәле, пөхтә кеше иде. Әнием дә, ул Рәбига исемле иде, гомере буена татар сәнгатенә хезмәт итте. Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында җырлады. Кыскасы, безнең өйдән артистлар, музыкантлар, язучылар өзелеп тормады. Әдәбият-сәнгать дөньясына тартылуымда болар да эзсез югалмагандыр, мөгаен».



Бүгенге көндә Әхәт Мушинский сәнгатьнең «өч яссылыгында» яши. Беренче чиратта—ул, әйе, язучы. Әйткәнебезчә, гаиләсендә татар тәрбиясе алса да Әхәт урысча язарга мәҗбүр (ни дисәң дә, шәһәр баласы, татар мәктәпләре ябылып беткән бер чорда, гомуми урыслашу бәласен читләтеп үтеп буламы соң), ул «Шейх и звездочет», «Треугольники», «Гол в девятку», «Тезка» дигән проза китаплары авторы. Аның «Кайту» һәм «Ак бүре» повестьлары «Казан утлары» журналында басылып чыгып, укучылар тарафыннан җылы кабул ителде. Шулай да әле яңарак кына дөнья күргән «Записки горбатого человека» романы авторның иң уңышлы әсәрләреннән саналырга хаклы. Биредә язучы, яшьлек идеалларына тугрылыклы калган хәлдә, югарырак кимәлдә фикер йөртә, тормыш, яшәү философиясе турында тирәнрәк уйлана. «Мәхәббәт һәм нәфрәт, чын һәм ялган шигърият, чын һәм ясалма кешеләр, тормыш мәгънәсе һәм андагы мәгънәсезлекләр»—әсәрнең кредосы менә шуннан гыйбарәт. Миргазиян Юныс, әсәргә бәя биреп, «Лирик геройның башы белән «кызыл стенага» һөҗүм итүен»дә, чор-заман фаҗигасен дә, шәхес һәм җәмгыять арасында барган көрәшнең аянычлы якларын да дөрес билгеләп үтә. Кыскасы, Әхәт Мушинский бу әсәре белән үзен житлеккән прозаик, каләм остасы итеп танытты.

Әхәт «өч яссылыкта» яши дигән идек бит... Ул—татар ПЕН-үзәгенең башкаручы директоры да бит әле. Мәгълүм булганча, ПЕН-үзәк моннан алты ел элек оешкан иде. Шушы дәвер эчендә ул шактый гына эшләр башкарды. Әйтик, Халыкара ПЕН-клуб ел саен конгресслар үткәрә. Татар ПЕН-үзәге шуларның Мексикада, Шотландиядә һәм Финляндиядә уздырылганнарында катнашырга өлгерде инде. Бу гамәл дә—ник кирәк ул тагын бер эшләмәгән бюрократик оешма, дип әйтүчеләргә җавап булсын!—татар милләтенең гомум кешелек аудиториясенә чыгуына, ә аудиториянең кабул итүенә бер дәлил. Әйтик, Бөтендөнья Язучылар ассоциясе 140 илнең ПЕН-үзәкләрен берләштерә, Русиядә мондый үзәкләр икәү генә—урысларныкы һәм татарларныкы. Бу безнең абруебыз үсә бару турында сөйли түгелме?

Белмәгәннәр белеп торсыннар дигәндәй, ПЕН-клуб, беренче чиратта, хокук саклау оешмасы: ул сүз иреге, иҗат иреге һәм иҗатчыларның иреге һәм хокуклары сагында тора. Әлбәттә, клуб хокук саклау функцияләрен генә башкара дип уйлау дөрес булмас иде, шуңа күрә клуб эшчәнлегенең конкрет

юнәлешләрен, кайбер тармакларын гына билгеләп үтү дә кайбер уйлануларга этәрер, мөгаен: «Әдәбиятларның үзара тәэсир итешүе», «Әдәби тәржемә һәм лингвистика хокуклары», «Төрле халыкларның телләрен һәм әдәбиятларын саклау». ПЕН-клуб каршында шушы эшчәнлек—әдәбият мәсьәләләренә караган эшчәнлек—хәзерге вакытта иң мөһиме булып тора. Үз чиратында, татар ПЕН-үзәге дә бу юнәлештә хәл кадәри эш башкара. Хельсинкида үткәрелгән конгресска ул инглиз телендә чыккан «Бүгенге татар әдәбияты» дигән китапны әзерләгән булса, Варшавада үтәсе конгреска, шулай ук инглиз телендә, «Татар халык әкиятләре» дигән сюрприз-бүләк алып барды. Татарның танылу юлы, шөкер, менә шулай төрле юнәлешләрдә дәвам итә. Узган ел Мәскәүдә уздырылган конгресста Рус ПЕН-үзәге президенты Андрей Битов сүзләре белән әйтсәк: «Күпмилләтле дөнья әдәбияты—зур болын ул, анда кирәкле яисә кирәксез чәчәкләр юк. Бер төр үсемлекнең юкка чыгуы—бөтен Җир табигате өчен зур югалту ул». Ә татар әдәбияты югалмаска, башка бик күп дөнья әдәбияты белән, аның алдынгы вәкилләре белән аралашып яшәргә тиеш.

«Өченче яссылык» дигәнебез, Әхәт Мушинский «Татарстан» дәүләт телевидениесе аша «Яшел камин янында» дип исемләнгән тапшыруларны алып баручы буларак дан-шөһрәт казанган тележурналист та бит әле. Сәгать буена сузылган, әмма бер дә ялыктырмый торган бу тапшыру, әйтергә кирәк, үзенең интеллектуаль югарылыгы ягыннан, рейтингы ягыннан бер дә мактаулы Мәскәү тапшыруларыннан калышмый; димәк, бу нәүбәттән, Әхәт үзе дә Мәскәү йолдызларыннан ким түгел дигән сүз. Әйе, президентыбыз М.Ш. Шәймиев, Дәүләт Югары Советы рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин кебек сәясәтчеләребез, Әмирхан Еники, Миргазыян Юныс, Разил Вәлиев кебек язучыларыбыз, Вил Мирзаянов, бертуган Акчуриннар һәм башка бик күп зыялыларыбыз катнашында алып барылган әңгәмәләр (барысы 70 якын) чын мәгънәсендә «хит»ка әйләнде. Монысы да Әхәт Мушинскийның киң эрудицияле, тыйнак, әмма кирәк чакта әйдаман әдип булуы хакында сөйли.

Яз, эшлә, иҗат ит, Әдип!

**Наис ГАМБӘР**

# БЕР СОРАУГА—БЕР ҖАВАП

**—Латин имласына кайту буенча бүгенге көндә республикабызда нинди эшләр башкарыла?**

Бу сорауга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан халыклары телләрен үстерү бүлеге мөдире Ким Миңнуллин җавап бирә:

—Узган ел Министрлар Кабинеты «Латин графикасына нигезләнгән татар алфавитын кайтару буенча беренчел чаралар хакында» карар кабуул итте. Фәннәр Академиясенә, Финанс, Мәгариф, Мәдәният министрлыкларына, дәүләт оешмаларына латинга күчү буенча тәгаен йөкләмәләр һәм күрсәтмәләр бирелде. Бүгенге көндә матди-техник һәм фәнни-методик база ныгытыла. "Мәгариф" нәшрияты «Татар теленең орфографиясе»н һәм "Әлифба" китабын, мәктәпләр өчен төрле таблицалар һәм ярдәмче әсбаплар бастырып чыгарды. Компьютерларга латин имласын кодлаштыру стандартлары һәм база программалары әзерләнде.

Яңа уку елыннан, Президентыбыз кул куйган Законда каралганча, беренче сыйныф балалары латин имласында укытыла башлый. Укытучылар бу җаваплы эшкә әзер. Мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү институтында башлангыч сыйныф укытучылары өчен махсус курслар эшләде. Анда белем алган укытучылар хәзер республика мәктәпләрендә латин графикасын өйрәтү дәресләре уздыралар. Латин графикасын кайтару ике төп нигез ташына—педагогик һәм методик нигезләргә корыла.

Быелдан башлап дәүләт оешмаларында, элемтә, сәүдә, матбугат һәм башка тармакларда эшләүче хезмәткәрләрне латин графикасына өйрәтүгә керешәчәкбез. Бу зур һәм җитди гамәл әле янә 4-5 ел дәвамында башкарылачак.

«Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турындагы Закон» быел, ягъни 2001 елның 1 сентябреннән үз көченә керә. 10 ел дәвамында, 2001 елның 1 сентябренә кадәр Республикада бер үк вакытта ике алфавит—латин графикасы нигезендәге һәм кириллица гамәлдә булачак.

# “МӘГАРИФ” ГАСЫРЫ

## «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ ЯНАДАН АЧЫЛУГА 10 ЕЛ

*ДОКУМЕНТЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР*

...Мәгърифәтле халыкның беренче китабы — дәреслек, уку әсбабы булган. Гасыр башындагы төүге нәшрият-матбагаларыбыз арасында “Мәгариф” исемлесе тикмәгә генә яктырып кабынганмы?

* * *

**1901 елда** Казанда Галиәсгар Камал, халык арасында ан-белем таратуга булышлык итү максаты белән, “Мәгариф көтебханәсе” исемендә китап бастыру һәм сату ширкәте оештыра.

*“Совет Татарстаны язучылары” дигән китаптан.—Казан, 1986. 226 бит.*

* * *

**1906 елның 1 ноябрендә,** “Мәгариф” нәшриятының база басмаханәсе буларак, “Матбагаи Шәрәф” типографиясе ачыла. **1913 елда** “Мәгариф көтебханәсе” житәкчеләреннән берсе Мөхәммәтәмин Мостафин “Мәгариф” типографиясен ача. **1913 елның 7 апрелендә** “Йолдыз” газетасы хәбәр итүенчә, Г. Тукайның “Мәгариф көтебханәсе”ндә сатылган китапларыннан җыелган 500 сумнан артыграк акчасы калган. Шагыйрь шул акчага бер ятим баланы мәктәптә тәрбияләп чыгаруны васыять иткән.

*“Татар әдәбияты тарихы”. 3 том.—Казан, 1986. 580 бит.*

* * *

“Мөхтәрәм Галиәсгар әфәнде Камал!

Бүген Сезнең милли әдәбиятыбызга каләм илә хезмәт итә башлавыңызга һәм дә мәктәп-мәдрәсәләремезне аяныч хәленнән чыгарып, яңа юлга салуга, яңа рухта тәрбия ителә башлавына вә милли әдәбиятымызның таралуына халкымызның иң беренче ярдәмчесе булган “Мәгариф көтебханәсе”не тәэсис итүенезгә 10 ел тулды...

Моннан соң да күп еллар ялыкмый шул юлда дәвам итүеңезгә ышанамыз.

Ихтирам илә: “Мәгариф көтебханәсе” әгъзаларыннан—Әмин Мостафин, Кәрим Хәнәфи, Гыйльметдин Шәрәф”.

*Бу тәбрик хаты Габдулла Тукайның “Галиәсгар әфәнде Камалның 10 еллык юбилейсе” дигән мәкаләсендә китерелә. —“Йолдыз” газетасы. 1910 ел, 22 ноябрь.*




*XX гасыр башында «Мәгариф» нәшрияты чыгарган дәреслекләрдән бер үрнәк*

* * *

“Мәгариф” Г. Тукай белән тыгыз элемтәдә була, Г. Тукайның барлык әсәрләре диярлек бу ширкәт тарафыннан бастырыла... “Мәгариф” үз исеменнән китап бастыру эше белән 1921 елга кадәр шөгыльләнә, берничә басма аның грифы белән 1922 елда да чыга... “Мәгариф” ширкәте чыгарган китаплар арасында Ф. Әмирхан, М.

Гафури, Н. Исәнбәт, Г. Исхакый... әсәрләрен күрәбез... Рус һәм чит ил әдәбияты Л. Н. Толстой, А. П. Чехов, Г. Х. Андерсен һ.б. язучыларның тәрҗемә ителгән әсәрләре аша тәкъдим ителә. "Мәгариф" китаплары арасында төбәк тарихы буенча хезмәтләр бар... Дәреслекләр һәм уку әсбаплары зур урын алып тора... "Мәгариф" нәшриятының Октябрьдән соңгы китаплары да аның беренче чиратта балалар әдәбияты һәм милли мәктәпләр өчен дәреслекләр, уку әсбаплары нәшрияты булуы, ягъни халык мәгарифенә хезмәт итү традицияләренә тугрылыклы булып калуы турында сөйли.

*Ә. Г. Кәримуллинның "Становление и развитие татарской советской книги" дигән хезмәте буенча.—Казан, 1989. 235—238 битләр.*

* * *

Дәреслек һәм балалар китабы бастырган, халыкның күнелен агартуда зур хезмәтләр күрсәткән нәшрият. Барча учаклар сүнеп беткәндә дә, "Мәгариф" сакланырга тиеш иде кебек, югыйсә. Юк, Сталин хакимияте моңа юл куймый, мал-мөлкәтен тартып алып, милләткә түгел—юлбашчыга хезмәт итүчеләр кулына бирә. Һәм бу тикмәгә генә түгел: милләтнен тамырына балта чабыйм дисән, китабын тартып ал син аның, мәктәбен корыт. Татарның мәгърифәт кояшы бату "Мәгариф"ләрсез калганнан соң башлана. Китап—кайчандыр мәгърифәтле, китаби татарның артта калуы, чикләнгәнлеге, җәберсетелүе күрсәткеченә әверелә.

"Мәгариф"нең мәгълүм "үзәкләштерү"ләр вакытында тарих чоңгылына китеп, коммунистик нәшрият системасы тарафыннан йотылган чоры бер гыйбрәт-аллегория булып күз алдына килә. Буйсынмавы өчен Аллаһ каһәренә юлыгып, кырык көн (җитмеш ел ук түгел!) балык карынында тоткын булган Юныс пәйгамбәр хакындагы риваять искә төшә... "Мәгариф"нең дә үзен "алла" дип санаган Сталин хакимияте каршында "гөнаһлары" зур—милләткә кылган хезмәтенә бәрабәр булган. Әнә шул хезмәтләре онытылмаганга, яңа заманда ихтыяҗы туу белән, "балык карыны"ннан кабат тормышка, иҗатка әйләнеп кайтты ул.

*Татарстан көндәлек матбугатыннан.*

* * *

Республика уку йортлары өчен педагогик әдәбият чыгару күләмен арттыру һәм сыйфатын яхшырту ихтыяҗы белән бәйле рәвештә, Татарстан ССР Министрлар Советы КАРАР БИРӘ:

1. ТССР Госкомиздаты системасында укыту-методик әдәбият чыгару буенча "Мәгариф" нәшриятын төзү турында ТССР Халык мәгарифе министрлыгы, ТССР Госкомиздаты тәкъдимен кабул итәргә...

Татарстан ССР Министрлар Советы Председателе М. Г. Сабиров.
*1991 ел, 11 май.*

* * *

МОСКВА 5/7 1722=
КАЗАНЬ БАУМАНА 19 ИЗДАТЕЛЬСТВО МАГАРИФ ВАЛЕЕВУ=
МИНИНФОРМПЕЧАТЬ РФ ВЫРАЖАЕТ БЛАГОДАРНОСТЬ КОЛЛЕКТИВУ ИЗДАТЕЛЬСТВА ЗПТ СВОЕВРЕМЕННО ЗАВЕРШИВШЕМУ ВЫПУСК ШКОЛЬНЫХ УЧЕБНИКОВ ТЧК ЖЕЛАЕМ НОВЫХ ТВОРЧЕСКИХ УСПЕХОВ= ЗАММИНИНФОРМПЕЧАТИ СУДАКОВ=

*Россия Матбугат министрлыгыннан килгән рәхмәт телеграммасы.—1993 ел, 5 июль.*

* * *

По поводу обращения руководителя Контрольно-ревизионного управления Министерства финансов РФ г-на Колобова Г. Н. к Премьер-министру РТ... сообщаем следующее:

...Главная причина всех бед и проблем заключается в хронической задержке оплаты выпущенных учебников. Так, за первую половину 1995 г. Министерством образования было оплачено лишь 20,5% всей выпущенной продукции. Задолженность Министерства на сегодняшний день составляет 2,4 млрд. руб., в результате чего к новому учебному году выпущено лишь 7,3% необходимого количества учебников.

Директор издательства "Магариф" М. Х. Валеев.
*Рәсми хаттан*

* * *

...Күрәсез, бу бина бөек исемнәр чатында—Пушкин урамында, Габдулла Тукай һәйкәленә каршы урнашкан. Моннан берничә адымда гына—мәшһүр "Болгар" номерлары, 97 ел элек Галиәсгар Камал бабабыз ачкан "Мәгариф" исемле китап ширкәтенең нигезе. Тарихи "Мәгариф" нәшриятының бишеге шунда тирбәлгән!..

Бүген безнең урамда икеләтә бәйрәм—"Мәгариф" нәшрияты бастырып чыгарган "Күчтәнәч" китабы республикабызның Тукай бүләгенә лаек булды. Дәреслек һәм балалар китабы чыгаруда Тукай васыятьләрен үтәүче "Мәгариф" чишмәсеннән бер йотым булсын дип, сезгә ул китапны бүләк итәбез.

*"Мәгариф" нәшриятының фирма кибете ачылу вакытында әйтелгән сүзләр.—1998 ел, 26 апрель.*

* * *

Каләм әһеле өчен барыбер иң олы бүләк—китабы басылып чыгудыр... Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт ага Галиев, мәсәлән, үзенең туган көнендә, Сабан туе мәйданының уртасына чыккан кебек, Камал театры сәхнәсенә басып, әле генә нәшриятлар "табасыннан төшкән" ике китабын берьюлы кулына алды. "Мәгариф" нәшриятында басылган "Көләч көзге" исемле китабын без, уенын-чынын бергә кушып: "Аксакал, Сезгә без бүген Хөкүмәт бүләген тапшырабыз",—дип бирдек. Һәм бу сүзләрдә шаяртудан бигрәк хаклык күбрәк иде...

Инде "Мәгариф"тә чыккан беренче китаплары белән Язучылар берлегенә кабул ителгән яшьләр дә бар. (Сүз уңаеннан әйткәндә, Россия күләмендә үткәрелгән балалар китабы конкурсында 90 нәшрият—шул җөмләдән урысның бай үзәк нәшриятлары!—арасында өченче батыр булып "Мәгариф" калды.)

*"Мәдәни җомга" газетасы.—28 май, 1999 ел.*

* * *

Татар дәреслеген кем генә кулына алса да, "Мәгариф" дигән "дәүләт"нең эмблемасына игътибар итми калмыйдыр, мөгаен. Беренче карашка ул бик гади: Республикабыз гербындагы ак барсның "малай чагы" гыйлем-мәгърифәтнең әлифенә—"а" хәрефенә таянган. Аның ике канаты—ике дәүләт телендәге китапларны гәүдәләндерә. Шул гади образга символик мәгънә салынган: "Мәгариф" нәшрияты үзе дә мөстәкыйльлегебезнең, дәүләтебезнең бер атрибуты (билгесе) бит.

"Таң җилләре" исә башлауга милли дәреслек нәшрияты төзелүнең стратегик максаты бар иде, һәм ул, вакыт күрсәткәнчә, үзен аклады. Гаяз Исхакыйның без девиз-шигарь итеп кабул иткән "Мәгариф—азатлык юлында беренче адым" дигән сүзләре дә XX йөз ахырында яңа мәгънәләре белән ачылып китте.

Әйе, без бүген гасыр башы белән гасыр ахыры арасында "электр дугасы" кебек киеренке һәм җегәрле бәйләныш кыры барлыкка килүен, рухи һәм җисми аһәңдәшлек пәйда булуын тоябыз.

*"Милли мәгариф: 10 еллык нәтиҗә" дигән фәнни-гамәли конференция өчен әзерләнгән чыгыштан.—2000 ел, 8 сентябрь.*

* * *

...Россия Китап палатасы мәгълүматларына караганда, илдә матур әдәбият бастыру һәм шулай ук балалар китабы чыгару соңгы ун ел эчендә 6—7 тапкыр кимегән, һәм бу тенденция әле дә дәвам итә икән. Инде никадәр нәшриятлар ачылып, атыша-тәртешә дәреслек бизнесына ябырылсалар да, баксаң, хәтта дәреслек һәм методик әдәбият бастыру да 1,7 тапкыр кимегән.

...Әле генә туган "Мәгариф"не бишеккә салып тирбәтмәсәләр дә, кырыс һәм кысыр заманда нәшрият кадәр нәшрият ачуга батырчылык иткән Хөкүмәт безне үз канаты астына алды. Моның нәтиҗәсе дә күз алдында. Мәсәлән, алдагы ел белән чагыштырганда, 2000 елда 1,5 тапкыр күбрәк китап чыгардык, Мәгариф министрлыгының дәреслек чыгаруга биргән заказын тулысынча үти алдык.

...Моннан ун гына ел элек әле Казанда нибары бер татар мәктәбе тереклек итә, татарча балалар китабы да, милли дәреслек тә җилемгә катып беткән ямьсез тышлык кигән, 2 нче сортлы дип атала торган саргылт кәгазьдә басылган булыр иде. Әлеге китаплар безнең балаларга "икенче сортлы халык иканегезне белеп үсегез!" дип тукып торалар иде сыман.

Бүген исә балаларыбыз кулында—якты, көләч чырайлы татар китаплары.

Ун ел элек китап тышлыклары гына түгел, фикерләвебез дә башка иде бит.

...Гомуми тиражы 13 миллион данәдән артып киткән 750 китап—әлегәчә башкарылган хезмәтнең нәтиҗәсе әнә шундый. Күпме бу, азмы? Балалар белән очрашканда, без шундый чагыштыру китерәбез: әгәр без чыгарган китапларны "гыйлем сукмагы" итеп салсан, ул сукмакнын бер башы Казанда булса, икенче очы... Берлинга барып житәр иде, дибез. Милли китапка, тулаем мәдәнияткә, әдәбият-сәнгатькә шундый кайгыртучан мөнәсәбәт булганда, "Мәгариф" нәшрияты Берлинны гына "алып" калмас әле.

*"Мәдәни җомга" газетасы.—2001 ел, 23 март.*

* * *

2000 ЕЛДА КИТАП БАСТЫРУ КҮЛӘМЕ БУЕНЧА ТАТАРСТАН НӘШРИЯТЛАРЫНЫҢ РЕЙТИНГЫ




*Татарстан Республикасы Матбугат, телевидение, радиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгы мәгълүматларыннан*

* * *

"Мәгариф" нәшриятын төзү турында карар ун ел элек—республикабыз тормышынын катлаулы һәм хәлиткеч чорында кабул ителгән иде. Яна нәшрият, үз өстенә зур җаваплылык алып, милли мәгариф һәм нәшрият эшенең бай традицияләренә таянып, эшкә керешге. Шул сәбәпле аны гасыр башында Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан замандашлары оештырган шул ук исемдәге, ягъни "Мәгариф" нәшрият-матбага ширкәтенең дәвамчысы сыйфатында кабул итү табигый дип саныйм.

Балаларыбызга туган телдә белем һәм тәрбия бирү кебек гаять мөһим бурычны гамәлгә ашыруда шушы ун ел эчендә ирешелгән казанышларыбызны "Мәгариф" нәшриятынын күпкырлы эшчәнлегеннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел...

"Мәгариф"—Россиядә милли дәреслек бастыру белән шөгыльләнүче иң зур нәшрият. Ул Европа һәм Азия кинлекләрендә татарлар тупланып яши торган һәр төбәккә мәгърифәт нуры тарата...

Чын мәгънәсендә милли дәреслек һәм балалар китабы үзәгенә әверелгән "Мәгариф" нәшриятынын эш сөючән, фидакарь коллективына, аның авторларына—күренекле галимнәребезгә, әдипләребезгә һәм рәссамнарыбызга—яна иҗади казанышлар, сәламәтлек, бәхет телим.

*Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев котлавыннан.*

* * *

...Коръәндә: "Күллү үммәтин түдгә илә китабиһә..." — ягъни *(Кыямәт көнендә)* һәр халык үзенең китабы янына чакырып китерелер, дигән сүзләр бар *("Җәсийә" сурәсе, 28 нче айәт)*. "Китап" сүзен гамәл дәфтәре мәгънәсендә куллана Коръән. Безнең татар да үзенең гамәл дәфтәре — Китабы белән башка милләтләр арасында лаеклы, горур урынын алсын иде.

*Yumor-satira*

## Aziz Nəsin,

tərek yazuçısı

### Өç fəreştəçeknen ənise

Ayaqların keçkə səyrəp ber qart bara. Anın başında bersen-berse quıp uyları almaşınıp tora. Menə alar:

«İn awırı cilkənnən üz awırlığını alıp taşlawdır...»

«Bu avtomobillər qotınnğanday çabışalar...»

«Ğəcəp xəl: gəwdən cinel bulğan saen yərüe awırlaşa...»

«Bigrək bay, zinnətle avtomobillər, tərle təstəgelər, tərle markalılar!»

«Belsən ide, min küpme awırlıqta ikən? Ber ille kilogrammnar. Yuq la! Küp bulsa, qırıq bişlərder...»

Şunda ul yutəlləp aldı. Annarı awır sulap quydı:

«Şuşı kengə qalırmın, dip, kem uylağan bit... Beraz tiennərem bulsa ide—ike kelinder alırlıq qına! Tağın ber stakan qaynar çəylek...»

Yalıq-yolıq kilep torğan zəngər limuzin kürende. Ruldə—şiğriət kebek güzəl xatın-qız! Anın çəçləre tuzğıp taralğan. Avtomobil tizlegen kimetə təşte. Qartqa rul totqan xatın üzenə tekəlebrək qarağan təsle toyıldı.

Yanaqları eçkə batqan yabıq qart kələmserəp quydı:

«Mina şul anın belən tipterergə genə qalğan, di!»

Yalıq-yolıq kilep torğan zəngər limuzin alğaraq ütep tuqtadı. Qart anın belən tigezləngəç, xatın tərəzədən başın tığıp qarap aldı. Yuq, qart yalğışmağan: xatın çınlap ta ana qarıy ide.

Zəngər limuzin beraz alğaraq kitte də tağın tuqtadı. Xatın qarttan küzen ala almıy ide. Bəlki, qartnı berər keşegə oxşatıp, yalğışqandır ul? Ə, bəlki, anı qızğanğandır.

«Əllə mina küze təşteme ikən son?»—dip, eçennən genə künelsez şayartıp quydı qart.

Zəngər limuzin əle alğa kitep bara, əle tuqtalıp qala ide. Qart uramnın un yağına çıqtı. Matur xatın ana qarawın maşinasının ikençe yaq tərəzəsennən dəwam itterde. «Ə bit yəşlegemdə min çibər sanala idem!»—dip uyladı qart, kəprəyep.

Ul yanadan uramnın sul yağına küçte. Zəngər limuzin anın yanına kilep tuqtadı da xatın tərəzədən ana qıçqırdı:

—Aç işekne, utır!

Qart yuğalıp qaldı. Əmma xatınnın yılmayıp qarawı ana qıyulıq əstəde həm ul maşinağa kerep utırdı. Limuzin quzğalıp kitte. Xatın süzsez ide. Qart ta süzsez. Limuzin ber zur yort yanına kilep tuqtadı. İşek təbendə ük alarnı xadimə qız qarşı aldı, ul küz qırıyı belən genə qartqa ğəcəplənep qarap quydı.

Alar bik zatlı-zinnətle bülməgə barıp kerdelər. Xucabikə qartqa qırt qına boyırdı:

—Çişen!

—Xanım, yuınıp alırğa ğına rəxsət itsəgezçe!

—Çişen, dim!

«Təmam təqəte təkəngən ikən, kürəsen, irlərne bik tansıqlağandır.» Qart əstendəge pıçraq, sələmə külməgen salıp ırğıttı.

—Çalbarıŋnı da sal!

Qartnıŋ inde bernindi şik-şəbhəse qalmağan ide. Açlıq-aruların da onıtıp, ul xucabikənen yuan botlarına, tulışıp-taşıp torğan kükrəklərenə aşarday bulıp qaradı. «Ə niğə bulmasın ikən?! —dip uyladı ul.—Min—anıŋ kaprizı. Yərəge quşqan da, ul menə nəq mine saylap alğan!»

«Xodayım, oyatqa ğına qaldıra kürmə! Mədət bir!»—qart şundıy yalwarulı uylar belən çalbarın da salıp quydı da xucabikəgə taba atladı.

—Iştanıŋnı da sal!—dip boyırdı xucabikə. Üze qıŋğıraw təyməsenə bastı. Xucabikəse şikelle ük çibər genə xadimə kilep kerde.

Qart əsərep kitte. «Nu, monısı uq artıq inde!— dip uyladı ul.—Minem yəştə ikesenə də keç citməster!»

Xucabikə xadiməsenə boyırdı:

—Tərbiyəçegə əyt, balalarnı bire kitersen!

Xadimə çığıp kitte. Qart şəp-şərə kileş basıp tora ide. Əllə tuŋudan, əllə dulqınlanudan ul der-der qaltırıy ide. Anıŋ berwaqıt işetkəne bar ide: nindider ber çibər xanım, xıyənət itkən irenə üçlektən, berençe oçrağan ir-atnı üzenə çaqırıp kertkən, imeş. «Menə bu xanım da mine üzeneŋ üç qoralı itep faydalanmaqçı bula»,—dip uylap quydı qart. Qoral bulırğa ğına yararlıq ide əle ul.

Xadiməgə iərep, bülməgə tərbiəçe belən əç bala kilep kerde. Balalarnıŋ zurısına un yəşlərder, keçesenə altı yəşlər çaması—ike qız belən ber malay. Əç səykemle fəreştəçek.

«Xadiməse belən tərbiəçese çuqınıp kitsen!—dip uyladı qart.—Əmma balalar aldında...»

Qartnıŋ ayaqları—ike tayaq, qulları—baw, muyını salam kebek ide. Xətta yıraqtan da anıŋ belenep torğan qabırğaların sanap bulırlıq ide. Keşe tügel, ə kerlənep qatqan sarı tire belən tarttırılğan skelet...

Xucabikə tərbiəçedən soradı:

—Aysılu bügen aşadımı?

—Bik az. Kakaosın eçməde,—dip cawapladı tərbiəçe.

—Ə Gəlsılu?

—Ul bətenləy aşamadı.

—Ə Altın niçek?

—Ber keçkenə şokolad kisəge qaptı.

Çibər xucabikə balalarına taba borıldı həm kerlənep qatqan sarı tənle yabıq qartqa törtep kürsətte:

—Kürəsezme bu adəmne? Ul yabıgıp skeletqa əwerelgən. Əgər aşamasağız, sez də nəq şundıy bulaçaqsız.

Əç fəreştəçek, qurqınıp, ənilərenen yuan botlarına kilep sarıldılar. Şiğriət şikelle güzəl xanım qorışıp kipkən qartqa qırıs qına boyırdı:

—Ə xəzer tiz genə kien də, sıptır monnan!

**Mars ŞABAYEV** tərceməse

# РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫНА ХАТ

*2001 елның 21 сентябрендә рус полкларының 1380 елда Куликово кырында монгол-татар гаскәрләрен җиңүен кайбер даирәләрнең бәйрәм итәргә җыенуы уңаеннан Мәскәүдәге Асадуллаев йортында үткәрелгән «Түгәрәк өстәл»дә катнашучылар Россия Федерациясе Президенты В. В. Путинга ачык хат кабул итте. Анда болай диелә:*

«Президент әфәнде!

«Түгәрәк өстәл»дә Бөек Ватан сугышы ветераннары, генераллар һәм рядовойлар, фән докторлары, академиклар һәм Мәскәү шәһәрендәге татар җәмәгатьчелеге вәкилләре катнашты. «Түгәрәк өстәл»не «Ватан» халык-демократик партиясе әзерләде һәм үткәрде.

Без Россия Федерациясе Оборона министрлыгының патриотик тәрбия «битлеге» астында җәмгыятьне таркатуына һәм милләтләр арасында дошманлык таратуына борчылу белдерәбез. Оборона министрлыгы кысасында әзерләнгән документта мондый сүзләрне укыйбыз: Россиянең «Победа» оештыру комитеты тарафыннан 2001 елда Ватаныбызның хәрби тарихына бәйле истәлекле вакыйгалар һәм ветераннар белән эшләү буенча үткәреләчәк чаралар исемлеге:

**1. Россия Федерациясенең «Россиянең хәрби дан (җиңү) көннәре турында» федераль законны үтәү буенча чаралар.**

Әлбәттә, Россия гаскәрләренең данлыклы даталарын билгеләп үтәргә кирәк. Ләкин «бөек кенәз Дмитрий Донскойның 1380 елда монгол-татарларны җиңүе» нинди патриотизм тәрбияләргә сәләтле соң?

Монголлар мәсьәләсенә килсәк, ул вакытта гына түгел, Алтын Урдада аннан элегрәк чорда да алар инде булмаган. Сарайда 1254 елда Батый хан кабул иткән Вильгельм Рубрикның әйтүенә караганда, 1227 елда Чыңгыз ханнан аңа мирас булып 5000 генә монгол кешесе калган. 150 ел эчендә табигый кимүне, төрле походлардагы югалтуларны, татарлар арасында ассимиляцияләнүне, ягъни «йотылу»ны исәпкә алсаң, алардан күпмесе генә калган икән? Менә шуңа күрә дә 1380 елдагы Алтын Урда монголлары турында сүз йөртү үзе үк житди эш була алмый.

Күпмилләтле илдә менә шулай бер милләтне икенчесенә каршы кую кемгә кирәк булды икән? Әллә ул татарларны мәңге гаеплеләр итеп күрсәтү өчен кирәк микән яисә эчке дошманны эзләү һәм табу өченме?

Әгәр дә болай фикер йөртсәләр, әлеге документның авторлары «данлыклы даталар» исемлеген тагын да тулыландыра, аңа 1552 елның октябрендә—Казанны, Ә 1556 елда Әстерханны алуны да кертә алырлар иде. Шул уңайдан Иван III һәм Иван IV гаскәрләренең бәйсез Тверь һәм Новгород шәһәрләрен буйсындыру даталарын да бәйрәм итә алырлар иде.

Әнә шулай итсәк, без кая барып чыгарбыз?

Куликово кырында 1380 елгы сугышны (әгәр ул булган булса, ни әйтсәң дә ул хакта тарихи документлар да, фактик материаллар да юк, сугышның кайсы урында булуы да мәгълүм түгел) берничек тә татарлар белән руслар арасындагы сугыш дип санап булмый. Ул сугышны шулай ук ике ил, ике дәүләт арасындагы сугыш дияргә дә нигез юк, чөнки әле ул вакытта рус дәүләте юк, бары тик Алтын Урда составындагы кенәзлекләр—вилаятьләр генә булган. Әлеге сугыш булган очракта да ул бер дәүләт составындагы ике субъект, ягъни Сарайга бәйле Мәскәү кенәзлеге гаскәре

белән Алтын Урданың бер вилаяте булган Кырым төмәне Мамай белән бәрелештән гайре нәрсә түгел.

Куликово кырындагы сугышны бәйрәм итү Россия армиясендә хәзерге вакытта хезмәт итүче рус милләтеннән булмаган солдат һәм офицерларның күбесе өчен, шулай ук ветераннар өчен мыскыллау буларак кабул ителәчәк. Татар халкының уллары күп гасырлар буе Россия Кораллы Көчләренең аерылмас өлешен тәшкил итеп килде. Аларны шушы рәвешле мәсхәрәләү һич тә акылга сыймый.

Без бөтенләй урынсыз бу бәйрәмне үткәрмәүне таләп итәбез, чөнки ул татар милләтеннән булган хәрбиләрнең дә, хәрби булмаганнарның да рухын сындырачак.

**Рәсим Акчурин**, *генерал-полковник, РТНКА президенты.*

**Арбек Әюпов**, *генерал-полковник, Ватан сугышы ветераны.*

**Алмас Әдһәмов**, *генерал-майор, Ватан сугышы ветераны.*

**Раил Әбраров**, *генерал-майор, Ватан сугышы ветераны.*

**Әмирхан Гәрәев**, *генерал-майор, Ватан сугышы ветераны.*

**Абделхан Әхтәмҗан**, *тарих фәннәре докторы, МГИМО профессоры, Мәскәү регионы татар академия җәмгыяте рәисе.*

**Әгъдәс Борһанов**, *тарих фәннәре докторы, профессор, сәяси фәннәр академиясе академигы, ТР Фәннәр академиясенең почетлы әгъзасы, Ватан сугышы ветераны, подполковник.*

**Шамил Абайдуллин**, *техник фәннәр кандидаты.*

**Шамил Мөхәммәдъяров**, *ислам көллияте профессоры, тарих фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академиясе академигы, Ватан сугышы ветераны.*

**Эдуард Кульпин**, *философия фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясенең көнчыгышны өйрәнү институты профессоры.*

**Абелхәмид Минаҗетдинов**, *татар академик җәмгыятенең гыйльми секретаре.*

**Гаяр Искәндәров**, *мөселман халыкларын үстерү фонды президенты, Бөтентатар Милли Мәҗлесе депутаты һәм башкалар.*

«Түгәрәк өстәл» исеменнән һәм аның кушуы буенча, **Мөхәммәт Миначев**, «Ватан» халык-демократик партиясе рәисе, Бөтентатар милли мәҗлесе депутаты.

*Мәскәү. 18. 03. 2001 ел.*



## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ПРЕЗИДЕНТ АНТЫ

Мәгълүм булганча, шушы елның 25 мартында Республикада Татарстан Президенты сайлаулары булып узды. Бу сайлауларда катнашучыларның 79,52 проценты **М.Шәймиев**не яклап чыкты һәм ул җиңү яулады. 12 апрельдә С. Сәйдәшев исемендәге зур концерт залында дәүләт башлыгының вазифасына керешүе уңаеннан тантана, ягъни инаугурация булды. Тантананың төп мәгънәсе—яңа сайланган Президентның Татарстан халкына биргән анты:

**«Татарстан Республикасы халкына тугрылыклы хезмәт итәргә, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын тәэмин итәргә, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә, Татарстан Республикасы Президентының үземә йөкләнгән югары вазифаларын намус белән үтәргә тантаналы төстә ант итәм».**

Татар һәм рус телләрендә әйтелгән бу анттан соң М. Ш. Шәймиев рәсми рәвештә Президент вазифаларын башкаруга, бу очракта—дәвам итәргә керешүе исәпләнә.

Тантаналарның, бәйрәмнәрнең дәрәҗәсе катнашкан кунаклар белән билгеләнә. Россиядәге күренекле сәясәтчеләрнең һәм регион җитәкчеләренең байтагы Казанда иде ул көнне. Килгән кунаклардан М. Шәймиевне иң әүвәл РФ Президенты аппараты җитәкчесе А. Волошин котлады. Аннары тәбрик сүзләрен Россия хөкүмәте рәисе урынбасары В. Матвиенко, РФ Президентының Идел буе Федераль округындагы вәкаләтле вәкиле С. Кириенко, Казакъстан Республикасы парламенты сенаты рәисе О. Абдыкаримов, Кабарда-Балкар Республикасы Президенты В. Коков, Башкортстан Республикасы Президенты М. Рәхимов, Әзәрбайҗан Республикасы вице-премьеры Э. Эфендиев, Дагстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе М. Магомедов, Адыгей Республикасы Президенты А. Дзаримов, Төньяк Осетия-Алания Республикасы Президенты А. Джасоховлар җиткерде. Тантанада, шулай ук, Татарстан вәкилләреннән—Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Чаллы Политехник институты студенты Ю. Томашевалар чыгыш ясады.

Татарстан Президенты исеменә йөзләгән тәбрикләү телеграммалары алынды. Алар арасында Европа, Азия илләре җитәкче даирәләренең дә котлаулары бар.

Дәүләт Советы сессиясе кысасында уздырылган бу утырышны Татарстан Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин ачты һәм алып барды. Тантанадан соң сәнгать осталарының бәйрәм концерты булды.

### ҺӘЙКӘЛ БУЛЫРГА ОХШЫЙ

1552 елда Казанны саклап шәһит киткәннәргә башкалабызда куелачак һәйкәл проектлары конкурсына 30 мартта йомгак ясалды.

Мәдәният министры И. Тарханов рәислегендәге жюри 20 хезмәт арасыннан беренче урынга рәссам **Нияз Хаҗиәхмәтовның** проектларын лаек дип тапты. Икенче урын рәссам **Хәнәфи Нәфыйков** проектына бирелде.

Һәйкәлне урнаштыру урыны әлегә ачыкланмаган.

### 1000 ЕЛЛЫК УҢАЕННАН

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе залында «Кремль—Казанның йөрәге» дигән күргәзмә ачылды. Ул башкалага нигез салынуга 1000 ел тулуга багышлана. Экспонатлар итеп сирәк очрый торган археологик, тарихи һәм архитектура һәйкәлләре турында язылган китаплар куелган. Болар—атаклы тарихчылар М. Рыбушкин, П. Заринский, М. Худяков, Н. Калининның иҗади эшләре. Нияз Халитовның «Казан ханлыгы архитектурасы» һәм «Казан Кремлендә Кол Шәриф мәчете» дигән китапларында Кремль архитектурасының күп гасырлар буе үсеш юлы үтүе турында язылган. Башка авторларның китапларында Сөембикә манарасы, Благовещение соборы һәм шулай ук Кремльдәге археологик казылмалар турында мәгълүмат табарга мөмкин.

### ЯЗУЧЫЛАР САФЫНА

29 март көнне Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булып үтте. Анда соңгы ике айда башкарылган эшкә хисап тотылды. Аерым алганда, 2 март көнне уздырылган «Әдәби

ел йомгаклары»на нәтиҗә ясалды. Г. Тукайның тууына 115 ел тулуга багышлап үткәреләчәк «Шигырь бәйрәме»нә әзерлек мәсьәләсе тикшерелде, тәрҗемә остаханәсенең эш планы расланды.

Әлеге утырышта берничә әдип Татарстан Язучылар берлеге әгъзалыгына кабул ителде. Алар арасында **Әнвәр Шәрипов** *(Чаллы)*, **Тәлгат Нәҗмиев** *(Саба)*, **Әсхәт Сәлахов** *(Әлмәт)* һәм **Валерий Модестов** *(Казан)* бар. Шулай итеп берлектә әгъза булып торган әдипләребезнең гомуми саны 285кә житте.

### БӘЙГЕДӘ ҖИҢҮЧЕЛӘР

3 апрельдә бөек Тукайның 115 еллыгына багышлап, А. Алиш исемендәге балалар иҗат үзәгендә Казан шәһәрендәге мәктәпләрнең өлкән сыйныф укучылары фәнни-гамәли конференциясе үткәрелде.

Анда мәркәзебезнең район бәйгеләрендә җиңгән 23 укучы чыгыш ясады. Докладларның темалары күптөрле, кызыклы фикерләргә бай иде. Идел буе районы 42 нче мәктәп укучысы Лилия Җәләеваның «Тукай иҗатының тәрбияви әһәмияте» хезмәте беренче урынга лаек булды. Яшь иҗатчылар бәйгесендә Р. Батулла, А. Арсланов, Р. Шаһиева, Ф. Мөслимова кебек әдәбият-сәнгать әһелләре һәм галимнәр чыгыш ясады.

### ӘДИП ИСЕМЕНДӘГЕ

Күренекле язучы **Афзал Шамовның** тууына быел 100 ел тулды. Шул уңайдан әдипнең туган авылы Танайда истәлекле очрашулар булды. Авылның урта мәктәбенә А. Шамов исеме бирелде, шунда ук, язучының музее ачылды. Яшел Үзән шәһәре һәм район хакимияте башлыгы Р. Зиннәтуллин карары белән татар әдәбияты өлкәсендә аеруча зур казанышларга ирешкән каләм ияләрен бүләкләү нияте белән әдип исемендәге премия булдырылды.

Юбилей тантаналарында Татарстан мәдәният министры И. Тарханов, Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, галим Г.Саттаров, язучылар М. Хәбибуллин, Э.Шәрифуллина, Ш. Мостафин һ. б. катнашты.

### Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ЯҢА ТОМЫ

100 еллык юбилее уңае белән Г. Ибраһимов «Әсәрләр»е җыелмасының сигез томы басылып чыккан иде. Әмма аның бай мирасы ул томнарга гына сыеп бетә алмады. Ниһаять, тугызынчы том дөнья күрде. Бу җыелмага әдипнең элекке «Әсәрләр»енә кермәгән автобиографик язмалары, хатлары, автографлары, телеграммалары, гаризалары тупланган. Язмалар төрле газета-журналлардан, Киев, Мәскәү, Казан, Уфа архивларыннан җыелган.

Бу томлык нигезендә Г. Ибраһимов—иҗтимагый мәнфәгатьләр белән янып яшәүче зур дәүләт эшлеклесе, киң белемле галим, талантлы язучы, көчле рухлы, трагик язмышлы шәхес итеп күз алдына килә.

### ШАГЫЙРЬ БӘЙРӘМЕ

Шагыйрь **Рәдиф Гаташның** 60 еллык юбилее уңаеннан Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендә әдәбимузыкаль кичә уздырылды. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты инициативасы белән үткәрелгән бу очрашу-кичәдә Тәлгат Галиуллин, Хатыйп Миңнегулов, Нурмөхәммәт Хисамов, Азат Әхмәдуллин, Резеда Ганиева кебек галим-профессорлар белән бергә яшь студент шагыйрәләр—Луиза Янсуар, Гөлнур, Гөлназ Гариповалар да чыгыш ясады. Соңыннан юбиляр шагыйрь үз шигырьләрен укыды, автографлы китапларын бүләк итте.

### ӘДИБӘНЕ ИСКӘ АЛУ

Күренекле әдибә, тәрҗемәче **Сәрвәр Әдһәмованың** тууына 100 ел тулу уңаеннан 3 апрельдә мәркәзебезнең М. Горький музеенда әдәби-музыкаль кичә булды. Анда Сәрвәр Әдһәмова һәм Кави Нәҗминең балалары, оныклары, туганнары һәм әдибәне якын иткән әдәбият сөючеләр катнашты.

### ЯШЬ ШАГЫЙРЬ КИЧӘСЕ

4 апрель көнне «Казан» милли мәдәният үзәгендә шагыйрь **Рәмис Аймәтнең** «Мәгариф» нәшриятында дөнья күргән «Шомырт салкыннары» исемле китабы чыгу уңаеннан «Тамырларым канат чыгара...» исемле театральләштерелгән шигърימузыкаль кичә үткәрелде. Кичәдә танылган шагыйрьләр, язучылар, артистлар катнашты.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Әдәбият, сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен «Салават күпере» балалар журналы һәм «Таһир-Зөһрә» газетасы баш мөхәррире **Хөснетдинов Зиннур Зыятдин** улына «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** С. Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концерт залы. *Н. Исмәгыйлев фотосурәте.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Радик Фәизов.

# ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ

Бу айда аңа 60 яшь тулган булыр иде. Кызганыч, юбилеена бер ай гына вакыт калгач, 2 апрельдә каты авырудан соң, талантлы каләмдәшебез, танылган язучы Тәүфикъ Әйди (Тәүфикъ Рамазан улы Әйделдинов) вафат булды.

1941 елның 1 маенда Мәскәү өлкәсенең Шатура районында туган Тәүфикъның балачагы, үсмер еллары Татарстанның Апас төбәгендә, Омск өлкәсенең Азов районында уза. Татарстанда—татар мәктәбендә, Себердә чакта казакъ мәктәпләрендә белем алып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә читтән торып укый ул. 1983-85 елларда Мәскәүдә югары әдәби курслар да тәмамлый. Гомумән, Тәүфикъ Әйди әдәбият мәйданына зур тормыш тәҗрибәсе туплап, үз каләменең көченә ышанып һәм инанып килде. 80 еллар башында ул үзенең «Божра» исемле мажаралы детектив повесте, публицистик язмалары, халкыбызның күренекле галимнәре һәм сәнгать әһелләре турындагы мәкаләләре белән танылды. Тәүфикъ Әйди оста тәрҗемәче дә иде. Казакъчадан, башка төрки теллӘрдән ул күп кенә күренекле язучыларның чәчмә әсәрләрен тәрҗемә итте. Шул ук вакытта Тәүфикъ Әйди каләмдәшләре иҗатына гаять ихтирамлы, игътибарлы, таләпчән һәм теләктәшле иде. Нәкъ менә шушы сыйфаты аңа озак еллар дәвамында «Казан утлары» кебек мәртәбәле әдәби журналның проза бүлеген җитәкләргә ярдәм итте дә. Үзгәртеп кору еллары башлануга ук журналда «Язгы аҗаган» (М. Хәсәнов), «Колыма хикәяләре» (И. Салахов), «Афәт» (Г. Тавлин), «Балта кем кулында?» (А. Гыйләҗев) кебек калын-калын, проблемалы һәм катлаулы язмышлы әсәрләр чыга башлаган икән, монда Тәүфикъ Әйдинең, һичшиксез, олы хезмәте—мөхәррирлек эшчәнлеге бар. Шул елларда үзенең дә «Елан угы» исемле күләмле романы, дистәләгән мәкалә-очерклары, юлъязмалары журналыбызда дөнья күрде.

Дистә еллар буе Тәүфикъ Әйди күрше төбәкләрдә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез тормышын өйрәнү белән эзлекле һәм нәтиҗәле шөгыльләнде. Молдавиядә яшәүче кардәшләребез—гагаузларның тормышы, рухи проблемалары турында беренче булып чаң сугучыларның берсе, аларга ана телендә газета чыгарырга ярдәм итүче нәкъ менә Тәүфикъ Әйди иде.

Алманиядә, Төркиядә һәм башка күп кенә илләрдә яшәүче күренекле милләттәшләребез белән якыннан аралашып, Тәүфикъ Әйди алар тормышын язып-өйрәнеп кенә калмады, ә бәлки милләт яшәешенең күп төрле мәсьәләләрен күтәреп чыкты, уйланды-эзләнде. Шул аралашулар-уйлануларның нәтиҗәсе булып, аның соңгы берничә ел эчендә үзе оештырган «Аваз» нәшриятында «Аһ, туган каумем газиз!», «Оҗмах утравы», «Йөртә безне язмышлар», «Кардәшләр кочагында», «Иблискә ришвәт» һ. б. китаплары басылып чыкты.

Тәүфикъ Әйдинең, бай тәҗрибә туплаган язучы буларак, иҗади дәрте көчле, планнары зурдан иде. Вакытсыз үлем һәммәбезне кайгыга салып, көтмәгәндә аны арабыздан тартып алды. Каләмдәшебезнең талантлы иҗаты, күркәм йөз-кыяфәте безнең күңелләрдә калыр, хәтердә озак сакланыр.

**Татарстан Язучылар берлеге идарәсе,**
**«Казан утлары» журналы редакциясе.**

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Татар теленең орфографиясе:** Методик кулланма. Казан: Мәгариф, 2000. Тиражы – 10000 данә. Редакторы: Р. И. Раскулова.

1999 елның 15 сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән һәм Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев кул куйган «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законы дөнья күрде. Ул 2001 елның 1 сентябрендә үз көченә керә. 10 ел дәвамында, 2011 елның 1 сентябренә кадәр, Татарстан Республикасында бер үк вакытта ике алфавит: латин графикасы нигезендәге һәм кириллица гамәлдә була.

Яңа алфавит 34 хәрефтән тора, анда сузык авазларны белдерүче – 9, тартыкларны белдерүче 25 хәреф күрсәтелгән. Тәкъдим ителә торган «Татар теленең орфографиясе» менә шушы алфавитка нигезләнеп төзелгән.

Әлеге китап укучылар, студентлар, укытучылар, матбугат хезмәткәрләре, латин графикасында татар язуын үзлегеннән өйрәнүчеләр һәм, гомумән, татар теле белән кызыксынучылар өчен чыгарыла.

**Tatar telenen orfografiəse:** Metodik qullanma. Qazan: Məğərif, 2000. Tirajı – 10000 danə. Redaktorı: R. İ. Raskulova.

1999 yılnın 15 sentəbrendə Tatarstan Respublikası Dəwlət Sovetı qabul itkən həm Tatarstan Respublikası Prezidentı M. Ş. Şəymiev qul quyğan «Latin grafikası nigezendə tatar alfavitın torğızu turında» Tatarstan Respublikası Zakonı dənya kürde. Ul 2001 yılnın 1 sentəbrendə üz keçenə kerə. 10 yıl dəwamında, 2011 yılnın 1 sentəbrenə qədər, Tatarstan Respublikasında ber ük waqıtta ike alfavit: latin grafikası nigezendəge həm kirillitsa ğəməldə bula.

Yana alfavit 34 xəreftən tora, anda suzıq awazlarnı belderüçe – 9, tartıqlarnı belderüçe 25 xəref kürsətelgən. Təqdim itelə torğan «Tatar telenen orfografiəse» menə şuşı alfavitqa nigezlənep təzelgən.

Əlege kitap uquçılar, studentlar, uqıtuçılar, matbuğat xezmətkərlərə, latin grafikasında tatar yazuın üzlegennən əyrənüçelər həm, ğemumən, tatar tele belən qızıqsınuçılar əçen çığarıla.

Индекс 73210



Радик Фәизов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)